
# Казан утлары

1
ЯНВАРЬ-1971



# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1

ГЫЙНВАРЬ
1971

## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Н. ХОДЗА. Сүз бирдеңме — сүзеңдә нык тор . 3
З. ВОСКРЕСЕНСКАЯ. Караңгы төндә . . . . . 4

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

С. ХӘКИМ. Барын да мин... Республикам турындагы декрет. Без давыллы бер чор кешеләре... «Сибелә чәчәк». Терелде уйда-күңелдә. Урман аша... Яңгыр явып үтте... Яз килә... Әнкәй... Төштә нәрсә күргәнлегең... «Яшәү белән үлем арасында»... Мәҗлесләрдә шагыйрьләр... Союз түгел... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 8
М. ХӘБИБУЛЛИН. Икмәк кадере. Повесть . . . 13
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Вакыт. Сөйли. Ни генә дә җиткесез... Космополит түгел... Идел ага. Тугры дусың улмы... Этюд. Бу сөю... Булчы, зинһар... Хиссият илендә икәү... Соңгарган шаһит. Сигезьюллыклар. Шигырьләр . . . . . . . . 67
Р. ХАРИСОВ. Яфраклар. Шигырьләр циклы . . . 73
Җ. МОСТАФИН. Күк тулпар. Хикәя . . . . . . . 77
М. ӘГЪЛӘМОВ. Уйна, курай! Таулар. Исәнмесез, өлкәннәр!.. Ай туганда. Имән. Казан. Каз өмәсе. Туй. Мин шундый җыр язмак булдым... Җырчы картым. Шигырьләр . . . . . . . . 86
Ә. ГЫЙЗЗӘТОВ. Күз яшьләре. Бала йоклый. Яңгыр малай. Беренче кар. Хатлар өйтсен. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 91
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Эшләмәсәң әгәр... Үкенерлек ялгышларың булса... Югалтырмын кебек... Бәхетнең ниндие насыйптыр... Йөк бавымда. Җиңеп кайту хакына. Кылган чәчле кызкай — бала чак. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 93

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Н. ЮЗИЕВ. Яңа матурлык җырчысы . . . . . . 96
Һади Такташ хатлары . . . . . . . . . . . . . 107

ГОМӘР БӘШИРОВКА 70 ЯШЬ

Г. БӘШИРОВ. «Иске будильник» кайсезләнә . . . 112
Г. АХУНҖАНОВ. И туган тел... . . . . . . . . . 128

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

НӘҖИП ҖИҺАНОВКА 60 ЯШЬ

Ил белән гел бергә . . . . . . . . . . . . . 131
Ю. КОРЕВ. Үзенчәлекле талант . . . . . . . 132
У. САТТАРОВ. Горурланабыз . . . . . . . . . 133

ДУСЛАР ҖЫРЫ

А. ТЯПАЕВ. Ленин янында . . . . . . . . . . 135
И. ПИНЯЕВ. Көн килер . . . . . . . . . . . . 136

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. ХӘМИТОВ. Тынгысыз көннәр. Очерк . . . . 137

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

А. МӨСЛИМОВ. 3309 номерлы мандат иясе . . 147

БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

Н. ИХСАНОВ. Һәрвакыт юлда. Очерк . . . . . 152

Л. УКРАИНКАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Л. УКРАИНКА. Өмет. Кайчагында... Бөтен җирдә... Юлым. «Моңнар» дигән циклдан. Җиңү. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 159

КИТАП КҮЗӘТҮ

Н. ХИСАМОВ. Дәрдемәнд шигырьләре рус телендә . . . . . . . . . . . . . . . . 163

Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . 169

ТӨРЛЕСЕННӘН

Б. ГАЛИЕВ. Төсле тавыш сәнгате . . . . . . . 172

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

С. ӘДҺӘМОВА. Ул шагыйрь йөрәкле иде . . . 180

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Р. МИҢНУЛЛИН. Казан төне. Төнге дөнья... Кояш. Беренче кар. Күз тимәсен... Саллар ага. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Г. Афзал. Ферзь гамбиты. Хикәя . . . . . . . 185
Дусларча шаярулар . . . . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.* Корректоры *Р. Сулейманова.*

Производствога бирелде 2/X-1970 ел. Басарга кул куелды 30/XI-1970 ел. ПФ 09124. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 80846 экз. Заказ С-540. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1971 ел.

**Нисон Ходза,**
рус язучысы

## СҮЗ БИРДЕҢМЕ—СҮЗЕҢДӘ НЫК ТОР

Бервакыт мондый бер хәл була.

Патша хөкүмәте Ленинны кулга алып, пароходлар да, поездлар да йөрми торган ерак, караңгы бер авылга Себергә сөргенгә җибәрә.

Шундагы күрше авылда да сөргенгә җибәрелгән бер революционер яши. Фамилиясе Лепешинский була аның.

Көннәрнең берендә Лепешинский Ленин янына килә.

— Әллә шахмат уйнап алабызмы, Владимир Ильич? — ди ул.

— Мин бик риза,— ди Ленин.— Ярый әле, монда шахмат алып килергә башыгыз җиткән. Мин үз шахматымны Петербургта калдырганмын.

Лепешинский, шахмат булмавын кызганып, кулларын сугып куя да:

— Мин дә шахматымны Петербургта калдырдым шул. Менә бәла! Монда акчага да шахмат табып булмый,— ди.

— Кайгырмагыз. Озакламый миңа туганнарым җибәрергә тиеш. Мин аларга яздым инде. Алдан әзерләнә торыгыз. Яңа елда шахмат уйнаячакбыз. Мин сезгә сүз бирәм,— ди Владимир Ильич.

Лепешинскийның күңеле күтәрелеп китә:

— Сез сүз биргәч була инде ул!

Шуннан соң ул өенә кайтып китә.

Бер ай үтә, ике ай үтә, ә посылка һаман юк та юк! Юлда югала тегә. Ә яңа елга санаулы гына көннәр кала.

Нишләргә? Ленин каян шахмат алсын инде хәзер? Владимир Ильичның моңа кадәр вәгъдәсен үтәми калганы юк әле...

Менә яңа ел да килеп җитә. Ленин Лепешинскийларга китә, өйгә керә, исәнләшә. Лепешинский исә:

— Сез шахмат алып килгәнсездер инде. Бик әйбәт! Хәзер уйныйбыз! — ди.

— Күрегез әле бу хәлне! Посылканың һаман килгәне юк бит! — ди Ленин.

Лепешинский, хәефе китеп, «их» дип сыкрап куя.

Владимир Ильич шунда кинәт чемоданыннан тактасы белән шахмат чыгара. Кулдан ясалган шахмат. Фигуралары нарат кайрысыннан кисеп ясалган. Шундый пөхтә, шундый матур итеп киселгән! Бер карауга та-

ныйсың — менә монысы — король, монысы — королева, ә болары — пешкалар.

Лепешинский үз күзләренә үзе ышанмый.

— Каян килде бу? Менә дигән шахмат ич бу! — ди.

— Ошыймы?

— Ошамаган кая! Миңа да булса иде. Моны ясап бирүче оста кайда яши? — дип сорый Лепешинский.

— Ерактан эзлисе юк. Оста алдыбызда утыра. Аларны мин үзем ясадым,— ди Ленин.

Лепешинский гаҗәпләнүдән ни дияргә дә белми. Ниһаять:

— Кем өйрәтте соң сезне? — дип сорый.

— Бер мәкаль өйрәтте,— ди Ленин көлеп.

— Нинди мәкаль? Ничек итеп?

— Бар инде шундый бер рус мәкале: «Сүз бирүдән тыелып тор, ә бирдеңме — сүзеңдә нык тор!» Ә хәзер шахматны тактага тезик тә эшкә керешик! Көрәшне башлыйбыз! — ди Ленин.

**З. Воскресенская,**

рус язучысы

## КАРАҢГЫ ТӨНДӘ

Бик күптән, 1907 елда ук, Финляндиядә булган хәл бу.

Декабрь ае җитсә дә, чын кыш әле һаман да башланмаган иде. Көньяк-көнбатыштан искән каты җил Ботник култыгының ныгып җитмәгән бозларын вата. Өсләрен кар каплаган меңнәрчә кечкенә атаулар һәм атаучыклар-шхерлар катып калган дулкын сыртларын хәтерләтәләр.

Або шәһәре ягыннан утраулар аша уза торган юлдан чана тартып бер ат килә. Ат башына Виктор Карлсон исемле фин утырган. Ул Лилльмэло утравына бер кеше илтә. Карлсонга бу кешене рус патшасының дошманы, ул патша полициясеннән качып йөри, диделәр.

Утырып баручы бу кеше Владимир Ильич Ленин иде.

Рус жандармнарына Ленинны эзләп табып, кулга алырга дигән әмер бирелгән, шуңа күрә Владимир Ильичка кичекмәстән чит илгә китәргә кирәк иде.

Кояш баеганда атлы чана кыя өстендә ялгыз утырган бер кызыл өй янына килеп чыкты.

— Килеп җиттек,— диде Карлсон, җитди генә итеп.

Үзе чана башыннан төшеп, атын бәйләп куйды да аягы белән төртеп ишекне ачты.

Алар килеп кергән кечкенә генә кухня бүлмәсе чип-чиста, ялт итеп тора иде. Идәненә тар палас җәелгән, стеналарга келәмнәр эленгән, зур мич янындагы шүрлектә ялтыратып агартылган җиз кастрюльләр тезелеп тора. Түшәм турысында ук мичтән стеналарга таба нечкә колга кишТә сузылып, аларга кабартма төсле җәенке арыш ипиләре тезеп куелган.

Карлсон бусагада торган килеш кенә йорт хуҗасы Бергман белән пышылдап нидер сөйләште дә, утыртып килгән кешесе белән саубуллашып, хуҗа хатынга баш изәп чыгып китте.

Владимир Ильич хуҗа кеше янына эскәмиягә килеп утырды, кулын аның җилкәсенә салып:

— Дус кеше, миңа тизрәк Стокгольмга барырга кирәк иде. Шуны ничек эшләргә икән? — диде.

Балыкчы агач ботагы төсле коңгырт сары бармагы белән трубкасына тәмәке тутырып маташа иде. Ике эшне берьюлы эшли алмаганга, ул тәмәкене тутырганда эндәшмәде. Ниһаять, трубкасын кабызгач, балыкчы тирән итеп суырды да, килгән кешенен көчен сынагандай, ана баштанаяк күз йөртеп чыкты һәм:

— Булмый! Юк, юк. Ни җәяүләп, ни көймә белән булмый. Бозның ныгыганын көтәргә кирәк,— диде.

— Сез: «Ни җәяүләп, ни көймә белән булмый»,— дисез. Әгәр җәяүләп тә, көймә белән дә барсаң? Үзең боз өстеннән атлыйсың, ә көймәне алдан этеп алып барасың,— дип аның сүзенә ялгап китте Владимир Ильич.

Балыкчы исә бер үк сүзне кабатлады:

— Булмый. Боз әле кешене чыдатырлык түгел. Көймә куерган бозлы суны ерып бара алмаячак,— диде.

Иртән Владимир Ильич хуҗа белән бергә торды. Юынгач, тәрәзә янына килеп утырды да дәфтәрен ачты.

Кечкенә тәрәзәдән кыялы сөзәк утраулар тезмәсе күренә, анда сирәк-мирәк агачлар үскән. Шәп-шәрә бу шома кыяларда ул агачларны нинди көч тотып тора икән? Аларның орлыклары бераз туфрагы булган кечкенә генә уентыкларга барып эләгә дә шунда тамыр җибәрә, тамырлары ярыкларны капшап табалар, гранит эченә кереп үсәләр, ныгыйлар. Һәм нинди генә каты давыл да бу агачларны сындыра-аудара алмый.

Бергман кухнядан йокы бүлмәсенең ачык ишегенә карап-карап ала, ә үзе Карлсонның сүзләрен исенә төшерә: «Патшаның иң көчле дошманы шушы микәнни инде?» — дип уйлый. Болай карап торышка гап-гади бер кеше үзе. Әнә сул якка янтая төшеп, зур башын кырынрак салып, өстәл янында утыра, җил улавына да, боз шытырдавына да игътибар итмичә, ашыгып-ашыгып нидер яза. Аннары ниндидер таблицалар актара, култык астына тыгып кулларын җылыта һәм янадан язарга тотына.

Семья иртәнге ашны ашарга утырды. Хуҗа хатын өстәлгә җиз савыт белән кофе китереп куйды, үрелеп киштәдән түгәрәк ипи алды.

— Табынга рәхим итегез,— диде хуҗа.

Владимир Ильич кухняга чыкты, ягымлы гына елмаеп куйды. Ул семьяның тормыш хәлләре, мәшәкать-борчулары белән кызыксынучы игътибарлы, киң күңелле бер кеше булып әверелде. Бергманның таштаулы бу җирдә ничек итеп иген игүен, нәрсәләр чәчүен сораштыра башлады, балык эләгәме? диде.

* * *

Владимир Ильич Бергманнарда берничә көн яшәде. Ләкин монда озак юанырга ярамый — аны ашыгыч зур эшләр көтә иде. Ничек кенә булса да, тизрәк Стокгольмга, аннары Швейцариягә барырга, шуннан торып Россия эшчеләре белән, партия белән бәйләнешле җайларга да киләчәктәге революцион бәрелешләргә әзерләнергә кирәк иде.

Тагын зарыктыргыч ике көн үтте.

Иртән гадәттәге: «Боз ничек?» дигән сорауга каршы, Бергман:

— Боз әле катмаган. Җилнең үзгәргәне юк. Яңа ел җитмичә, моннан китеп булмас. Киләсе атнада рождество бәйрәмнәре башлана, ә бәйрәмдә кем юлга чыксын инде? — дип җавап бирде.

— Юк. Миңа рождество бәйрәмнәренә кадәр Стокгольмда булырга кирәк. Без иртәгә юлга чыгарга тиеш. Иртәгә! — диде Владимир Ильич, катгый итеп.

Балыкчы эндәшмәде, ул үз эше белән мәшгуль иде.

Ләкин төшке аштан соң Бергман яссы төпле кечкенә генә көймәсен лапастан алып чыгып, аны караштыра башлады: ишкәк чөйләреннән алгарак ярты метр чамасы озынлыктагы нык кына ике таяк бастырып кадаклап куйды, шуларга аркылы колга беркетте.

Кич җиткәч, Бергман: «Юлга чыгарга була, бар нәрсә әзер»,— диде. Таң атканчы ук кузгалырга кирәк, чөнки кеше яши торган җирләрне карангыда үтеп, бозваткыч салган су юлына вакытында барып җитәргә кирәк иде. Бергман кунакның хром итекләрен ошатмыйча карап алды да кичке аштан соң каядыр китеп барды. Балыкчылар кия торган алыптай зур итекләр күтәреп кайтты.

...Таң беленергә ике сәгатьтән азрак вакыт калды. Хуҗа хатын өстәлгә кыздырылган балык, ипи, кофе китереп куйды.

Владимир Ильич аз гына кофе эчте дә хуҗа хатын янына килеп:

— Бик зур рәхмәт! Барысы өчен дә зур рәхмәт! — дип, каты итеп аның кулын кысты.

Хатынның йөзендә төньякның кышкы кояшы төсле тыйнак кына елмаю нуры яктырып китте...

* * *

Диңгез ягыннан пароходларның шомлы итеп кычкырган тавышлары ишетелә. Томан эченнән ай килеп чыкты һәм Ботник култыгының каракучкыл су өстен яктыртты.

Юлчылар, икесе ике яктан колгага тотынып, көймәне этеп баралар. Агач көймәнең төбе кытыршы боз өстеннән шатыр-шотыр килеп шуып бара, аяклар ябышып каткан кар кантарларына абына. Владимир Ильич уң кулы белән колгага ябышкан, сул кулына балыкчы фонаре тоткан.

Бергман көймәне үзе генә белгән әллә нинди бормалы-сырмалы юллардан алып бара. Илле-алтмыш адым үткән саен туктый, көймәдән очлы багор ала да, аны бөген көче белән селтәп, «я-гха» дигән тавыш чыгарып, көймәнең алдына китереп кадый, шул рәвешчә бозның ныклыгын сыный иде.

Төньяк җиле көчәйгәннән-көчәя бара, юлчыларның битләрен камчылый, фонарь яктысында энә төсле чәнечкеле кар бөртекләренең кыйгачлап бәреп яуганы күренеп кала иде. Ике километр җир китмәгәннәрдер, юлчылар тәмам арыдылар, битләреннән аккан тир күзләрен томалады.

Тонык кына булып соры, сүрән таң беленде. Якты көн беркайчан да тумас төсле иде.

Утраулар арасы ерагайганнан-ерагаеп, боз тигез җирләр киңәйгәннән-киңәя барды. Бер утрау янында бик зур җылуга очрадылар. Юлчылар беренчә тапкыр көймәгә утырдылар, әмма ишкәкләрне бер-ике селтәүгә тагын боз читенә килеп төртелделәр. Аннары көймәне өстерәп утрау аша алып чыктылар.

— Хәзер әнә теге утрауга җитәргә кирәк,— диде Бергман, бияләе белән алга таба төртеп күрсәтеп.

Алда кар каплап киткән боз өемнәре күренде.

Владимир Ильичның кулы колгадан әледән-әле ычкынып китә, ул Бергманның хәрәкәтләренә җайлашырга тырыша, үзе еракка карап-карап ала.

— Күп үттекме әле? — дип сорады ул.

— Юлның иң озыны артта калды, иң кыены алда әле,— дип сәер генә җавап бирде Бергман.

Ул, үзенен «я-гха»сын әйтә-әйтә, ешрак туктый башлады. Бу сүз әле бер шомлы аваз булып, әле сорау булып, әле ярсулы сүгенү булып яңгырый иде.

Владимир Ильич зур гына бер җәлпәк боз өстендә хәл җыеп, бераз аяк-кулларын язып алырга булды. Ләкин ике адым атларга да өлгермәде, боз бер якка янтаеп китте дә, сул аягы таеп суга чумды.

Владимир Ильич колгага тагын да катырак ябышты һәм уң аягын кар астыннан чыгып торган үтә күренмәле боз кисәгенең кырыена күтәреп салды. Ләкин менеп басарга өлгермәде, боз кисәге чумып китте, итек эченә су тулды, колга шыгырдый башлады...

Боз кисәкләре шомлы шытырдашып төрлесе төрле якка шуышты, аяк астында боз калмады: куркыныч зур иде!

Владимир Ильич юлдашына күз ташлады: Бергманның түсе качкан, күзләре шар булган, үзе бил тигентен суга баткан, ах-ух килә иде.

— Көймәгә менегез! Тизрәк көймәгә менегез!

Кем әйтте соң әле моны? Бәлки Бергманга шулай ишетелгән генәдер?

Икесе дә, кулларын колга буйлап тиз-тиз шуыштырып, көймәгә якынлаштылар. Колга сыгылып-сыгылып китә, шыгырдый иде. Юлчылар ишкәк чөенә килеп ябыштылар да икесе ике яктан берьюлы сикереп көймәгә мендеиләр.

Владимир Ильич салкыннан дер-дер калтырана башлады. Тешләренең шыкылдавын баса алмыйча, ул кинәт шаркылдап көлеп:

— Алай да суы салкын икән...— дип куйды.

Бергман калтыранган куллары белән көймәдәге зур гына киез төргәкне чишеп җибәрде. Аннан Владимир Ильичның итеген тартып чыгарды. Итек әле генә мич башыннан алган төсле җылы, ә эченә мәрхәмәтле хуҗа хатын йон оекбаш салган иде. Балыкчы бу юлдашының шаян елмаеп рәхмәт хисе белән карап торуын күрде дә күзләрен читкә алды.

Владимир Ильич кулына оекбаш тоткан хәлдә Бергманнан: «Синең үзенә су үтмәдеме соң?» — дип сорады. Юк, үтмәгән, ул чыланмаган икән. Аның өстендә брезент комбинезон, итек кунычы комбинезонга тоташтырып тегелгән иде. Владимир Ильич оекбашын, итеген алыштырып киде дә җылынып өчен кулбашларын селкетә башлады.

Бергман ул арада киез эченнән фляга чыгарды, җайлап кына капкачын борып ачты. Флягадан кайнар кофе пары бәреп чыкты.

Владимир Ильич, кайнар кофены кружкага салып эчә-эчә:

— Шәп! — дип куйды.

Бераз капкалап алгач, юлны дәвам иттерделәр. Боз читенә килеп җиткәч, көймәне тагын өстерәп алып киттеләр.

Хәзер инде Нагу утравына, шул утрау янында үтә торган су юлына нибары ярты километр чамасы гына калды. Анда Абодан Стокгольмга баручы швед пароходын көтәргә кирәк иде.

Шул калган бернечә йөз метр ара иң кыены булып тоелды.

Менә, тар гына тасма булып ялтырап, бозваткыч салып киткән су юлы күренде. Ә бераздан ике юлчы, көймәгә утырып, пароход көтәләр иде инде.

Бергман көймәнең ян-ягына кадакланган таякларны алып ташлады. Бу таяклар хәзер кирәк түгел иде. Көймәсен ул таныш балыкчысында калдырачак та үзе пароход белән кайтачак.

Томан тарала башлады. Боз өсте яшькелт-күк төскә керде. Көн туды.

Владимир Ильич белән Бергман пароход килер якка, төньяк-көнчыгышка карап көймәдә утыра бирделәр.

Менә калку утрау өстендә соры төтен күренде. Пароход иде бу! Тар гына су юлында ул гаять зур булып күренә иде. Юлчылар шарфларын болгарга тотындылар... Пароходтан аларны күреп алдылар, көймә төшерделәр.

Владимир Ильич ике куллап Бергманның кулын кысты, аннары аны үзенә таба тартып җилкәсеннән кочаклап алды.

— Хәерле юл! Хәерле юл! — дип, әкрен генә кабатлады Бергман.

Рәис Сабиров тәрҗемәләре.

## Сибгат Хәким

●

Барын да мин язып бетердем дип,
Иөрдем уйлап, бик нык алдандым,
Язын төртеп яңа үлән чыкты,
Хәбәр итсен нигә алдан бер.
Туган якта язын яшел үлән —
Яңа буын... бүтән, башкача...
Әйтми калган сүз күк чыкты үлән
Әнкәй каберендәге таш аша.
Кыякларын җәеп чыкты, яши,
Мин дә яшим, мин дә бүген бар...
Кабатларга мөмкин түгел икән,
Кабатланмый икән буыннар...

1970.

●

Республикам турындагы декрет.
Ленин төзегән, Ленин булышкан.
Җире, чиге... Каян кая хәтле...
Саналганнар өяз, волостьлар.
Шунда минем туган авыл да бар
(Ленинга хас күңел киңлеге):
Марилардан алып, декретына
Кертеп куйган Күлле-Кимене.
Бер ягында — чиркәү, бер ягында —
Кирәмәтләр... Шунда кысылып,
Бураннарда ул күмелеп калса,
Ни югалтыр иде кешелек?
Марига да ихтирамым бик зур,
Туры килгән саен мактармын,
Тик Ленинча татар булып калыйм,
Бар язмышым белән татармын.

1970.

●

Без давыллы бер чор кешеләре,
Ничек инде аны тапмаска;
Йөз елдан соң да мин Такташ белән
Очрашырмын... Сәлам Такташка!
Җирдән күпме зур-зур вакыйгалар

Узган булыр... Күпме су аккан...
Очрашырмын, «Фазыл чишмәсе»нә
«Урман кызы» килер сукмактан.
Очрашырмын, ышанам бит шуңа,
Яшермичә сөйлим хистәген,
Тавышы алда серле урманнарда
Үзем иҗат иткән чишмәнең..

1970.

## «Сибелә чәчәк»

Бу йөрәккә төрле дәва кирәк,
Авыруларын аның тап, назла.
Сагынырмын, безнең ансамбльнең
Концертләры бара Кавказда.
Бу йөрәккә төрле дәва кирәк,
Туңам көндез, туңам төннәрдә,
Савыктыргыч иң шифалы дәва
Беләм, беләм, туган телләрдә...
Кычкырасым килә җиргә минем:
Һич туймадым синдә яшәп, дип...
Ә ансамбль үч иткәндәй җырлый,
Җырлый һаман «Сибелә чәчәк» дип.
«Сибелә чәчәк»... Болай, бу кадәрле
Моңсу түгел идең син элек.
Көз. Кавказда концерт. Ишетәм залдан:
«Сибелдек шул, дуслар, сибелдек»...

1970.

●

Терелде уйда-күңелдә
Яңадан үткән.
Чыра... Электр... Төрлечә
Яналар утлар.
Җыр миндә йоклый, басмаган
Җыр әле сафка,
Мин әле малай, бер малай
Чыпталы чакта.
Ничек ди язын ак кардан
Чыкмасын эзләр...
Суктылар чыпта төн буе
Чыптачы кызлар.
Сөйләшсәм — сүнәр, сүз белән
Борчырга куркып,
Утырдым шыпырт, утырдым
Мин чыра тотып.
Кабыздым берсен, ә берсен
Ярдым очыннан.
Ул янды, янды яшь кызлар,
Яндым эчемнән.
Бүлепгте шунда үзара
Кызлар эчсерне...
Чыралар әкренләп, хәлсез,
Кызганыч сүнде.

Сүнделәр әкрен, хәтердә
Бүгенгем төсле:
Әйләнеп алар күмергә,
Бөгелеп төште...
Соңыннан инде шигырьдә
Телдем чыралар.
Пештем, ярадым, куймадым,
Беләм, чын алар.

1970.

●

Урман аша узган чакта кердем,
Мари өе гади, кин, якты.
— Без чи мари, чукынмаган мари...
Шулай диде миңа Илбакты.
Яши монда төрле сагышларның
Жыеп көзге, кышкы, язгысын...
Самовары әзер... Бастырды ул
Самовардан алда... язмышын.
Кем баш тартыр юлда Илбактының
Тәбикмәге, кайнар чәеннән.
Чәйгә очкын атып зур мич яна,
Яна төпләр, яна чөерләр...
Йоклар идем, карый карт наратлар
Тәрәзәдән, күзләр-чокырлар,
Карлы, бозлы салкын куллар белән
Торгызырлар кебек йокымнан...
Төн. Кышкы төн озын. Тәрәзәне
Әллә кеше, әллә җил какты...
Шаулый нарат, шаулый үткән тарих...
Юл. Ялгыз йорт. Урман. Илбакты.

1970.

●

Яңгыр явып үтте әкрен генә,
Юаш кына, юаш кына.
Туган якка кайтам, мин ашкынам,
Юл ашкына, юл ашкына.
Яңгыр явып үтте матур гына,
Бер хәвефсез, бер хәвефсез.
Ал, зәңгәр, чуар яулыклар
Бөркәнеп сез, бөркәнеп сез.
Чәчәкләр, кемне көтәсез?
Мин ерактан, мин ерактан...
Кырлар тын... Әнкәй дәшә күк
Тик зираттан... тик зираттан.

1970.

●

Яз килә. Көтәм. Иөримен
Юка бозга баскалап.
Язгы сулар да юл тапмый
Кар астыннан баштарак.

Кузгала, юл ера, ташый,
Болганып ярсый сулар...
Мин торам, минем күңелдә
Тугайлар ясый сулар...
Мин торам, еллар күңелгә
Сагышын салып үзган.
Ташулар аккан урында
Сары ком, сары эзләр...

1970.

●

Әнкәй, синнән күпме ишеттем мин:
Нигез уйный, дисең.
Ул гына аз, житмәсә син әле:
Нигез уйлый, дисең.
Ничек инде, әнкәй, безнең нигез
Таш та туфрак бит ул...
Таш та туфрак... ләкин бөтен уйны
Ята туплап бит ул.
Ята тыңлап йөрәк тибешеңне,
Күп дәверләр кичә...
Күңелең белән бергә уйный нигез,
Күтәрелә, төшә.
Борчыласың... сизеп тора нигез
Бу кайгыңны анда...
Таш та туфрак... Бишек жыры сеңгән,
Тукай моңы анда.
Бу нигезне шулар тотса тотар,
Башка берни тотмас...
Уйный нигез, ята дүрт почмакта
Иңеп жиргә дүрт таш...

1970.

●

Төштә нәрсә күргәнлеген беләм
Мусаның мин үләр алдыннан:
Туган авылы... Әнисе мич яккан,
Кабартмалар пешерә ак оннан.
Пешерә дә капат белән майлый,
Чүмәлә күк өя табакка.
Юрганыннан чыккан аягыннан
Тартып китә: пеште кабартма...
Юл мәктәпкә, кырга, болыннарга,
Алда якты юллар ачылган.
Чыжлый таба, Муса уянган да
Карап ята юрган астыннан.
Өйдә эрем себеркесе исе,
Үзе жыйды, үзе бәйләде,
Оренбурның яшел далалары,
Оренбурның ямьле жәйләре.
Әниеңә эшкә ярый идең,
Әниеңә ике күз идең,
Елый төштә: азат, ирекле бул,
Хужасы бул, себер үз өең...

1970.

●

*Нәби Дәүлигә*

«Яшәү белән үлем арасында»
Я боега, я бик шатлана,
Әйтерсең лә мәгърур көлә-көлә
Мефистофель чыга сәхнәгә.
«Яшәү белән үлем арасында»
Үзе кыйный, яки кыйнала,
Кайчак аска тәгәри ул, кайчак
Менеп баса кебек кыяга.
«Яшәү белән үлем арасында»
Әйтми кем дә: тукта, ялга бар...
Бу тормышның законнары каты:
Тартыш, сугыш, көрәш, яулап ал.

1970.

●

Мәҗлесләрдә шагыйрьләр аз түгел,
Таныш алар, иптәш, дус алар.
Киңәш итим дисәң — Кутуйлар юк,
Таянырга — Фатих, Мусалар.

1970.

●

Союз түгел, йөз язучы түгел,
Калмаганнар ничек куркып, әй,
Хакыйкатьне әйтеп бирер өчен
Бер Толстой җиткән, бер Тукай.

1970.

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ИКМӘК КАДЕРЕ

ПОВЕСТЬ

Төнозын яңгыр яуды. Көчле яңгыр, әйтерсең, болыты белән төште: асфальт җәймәгән авыл юлларын машина үтмәслек итеп лыҗырдатты, чокыр-чакырлардан шаулап гөрләвекләр акты, борынгы Болгар авылына урнашкан райүзәкнең таш-ком күрмәгән урамнарында күбекләнеп зур-зур күләвекләр хасил булды. Районда хәрәкәт тукталды: юлларда, саз-пычракка батып, машиналар калды. Әрсезрәк, тәҗрибәлерәк шоферлар, райүзәккә килеп җитәргә тырышып, машина көпчәкләренә чылбыр урадылар, батып чумганнары, чыгу һәм барып җитү нияте белән, машиналарын юл уртасында калдырып, җәяүләп, якын-тирә авылларга трактор эзләргә киттеләр.

Шушы көндә, иртәнге сәгать унда, район культура сараенда конференция ачылды. Район партия оешмасының чираттан тыш чакырылган бу конференциясенә кайберләре трактор белән, беришесе җәяүләп килгән коммунистлар телендә вакытсыз яуган яңгыр да, юлда батып калган машиналар да булмады, тәнәфескә чыгу белән алар арасында райкомның беренче секретаре Бакир Галиев турында гәп-әңгәмә башланды.

— Бакир Галиевне бездән алалар икән, соңгы отчеты диләр...

— Кая алалар?

— Нефть районнарының берсенә, ди.

— Әйбәт кешене, әлбәттә, күтәрәләр инде...

— Сиңа әйбәт, миңа начар иде,— диде кулуарга аркасы белән терәлеп торган, йөзен җирән сакал-мыек баскан берәвесе,— үткән айда миңа тиктомалга каты шелтә чәпеде.

— Һәй, Ибрай туган, кеше фәрештә түгел. Ул эш өчен сине төрмәгә үк утыртасылар иде түгелме? Ярый, Бакир Әхтәмович алып калды үзеңне...

— Бик хөкем итәселәре иде дә, гаебемне таба алмадылар...

— Син аны, Ибрай туган, миңа сөйләмә, әнә туксан яшьлек хаста әбиеңә кайтып сөйлә, яме!.. Барыбер гадел җитәкче иде...

— Кемгә гадел, кемгә усал, кеше шырпы түгел, яндырып карап булмый...

Фойедагы имеш-мимеш дөрес булып чыкты. Райком составын сайлаганда Бакир Галиев кандидатурасы күрсәтелмәде. Әйтергә кирәк, Бакир үзе моңа тиз генә риза булмады. Өч көн элек районга килеп төшкән өлкә комитеты вәкиле Галиевка икенче районга күчү күздә тотылуын әйткән иде. Башта: «Кыен булыр бит анда миңа, нефть эшен начар беләм»,— дип барган Бакир, сөйләшә торгач, күнде. Кайда да кешеләр белән эшлисе, ә алар барысы да бер ил күге астында яшиләр, өйрәнермен, дип уйлады.

Өенә кайткач, китүе турындагы яңалыкны хатыны белән әнисенә кичтән әйтми торырга булды. Аларның каршы килүләреннән куркып түгел, иртән әйтермен, дип уй йөртте. Ләкин алар инде ишеткән булып чыктылар, өйгә кайтып, табынга утыру белән, әнисе:

— Әллә, улым, үтмәс товар булдың инде, һәммә җирдән алалар, беркая да эшләтмиләр үзеңне,— дип Бакирның күңелен борчып алды.

Хатыны Әминә дәшмәде. Ул ирен сүзсез дә аңлый иде. Партия җибәрә,— димәк, шулай кирәк. Ә әнисенең партиясе бүтәнчә: эчендәге — тышында, күңелендәге — телендә. Ана сүзләренә гамьсез калырга теләсә дә, Бакир күңел түрендә нидер төерләнүен тойды. Чынын, тик чынын гына әйткәндә, аның биредән китәсе килми иде. Бу районда ул зур эшләр башкарды. Бакир килгәнчегә кадәр макталып телгә алынмаган район былтыр ике норма икмәк сатты, сөт саву буенча республикада беренче урынга менде. Аз хезмәт салмады моңа Бакир. Ә менә хәзер тот та шуннан кит, каядыр барып, өр-яңадан эш башла.

Кич йокыга яткач, ул, ике кулын баш астына куеп, әнә шул турыда уйлап ятты. Әллә, чынлап та, ризалык биреп ялгыштымы? Бәлки өлкә вәкиленә бирегә калырга теләвен әйтергә кирәк булгандыр?.. Әмма Бакир алай итмәде. Нигә? Бит өлкә вәкиле аңа бу зарури, шулай кирәк, иптәш Галиев, дип әйтмәде. Ләкин Бакир күрде, өлкә комитеты вәкиленең тел төбеннән үк аңлады: ул Бакир Галиевның партия җибәргән районга барасына ышана иде.

Карышу артык иде, кирәкми иде, әлбәттә. Районнан районга беренче тапкыр гына күчүе түгел бит аның. Тик менә барган мәлне ялгызлыгы гына кыенрак булыр. Нишлисең, Әминәсе белән әнисен китергәнче гостиницада торып торыр.

...Бакир хатынының чәченә кагылды, бармаклары белән битеннән сыйпап алды. Әминә дә йокламый иде, ул иренең кулын тотып алды да кайнар учына кысты.

— Тиз генә кайтып ала алмассың инде?..

— Бәлкем, баргач та квартира булыр, карарбыз,— диде Бакир, Әминәсен тынычландырырга теләп.— Миңа да кыен булачак бит анда...— «Сездән башка»,— дип әйтергә уйлаган иде, әйтмәде. Яңы белән ятты да хатынының күкрәгенә кулын салды. Аның кулы тигез итеп таза йөрәк кагуын тойды. Менә шул хәрәкәт күңел төпкелегендәге бер хатирәне актарып чыгарды. Нигә? Ул вакыттан бирле күп еллар үтте, бик күп сулар акты бит инде. Нигә бүген, менә хәзер исенә төште әле бу Мөршидә? Ә?! Менә ни өчен икән: Мөршидә бит ул барасы районда эшли. Менә бит ул, күңел хатирәсе дигәнең, бер кереп урнаштымы, һич кенә арынып булмый. Әй, соң бер селтәнүдә алып ташларлык хатирә идеме ул Бакир өчен?!.

...Беренче тапкыр ул аны «Совет» гостиницасы коридорында очраткан иде. Бакир аңа текәлеп карап үтте. Карамаслык түгел иде шул: чибәр-сылу иде Мөршидә. Җитмәсә, Бакирга, озын керфекләрен еш-еш кагып, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп та үтте. Шул гына. Аһ, шул гына булып калса икән! Кич буе коридорда йөреп чыкты Бакир. Кызга да нидер булган иде, ул да ары-бире үткәләде. Кыз каршыга килгән саен,

йөзенә нииндидер кайнар дулкын кагылып китүен тойды Бакир. Мәгәр сүз катарга кыюлыгы житмәде.

Ләкин язмыш аларны үзе кавыштырды. Икенче көнне беленде: кыз да партия мәктәбенә укырга килгән икән. Алар күптәнге танышлар кебек күрештеләр.

— Мөршидә! — диде кыз аңа, йомшак кечкенә кулын Бакирның уч төбенә салып.

— Ә мине Бакир дип йөртәләр, аз гына бакыр түгел... Сез каян, кайсы районнан? — дип сорады Галиев, кинаяле шаяру тонында.

Өлкәнең икесе ике башыннан булуларына көлешеп алдылар.

Шул булды танышулары. Әмма шуннан соң гел диярлек, һәр көн диярлек бергә булдылар. Зур Казанның күрмәгән төшен, йөрмәгән урамын, утырмаган эскәмиясен калдырмадылар. Көннәр төнгә, төннәр көнгә кушылды. Уку белән бергә, күңелләрендә гыйшык уты кабынды, йөрәкләрдә мәхәббәт җепләре төенләнде. Бергә булган көннәр алты йөзгә якын җыелды. Бер-береңне белү өчен, таңу-танышу, ярату өчен аз гомер түгел иде бу. Шуңа күрә булса кирәк, бер-берсенә ышану арткannан-арта барды һәм, ниһаять, ул күкрәк-күңелгә генә сыеша алмыйча, иркенләп кавышуны таләп итә башлады. Беркөнне шулай Мөршидә Бакир яшәгән бүлмәгә килеп керде. Бер тын сөйләшеп, көлешеп утыргач, Мөршидә кайтырга җыена башлады. Шунда Бакир аны кочагына алды да җете күк күзләренә карап:

— Кайтма, кал монда, Мөршидә?..— диде.

Мөршидә шаккатмады һәм шаккатырлык нәрсә дә күрмәде. Өйләнешү турында сүз куешмасалар да, барысы да аңлашыла иде бит. Алар бергә булырга тиешләр.

Шулай дип торганда Бакирның бүлмәдәше кайтты. Сабакташы аны сүзсез дә аңлады. Әмма ярым шаярулы тондарак:

— Кунарга урын табармын, тик кара аны! — дип бармак янап чыгып китте. Бакирны: «Өйләнә күрмә, кул-аягың бәйләргә өлгерерсең әле»,— дип үгетләгән бу кеше Мөршидәнең бирелә калуын белмәсә әйбәтрәк булыр иде, әлбәттә. Ә ул әнә белде. Бакир шуңа пошынып алды.

Аннары ул:

— Мөршидә, Мөршидәм, йом әле күзләреңне... Йом инде!! — диде һәм аны үбә-сөя башлады.

Мөршидә башын аның күкрәгенә куеп, йөрәк тибешен тыңлап ятты. Бакир аның чәченнән, битеннән сыйпады, шатлык-бәхеттән яшь белән тулган күзләреннән үпте...

— Бакир, бир әле кулыңны, бир инде? Менә, ишетәсеңме, ничек тибә? Ничек ярсып тибә, Бакир!

...Бакир тәрәзәгә күз ташлады. Төн. Караңгы. Күк гөмбәзендә йолдызлар җемелди. Тынлык. Бу — зур авылдан узмаган район үзәге өчен гадәти тынлык иде. Ә ул вакытта, ул төндә, анда, Казанда? Мөршидә ни диде аңа, Бакир аңа ни әйтте?!.

Шагыйрьләр яраткан язгы матур төн иде ул. Тулган айның яктысы киң өлгеле тәрәзә аша Бакир белән Мөршидә яткан караватка төшә. Ай гүя күзләрен зур ачып, шатлык һәм тылсымлы гыйшык әфьюне эчкән Мөршидәнең йөзен күрергә, гүя кызга нәрсәдер әйтергә, аны нидәндер саклап калырга тели иде. Ләкин ай түгел, Бакир әйтергә тиеш иде ул сүзләрне Мөршидәгә.

Ә ул аңа әле әйтмәде.

Бу төнме?! Бакирның күңел төпкелегендә мәңге җуелмас эз калдырды бу төн. Мәңге онытылмас хатирә булып, йөрәк түрендә текмәкләнеп калды.

Истәлеккә дип, бүләк итеп кешегә әйбер бирәләр, янсә кәгазь кисәгенә шигъри сүзләр язып калдыралар. Тегесе дә, монысы да һәркем өчен

яшьлек хатирәсе буларак кадерле. Ләкин андый истәлек җуелучан була. Чөнки ул әйбер генә, аның җаны, аның хуш исле чәчләре, кофе төсендәге зур күзләре, кайтарылып торган озын керфекләре, бәхет тулы күз яшьләре, исерткеч ләззәт бирә алган мәхәббәт татысы юк. Чөнки ул әйбер генә, ул туза, ул югала, ул яна.

Истәлек өчен дип Мөршидә Бакирга канәфер чәчкәсе бирде.

— Париж коммунарлары сайлаган чәчкә,— диде ул аңа, ниндидер җавап көтеп күзләренә текәлде. Бакир җавап таба алмады, дәшмәде. Шул чак Мөршидәнең керфекләре калтырап китте, ул нидер әйтергә теләде, Бакирның нидер әйтүен көтте...

Чәчкә?!

Мәңгелекме ул? Юк. Бакирга ул иң кадерле чәчкәсен — беренче мәхәббәтен бирде!

Чәчкә?!

Чәчкә шиңә, кибә, корый ул.

Ә мәхәббәт — мәңгелек. Чәчкә кебек өзеп ташлап кына булмый аны. Чөнки ул барыбер үз чәчкәләрен калдыра.

Аны Чүпрәлегә эшкә җибәрделәр. Ә Мөршидә көнчыгыштагы районнарның берсенә китте.

Ә соңгы төннәре, аерылышырга ике көн калгач үткәргән төннәре?!.

Ул вакытта Бакир берни аңламады. Мөршидә кисәк икеләнә калды. Партия аларны икесен ике районга эшкә җибәрде. Димәк, алар икесе дә ил өчен хаҗәт кешеләр. Ләкин бит алар өйләнешә дә алалар иде. Әйтмәделәр. Ул да, Бакир да. Ә ни өчен Мөршидә түгел?!. Бит кем дә булса әйтергә тиеш иде!..

Мөршидә дә Бакирдагы үзгәрүне күрде, нидер сизде. Ни өчен үзгәрсен ул, бер дә үзгәрмәгән кебек иде бит! Нәрсә күрде соң ул Бакирда? Әллә Бакирның ул чактагы бүлмәдәше Локман берәр сүз әйттеме кызга?..

Бакир Локманның Мөршидәгә ни әйткәнен исенә төшерергә тырышты. Чыгарыш кичәсенә бер көн калгач бугай, бүлмәгә Мөршидә килеп керде. Ул шат иде, язгы кояшка уянган күбәләк кебек очынып тора, шаян сүзләр сөйли. Шунда аңа Локман:

— Мөршидә, чык миңа кияүгә, Бакир — бакыр ул, курка, икеләнә, ә син минем кебек тәвәккәл, корыч кеше кирәк,— диде.

Уен-көлке арасында әйтелгән шул сүздән соң Мөршидә эчтән генә уйлана башлады. Әллә ул чынлап та Бакирны сайлап ялгыштымы? Әллә инде сүзнең иң дөресен әнә шул Локман әйтте? Иртәгә чыгарыш кичәсе. Ә Бакирның: «Әйдә, Мөршидә, языльшабыз»,— дигәне юк әле. Нигә әйтми ул? Әллә чынлап та яратмавымы?..

Ә чыгарыш кичәсенең икенче көнендә менә шундый бер вакыйга булып алды.

Алар иртән үк Иделгә су коенырга төштеләр. Шунда Мөршидә көймә алырга һәм Идел уртасындагы утрауга барып килергә дигән фикер әйтте. Бакирга җитә калды. Ул берәүгә биш сум акча бирде дә, ике сәгатькә генә дип, моторлы көймәсен алды. Рульгә үзе утырды. Мөршидә белән Локман алга үттеләр. Бакир моторны кабызды, көймәне әкрен генә кузгатып, утрауга таба юнәлтте. Менә ул моторны бар жегәрлегенә эшләтеп газ бирде. Көймә, дельфин балыгы сыман башын чөя төшеп, алга очты.

Мөршидә шат иде. Ул бер иһаһайлап көлә, бер җил тузгыткан чәчләрен рәтли-рәтли, үз итеп, руль тоткан Бакирга карап елмая. Локман аның янына утырган һәм, иелә-үрелә, Мөршидәнең колагына нидер сөйли. Мәзәк булса кирәк, Мөршидә Бакирга күз сирпеп ала һәм егетенең көнләшәм, дуэльга чакырам дип бармак янавын күреп, аны үртәп Локманның җилкәсенә башын куя, аңа елышкандай итә, ә үзе бертук-

таусыз шаркылдап көлә. Бакир мотор тавышыннан аларның сүзләрен ишетмәсә дә, сер бирмәскә тырышып, үзе дә көлә башлады.

Мөршидә чия төсендәге коену костюмы кигән, бик тә килешә үзенә. Бакир, эчке бер ләззәт тоеп, Мөршидәнең тулы янбашларына, нечкәреп килгән биленә, сылу сынына сокланып карый. Карый да шушы сылуның үзенеке булуына янә бер куанып куя.

Менә Локман, борылып, Бакирга күзен йомарга әмер бирде, ә үзе, уенын-чынын бергә кушып, көлә-шаяра Мөршидәнең яңагыннан үбеп алды. Бакир аңа йодрык күрсәтте. Һәм ни эшләгәненә никтер үзе дә исәп бирмичә, көймәне бик кинәт итеп сулга борды. Алда утырган Мөршидә белән Локман суга мәтәлделәр. Икенче мизгелдә мотор сүнде һәм көймә, аягүрә басарга теләгәндәй борын чөеп, бераз суны ерып барды да туктап калды.

Зур тизлек белән барган көймәне шулай боруы белән ялгышлык эшләвен сизеп алган Бакир, аны туры эзгә салырга теләп, рульне уңга алды, әмма соң иде инде: көймә тагын үрә баскандай итте һәм бер мизгелгә генә тынып торган сыман булды да суга бата башлады. Бакир тиз генә рульне ычкындырды. Ләкин көймәдән төшеп өлгерә алмады, көймә белән су астына китте. Шунда ул бар көченә ишә-ишә көймәдән читкә тайпылды һәм инде сулышы бетеп, авызын ачыйм дигәндә генә Идел өстенә калыкты, ашыга-кабалана ярга таба йөзеп китте. Озак йөзде кебек. Ниһаять, аның аяк очлары төпкә тиде. Ул еш-еш сулыш ала-ала сайрак төшкә чыкты да, борылып, көймәгә карады. Һәм кинәт йөрәге жуу итеп китте. Бакир ярдан шактый еракта йөзүче Локман белән Мөршидәне күреп алды. Кылт итеп Мөршидәнең йөзә белмәве аның исенә төште. Ул кадала-каплана суга ташланды һәм еш-еш селтәнеп Мөршидә белән Локманга каршы йөзеп китте. Ул шул тикле ашыкты, хәтта судан башын да сирәк чыгарды. Шулай тизрәк йөзә иде ул.

«Ничек онытты соң әле ул аларны?.. Тизрәк, тизрәк!!! Мөршидәне, Мөршидәне коткарырга!..»

Бакир, бер мизгелгә туктап, Идел өстенә карады.

«Әнә, әнә, алар... Йөзәләр әле! Хәзер, хәзер, Мөршидә җаным, хәзер!»

Ләкин Бакир ярдәмгә килеп җитә алмый калды. Каяндыр килеп чыккан көймәче Локман белән Мөршидәне үзенен көймәсенә алды. Моны күргәч, Бакир чалкан әйләнде һәм, хәл ала-ала, ярга таба борылды. Аягы су төбенә тиюгә ул үзенен тәмам хәлсезләнеп калуын, ярсып-калтырап йөрәге кагуын, башы әйләнә башлавын тойды.

Ләкин сер бирергә теләмәде. Көймәче абзый Локман белән Мөршидәне ярга төшерә башлар-башламас ук килеп, Мөршидәгә төшәргә ярдәм итмәкче булды — кулларын сузды. Моны күреп Мөршидә аңа үтергеч бер караш ташлаган иде, Бакир үрелгән кулларын тартып алуын сизми дә калды. Мөршидә көймәдән үзе төште һәм, Бакир ягына күз дә салмыйча, китеп барды. Локман да Бакирга көйдереп карады, аннары:

— Их, җүләр баш! — диде дә Мөршидә артыннан китте.

Бакир калтырап куйды, әйтерсең, аркасына боз койдылар, хәтта аяк астындагы җир кузгалып куйгандай булды...

Бу көнне Мөршидә Бакирга бер кәлимә сүз дәшмәде. Локман исә башта көлеп йөрсә дә, Бакирның бик кайгыруын күреп, Мөршидә белән аны килештерергә теләде, шул темага мәзәкләр сөйләп маташты. Ләкин Мөршидәнең күңеле ачылмады. Ул Бакирга бер сүз катмыйча, кичтән үк үз бүлмәсенә кереп бикләнде.

Икенче көнне кызның кәефе күтәренкерәк иде. Хәтта кичкә таба көлеп, шаярып та йөрде. Бакирның эченә җылы йөгерде. Ә кич белән

Бакир аңа тәкъдим ясады. Мөршидәгә өйләнергә теләве, аны яратуы, ансыз тора алмавы турында әйтте.

Мөршидә кисәк боегып китте, бик озак сүзсез утырды. Аннары, олы фикер иясе кешеседәй җитдиләнеп, киңәш итәндәй: «Бакир, без икебез ике районга эшкә китәбез. Әүвәл барып эшлик әле бераз. Аннары уйлашырбыз. Мин үзем сиңа хат язармын»,— дигән булды.

Бакир аңа ышанды да, ышанмады да. Эшкә килгәч, һәркөн Мөршидәдән хат көтте, үзе язды, хәтта телефоннан да шалтыратып карады. Ниһаять, Мөршидәдән хат килде. Ул инде иргә чыгуы һәм үзе белән торган кешене үлеп яратуы турында язган иде. Бакир берни кыла алмады. Ул шуңа гына гаҗәпләнде: Мөршидә ничек икенче берәүгә кияүгә чыкты икән? Әллә көймә вакыйгасы аны шулай үзгәрттеме? Әйтик, ул анда, югалып калып, Мөршидәне үзе коткара алмады, ди. Әйтик, ул көймәне кинәт борып зур ялгышлык эшләде, ди. Шуның өчен, тик шуның өчен генә яраткан кешеңнән ваз кичү ярый торган хәлме соң? — дип уйланып, әллә кайчан үткән мәхәббәте өчен хафаланып ятты Бакир.

Тик Бакир бер нәрсәне белмәде: соңыннан Мөршидә үзенең тәкәббер горурлыгын, яшьлек һавалыгын җиңә алмыйча, Бакирны гафу итмәвенә үкенде. Ләкин аның ире Сафа кече җанлы, күркәм кеше булып чыкты. Бергә тора-яши башлагач, ул аңа ничектер бик тиз ияләшеп китте.

Тәҗрибә — менә кайда мәңгелек тормыш мәктәбе. Ә ул тәҗрибә Мөршидәдә юк иде әле, ул катлаулы, каршылыклар белән тулы тормыш эченә кереп кенә бара иде.

Инде Бакирга килгәндә, ул да Мөршидә хәлендә түгел идеме? Нигә ул аңа шул хәлдән соң бер сүз дә әйтә алмады? Әгәр дә теге вакытта Мөршидә югалтылган икән, димәк, ул сине яратып җиткермәгән. Шулаймы?! Нигә соң мин генә әлегә тикле аның өчен өзгәләнәм?..

Бакир Мөршидә алдындагы гаебен әнә шундый дәлилләр белән капларга теләде. Ләкин бу хәл аның күңеленә гомер җуелмас хатирә булып сеңгән иде.

Дөрес, еллар үтү белән тормыш мәшәкате, җаваплы эш аның Мөршидәгә булган хис-тойгыларын акрын гына сүрелдерә, күмә барды. Бәлкем, шулай мәңге күмелеп тә калыр иде ул хис. Тик аңа тагын бер тапкыр үткәннәрне күңел түреннән кайнатып чыгарырлык хәбәр ишетергә туры килде. Казанга бер киңәшмәгә килгән Локман дусты бер чакны, хәл-әхвәлләр сорашылгач, кинәт нидер исенә төшкәндәй:

— Әй, онытa язганмын бит, Мөршидәнең кызы үсә дип ишеттем мин... Онытма, тәбриклэп хат яз үзенә,— диде.

Бакирның йөрәге, җәтмәгә эләккән балык кебек, бер чәбәләнеп, бер талпынып алса да, ул инде берни кыла, берни эшли алмады. Ул Әминә белән тора иде инде.

...Бакир, пошынуга бирелеп, икенче ягына әйләнеп ятты. Һәм шушы пошыну һәм ташып торган эчке хатирәне онытырга теләп, кулларыбелән Әминәсенең йөзенә үрелде. Әминә, күрәсең, һаман йокламый иде, иренең кулын янә кайнар учына кысты.

Иртән ул Әминәсенә әйтте:

— Әллә, Әминә, минем белән үк барасыңмы?

Хатыны өмет тулы күз карашы белән тыенкы-оялчан гына елмаеп:

— Юк инде, Бакир, әүвәл үзең барып урнаш, эшләп киткәч кайтып алырсың әле,— диде.

Һәм ул хаклы иде: Бакир килеште. Кадерле иде Әминәсе аның өчен. Ләкин ул бала тапмады. Балалар йортыннан берәр нәнине алып үстерә алалар иде. Әлегә кадәр нигәдер бу турыда уйлап та карамадылар. Ә менә бүген, Мөршидә эшләгән районга барасы иткәч, балалары бул-

мавын нигәдер аеруча кискен тойды ул. Шуңа, шул хәлгә күңеле кимсенде.

Юлга чыгар алдыннан әнисе пешергән төче коймакны ашарга утырдылар. Нигәдер сөйләшмәделәр. Һәм нигә сөйләшергә? Барысы да аңлаешлы: берәүсенең улын, икенчесенең ирен яңа җиргә, ниндидер районга эшкә күчерәләр. Гадәти хәл. Бакир укып чыккач яшәү дәверендә ике районда эшләде инде. Бу — өченчесе. Бәлкем соңгысы булыр. Район зур, житмәсә нефть идарәләре дә бар. Димәк, тырышып эшләгәндә, төпләнеп калырга да ният тотарга була. Инде бит бишенче дистәне куып бара. Бер кеше ике гомер яшәми, ярты гасыр гомер иткәч, ниһаять, үзеңнең нигә сәләтле икәнеңне аңларга тиешсеңдер.

Әйе, аны яңа районга күчерәләр. Әнисе моңа риза түгел. Гел сүз дәшмәс булды. Күренеп тора: үпкәләгән. Өйрәнгән йорт-каралтыларны, зур-зур тәрәзәле җылы һәм якты бүлмәле өйне ташлап китәсе килми. Ул бередә барысыннан да канәгать иде. Шул турыда ул улына әйтмәкче була. Тәмле коймактан соң, куе чәй ясаганда:

— Әллә нигә, улым, ул җиренә күңелем тартмый,— диде.

— Юкка борчылма; инәй, анда ванна-туалетлы, газ-сулы менә дигән квартирада торачаксың,— дип, әнисенең күңелен күтәрмәкче булды Бакир. Ләкин гражданнар сугышы нужасын, бөек Ватан сугышы газапларын үз җилкәсендә татыган, күп еллар укытучы булып эшләгән Мәсновия әбигә улының җавабы ошамады.

— Һәй балам! Миңа барыбер лә... Синең бередә сарыф иткән көчең жәл миңа. Барысын да яңабаштан башларга кирәк ләбаса. Төннәрен кайтмый чаба идең... Әлегә кадәр бу тирә күрмәгән уңыш үстерә башлагач кына бит!..

— Анда, инәй, нефть тә бар...

— Дегет күргәнең юкмы?..

— Ярый,— диде Бакир,— яши-тора өйрәнерсез. Сез дә, мин дә... Синең бу кайгың, инәй, кайгы түгел. Икмәген дә, нефтен дә биргән районда эшләү начармыни?!.

Озатырга икесе дә чыктылар.

— Инәй, син бар, кер, салкын тияр,— диде Бакир. Әнисенең коргаксыган гәүдәсен кочып, калак сөяге беленеп торган аркасыннан сөйде.

Әминә оялыбрак, чират көтеп, бер читтәрәк басып торды. Хәер, ул һәрвакыт шулай: Бакирга олы кеше итеп, нигәдер тартыныч карый.

Бакир хатынының боеккан йөзенә күзе төшү белән сәер бер васвасәгә калып: «Әллә үз итеп бетерми, әллә чынлап та ояла»,— дип уйлады.

Ул кызлар матурлыгын югалтмаган Әминәсенең сылу сынына, калкып торган күкрәгенә, яшьле күзләренә карады да сабыры төкәнеп:

— Кил инде! — диде.

Бакир хатынын кочагына алды да, күзләрен йомып, аңа ничектер сәер итеп тә, шул ук вакытта чиксез дустанә-якын күреп тә яңа бер тапкыр:

— Әйдә, минем белән, Әминә! — диде.

Әминә, җавап урынына, кайнар, йомшак иреннәре белән аңа елышты. Аннары, беркавым ир кочагында тынып торгач кына:

— Урнашып киткәч кайтып алырсың әле, Бакир,— дигән бер үк сүзне кабатлады.

Бакир яңадан бу турыда сүз кузгатмады. Хатынын янә бер кочты да зур-зур атлап, үзен көтеп торган машинага барып утырды. Урам чатына житкәнче арткы тәрәзәдән карап барды. Капка төбендә, башын ия төшеп, кыюсыз-тыенкы гына кул изәп Әминәсе басып калды.

— Мөршидә апа кичке сәгать бишләргә кайтып житәргә кушты,— диде аны алырга килгән шофер, зур авылга урнашкан район үзәгеннән чыгып, олы юлга төшү белән.

— Ә ул кешегез кем булып эшли сезнең? — дип сорады Бакир бел-мәмешкә салышып.

— Икенче секретарь.

— Алай икән,— диде Галиев һәм офык читенә кереп югалган оч-сыз юл тасмасына карады. Алда аны, шушы очсыз юл кебек, бетмәс-төкәнмәс эш көтә иде.

* * *

Бакир Галиевны секретарьлыкка сайлаганда районның промышлен-ностенда һәм авыл хуҗалыгында эшләүче коммунистлары Бакир ту-рында күбрәкне белер өчен бик төпченеп һәм җентекләп сораштылар. Һәркемне төпле ышандыра алырлык конкрет җаваплар бирелде. Өлкә вәкиле дә, Бакир үзе дә ике-өч кат торып сөйләделәр.

Икенче көнне районда яңа секретарь эшли башлады.

...Район үзәге шактый зур. Поселокта егерме меңгә якын кеше яши икән. Иртән эшкә атлаганда Бакир урам-өйләргә карап барды. Посе-локны ул ошатты. Яшеллек мул иде, юлның ике ягына да ике рәт тирәк, уртага алмагачлар утыртылган, машина юлы читендәге сәрби агачлары әйбәтләп, тигезләп киселгән. Ике якта да икешәр, өчәр, бишәр катлы өйләр. Чисталык, пөхтәлек. Нефтьчеләр клубы каршындагы клумбалар-да төрле-төрле чәчәкләр үсә. Алар таҗларын җәеп, иртәнге кояш нур-ларында коенып утыралар. Чәчәкләр янында, ике яклап, производство алдынгыларының фотовитринасы урнаштырылган. Үзәк урамда хәрә-кәт бер дә башкаланың Бауман урамындагыдан ким түгел. Кешеләр дә нәкъ Казандагыча ашыгалар: кайсы эшкә бара, кайсы баласын ясле-гә, бакчага илтә. Ике катлы райком бинасы да үзәк урамга урнашкан. Бина чак кына эчкәрәк кертеп салынган, машиналар туктау өчен җәел-гән асфальт мәйдан күзгә кебек ялтырап тора: иртән иртүк су сибәргә дә өлгергәннәр.

Бакир белгән-күргәннәр белән нәзакәтле генә күрешә-исәнләшә рай-ком бинасына килеп керде. Иплән кенә икенче катка күтәрелде. Пла-щын салып чөйгә элде дә кабинетка үтте.

Якты, зур иде кабинет. Өсләре күзгә кебек ялтырап торган өстәл-ләрдә иртән кояш нурлары биешә, ачык тәрәзә төбендә ике песнәк ни-дер чупли иде. Бакир килеп керү белән очып киттеләр һәм тәрәзә кар-шындагы бөдрә каенга кундылар. Бакир, тәрәзә янына килеп карагач, ясап куелган кош ашаткыч күрде. Шунда ук күңел күгендә кошлар ашатып торучы элекке секретарь Садыйков пәйда булды. Садыйков язгы бозлавыкта авариягә эләгеп үлгән иде. Өйдә дә түгел, каядыр Казан юлында...

Бакир өстәл янына килде һәм иң әүвәл сводкаларны, район газета-сын карап чыкты. Районда икмәк тапшыру әйбәт кенә барса да, сөт саву начар иде. Димәк, эшне колхозлар белән танышудан башларга кирәк. Секретарь теленә килү белән ул Мөршидәне чакырырга кушты. Кушты һәм шунда ук үкенеп тә алды. Аның нигәдер эш башлавының беренче сәгатеннән үк Мөршидәне күрәсе килмәде.

— Тәбриклим, Бакир Әхтәмович! — дип ничектер сәеррәк елмаеп Бакирның кулын кыскан иде ул конференциядән һәм бюродан соң. Ба-кирның бирегә килүен, күрәсең, ул бик үк теләмәгән. Бакирга аның бе-лән уртак тел табып эшләргә кирәк булачак.

Тимер үкчәләрнең такылдавын ишетүгә, Бакир йөрәге ешрак кага башлаганын тойды. «Очлы үкчәле туфли кия икән»,— дип уйлап алды.

Кабинетка өстенә зәңгәр йон күлмәк кигән, билен шундый ук төстә-ге пута белән буган, шактый юанаеп тазарып киткән Мөршидә килеп керде.

— Хәерле иртә, Бакир Әхтәмович! Нигә дәшкән идегез? — дип со-рады ул өстәл янына килеп басу белән. Бакир борынына Мөршидә гәүдәсеннән тәмле ислемай дулкыны килеп бәрелде.

Әйе, тота белә Мөршидә үзен, киенә дә белә, һәм затлы кием килешә дә аңа.
— Сезгә бер үтенеч бар, Мөршидә Хәбировна...
— Зинһар өчен шәхси үтенеч була күрмәсен! — диде Мөршидә, аның күзләренә карамаска тырышып.
Бакирның йөзенә сизелер-сизелмәс алсулык йөгерде. Моны күреп алган Мөршидә күз читләре белән генә елмаеп алды.
— Утырыгыз, рәхим итеп...
Мөршидә читкәрәк китеп утырды да аягын аяк өстенә куйды. Бакирның күз карашы аның ялтырап торган тән төсендәге капрон оекларына төште. Мөршидә моны күрүдән бигрәк, тоеп алды һәм тагын сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды.
— Иң әүвәл минем колхозларга чыгасым килә. Кайсы колхоздан башларга киңәш итәсез? — диде Бакир карашын өстәлгә төбәп. Аннары: «Нәрсә бу, нигә аңардан оялам», — дип уйлап алды ул, янә йөзенә кан йөгерүен тоеп.
— Мин сезгә районны биш бармагы кебек белгән инструкторны тәкъдим итә алам. Үзе белән дә танышырсыз. Тәҗрибәле, яхшы белгеч, колхозларны да әйбәт белә...
— Ярый, керсен әле ул миңа...
Район авыл хуҗалыгы бүлегенең өлкән инструкторы Исмәгыйлов бөдрә чәчле, җете кара күзле, киң кара кашлы, түгәрәк йөзле бер кеше иде. Ул Бакир белән ипле генә күреште дә машинага утыру белән шоферга:
— «Алга»дан башлыйк, Фоат, — диде.
...Колхозларда йөреп кайткач, Бакир тагын бүлмәсенә керде дә кулларын салкын өстәлгә җәеп салды, тәненә бераз суык йөгерүен тоеп, уйланып утырды. Житешле яшиләр колхозчылар биредә. Хәер, теге районда да нәкъ шулай иде. Әмма биредә газ, су, электр һәр авылда, һәр бригадада бар. Күп колхозлар аша асфальт юллар үтә. Бүген карап йөргән колхозлар барысы да ашханәле иде. «Бүләк» колхозының ашханәсендә токмач ашы бик тәмле иде. Әнисе дә шулай токмач ашы пешерергә ярата бит... Әминәсе, әнисе исенә төште. «Алар нишләп яталар икән? Хатларны ешрак язасы булыр үзләренә», — дип күңеленә теркәп куйды.
Колхозларда механизаторлар белән хәл начаррак икән, дип уйлады ул. Бу, күрәсең, районда промышленность предприятиеләре күп булудандыр. Тәҗрибәле механизаторлар нефть эшенә керәләр. Авылда я пенсиягә чыгардай өлкәннәр, я былтыр гына унны тәмамлаган яшьләр эшли. Яшьләр — әйбәт. Тик алар да авылда ике-өч ел эшләп тәҗрибә туплыйлар да нефть эшенә китәләр икән. Механизаторлар житешле булганда җибәрү ярый. Ләкин биредәге колхозларга тәҗрибәле механизаторлар җитми. Авыл халкының күбесе нефть чыгару эшендә. Киләсе елга «Сельхозтехника» каршында механизаторлар укытуны күздә тотарга булыр. Ә иртәгә колхозларның бөтәннәрен күреп, әйләнеп кайтырга да промышленность предприятиеләренә чыгып йөрергә кирәк.
Ләкин икенче көнне ул колхозларга чыга алмады, аны өлкәгә чакырдылар. Ике көн анда булып кайтуга, Мөршидә өйдә юк иде инде.
— Мөршидә курортка, ял итәргә китте, — диде аңа иртән эшкә килү белән кечкенә буйлы, юка, чандыр гәүдәле өченче секретарь. Гәүдәкыяфәте бер дә тимер-корычка охшамаган Тимерхан сөйләшкәндә тиз сөйли, теле артыннан туктаусыз кулы йөри иде.
— Беләм. Ул миңа шалтыратты, — диде Бакир.
— Ул сезгә хат калдырды, Бакир Әхтәмович.
Хат түгел, кош теле кадәр язу кисәге генә иде бу. Мөршидә хатны кыска язган. Ләкин Бакир аның укучы балаларныкыдай чак кына кыек-

лап, хәреф койрыкларын җиренә житкереп язган ике юллык хатына озак итеп карап торды. Шушы таныш, якын хәрефләр күз алдында бергә кушылдылар, агым суга эләккән йомычка кисәкләре кебек бөтерелә башладылар. Берничә секундка Бакирның күнел күгенә Казандагы Мөршидә килде.

— Ярый, тынычлап ял итсен...— диде ул, янында басып торган Тимерханга.

Аннары алар Исмәгыйлов белән тагын колхозларга чыгып киттеләр. Теге көнне гел сөйләшеп барган Әхәт бүген исә авызына су капкандай дәшми, каядыр карап уйга чумган иде. Фоат та нигәдер сөйләшми, юлга төбәлгән дә дөньясын оныткан.

Бакир тәрәзә пыяласын төшереп, терсәген ишеккә куйды да йөзендә машина җилен тоеп, кыр-басуларга, урманнарга карап бара башлады. Кая күз ташлама, шунда нефть вышкалары, скважиналар һәм басуларны аркылы-торкылы уратып алган электр чыбыклары, элемтә баганалары күренә. Әйе, комбайнчыларга, тракторчыларга җайлы түгелдер бирелә.

Алда бер урамы белән тауга орынып торган авыл күренде. Машина текә генә борылды да, асфальт юлдан чыгып, вак таш җәелгән тар юлга төште.

— Сәхаб Кадыйров колхозы,— диде моңа кадәр тыныч утырган Әхәт.

— Ягъни? — дип, аңа табан борылды Бакир.

— Каты куллы, әмма акыллы, тырыш председатель эшли бирелә. Былтыр гектардан егерме биш центнер арыш, утыз центнер бодай җыеп алды.

— Каты куллы,— дип кабатлады Бакир.— Әллә халык канәгать түгелме үзеннән?

Исмәгыйлов Бакирга биш бармагын җәеп күрсәтте.

— Кулдагы бармаклар да тигез түгел. Шуның кебек, колхозчыларның да төрлесе бар. Бер ишесе канәгать, икенчеләре — Сәхабны иртәгә үк эшеннән алыр иде дә, күпчелек Сәхаб яклы.

— Хикмәт күпчелектә, әлбәттә.

— Хикмәт, минемчә, гаделлектә...

Шул чакны кинәт:

— Сабыр ит әле, Фоат, Ходайбирдинның «изге эшен» күреп китик,— дип, Әхәт шоферның җилкәсенә кагылып алды.

— Шушындамыни?

Машинадан төшкәч кенә Бакир нефть белән пычратылган басуны күрде.

Утыз-кырык гектар уҗым ермачланып беткән, әйтерсең, мәхшәр булган, яисә меңләп баш терлек таптап үткән — яшел басу кара көеп калган иде.

Кыр уртасында әле дә күләвек-күләвек булып нефть ялтырап ята. Уртага хәтта трактор белән дә керә алмаганнар. «Беларусь» бульдозеры көпчәк канатларына кадәр кереп чумган. Аны чыгарырга керүче дә, кузгатырга тырышучы да юк. Колхозчылар көрәкләр белән килгәннәр: нефтьне кай төштә яндыралар, кай төштә ерып агызмакчы булалар. Бер-ике җирдә янган нефть төтене аждаһадай койрыгын болгый-болгый һавага күтәрелә, ут янында тимер каскалы янгын сүндерүчеләр күренә иде.

Бакирның кәефе кырылды. Ул колхозчылар янына бармакчы булган иде, көйгән уҗымга килеп керү белән бер аягы нефтьле сазга чумды, ә Әхәтнең аягында кирза итек булганга, ул бата-чума колхозчылар канау ерган төштән китте.

Райком «Волга»сыннан төшеп, берәүнең үзләренә таба килүен күргәч, колхозчылар канау казудан туктадылар, кайсы тәмәке көйрәтеп

җибәрде, кайберләре күрәкләренә таянып хәл җыярга әзерләнде. Әхәт аларның һәрберсе белән күрешеп чыкты да кул болгый-болгый сөйләгән колхозчыны тыңлап торды, аңа нидер әйтте һәм кире борылды.

— Начар,— диде ул килеп җитүгә. Дегет-мәтегә баткан итеген юл буендагы үләнгә сөртә башлады.— Сәхаб өйдә юк, Әлмәткә, нефть берләшмәсенә киткән...

— Әйдә, барыбер барып килик. Фермаларын күреп китәрбез. Колхозы сөт савуда беренче урында тора, күрәсе килә, ни белән алдыра икән...

— Әйбәт ашата, менә ни белән,— диде моңа кадәр сүзгә кысылмаган Фоат.— Былтыр барлык колхозлар ашлыкларын кырып-себереп дәүләткә саттылар, янәсе акчалы булалар, ә Сәхаб абый мул итеп фураж калдырды һәм менә ике колхозның сөтен сава. Сыерның сөте теләндә, Бакир абый.

— Бу да тәҗрибә, бу да акыл,— диде Бакир.

Райком «Волга»сы сикәлтәле-бормалы юлдан инеш буендагы ферма абзарларына таба юл тотты. Бакир Сәхабның шушы сикәлтәле юлдан һәр көнне фермага төшүен күз алдына китерергә тырышты.

— Сәхаб абый карар күзгә тыйнак кына күренсә дә, усал сүзләр ычкындыргалый... Бер каның кайнатсалар — бетте, шәфкать көтмә аңардан,— дип сөйли барды Исмәгыйлов Бакирга.— Нефть түгү мәсьәләсендә Ходайбирдинның котын алган әнә. Партиядән кудыртам мин синең кебек корткычны, дип куркыткан...

Бакир, Әхәтнең сүзләренә колак салып, Ходайбирдин турында, аны партиядән кудыртам дип тавышланган Сәхаб турында уйлады. Нишләтер ул аны? Чынлап та, партиядән кудыруга кадәрен нигезли алса? Әшне бюрога җиткерсә? Анда бит бәхәсне бары тик хак фикер һәм күпчелек тавыш хәл итәчәк...

Бераздан алар бер рәткә тезелеп киткән ферма абзарлары янына килеп җиттеләр. Абзарларның барысы да типовой проект белән салынган — моңысы Бакирга ошады. Алар тирәли тирәкләр утыртылган. Бу да үзенә бер хозурлык иде.

— Шунда тукта,— диде Бакир шоферга, абзар янындагы трактор тирәсендә кайнашкан ике-өч кешене күреп.

Бакир машинадан төште дә, туфлие пычрануга карамыйча — аның берсе барыбер дегеткә баткан иде — трактор янындагы кешеләр янына таба китте. Арырак урнашкан утарда ак халатлы савымчылар күренә иде.

— Сәламәтлекме, егетләр?!

— Шөкер генә, дус кеше,— диде барысы өчен дә озын кара мыеклы агай.

— Әйдә, күрешеп танышыйк,— диде агай, ике куллап күрешкәч.

Бакир тракторның икенче ягына чыкты, егетләрдән нидер сорашып торды.

— «Беренчеме» әллә? — дип сорады Габдулла абзый Әхәттән.

— Үзе,— дип Әхәт йомры, йонлы кулын мыеклыга сузды.— Исәнсау эшләп ятумы, Габдулла абзый?

— Болай ару гына иде дә, саву аппараты көйсезләнде бит әле, Әхәт туган. Клапаннар бетте, клапаннар эштән чыкты. Әнә, гел кулга калдык.

— Нинди клапаннар? — дип сорады егетләр янынннан борылып килгән Бакир.

— Әй лә, шул тиклем җаңга тиде ул нәмәстә, телгә дә аласы килми хәзер үзен. Саву аппаратының клапаны. Эзләмәгән җир калмады инде.

— Ферма мөдире булыр бу ага, Бакир Әхтәмович.

— Бик һәйбәт.— Секретарь үзе фамилиясен әйтте дә нык сенерле, кып-кызыл йөзле Габдулланың битенә карап торды: «Пенсиягә китәргә

вакыт бу абзыйга. Эшне ничегрәк башкара икән? Араларында институт тәмамлаган яшь-җилкенчәк күренми. Олы бит инде абзый»,— дип уйлады.

— Теңкәңә иң тигән хаҗәтең турында гына сөйлә, Габдулла абзый,— диде аңа Бакир, теге ерактан тотынып аңлата башлагач.

— Бик әйбәт, мин үзем дә, теге ни, кыска сөйләүне яратам... Ичмасам, күземә килеп чалынгач, бушанып калыйм әле дигән идем. Ярар, алайса иң хаҗәт әйберем турында: шул инде, Бакир туган, клапаннар вакытсыз картайта безне... Һичбер каян таба алмыйбыз. Сәхаб үзе дә эзләп карады.

— Кайларда булдыгыз?

— Иөрмәгән җир калмады. Казанында да булдык. Агрегатын чыгаралар, запчастен ясамыйлар. Кызлар әнә өченче көн инде сыерларны көйгә китерә алмый интегә.

— Ничек?

— Бер-ике ай агрегат белән сөтләрен төшерми җәфаландылар, хәзер әнә кулдан саудырмыйлар. Үз хәзинәсе бит, имчәгеn кисеп алып булмый. Теләсә — бирә, теләмәсә — юк. Психика, инстинкт, ди зоотехник. Әллә хәзерге сыерларга да кеше акылы керә башлады инде, элек аның исеме хайван иде.— Габдулла агай, мин бер нәмәрсә дә аңламыйм дип, кулларын җәеп җибәрде.— Ышанмасагыз, әнә егетләрдән сорагыз, аптырагач, кызлар юри кыланалармы әллә дип, халат киеп, үзем савып карадым. Тибенми дә, койрыгын да селекми — сөтне дә бирми. Ни галәмәт булгандыр малкайларга, ике-өч көндә дөнья кадәр сөт кимеде...

Бакирның Чүпрәледә дә колхоз председательләренең шул клапаннарны эзләп йөргәннәре исенә төште. Үзе үк өлкәгә барып, тәэминатчыларның теңкәләренә тиеп беткән иде. Шуннан соң вагон белән җибәрделәр бугай, клапаннарны ике-өч ел телгә алучы да булмады. Бәлкем, әле дә ятадыр анда клапаннар?

Габдулла белән сөйләшкән арада әнә шул турыда уйлады Бакир.

Кайткан чакта ул Әхәттән:

— Күптән эшлиме бу Габдулла абзый ферма мөдире булып? — дип сорады.

— Мин белгәннән бирле,— диде Әхәт.

Янадан алар сөйләшмәделәр. Көн аяз, кояшлы иде, шулай да күршетирә өлкәләрдә янгырлар яугалавы турында радиодан ишеттерә башладылар. Бакир, икмәк җыйган комбайннарны күреп, әнә шул турыда уйлады. Бик аз кала бит икедән артык нормага. Район гомер булмаган икмәк сатачак быел дәүләткә, гомер булмаган!.. Менә сөт белән начар. Арттан өченче урында таптанабыз... Сәбәбе нидән? Әгәр дә, бар сәбәпләрен белеп, бу якны да юлга салса, Бакир бирегә кучеп килүенә үкенмәячәк... Ягъни, аңа сөт буенча сикереш кирәк иде.

Икенче көнне иртән иртүк ул Чүпрәлегә шалтыратты. Анда клапаннар бәрлыгына чынлап торып ышангач, тегеләр бирергә дә булгач, иртә булса да торгандыр әле дип, Сәхабны сорады.

Сәхаб идарәдә иде, күрәсең, шунда ук җавап бирде.

— Иптәш Кадыйров, ферма мөдирегез Габдулла абзыйны районга җибәрегез әле. Әйе, үзен, үзен. Чек кенәгәсе бирегез һәм бер өч көнгә командировочный... Булдымы?..

Һәм секретарена Әхәтне чакырырга кушты. Бөтен булган фермаларны йөреп чыксын һәм нәтиҗә ясасын. Бюрода караячакбыз. Бәлкем, сөткә поход шуннан башланыр. Әхәт Исмәгыйлов — төпле, тәҗрибәле кеше, керешсен әле шуңа.

Исмәгыйловка уй-хыялын аңлаткач, теге берсүзсез юлга җыенырга булды. Чүпрәледә ирешкән тәҗрибәсенә таянып, ул аңа наряд мәсьәләләре белән, нәселне яхшырту, фермаларны механикалаштыруның торышы белән, азык-төлек әзерләге, аның запасы, төрлелеге белән кызык-

сынып кына калмыйча, һәр колхозны аерым күрсәтергә кушты. Ярдәмгә районның баш зоотехнигын, инженерын һәм тагын бер инструкторны алырга киңәш итте.

Исмәгыйлов чыгып киткәч, Бакир, киерелеп, сөякләрен шытырдатып, сузылып куйды.

— Әйе, сөткә походны әнә шуннан башларга...

Район газетасын һәм сводкаларны карап утырганда, аның янына райкомның промышленность бүлеге мөдире Воронцов килеп керде.

— Бакир Әхтәмович, сәлам. Иртә тотынгансыз эшкә,— дип, ул кулын сузып күреште дә, урындык тартып, өстәл янына чүкте.— Бакир Әхтәмович, бездә ЧП.

— Нинди?

Бакир, кинәт башын күтәреп, Воронцовка текәлде.

— «Ленин юлы» колхозы председателе иптәш Кадыйров нефть идарәсе начальнигы Ходайбирдингә суккан...

— Ничек суккан? — Бакир турая төште, кулындагы кызыл карандашын өстәлгә ташлады.

— Белмим, ничек булгандыр, әмма Ходайбирдинның больницада ятуы хак...

— Фоат бирәдәме?

— Гаражда маташа бугай.

— Секретарьга әйтегез әле, дәшсен.

Воронцов чыккач, Бакир беравык уйланып утырды.

Бакирны секретарь итеп сайлаганда Сәхәб аңа каршы кул күтәрде дип ишеттергәннәр иде. Ходайбирдин беренче булып Бакир өчен тавыш биргән. Үткән хәл, әлбәттә, хикмәте дә, әһәмияте дә юк, әмма нигәдер искә төшеп куйгалый.

...Ходайбирдин сыңар күзен генә калдырып битен-башын бинтка ураган хәлдә бер үзе бер палатада ята булып чыкты. Бакир килеп кергәч, ул иренеп кенә торды да озын бармаклы чандыр кулын күрешергә дип сузды.

— Әллә Айның өсте тигез булмадымы? — дип шаяртып алды Бакир, килеп керү беләи.

— Шулайрак булды шул, Бакир Әхтәмович. Анда да юллар ташлы икән...

— Алаймы? — дип, Бакир аның белән янәшә караватка утырды.

— Ни булды, Вәкил Әкрамович?

— Менә күрәсез, күзне чыгара яздым,— диде Ходайбирдин.

— Мин ишеттем...

— Случайность,— диде Ходайбирдин.— Рульгә үзем утырган идем, бер машинаны узам дигәндә тәгәрмәч астыннан очкан таш минем машинаның пыяласына килеп тиде һәм... күрәсез, аз гына күзсез калмадым...

— Ә мин сезне «Ленин юлы» колхозы председателе белән сугышкансыз дип ишеттем.

Ходайбирдин аягүрә торып басты.

— Аның белән дә шәп килеп чыкмады, Бакир Әхтәмович,— диде ул, гаепле кеше сыман.

— Шул уҗым өченме?

— Әйе. Бик ачулы иде Кадыйров. Кабинеттан чыгып киткәндә ишекне шундый итгереп япты, хәтта бер тәрәзә күзе очты. Утка баскан мачы кебек йөри...

— Уҗым белән сезнең шәп килеп чыкмады, Вәкил Әкрамович,— диде Бакир.

Ходайбирдин кире караватка утырды, озын бармакларын тез өстендә биетеп тора башлады.

— Ну, мин нишләргә тиеш? Аның сортлы ужымы анда булуга мин гаепләме әллә?!

— Беренчедән, ужым аныкы түгел, колхозныкы. Икенчедән, сезнең тәүлегенә биш йөз тонна нефть биргән скважинагыз анда булуына, җитмәсә үз вакытында ремонтламыйча авария ясавыгызга колхоз гаепләме?! Кадыйров үзе өчен түгел, колхоз өчен йөри ул!.. Ә минем сезгә бу турыда әйтергә вазыйфам мәҗбүр итә...

Ходайбирдин башына тотынды, колак артыннан уратып, сыңар күзен бәйләгән бинтны рәтләгәндәй итте, аннары тын калып, беравык идәнгә текәлеп утырды.

— Күңелле хәл түгел, әлбәттә. Ләкин, Бакир Әхтәмович, бирегә без — нефтьчеләр генә гаепле түгел. Техника булгач, авариясез булмый. Әнә ни төгәл самолетлар да чәчри. Аннары без аларга ул җирләрне пычраткан өчен дөнья чаклы акча түлибез. Нәрсә оттыралар алар?! Икмәк бәясе — нефть бәясе түгел! Без нефтьне алтынга сатабыз!..— диде Ходайбирдин һәм шәбәеп йөреп китте.

— Икмәктән олы булып булмый, Вәкил Әкрамович!..

Ходайбирдин кинәт туктап калды. Нидер әйтергә җыенып, кулын күтәрде, ләкин Бакир китәргә дип торып басты.

— Ярар, тынычланыгыз, Вәкил Әкрамович, сез әлегә авыру кеше, дәваланыгыз, сәламәтләнегез... Ә ул мәсьәлә турында соңыннан...

Беренче секретарь чыгып киткәч, Ходайбирдин беравык идән уртасында сүрән кыяфәттә басып торды. Яра борчымый, больницадан чыгарга да була иде, әмма күз алмаңа кан сауган дип, хатыны берничә көн ятарга кушты. Ул — врач, ул аны дәвалый, тыңламыйча булмый.

Ходайбирдин караватына сузылып ятты һәм, палатаның күз камашырлык ак түшәменә карап, уй-хатирәгә чумды. Буш вакытларында ул сәгатьләр буе кымшанмыйча уйланып ята ала, үткән гомерен исенә төшерә, уңышларын барлый, кылган ялгышларына анализ ясый иде.

СССР газ һәм нефть промышленносте Министрлыгында утырып, хәзер пенсиягә чыккан, әтисе белән бертуган абыйсы институттан соң кая эшкә китәргә дип уйланып йөргән Вәкилгә:

— Татарстанга бар. Анда ил чыгарган нефтьнең өчтән бере бирелә. Яшь белгеч өчен иң өметле район,— диде. Киңәш-сабак, үгет-нәсихәт моның белән генә бетмәде, әлбәттә.

Вәкилнең, бару белән, һич югы участок начальнигы буласы килә иде. Грозный промыселларында практика үтеп, бераз күреп-күзәтеп кайткан, нефть эшенең рәт-җаена төшенеп өлгергән, шунда участок начальнигы булып та эшләгән иде ул. Кыскасы, Вәкил үзенең башлык була аласына мизгел дә шөбһәләнми иде. Бу фикерен ул абыйсына да белдерде.

Күпне күргән, эш-хезмәтен гади оператордан башлап Министрлыкта тәмамлаган абыйсы Вәкилнең бу ниятен хупламады.

— Сиңа васыятем шул: җитәкче булырга ашыкма. Авызың пешүе бар. Син яшь әле... Начальник булырга кайчан да соң түгел. Син әүвәл үзеңне эштә күрсәт...

Вәкил абыйсына үз сәләтен тик җитәкче булгач кына күрсәтә алачагын әйтте. Моның өчен үзендә институт белеме, потенциаль җегәр һәм ташып торган теләк булуын белдерде.

Абыйсы аның бу омтылышын килештереп бетермәде:

— Эшче халкы институт эскәмиясеннән төшеп, килү белән начальник булып алган җитәкчеләрне яратмый. Ул әүвәл үз араларында кайнап киткәннәрне аеручарак хөрмәт итә һәм үстерергә ярата. Моны беркайчан да исеңнән чыгарма, Вәкил. Ә җитәкче булу өчен бер теләк кенә җитми кешегә, моның өчен аңарда иң әүвәл сәләт, талант булырга тиеш,— диде.

Вәкил абыйсының кайбер акыллы сүзләрен күңел түренә яшереп

куйды. Әтисе мәрхүм аңа әйтә торган иде: «Кеше сиңа үгет-нәсихәт, акыл-сабак биргәндә, әдәп йөзеннән булса да, киңәшен тыңла, бүлдермә, белдекле булып күренмә. Киңәшенә игътибарсыз калсаң да, үзеңә кирәген ал. Чөнки кешенең һәр киңәш-сабагында үзе күргән тормыш тәҗрибәсе ята, аның күп сүзе арасында чүплектә аунаган алмаз-гәүһәрләр кебек акыллы сүзләр булуы бар».

Вәкил үзе дөнья нужасын бик артык татып үсмәде диярлек. Бик яшьли әнисез калды, ә әтисе шуннан соң дүрт-биш тапкыр өйләнеп караса да, берсе белән дә торып китә алмады. Вәкилнең кулына акча тоттыра иде дә: «Үзең ашханәгә кереп аша»,— дип, китеп югала иде. Вәкил ашханәгә бармыйча, күбрәк мороженое, төче-мөче ашап йөри торган иде. Шуңамы ул төскә-йөзгә ак чырайлы, озын, чандыр гәүдәле, хатын-кызныкы кебек нечкә тавышлы, тар җилкәле, каз муенлы булып үсте. Дөрес, укырга хирес иде, институтны җиңел бетерде.

Аннан соң, абыйсының киңәшен тотып, бирегә, Татарстанга килде. Әле булса хәтерендә, бораулау конторасында инженер булып эшли башлагач, ул партиягә керде. Райком бюросында аңардан берсе:

— Әллә сез җырлыйсыз дамы? — дип сорады. Вәкилнең, әйтерсең, битенә кайнар су бөркеделәр. Ул, борылып, сорау биргән кешегә карады. Башкалар җитди сораулар биреп утырганда аксыл чырайлы, тулы йөзле ул кешенең юка иреннәрендә мыскыллы елмаю күреп: «Тукта, изге бәндә, дөнья булгач очрашырбыз, менә шунда мин сиңа җырлап күрсәтермен!» — дип, күзен-кашын җимереп, аның төс-йөзен хәтерләргә теләп, тегенә сөрелеп алды. Ләкин Ходайбирдинның сорау бирүче кешене моңарчы күргәне юк иде, танымады, белмәде. Ул аны соңрак, бораулау конторасында баш инженер булып эшләгәндә, башбаштаклаһның, бодай җиреннән вышка үткәргәннән соң белде.

Әлегедәй хәтерендә: объектларга чыккач, ул вышка күчергән төшкә килде. Биш-алты трактор белән сөйрәтеп барган бораулау вышкасын монтажчылар ниндидер колхоз басуы читенә китереп туктатканнар да кемнедер көтеп торалар иде. Каршыда югары вольтлы электр линиясе. Аны өзәр өчен уннарча начальник белән элемтәгә керергә кирәк булган. Бу эшнең формаль ягы хәл ителгән булса да, нигәдер электриклар бригадасы килеп җитми иде. Шул ук вакытта электр линиясен бодай кыры аша да әйләнеп чыгып була иде. Монтажчылар электрикларны иртәннән бирле көтәләр икән. Моны күреп, Ходайбирдин бодай кырыннан әйләнеп чыгыгыз дип әмер бирде. Бригадир каршы төште. Минем башым ике түгел, әгәр шулай теләсәгез, приказ язып бирегез, диде. Әйткәләшергә тотындылар. Ә вышка, кайчан инде мине биредән алып китәсез дигәндәй, башын һавага чөеп тора бирде. Вышка монтажлауның һәр минуты, һәр сәгате кадерле чакта!

Ходайбирдин түзмәде:

— Бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам, урап чыгыгыз бодай жиреннән! — дип боерды.

Бригадир аяк терәп карышты, баш инженердан приказ, һич югы, язу сорады. Абруй — менә нәрсә кыйммәт иде бу минутта Ходайбирдин өчен. Һәм ул язды да бирде: «Бодай кырыннан үтәргә боерам! Ходайбирдин»,— дип кул куйды.

Бригадир кулындагы приказны әйләндергәләп торды да:

— Җавапны сезгә бирәсе, баш инженер! — дип, тракторларга кузгалырга кушты.

Шунда ук җир селкетеп тракторлар гөрелти башлады, аңа тамак ертып кычкырган кеше тавышлары кушылды. Менә утыз-кырык тонна авырлыктагы, кырык-кырык өч метр биеклектәге вышка, борынгы таш аткычка охшап, җиңелчә чайкалып куйды һәм яңа гына буйга сикереп, аксыл-яшел төскә керә башлаган бодай җиренә таба шуышты. Вышка тарткан тракторлар артыннан насос, лебедка, вәмә болгаткыч

һәм башка җиһазлар төягән чаналар, арбалар кузгалды. Алар артыннан утыз-кырык метр киңлектәге бодай җире асты-өскә килеп, кайбер төшләре кызыл балчыкка кадәр сөрелеп, актарылып, кантарланып, каралып калды.

— Яман кеше яудан яман, моның өчен безнең баштан сыйпамаячаклар, менә күрерсез,— дип сукранды бригадир.

— Беләсезме сез: электр линиясен бер сәгатькә өзү күпмегә төшә?— диде Вәкил «Сез ялгыштыгыз, сезгә карап мин җүләр ялгыштым», дип һаман тынычлана алмыйча сукранып торган бригадирга.— Сәгате ничәмә йөз сумга. Ә бодай җиренең бәясе аның ярты хакына да тормый...

— Барыбер җәл,— дип карышты үҗәтләнеп киткән бригадир һәм баш инженер янынннан саубуллашмыйча китеп барды...

Ходайбирдингә бу башбаштаклыгы өчен бораулау конторасыннан китәргә һәм өстәвенә партиядән шелтә алырга туры килде. Беренче карашка хәтта бер гаебе булмаган бригадир да шелтәдән мәхрүм калмады.

Шушы вакыйганы Вәкил һәрчак эчке бер оялу белән, йөзен көзән җыергандай чытып исенә төшерә иде. Беренче тапкыр аны әнә шул бодай җире өчен «кыйнадылар». Ул бораулау конторасыннан китәргә һәм нефть чыгару идарәсенә килергә мәҗбүр булды. Биредә, нефть идарәсендә, баш инженер булып эшли башлагач, Ходайбирдин тагын бер «ЧП»га эләкте.

Анысы болай булды.

Вәкил үзе кебек озын, әмма үзе кадәр ике юанлыктагы таза гәүдәле күз врачына өйләнде. Аны ул Мәскәүдән алып кайтты. «Өйләнмәгән кеше — йөгәнсез ат, яхшы хатын — ныклы тыл, үсү өчен сиңа әйбәт хатын кирәк»,— диде тормышның әчесен-төчесен татыган, күпне күргән шул ук абыйсы. Вәкил аны хөрмәт итә, аңа ышана иде, шуңа күрә карышмады, өйләнде.

Яшь хатынны алып кайтканда кыш иде. Өйләнешүнең бөтен ямен китереп, ял саен урманга бардылар. Беркөнне Вәкил үнике калибрлы мылтыгын да алды. Идарәнең өр-яңа ГАЗ-69 машинасы белән урманның теләсә кай төшенә кереп йөрделәр. Башта ау кайгысы булмады, алган шампанскийларын авыз итеп, уйнап-көлеп кар атыштылар, мул булып бәс кунган чыршы астына кереп үбештеләр. Аннары мылтык искә төште. Саесканнар, ала каргалар атып йөрделәр. Ул арада көн кичкә авышты, кышкы сүрән кояш соңгы нурларын агач башларында гына калдырып байый башлады.

Кайтырга чыктылар. Икесе дә бәхетле, икесе дә шат, икесе дә үткән көннән канәгать иделәр. Ләкин бер күңелле кеккә ике күңелсезлек туры килер, ди. Урала-бутала урманны чыгып килгәндә машина каршында мөгезләрен як-якка ташлап мәһабәт поши пәйда булды. Поши бер үзе иде, үгез иде, машиналарны күп күргән иде, күрәсең, курыкмады, батыр кыланды...

Ходайбирдин соңыннан гел көрсенеп шушыны исенә төшерде: каян килгәндер ул тәвәккәллек, машинаны шып туктатты да мылтыкка үрелде һәм, күз ачып йомганчы чыгып, үзенә карап торган пошига ике көпшәдән дә атып җибәрде. Кышкы зәңгәр һава ярылып, чәрдәкләнеп китте шикелле, якын-тирәдәге агач ботакларыннан бәс коелды. Ату тавышы шул кадәр көчле булды — ул, кайтаваз булып, урманны яңгыратып бик озак ишетелеп торды. Поши башта кинәт артка чүкте, аннары алгы аякларына тезләнде, аннары гөрселдәп бер якка ауды һәм киң борын тишекләреннән кан катыш бу чәчә-бөрки, алсу кайнар канына йотылайотыла һава суларга тотынды — яшәргә теләде. Ул чәбәләнде, үлә алмыйча ун минутлар тыпырчынды. Инде тынып калды дигәч тә тәненең аерым урыннары көзән җыергандай тартышып торды. Һәм мәшһүр хай-

н, ниһаять, тынып калды. Бу хәленә, кылган эшенә өне алынып, ылтыгын һаман пошига төбәгән көйгә катып торган Вәкилне:

— Нишләдең син?! Аһ, Вәкил!?— дип аһ-ух килеп, машинадан төп, янәшәсенә баскан Лидасы аңына китерде.

Хатыны, ауган пошины күрүгә коты алынып, агарынып киткән иде. Пошиның киң итеп ачкан күк күзеннән мөлдерәп яшь тама. Яшь ымчылары, йөзе буйлап, йоннар өстеннән йөгерешеп, кан чәчрәгән ирга төшә һәм аны тишеп, чокыр ясап кар куйнына сеңә иде.

Моны күрүгә, хатыны Вәкилнең җиңенә килеп сарылды.

— Нишләдең син? Пошиларны атарга ярамый бит!.. Нигә ул без?.. Шундый матур хайванны!..— дип такмаклап еларга тотынды.

Вәкилнең хатынына ачуы беренче тапкыр шунда чыкты. «Ни булын миңа, берни дә булмас? Хәзер утырырга да китәргә кирәк»,— дип йлады һәм хатынын юата-тынычландыра машинага әйдәде. Лида ынычлана алмады.

— Нигә ул безгә? Нигә?! Вәкил, нигә дәшмисең?!.

— Житте, житте сиңа! Әйдә, утыр тизрәк! Утыр дим, китәбез! — иде Вәкил тагын ачулана төшеп.— Житте, җылама! Миңа берни дә улмаячак! Әллә мин вак-төяк кешеме? Шуны да йомып калалмас диенме?! Нигә үкерәсең, ә?! Кеше үтермәдем бит... Утыр!..

Вәкил шулай дип торганда алар янына урман каравылчысы килеп ыкты...

...Вәкил: «Миңа берни булмый»,— дип барса да, поши мәҗарасынан дөнья хәтле акча түләп, көчкә, мең бәла белән генә котыла алды. ләм: «Яңадан кулыма мылтык алмам!» дип үз-үзенә ант итте.

Һәм алмады да. Башы белән эшкә чумды. Шактый эшлекле тәкъимнәр кертте, көн-төн промыселларда югалып йөрде. Идарә начальигы, үсүгә таба китеп, берләшмәгә күчерелгәч, ул үз урнына баш инженер Ходайбирдинны тәкъдим итте. Идарә начальнигы дәрәҗәсенә сеп житте Вәкил. Бу турыда ул абыйсына да хат язып белдерде.

Абыйсы аны бу уңышы белән тәбрикләсә дә: «Син хезмәт юлының иртысын гына үттең әле, әтәчләнмә, күбрәк нефть чыгарырга тырыш, шунда гына теләгеңә ирешә алырсың»,— дип, янә киңәш-сабак биреп хат язды.

Ходайбирдин ничек итсә итте, эшли башлавының икенче кварталында ук Бөтенсоюз ярышында беренче урынны алуга иреште. Вәкил өчен бу зур җиңү иде. Идарә коллективы турында республикада гына түгел, Союз күләмендә сөйли башладылар. Уңыш килгәч, Вәкил үзенчә итеп менә ничек уйлады: барыннан да элек синең планнан тыш күпме нефть чыгара алуың кызыксындыра. Шуңа карап сине күрә-таный башлыйлар, киңәшмә-җыелышларда яхшы ягың белән телгә алалар, артта сөйрәлүчеләрне синең белән тиңләшергә өндиләр, ил алдында абруй-дәрәҗәнне күтәрәләр.

Шуңа күрә ул теше-тырнагы белән бары тик нефтьне күбрәк чыгаруга ябышты.

Ул белә иде, идарә файдаланган нефть ятмасы вакытсызрак сүнә: геологлар планлаштырган запасны тулысынча бирми. Ләкин моңа Вәкилнең исе китмәде. Скважиналарны электрлаштыру, автоматлаштыру, батырма насослар төшерү хисабына айдан-айга планны арттырып үтәп килде. Бу эшкә ул чатыр ябышты. Югары басымга көйләнгән яңа куст насос станцияләре салдырды. Бу хәл катламга су тутыруны бермәбер арттырды. Шуның хисабына меңләгән тонна өстәмә нефть алынды. Күпләр шикләнеп, ай-һай, ул-бу булмагае дип, җиде үлчәп бер кисеп эшләгән тәкъдимнәрне Ходайбирдин кыю төстә производствога кертте. Кул астында эшләгән кешеләрнең беришеләре белән ул тату эш итте, ә аңа каршы әйткән белгечләрне ничектер җайлы гына итеп бүтән урынга күчерә белде. Ул беркайчан да кешене эш урынында орышма-

ды: итагатьле, йомшак табигатьле, гадел житәкче булып күренде. Вак ланмады. Әмма гаеплеләрне җыелышларда кызган табага бастыры сукте, әйтсә — усал әйтте. Моның өчен аны күбесе хәтта мактап телг алды. Документацияләр алып баруны, промыселларга яңа техника кертүне, производство мәсьәләләрен хәл итүне ул тулысынча баш инже нерга һәм бүлек начальникларына йөкләде. Кирәк чакта аларны макта ды да, орышты да. Үз өстенә төп эш итеп нефть чыгаруны алды. Бу өлкәдә ул бернәрсәдән дә иренмәде. Шулай итмәгәндә ул җитәкләгән идарә Союз күләмендә беренче урынны алуга ирешә алыр идеме? Юк. Ә план ай саен арттырыла. Соңгы вакытта шактый кыен юлларга төшәргә туры килә башлады. Ходайбирдин, әйтик, ремонт вакыты җит кән скважиналарны икешәр срок эшләтте. Кайчакта хәтта геологлар күрсәтмәсен бозды. Байпас белән шаярган участок начальникларын, операторларны күрсә дә күрмәмешкә сабышты.

Әлбәттә, бу чамасыз мавыгып китү иде.

Әйе, җитәкче буларак ул шактый тәҗрибә туплаган иде инде. Элек кеге кебек эш урынында кычкырышып киткәләү, ни буласын алдан уйламыйча бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, кирәкмәгән боерык приказлар язуы бетте. Ул хәзер эшендә дә элекке кебек көне-төне өтә ләнми инде: ял көннәрендә я китап укый, я телевизор карый, ә гөмбә гә йөри, я хатынын култыклап кино-театрга бара.

Вәкилнең шулай шөгыльсезләнеп калуын нигәдер хатыны да килеш термәде.

— Берәр ялны балыкка барыр иден ичмасам. Болай өйдә ятып гәү дән йөртерлегеӊ калмады бит инде,— дип әйткәли башлады.

Гәүдә йөртү мәсьәләсендә, әлбәттә, хатын хаклы иде — ул күбрәк белә, аңа күренәрәк төшә... Шуннан соң Вәкил балыкка баргалады. Ләкин, бер килмәсә килми бит, аңа бу шөгыльдән дә баш тартырга туры килде.

Беркөн шулай ул шамбы балыгы тотып алып кайтты. Аны, бозыл масын да, шул ук вакытта туңып та китмәсен дип, суыткычның иң аскы катына куйды. Дүшәмбе көнне, өйгә иртәрәк ашыгып, хатыны кайткан чы уха пешерергә булды. Шамбыны суыткычтан алып сулы савытка салды да, кухняга кереп, җиң сызганып бәрәңге әрчергә кереште. Ба рысын да хәзерләгәч, балыкны тазартырга дип коридорга әйләнеп чыкса, савыттагы шамбыны күрмәде. Шамбысы шамбы гына идеме соң?! Өч кило тартмаса да, шуңа якын, симез иде. Ләгънәт, күрше песи алды микәнни?

— Бу ни бу?

Ваннада ниндидер тавыш ишетеп, шунда керсә, күзләре шар булды. Сигез яшьлек кызы Наилә, мәктәптән кайтып, дәресләрен карау урынына, ваннага су агызып, шамбыны җибәргән һәм бер корсак өстен ятып, бер сыртын чыгарып йөзеп китәргә маташкан балыкка карап куанып туя алмый куана!

— Кызым, нишләвең бу? Бир, мин аны тазартам? Әниең эштән кайтканчы уха пешерик...

Кызның күзләре зурайды, мөлдерәп яшь белән тулды.

— Әти, тере бит ул, йөзә...

— Уха пешерәбез хәзер без аңардан, телең йотарсың менә...

Вәкил инде терелеп китеп йөзә дә башлаган балыкның саңагыннан эләктереп алды да кухня ягына атлады. Кыз аңа иярде.

— Әти, әллә балыкны суясың?..

— Суймыйм. Тазартам,— диде Вәкил гамьсез генә.

— Әти, әти... тазартма, әйдә йөздерик, тере бит ул... йөзә...

— Балыклар барысы да йөзә...

Шул сүзне әйткәндә Вәкил чәбәләнеп торган балыкның эчен яры җибәрде.

Бала бу тамашаны күргә күзләрен шардай итеп катып калды, ан-
ары лып итеп идәнгә утырды.

Вәкил курка калды. Ул баланы тиз генә күтәреп алды да диванга
илтеп салды, мангаена юеш сөлге куйды. Шул чак әнисе кайтып керде.

— Ни булды балага, Вәкил?!

Ана йөзе агарынган баласы янына килеп утырды.

— Ни булды, әллә пештеме?..— дип сорады ул хафаланып.

— Белмим, мин балык тазартканда шулай иссез калып ауды да
китте...

Вәкил булган хәлне әйтергә базмады.

Балага әнисе ниндидер дару эчерде, укол кадады. Бераздан бала
янына килде.

— Уф! — диде әнисе, баланың башын тотып, күзләренә карады.—
Ни булды сиңа, кызым? Уф, тәмам котымны алдың бит. Ни булды, ни-
дән курыктың?..

— Әти балыкны суй-й-ды... Ул, ул!..— дип бала яшь аралаш такмак-
ларга, үксеп-үртәлеп еларга тотынды.

Төнлә баланың тәне кызышты. Әнисе, ашыгыч ярдәм китертеп, аны
больницага алып китте. Бу төнне Вәкил берүзе бер квартирада зык
кайгырып, булган хәл турында уйлап чыкты.

...Наилә больницада бер атна ятты. Өйгә ул ябыгып, шиңгән гөл
кебек сурелеп кайтты. Күңеле йомшармасмы дип, Вәкил аның кайтуы-
на аквариум алды һәм аңа төрле балыклар җибәрде.

...Хәзер инде Наиләгә унике яшь тулды, бишенчедә укып йөри, ә һа-
ман балык белән булган хәлне оныта алмый. Ата белән кыз арасында
бәхәс кузгалдымы:

— Әти, син каты бәгырьле кеше,— ди...

...Ходайбирдин Сәхаб белән булган хәлгә күчә алмады, аның уйла-
рын бүлдереп, палатага хатыны килеп керде.

— Йоклапмы, уйланыпмы ятасың? — диде ул. Вәкил янына үтте
һәм аны йомшак иреннәренә кагылып үбеп алды.

— Бала кая, нигә килми? — дип сорады аннан Ходайбирдин.

— Килде дә ул, нигәдер кермәде. Мин әти белән тәрәзәдән генә сөй-
ләшәм,— дип калды.

Вәкил, күңел төпкелегенә тагын бер уч юшкын утыруын тоеп:

— Керсен иде ул, Лида,— диде.

Сәхаб, хатынын җирләп бер ай үткәч, әнисенә әйтте:

— Әнкәй, тора алырбызмы икән, балаларны үстерә алырбызмы
икән?

Мәстүрә карчык дөнья күргән кеше иде, улының тел төбен шунда ук
аңлап алды. Мәрхүмәнең кырыгы үтмичә, бу турыда сөйләргә оят,
улым, сиңа, диде.

Сәхаб кан төсенә кереп оялды. Чынлап та, малайлары зурлар бит
иде...

Тора-бара ул ялгыз торуга да өйрәнеп китте. Болай да кыр-басудан,
дәрәдән кайтмаган кеше, бер караңгыда китеп, өйгә икенче караңгы-
да гына кайта торган булды.

Мәстүрә карчык моны ошатмады.

— Килен булмагач, гел күзгә күренмәс булдың, балаларың бизәр
зеңнән, көндез дә кайткала, улым,— диде.

Әнисе дөрес әйтә иде. Сәхаб, малайларына күренеп, туры килгәндә
өендезгә якта да ашарга кайткалады.

...Мәрхүмә Нәсимәсе аңа ике малай табып калдырды. Берсе аның
л сугыштан кайтып бер ел үткәч туды, икенчесе — ике ел үткәч. Ләкин
нигәдер малайлар арасында аерма булмады диярлек. Алар гел бер-
ә үстеләр. Зурысы аз ашады, нәзберек булды, кечесе исә талымсыз

кыланды, алдына ни куйсаң, шуны сыпырды. Шунамы алар гел игезәкләр кебек бер буйда, бер чама булып үстеләр. Сәхаб мәктәпкә дә икесен бер елда бирергә уйлаган иде, әниләре каршы төште:

— Нигә алай итәсең, атасы, иптәшләре кыерсытырлар, керсен үз яшьтәшләре белән,— диде.

Сәхаб күнде. Өлкән малайны мәктәпкә әнисе алып китте. Кечесе, мин дә барам дип, үкереп елап калды. Чөнки сине дә мәктәпкә кертәм дип, Сәхаб аңа да сумка-дәреслекләр алган иде. Баланы тынычландырырга теләп, Сәхаб үксеп беткән малайны машинага утыртты да комбайнчылар янына, кырга алып чыгып китте. Малайга машиналар ошады, көнозын комбайнчылар янында уралды: утырып йөрде, өйлә вакытында менеп штурвалны боргалады, авыз эченнән нидер мыгырданды. Кайтып китәргә дигәндә янә разбой купты, Сәхаб малайны кичкә кадәр комбайнчы янында калдырырга мәҗбүр булды...

Менә хәзер үсеп җиттеләр. Әмма Илгизәр машина яратуын ташламады. Укуында алдынгылардан саналмады. Өлкән малай Алик исә китаптан башын күтәрмәде. Гел бишлегә укыды. Мәскәүгә экскурсияләргә барып кайтты, грамоталар алды. Сәхаб, өлкән баласында укуга дәрт күреп, унны бетерер елны аның кая укырга барырга теләге барлыгын белергә уйлады.

Алик җавап бирергә ашыкмады, күзлеген рәтләп, беравык әтисенә карап торгач:

— Әти, ул турыда сөйләшергә иртәрәк түгелме соң әле? — диде.

— Иртә түгел, улым, иртә түгел...

— Минем, әти, авыл хуҗалыгы институтына керәсем килә, агроном булырга исәп...

Сәхаб, хискә бирелеп, «Рәхмәт, улым, мин теләгән җиргә барасың, ата-бабаңның туган туфрагын ташламыйсың»,— дип, малаен кочып яратырга уйлаган иде, өлкән малайның үзен өнәп бетермәгәнен, әнисе үлгәч, гел дә аңардан читләшкәнен сизеп, тыелып калды, ирләрчә «ярый, яхшы» дию белән генә канәгатьләнде.

Алик турында ул хәзер кайгырмады. Аликның үз хыялы бар, ул үз теләгән тормышка ашырачак, андый кешеләр бәхетле булалар, чөнки барысын да алдан күреп эшлиләр. Сәхаб кече малае Илгизәр белән нишләргә белми иде. Укытучылар аңы бернечә тапкыр мәктәпкә чакыртып та сөйләштеләр. Кул җитми, көн-төн колхоз эшендә чабам, дип акланмакчы булган иде Сәхаб, иплэп-җайлап кына аңа аталык вазифасын аңлаттылар. Сәхаб тугызынчы класста укып йөргән Илгизәрне, бер көн иртәрәк өйгә кайтып, мәктәптән көтеп алды да, тегенең, әтиәбисенә игътибар итмичә, сумкасын диванга ташлап чыгып китәргә җыенуын күргәч:

— Туктале, улым. Кая болай ашыгасың? — дип, үз янына дәште.

Малай каядыр ашыга иде.

— Мин мастерскойга барам, анда Зиннур абый машина ремонтлый,— дип, бер телем ипи кисеп алды да ишеккә китте.

— Тукта!.. Шельма!

Әтисенең боеручан усал тавышы малайны туктарга мәҗбүр итте.

— Кил әле бире, утыр әле менә монда! Сөйләшәсе сүз бар...

Әбисе ишегалдына чыгып китте, ата белән ул өйдә үзләре генә калдылар.

Сәхаб сүзне ерактан башлады. Үзенең машина яратып тракторчы булуы, танкист булып сугышка китүе, анда бернечә тапкыр әҗәл тырнагына эләгеп яна язуы, балаларга тәрбия бирүче әнисенең кисәк кенә үлеп китүе, ата кешегә Илгизәрне укытырга кыенга килүе турында — барысын да тезде, калдырмады. Әнә шуларны йомгаклап, укымыйча, ягъни такы-токы укып, укуга күнел бирмичә йөрсә, Илгизәрнең дә әтисе кебек тугыз класс белән калуы турында әйткәч, малай:

— Ә мин унынчыда укымыйм,— дип торып китмәкче иткән иде, этисе, карчыга чыпчыкны каптырган кебек, малайның беләгеннән эләктереп алды.

— Утыр!

Малай бераз шүрләде, ләкин тынычлана төшкәч, тагын җәелеп сөйләшә башлады.

— Мин институтка керергә җыенмыйм, эти, механизатор булам,— диде.

— Әйбәт, ләкин аңа да ун класс белем кирәк бит.

— Анда тугыз класс белән дә алалар.

Сәхаб малайның үзенеке кебек ак чәченә, кара кашына, зәңгәр күзенә карап торды. Һәм малайның бөтен торыш-кыяфәтендә, холык-фигылендә үзен күреп: «Булмас бу эт каешын кеше итеп, әйдә тугызны бетерсен дә, киләсе елга Бөгелмәгә илтермен»,— дип, үзен-үзе тынычландырудан башка әмәле калмады.

Ләкин Илгизәр тугызны тәмамлаганчы да күп мәшәкать ясады аңа, авыл башлыгы буларак Сәхабка халык алдында күп кызарырга туры килде.

Ниһаять, Илгизәрне этеп-төртеп булса да, тугызны тәмамлады дип, мәктәптән чыгардылар. Аликны авыл хуҗалыгы институтына озаткач, Сәхаб: «Бу дошман үзе генә бармас, я берәр кая качып китәр»,— дип, Илгизәрне Бөгелмәдәге «Киң профиль авыл хуҗалыгы механизаторлары мәктәбе»нә үзе китерде. Һәм өйрәтүче мастерны күреп, аның белән танышкач:

— Сөяге миңа, ите сиңа, әнкәсе юк, минем вакыт тар, аталарча карагыз, укысын, каты булыгыз,— диде.

— Без аны мена дигән егет итәрбез, тыныч бул малаең өчен, эти кеше,— диде мастер.

Сәхаб тынычланып кайтып китте.

Бер айдан өлкән улы Аликтан хат килеп төште. Ул институтка керүе һәм бераз акча кирәклеге турында язган иде. Сәхаб колхоз кассирына килде дә:

— Һәр айны менә бу адрес белән минннән кырык сум акча сал. Аңлашылдымы? — диде.

— Мәйлен, Сәхаб абый, Аликка була, димәк...

Сәхаб шат иде: ниһаять, малайларын үстерә, кеше итә.

— Аңла, агроном булачак малай, Нәҗип туган, агроном...

Кеше шатлыгын кеше белми, кассир Нәҗип: «Әһе, әйе»,— дип баш кагып куйгач, Сәхаб:

— Беренче юлда илле сум итеп сал,— диде.

Сәхаб өлкән малае Аликка зур өмет баглады. Ул аның агроном булып кына калмыйча, хәтта галим булуына да ышана иде. Һәм күңеле дөрес тойган икән. Алик институтны тәмамлау белән аспирантурада калды. Хәзер яңа сорт арыш чыгарып йөри, исеме илгә билгеле булган профессор кул астында эшли.

Былтыр кайтып, авылда ике ай ял итеп китте. Ләкин Алик өчен ял булмады ул. Әтисе аларга, колхоз агрономы белән икесенә, меңтөрле эш йөкләде. Һәр кырның туфрак анализын алдыртып, кайсы басуга күпме һәм нинди ашлама кертү турында туфрак картограммалары төзетте. Аликка ул үз машинасын бирде, ә үзе җирән кашка белән, ул арыгач, мотоцикл белән чапты. Алик эшен тәмамлап киткәч, Сәхаб картограммага карап җирләрне ашлауга керешге. Тартып-йолкып булса да артык ашлама алды, торф чыгаруны, аны ваклатуны җайга салды, булган тиресне өйдереп, җир туймас борын кырга чыгара башлады. Моңа ул хәрәкәттәге барлык механизмнарны җикте. Кайсына күчереп, кайсына акчалата түләп, предприятие житәкчеләрен җайлап-көйләп, һәр атна саен йөзләгән үзбушаткыч машина китерде, машина йөртүче-

ләрне сарык-тана суеп ашатты, шунда ук акчасын чыгарып, хезмәт хакын да бирде. Яңа ел алдыннан отчет-сайлау җыелышында колхозчылар да моның бөтенесен хуплап сөйләделәр.

Сәхаб һәр гектардан кимендә утыз-утыз биш центнер уңыш алу турында хыяллана башлады. Икенче елны ул Аликны үзе барып алды. Агрономның гына башы җитмәс, булыш әле шул тәҗрибә нясенә дип. Аликтан уңике басулы чәчү әйләнешендә культуралар чиратлашу картасын төзүне үтенде. Алик башы белән эшкә чумды. Әмма беркөнне Сәхабка Аликның нинди дә «чәчби» артыннан һәр көнне шәһәргә чабуы турында җиткерделәр. Сәхаб Аликтан бу турыда сорарга яхшысынмады. Малаеның начар ният белән йөрмәвен белә, аңа ышана иде. Ләкин тел кашып, теш агартучылар аның шик-вәсвәсәсен ахыр чиккә җиткерделәр. Имеш, Аликның өйләнергә исәбе бар икән дә, эшең күп дип, Сәхаб кушмый икән.

Сәхаб моңа түзә алмады, бервакыт ашап утырганда Аликтан:

— Кем артыннан һәркөн иртән шәһәргә чабасың да, көнозын үзең белән йөртеп, кич илтеп куясың? Нинди «кызыл авыз» ул? — дип сорады.

— Безнең институтның беренче курс студенткасы. Ялга кайткан, миңа ярдәм итәргә алынды,— диде Алик тыныч кына, гадәти бер нәрсә турында сүз барган кебек.

Ләкин Сәхаб Аликның бит очларына алсулык йөгерүеннән үк шуны сизде: малай кызга гашыйк булган. Ата буларак ул малайның гашыйк булуы өчен кайгырмады. Алик — төпле егет, ахмаклык эшләмәс. Ә менә шул «чәчби» аркасында чәчү әйләнеше картасын төзеп бетерми китүе бар. Шуның өчен ул, сүз ара сүз чыгып әйткәндәй:

— Системаны картага төшерә башладыңмы соң әле? — диде.

— Юк әле, эти, анысына барып җитмәдем,— диде Алик гамьсез генә. Һәрхәлдә, Сәхабка шулай тоелды. Ата пошаманга калды.

— Киткәнче син аны бетереп, агрономга тапшырып кит инде...

— Тырышып карармын... Эше бик күп шул. Ике айда гына... белмим...

— Мин сиңа яңа кайткан «Волга»ны бирәм.

Алик, көлемсерәп, күзлек аша этисенә карап алды.

— Кирәкмәс, эти, «Волга» белән басу юлларында йөреп булмас. Биргән машинаң бик әйбәт. Аннары минем аңарда йөргән дә юк, я бәреп ватармын...

Сөйләшү шунда өзелде. Сәхаб берни кыла алмавына ышанды. Ә бит ул аны көзгә һичшиксез бетерәм дип әйткән иде. Бу «чәчби» булмаса, бәлкем, чыннан да бетерер иде.

— Кем кызы? — дип сорады ата.

— Моның сиңа һич хаҗәте юк, эти,— дип Алик елмая-кызара күзләген салды һәм ашыкмый гына күзлек пыяласын сөртә башлады.

Илгизәр ике ел укып, механизатор булып авылга кайткач, Сәхаб аңа кукуруз комбайнына утырырга тәкъдим итте. Ләкин Илгизәр этисенә, бөртек комбайнына утырам, шуңа риза булмасаң, Чаллыга китәм, дип әйтте. Теләсә-теләмәсә дә Сәхаб риза булды.

— Кайту белән яңа комбайнга утыртырга кешедән яхшы түгел, шуны да аңламый, ахмак малай,— дип сукранды үз-үзенә Сәхаб.

Ләкин Илгизәргә озак эшләргә туры килмәде, көз җитүгә аны армиягә алдылар.

— Синең кебек, эти, танкист булам. Менә күрерсең,— диде Илгизәр, Сәхаб малайны Бөгелмәгә озата килгәч.

— Хат язып тор, онытма! — диде этисе.— Миннән сиңа үтенеч шул, Илгизәр улым...

Һәм шундый сүзләрне Нәсимәсе 1941 елда аны сугышка озатканда, менә шушы ук перронда үзенә әйткәне исенә төште. Өйләнешкәч, алар

бер ай гына торганнар иде әле. Озата килгәч, Нәсимә аның муенына сарылып: «Хат язып, исәнлегеңне хәбәр итеп тор, Сәхаб, онытма! Онытма, исән йөр, саклан, яме?» — дип өзгәләнә-өзгәләнә елаган иде. Илгизәрен утыртып алып киткән вагоннарга карап калганда әнә шул хәл күз алдына килде.

Аннары күп еллар ялгыз яшәгән карт кешедәй, үз-үзенә:

— Үткән гомер үтә, менә сугыштан кайткач дөньяга килгән малаемны да армиягә озатам,— дип сөйләнә-сөйләнә куе зәңгәр офык түренә кереп югалган тимер юлга соңгы тапкыр күз ташлады да перроннан шәһәргә төшә торган баскычка таба китте.

Арыш чәчәр вакыт житте. Алик әтисенә, Казанга барып, институт чыгарган яңа сорт арыш орлыгын алып кайтырга һәм үзе сайлаган жиргә чәчәргә нияте булуы турында әйтте. «Агроном белән киңәшеп карарбыз, мәшәкате булмагае»,— дип, Сәхаб киреләнеп маташкан булды, әмма Аликның теләге зурлыгын күреп:

— Ярый, бәхетне сынап карыйк. Иртәгә бер машина белән бухгалтер абыеңны ал да Казаныңа барып кайт,— диде.

Аликның түбәсе күккә тиде. Ниһаять, ул шефы чыгарган, әмма әле республикага таралмаган, селекция совхозында гына сыналган, шул сортны чыгаруда үзенең дә өлеше кергән арышны республика колхозларының берсендә, житмәсә тагын үзенең туган авылы басуында сыначак. Бәлкем, яңа сорт арыш тормышка путевканы нәкъ шуннан алыр?!

Ике көннән сортлы арыш кайтарылды һәм Алик сайлап алган жиргә чәчелде. Арышны чәчкәндә Алик янында теге «чәчби» дә йөрде, нидер киңәш итте, булышты, чәчкечләрне тикшерде, күмелү тирәнлеген үлчәде.

Гәүдә-сыны, кул-йөзе кемгәдер охшатып, әмма кемгә икәнен төшенә алмыйча, Сәхаб җете кара чәчле, куе киң кашлы, карасу-күк күзле кызга сокланып, хәтта бераз көнләшеп карап торды.

— Бу нәмәрсә итәк тулы балалы семьяда үсмәгән, кара син аның киеменә генә, гел нейлон да капрон өстендә,— дип сөйләнде.

...Арыш тигез, матур булып шытып чыкты. Үткән-сүткәндә гел шул тирәдән узарга гадәтләнеп алган Сәхаб яшәреп барган уҗымга карый иде дә куанып бетә алмый иде. Яңгыр кирәк! Яңгыр булса, тагы да калкып китәчәк иде уҗым.

Сәхабның зарын ишеткән кебек, икенче спасста яңгыр яуды. Уҗым күзгә күренеп яшәрде, ә ун көннән, яшел хәтфәгә охшап, искән жилдә дулкынланып ята башлады. Алик хат аша арыш турында белешеп, хәбәрләшеп торды, агрономга төрле киңәшләр бирде, әтисеннән теге якны бу ашламаны алдыруын үтенде. Сәхаб иренмәде, барысын да эшләде. Беркөн шулай, басуга чыккач, янә арыш жиренә барып килде. Аликның арыш жирен сайлый белүенә исе китеп, сокланып яшел басуга карап куанды. Бирелән картлар гомер-гомергә мул уңыш алганнар, арыш нигәдер аеруча уңа торган булган. Бу басудан жир Жамалетдин муллаларыкы булганда да, жирләр колхозга күчкәч тә шулай ук һәрчак мул уңыш алынган. Каян белгән Алик арышка бу жирне сайларга кирәклеген? Картлардан сорашкандыр. Бәлкем, сорашмагандыр да, туфрак анализлары күрсәткәндер. Әлбәттә, шулай...

Ата улы өчен горурлана һәм әченнән генә, яшерен генә булса да аны колхозга агроном итеп кайтарырга хыяллана иде. Атасы — председатель, улы — агроном.

Сәхаб уҗым эченә кереп баскан да әнә шундый татлы хыялларга чумган. Председатель шат, ул үзалдына елмаеп ала һәм иелеп, киң кыяклы арыш сабакларын сыйпый, шунда ук уҗымның үтә куе һәм әйбәт үсүенә янә куанып:

— Буынга сикермәсен тагын! — дип шикләнеп куя.

Ярата Сәхаб Сәләй тавы буенда булырга. Аның итәгендә арыш җире булганга гына түгел, юк. Шунда ул, шушы кырда, беренче тапкыр Нәсимәне кочып үпте. Алар көлтә ташыйлар иде, ә Сәхаб трактор белән ике лобогрейка тарттыра. Унган иде дә соң мәрхүмә Нәсимәсе! Эшли башласа, кулларында ут уйнатыр иде!

Сәхаб Сәләй тавына күтәрелеп карады. Аның нәкъ түбәсендә биек булып вышка утыра. Бораулаган чаклары, күрәсең: агрегатлары күренә. Түбәндәрәк, иңкүлектә, арыш эчендә, нефть идарәсенең тәүлегенә биш йөз тонна бирә торган данлыклы скважинасы. Кызыл тасмалар үзендә — лозунглар, плакатлар, әлбәттә... Дегет суырта торган «кое» гына димәссең!..

Сәхабның еш кына кыр-басуларны нефтькә пычратучыларга ачуы чыга, мәгәр аларның теләсә кая скважина утыртуларын яратып бетермәсә дә, кайчак туган туфрагы һәм җир-ана өчен горурланып та куя иде.

— Бумы, безнең җирләрме дәүләт өчен хәзинә түгел?! Икмәкне илнең күп районнары бирмәгән итеп үстерә һәм ил гомере күрмәгән куләмдә кара алтын бирә?! Бумы, безнең туфрагыбыз, безнең җиребезме хәзинә түгел?!— дия иде ул. «Кыр-басуларыбызны телеп бетерделәр, җир кадерен белмиләр, чәчкән икмәкләр белән исәпләшмиләр нефтьчеләр»,— диләр кайчакта кайбер колхозчылар. Һәм шулай ук, бу сүздә бераз хаклык күреп, кыр пычраткан нефтьчеләргә Сәхабның эченнән генә ачуы да кайнап куя иде. Бу ачу кайчак ашып-ташып та киткәли. Һәм шунда ул машинасына утыра да промыселларга чаба, инженер-начальникларны, мөдирләрне эттән алып эткә салып тирги, ахыр чиктә якасыннан тотып машинасына утырта да, тегенең ай-ваена карамыйча, пычратылган җирне күрсәтергә алып килә иде.

— Карагыз, нишләткәнсез җирне! Монда кайчан икмәк үсәчәк? Бу җир кайчан чәчәргә яраклы булыр? Беләсезме сез шуны, юкмы?! — дип, сафура бураннары чыгарып орыша иде. Әмма дәгъвага барып җитми, ничек кабынса, шулай сүрелә дә белә иде.

Ләкин соңгы «ЧП» аны тәгаен чыгырыннан чыгарды. Бу хәл һич көтмәгәндә, һич уйламаганда булды. Кырдан кайткан агроном, төсейөзе качып, аның янына килеп керде.

— Сәхаб абый, уҗымга нефть ага!

Сәхаб бәрелә-сугыла ишеккә ташланды. Рульдә утырган бер өйрәнчек малайны, теге авыз ачып сүз әйткәнче, тартып төшерде дә, икенче яктан кочкә утырып өлгергән агрономга сирпелеп тә карамыйча, Сәләй тавы астына чапты.

Бирегә хәл матурдан түгел иде. Танылган скважинадан егермеегерме биш метр өскә нефть катыш су фонтаны ургыла. Ул бер җиргә авышә, бер турая. Тирә-яктан иңкүлеккә таба, хәтфәдәй яшел уҗымны кара төскә буяп, нефть гөрләвекләре ага: шулар инешкә кадәр житсә, бөтен арыш басуы юылачак, сортлы арыш җиренең бер кишәрлеге дә пычранмыйча калмаячак иде.

Сәхаб, бу тамашаны күргәч, агрономга бульдозерны һәм урман сабанын тагын ике трактор китертергә әмер бирде дә үзе скважина янына йөгерде. Скважина тирәсендә «елочка»га якын бара алмыйча, ике оператор аптырап басып тора иде. Сәхаб, сулышына капланып, алар янына килеп җитүгә:

— Ни булган, нигә агызасыз?! — дип кычкырды.

Операторлар беравыздан:

— Елочка өзелгән, берни эшләп булмый,— диделәр.

— Нигә задвижканы япмыйсыз?

— Юк анда задвижка, колонна төбеннән өзелгән... Күрмисезмени?

Оператор дегет-нефтькә батып беткән куллары белән бер як читтә яткан «елочка»га күрсәтте. Сәхаб операторларга нәфрәт тулы күзләрен акайтып карады да:

— Кисегез агач, трубасына бөке кагабыз! — дип боерды.

— Бирегә йөз утыз атмосфера басым!

— Ә ничек туктатмакчысыз соң?!

— Алла белсен. Хәзер начальство килә...

— Бирегез агач башы кисеп, бирегез кувалда, үзем кагам!..

— Абый кеше, сез анда ничек кермәкче буласыз?

— Керәм! Бирегез, ясагыз бөке!!

Операторның берсе будкага йөгерде.

— Ничә дюймлы труба колоннада? — Сәхаб трубаларны яхшы белә иде, ферма абзарлары төзегәндә күп эшләде аларны.

— Дүрт булырга тиеш!..

— Нигә дүрт түгел. Ник төгәл белмисең?!

Сәхаб чигә чәче агара башлаган, үз яшьләрендәге кешегә авыр йодрыгын күтәрде.

— Акча алырга яратасыз... Ә үзең эшләгән техниканы белмисен, сволочь!

Оператор моны көтмәгән иде, тәпен-тәпен артка чигеп, китә башлады.

— Тукта! Китмә, бер кая да китмә! Янсак бергә янарбыз!..

Ул арада яшь оператор килеп житте. Сәхаб аның кулыннан бөкене алып әйләндереп карады да кувалданы агайга сузды.

— Мә! Мин тотармын, сез кагарсыз!

— Нефтькә батып үләрсез, кермәгез,— диде яшь оператор.

— Молчать!..— Сәхаб күкле-яшелле тавыш чыгарып яшь операторга кычкырды һәм өлкәненә команда бирде: — Әйдә!!

Скважинага якынайган саен, җир астыннан үкереп чыккан нефть көчәя барды. Сәхаб, җил ягына чыгып, гайрәт белән су катыш нефть ургылган колонна янына якынлашты. Өстенә нефть яңгыры коя, битебашы буйлап та шул кара нәрсә агыла.

«Күзгә генә кермәсен, томалыйм да томалыйм»,— дип, адым саен колоннага якынлашты Сәхаб. Ниһаять, ул килеп җитте һәм агач бөкене иплән кенә колоннага таба юнәлтә башлады. Ләкин колонна башы торба сынганда җәйпәкләнгән булып чыкты. Бөке сыярлык түгел иде. Сәхаб, ярылып булса да керер әле дип, бөкене тиз генә колонна өстенә куйды. Ләкин шунда ук нефть дулкыны аны кулдан суырып алды һәм фонтанга нәртеп алып китте. Сәхабның өстенә нефть коелды, ул, аягы батып, артка утырды.

— Назад! — дип кычкырды өлкән оператор. Сәхаб тиз генә мүкәләп торды да, дүрт аяклап бераз баргач, аягүрә басып читкә йөгерде.

Ул чыкканда скважина тирәсенә халык җыелган, тирә-якка янгын машиналары, агрегатлар, бульдозерлар килеп туктаган иде.

Сәхабны һәм өлкән операторны, авыз да ачарга бирмичә, машина белән авылга алып киттеләр.

Сәхаб, өстен алыштырып, ашык-пошык юынды да газигына утырып райүзәккә чапты. Нефть идарәсе бинасы каршына көпчәкләр астыннан ут чыгарып килеп туктавы булды, йозактан ачкычны да алмыйча, машинасыннан сикереп төште. Атылып икенче катка, Ходайбирдиң кабинетына йөгерде. «Сугам да үтерәм, башым Себер китсә китәр»,— дип уйлады Сәхаб, йомшак креслода тәмәке тартып утыручы Ходайбирдинны күз алдына китереп.

Секретарь хатын аны кертмәскә итте, каршы төште, аның эше бар дигән булды, ләкин Сәхаб аны бер якка җилтерәтеп кенә җибәрде.

Ходайбирдин чынлап та күн креслога чумып, тәмәке тартып утыра иде. Сәхаб килеп керү белән үк аңа тыныч кыяфәттә күтәрелеп кара-

ды да алдында торган Дон-Кихот статуясына сигаретыннан көл сала башлады.

— Ни йомыш, иптәш Кадыйров? Тагын труба кирәкме?

Сәхабның, колхозга хаҗәте чыгып, идарәдән иске торбалар алганы бар иде. Аларның яртысы эшкә ярамады. Шул турыда ул Ходайбирдингә шалтыраткач, тегесе: «Шуның өчен бит ярты бәягә саттык»,— дип аңлаткан булды.

Анысы — үткән эш. Менә бүген исә, нефть түгелүгә эче янып, утка баскан мәчедәй кая барырга, кемнән ачуын алырга дип өтәләнеп йөргәндә, Ходайбирдинның һични булмаган кебек әллә кайчангы торбалар турында мыскыл иткән, үртәгән сыман сорап куюы, әйтерсең, Сәхабның үтен сытты, җен ачуларын чыгарды.

Сәхаб, ачуы ташуга тыела алмыйча, йодрыкларын буыннары агарганчы йомарлап, Ходайбирдин өстенә таба килә башлады.

Ходайбирдин авария турында ишеткән иде, ләкин председатель үзе килеп керердәй фаҗига-афәт булгандыр дип күз алдына да китермәде. Шуңа күрә авария булган җиргә баш инженерын гына җибәргән иде. Әмма күзләрен алаландырып үзенә таба килүче Сәхабны күргәч, эшнең уеннан узуын чамалап алды һәм председательне тынычландырырга теләп:

— Сәхаб Вәлиевич,— дип аваз салган иде, председатель, әйтерсең, аны ишетмәде дә, киерелеп өстәлгә сукты: Дон-Кихот сынлы тәмәке савыты авып идәнгә очты, Ходайбирдин чәчрәп торып басты.

— Скважинагыз шартлаган!.. Бөтен басуны нефть баса, ә сез тәмәке тартып тынычланып утырасыз... Оят түгелме?!.— дип җикерде Сәхаб ачулы тавыш белән.

Ходайбирдин «оят» дип әйтергә тел кутәрмәде.

— Минем анда баш инженерым китте,— диде ул, гайрәтләнеп.

Сәхаб, яңак сеңерләрен уйната-хәрәкәтләндерә, бармак буыннары агарып чыкканчы өстәл читенә ябышты һәм Ходайбирдинга нелә төшеп:

— Беләсезме, Ходайбирдин, бу юлы мин сезне нишләтәм?.. Судка бирәм! Партиядән кудыртам!.. Ишетәсезме, партиядән!..

Вәкилнең ак чырае күгәреп, зәңгәрләнеп киткәндәй булды. Ул сул кулы белән өстәл янындагы кнопканы эзләде, әмма калтыранган бармаклары гел басарга гадәтләнгән төймәне тапмады. Ходайбирдинның калтырый-кабалана кнопка эзләвен күреп, Сәхаб айнып киткәндәй булды, кинәт борылып, ике якка ачылышлы сары күн белән тышланган ишеккә таба китте. Ишекне ул шулкадәр каты итеп япты,— хәтта ачык тәрәзәнең бер күзе ватылып урамга очты.

Вәкил асфальтка төшкән пыяланың чылтырап ватылуын ап-ачык ишетте. Һәм, мәсьәләнең җитди төс алганын хәзер генә аңлагандай, аварияне үз күзе белән барып күрергә булды...

Машинасына утырды да, поселокны чыгу белән, тизлек стрелкасын йөздә тотып, авария булган төшкә куды. Бер машина артыннан икенчесен узды. Алда үзбушаткыч ЯАЗ бара иде, аны узарга ташланды. Ләкин рульне сулга алуы булды, алгы пыялага нидер килеп бәрелде. Ходайбирдинның күзләреннән ут очты һәм ул механик рәвештә тормоз педаленә басты. Әнә шуннан соң ул больницага эләкте...

Булган хәл белән якыннан танышу өчен Бакир колхозга үзе килде. Сәхаб, нәкъ шуны көткән кебек, кабинетында утыра иде. Бакир авария турында йомшартыбрак сөйли башлагач, председатель:

— Мин сезнең үгетегезне, Бакир Әхтәмович, хөрмәт йөзеннән генә тыңладым. Бюрога мин дәгъва язып бирдем, ә аны тикшерү сезнең эш. Аннары мин үзем дә бюро члены бит, әйтик, мин үзем дә бу турыда ниндидер тәкъдим әйтә алам,— дип аны бүлдерде.

— Сез дөресен әйтәсез, иптәш Кадыйров. Ләкин әле бит эш өсте. Икмәкне ике ярым нормага якын итеп сату алдында торабыз, бәрәңге килеп керәлде...

— Ходайбирдин бәрәңге алмый һәм икмәк тапшырмый. Мин аңардан гарык булганга моны эшлим, Бакир Әхтәмович.— Сәхаб кулы белән муенын кисеп күрсәтте.— Менә ничек гарык ул кешедән. Мин бит моны шәхсән аңа үч тоту йөзеннән эшләмим. Киләчәккә акыл булмасмы дим. Техника куркынычсызлыгы турында бармакка бармак тигерми. Сүзендә тормый. Яз көне дуңгызлар фермасына нефть җибәргәч ни әйткән иде?! Хәер, сез юк идегез.— Кадыйров Бакирга таба иелә төште.— Утыз ике баш дуңгызны үтерде... Ит заданиесен башка терлек хисабына тутырырга туры килде. Ун гектар чәчү җирен пычратты, бер саман абзарны җимерде. Яхшы абзар, шифер белән япкан җылы абзар иде. Менә хәзер тагын... Бер елда бит, бер елда шул тикле зыян!..

— Сез, Сәхаб Вәлиевич, Ходайбирдинның да дәүләт эшен башкаруын онытмагыз. Минемчә, бу мәсьәләдә бер ул гына гаепле түгел. Техника ватылмый, җимерелми тормый, әлегә бездә мәңгелек бернәрсә дә юк.

Кадыйровка секретарьның бу киңәше янә ошамады, ул күзен-кашын җимерде, йөзенә ачу бәреп чыкты.

— Ә бит мин сезне бу мәсьәләдә объектив килерсез дип уйлаган идем, Бакир Әхтәмович...— Сәхаб, торып, кабинет буйлап йөреп китте.

— Ул больницада ята, авариягә эләккән,— диде Бакир тыенкы гына.

Кадыйров туктап калды, бер тын секретарьга карап торды, аннары аның янәшәсенә утырды да:

— Мин аны үлсә дә кызганмас идем, билләһи, кызганмас идем.— диде.

— Нигә ул кадәр мәрхәмәтсезлек?..

Сәхаб тынычлана төште, секретарьның сүзләре аңа тәэсир итте, күрәсең, ул идәнгә текәлеп:

— Авариягә эләгүе чын булса, әйбәт түгел, әлбәттә. Мин аны кичә нык кыздырдым. Әле булса да үз-үземә аптырыйм, ничек сукмадым мин аңа шунда?!. Ничек тыелып калдым?!.

— Әйе, мәсьәләне бюрода карамый булмас. Чөнки эшнең чынлап та зурга китүе бар...

— Бик һәйбәт булыр. Берләшмәдән дә кешеләр чакырырбыз. Хәер, аларның хаҗәте дә булмас дип уйлыйм, чөнки Ходайбирдинның кем икәнен беләләр... Менә бит, Бакир Әхтәмович, бер чик куелырга тиештер, әһ?!.

— Бик тиеш, бик тиеш, тик без моңа әзерме? Техник хәзерлек җитәрлекме?

— Җитәрлек. Теләгән кешегә, җир кадерен, табигать кадерен белгән кешегә бик җитәрлек!..

Председатель булмасенә яшь кенә агроном килеп керде.

— Әйдә, әйдә, Рәхим. Нәкъ син кирәк идең безгә. Нефтьчеләр күрсәткән зыяннарны Бакир абыеңа укы әле. Синдә аның барысы да бар.

Рәхим түргә үтте, кесәсеннән иләп кенә блокнот чыгарды. Агрономның йөзе кояшта йөреп тутланып беткән, кара кашлары саргаеп калган иде. «Кадрларны үстерә белә бу Сәхаб», дип уйлап алды Бакир. Ул агрономның ике ел элек колхозда шофер булып эшләвен, хәзер читтән торып авыл хуҗалыгы институтында укуын бирегә килгәндә Фоат теленнән ишеткән иде.

— 1965 елда ун гектар бодай басуы таптатылды, аннан гектарыннан унтугыз центнер уңыш алырга планлаштырылган иде. 1966 елда, җир

нык тапталу сәбәпле, ул участокны ике тапкыр сөреп, культивацияләргә туры килде. Тракторчыларга өстәмә түстә мең сумга якын хезмәт хакы түләнде. 1967 елда җир бозулар азрак булды, аның каравы, инешкә нефть җибәреп, терлекләрне сусыз калдырдылар. Кое бораулатырга туры килде. Һәм аңа ике мең сумнан артык чыгым тотылды. Үткән елгы эшләр аннан да хәтәррәк. Безнең басуларга биш меңгә якын тонна нефть акты. Шуның өстенә ун гектарны идарә бүтән төштә юк итте. Әлбәттә, моңа күмелмәгән канаулар да керә. Күмелгән хәлдә дә өскә ташлы сары балчык өеп китәләр. Бу җирләрдән, кагыйдә буларак, унунбиш ел уңыш алынмый диярлек. Быел менә дуңгызлар үлде, бер абзар җимертелде. Кыскасы, үткән елда нефть идарәсе бер безнең колхозга гына егерме биш мең сумлык зыян китерде. Шуңардан, гаепне үз өсләренә алып, җиде мең сумын түләргә мәҗбүр булдылар.— Агроном, председательгә мөрәҗәгать итеп: — Күл, балыклар турында сөйләргәме? — диде.

Кадыйров аңа туктарга кушып кулын күтәрде.

— Җитеп торыр, алары калып торсын.— Һәм Бакирга борылып: — Менә күрәсезме, кая таба китте безнең конфликт, Бакир Әхтәмович. Мин күрә алмыйм ул Ходайбирдинны. Балык башыннан чери, җитәкче буларак ул үзе гаепле моңа,— диде.

Бакир кайтыр юлга чыккач та бик озак тынычлана алмады. Ул икесе дә бюро члены булган кешеләр арасындагы конфликтның шәхси мөнәсәбәтләргә бәйле булмавын яхшы белә иде. Шуңа аның бераз эче поша. Конфликтны районнан читкә чыгармаска да телидер бәлки. Фоат та, секретарьның кәефе кырылуын күреп, сөйләшмәде, җилне узып китәргә теләгәндәй, гел йөз белән куды. Вакыт соң иде инде. Бакир райкомга кермәде, Фоатка турыга гостиницага барырга кушты. Кайткач, буфетта тамак ялгап алды да пижамын киеп диванга сузылды.

Бакир икмәк турында уйлап ята-ята этисен искә төшерде һәм аны кай ягы беләндер Сәхабка охшатты.

Колхозлашу чоры. Әтисе председатель булган чак. Ул күрше авылларга барып та чәчүлек җыярга булышып йөрде. Бер төнне, ишекне ватып, өйгә кешеләр килеп тулды. Әтисе аларга балта белән ташланган иде, бөтереп алып, кул-аягын бәйләп, авызына яулык тыктылар. Әнисе, өнсез калып, кулакларның алларына тезләнде, алла хакы өчен исән калдыруларын сорады. Кайсыдыр аның күкрәгенә типте. Шунда мич башында утырган Бакир чырыйлап аваз салды. Аны мич башыннан сөйрәп төшерделәр. Әтисеннән, бертуктаусыз даулап, колхозның келәт ачкычларын, ниндидер язулар таптырдылар. Әйтмәгәч, кыйнадылар, типкәләделәр, өй бетереп нәрсәдер эзләделәр. Ахырда, әтисеннән бер кәлимә сүз ала алмагач, аларның өчесен дә Ык буена алып төштеләр. Берсе әтисенең башына мылтык түтәсе белән сукты, икенчесе, муенына гер ташы бәйләп, аны яр читенә китерде. Әтисе аңын югалткан иде инде, күрәсең, ни сорасалар да сүз әйтерлеге калмаган иде.

Шунда Бакир әтисенә ташланды, аны берәүсе эләктереп алды, зур йодрыгы белән башына сукты. Бакир аңын җуйды. Ә аңына килгәндә арбада бара иде инде. Мичәүле атлар чаба-юрта Аю чокырын меңәләр. Бакирга бу чокыр таныш. Берсе шунда:

— Ташлыйк шунда бу этен дә, атларга гына авыр,— диде.

— Тибеп төшер! — дип боерды икенчесе.

...Бакир сискәнеп китте. Гүя хәзер дә кемдер аның аркасына тибә иде.

Аннары ни булды соң әле? Әйе, Бакир авыртуга иренен тешләп түзде. Әмма җиргә төшкәч тә сикереп тормады, кычкырмады. Тик кулаклар күздән югалгач кына Аю чокырына йөгерде. Чокырга төшкәндә

өч-дүрт тапкыр тәгәрәп китте. Үзе елады, үзе әнисен чакырды. Озак эзләде, тапмады. Чокырны тоныкык кына яктырткан ай Күктәкә атавы артына кереп югалды. Бакир тавышы беткәнче, тамагы карлыкканчы кычкырды да кычкырды:

— Инәй, инәкәй!..

Таң атты. Шунда Бакир, хәле-өнә бетеп, бер каен төбенә утырды. Кояш чыкты. Бакир тагын чокыр төбенә төште. Төште һәм коты алынып кычкырып җибәрде. Аның әнисе ике кушкаен төбендә анадан тума шәрә ята, өстендәге күлмәк-ыштаннары умырылып, телгәләнеп ташланган.

— Инәй!..

Бакир әнисен күтәрергә маташты, ахырда селеккәләргә тотынды.

— Инәй, инәкәй!..

Әнисе күзләрен ачты, кан саркып, кипшереп, чатнап яргаланып беткән иреннәрен ялады.

— Су, су бир, улым...

Бакир, атыла-каплана, чокыр төбендәге чишмәгә йөгерде. Кушучына алып, калтыранган куллары белән әнисенең авызына салкын чишмә суы койды. Бераздан әнисе аңына килде һәм, ертык күлмәкләрен учлап тотып, коты алынып үзенә карап торган Бакирдан:

— Атаң кая? — дип сорады.

Бакир бер сүз дәшә алмады, үксеп, әнисенең күкрәгенә капланды.

Әнисе кулакларны хөкем иткәндә Бакирны да алып барды.

Дошманга тиешлесе бирелде: өчесен атарга хөкем чыгардылар, калганнарына унбишәр ел сөрген.

Менә нинди бәягә төште алар семьясына колхоз икмәге!..

Бакирның моны мәңге онытасы юк...

Ни әйтсәң дә, Сәхаб бик хаклы, әлбәттә. Әмма Ходайбирдин да начар кеше түгел. Идарәсе Союзда беренче урында тора. Ниғәдер ана да җил тидерәсе килми.

Шулай уйланып ята торгач, ахырда Бакир бу мәсьәләне Мөршидә кайтканчы карамаска булды. Ул бу өлкәне, бу кешеләрне яхшырак белә, объектив килеп, тиешле киңәш бирер. Бәлкем, ул Сәхаб белән уртак тел табар дигән фикергә килде.

Аннары ул караватына сузылып ятты да, йон юрганны башыннан ук бөркәнеп, күзләрен йомды. Шунсыз йоклый алмый иде ул.

Промышленность предприятиеләренә дә чыгып йөрүләр башланды. Пычратылган ужымны тагын бер тапкыр күрү нияте белән, Бакир райкомның промышленность бүлеге мөдире Воронцовны, Исмәгыйловны, комсомол башлыгы Беляевны үзе белән алырга булды.

Көн җылы, күк йөзе аяз, кояшлы көньяктан йомшак җил исә, күктә адашып йөргән сирәк-мирәк кысыр болытлар гына күренә.

«Волга» Чатыр тавының сыртын кисеп чыккан асфальт юлдан үр менә башлады.

Бакир машина көзгесеннән Воронцовның арыган йөзен, ярым йомык күзләрен күреп: «Әллә йоклап барамы, тагын?» — дип уйлап алды. Воронцовны ул әле бик якыннан белми иде. Семьялы, хатыны — укытучы, диделәр. Өч баласы бар, җитмәсә берсеннән-берсе кечкенәләр икән. Күрәсең, Воронцовка йокы аз тия, бәлки шуңа юлда йоклап бара-дыр. Хатыны — укытуда, кич белән дәфтәрләр тикшерә, иртәгесе дәрескә план төзи, ә Воронцов балалар белән мәш килә: юындыра, коендыра, йокларга сала, экият сөйли. Аннары иртән иртүк киендерә дә берсен нәртеп, икенчесен күтәреп, бакчага чаба булыр. Хатын исә беренче баласы белән мәктәпкә китә. Кыендыр Воронцовка.

Бакир аның ике кулына ике баласын күтәреп бакчага барганын күргән иде. Воронцов аларга нидер сөйли-сөйли ашыга-кабалана атлый. Бакирны күргәч, оялып китте. Чөнки сәгать сигез тулып килә иде инде, ә аның балаларны илтәсе, тапшырасы бар әле. Шул көнне ул сигез тулып дүрт минут киткәндә генә, плащен җилбәгәй җибәреп, эшкә килеп керде.

— Һаман болай йөрсәгез, Василий Иванович, бик кыен булыр бит сезгә. Өйдән иртәрәк чыгарга кирәклеге күренеп тора,— диде аңа Бакир ничектер сизелмәс ягымлылык белән елмаеп.

Әйе, мәшәкатьле яши Воронцов.

Бакир янә уйга калды. Үзенең шәхси тормышын Воронцовныкы белән чагыштырып карады. Аларда һәрвакыт тыныч иде, шылт иткән артык тавыш булмас. Иртәнге якта да кабаланып эшкә җыенучы юк. Ләкин бу бәхетме? Гомумән, кеше үз бәхетен нәрсәдә күрергә тиеш соң? Әйтик, бәхетле яшиме ул Әминәсе белән?.. Бәлкем, зур бәхет дигәнең, кич семья җыелып беткәч, балаларны аркаңа атландырып, өстәлнеураудыр? Аларның таралып йоклауларына карап, минем бит менә шундый дәвамым бар дип шатланудадыр?

Бакирның башына әнә шундый уйлар килдеме, хәтер күгенә Казандагы Мөршидә килеп баса, аның баласы барлыгын хәбәр итүче Әлмәт дусты Локман исенә төшә иде.

Юл, кисәк борылып, урман эченә кереп китте. Кара асфальт тасманың очына тизрәк җитәргә теләгәндәй, «Волга» ике яклап калын дивар булып үскән агачлар арасыннан кош кебек очып бара башлады.

Нинди гүзәллек! Никадәр мул яшеллек безнең якларда! Әйтерсең, табигать бирегә бөтен дөнья хозурлыгын җыйган. Әнә карт имән кәперәеп утыра, әнә сылу каен еламсый, әнә ямь-яшел усак үз сынына үзе сокланып утыра, әнә мәңге яшел мәһабәт наратлар, әнә кытай җилпәзәседәй ябалдашларын җәйгән юкә, карама, чикләвек агачлары торалар, әнә хаста даруы — миләш — кызгылт-сары тәлгәшләрен юл ягына салындырган, әрсез шомырт исә аның аша үрелгән; шулар белән янәшә җете кызыл учмаларын тирә-якка сибеп балан утыра...

Бакир күз карашын алдагы көзгегә юнәлтте. Воронцов белән янәшә — райкомолның беренче секретаре Рифкать Беляев. Ул ниндидер китап укый. Шунсыз булмый, информация чоры — һәр минуттан нәтиҗәле файдаланырга кирәк.

Исмәгыйлов тәрәзәгә караган килеш уйга калган.

Ә монысы ни турында уйлый икән? Күптән түгел хатыны тапкан игезәк малайлары турындамы әллә? Төпле, акыллы, зирәк инструктор. Авыл хуҗалыгын әйбәт белә. Хәтта бик яхшы. Райком инструкторларын Исмәгыйлов кебекләрдән тупласаң иде. Кадрлар — менә кемнәр хәл итә эштә уңышны. Кадрлар сайлау — зур нәрсә. Ә мин биредә аларны яхшы беләмме әле? Әйтик, менә бу Фоат. Кайда укый диген син аны — университетта, юрист булмакчы. Киләсе елга диплом якларга тиеш. Ни беләм мин үз шоферым турында? Әйе, кеше ул — ачылмаган планета, табылмаган элемент.

Алда, калкурак бер җирдә, промысел бинасы күренде. Бина түбәсендә — телеантенналар, ниндидер тәлинкә сыман ялтыравык түгәрәкләр. Якында гына меңәр тонна нефть сыйдырышлы өч чан тора. Алар ап-ак алюмин төсенә буялган, шуңамы — тирә-юньгә ниндидер бертөрле мәһабәт ямь биреп торалар. Бер чанның өстендә кызыл яулык бәйләгән хатын-кыз йөри. Чаннар тирәли биек итеп балчык өеме өелгән, аннан ун метр читтәрәк исә яшь тирәкләр үсә.

— Монда туктыйбызмы, иптәш Воронцов? — дип сорады Бакир артка таба әйләнми генә. Ул Василий Ивановичны шофер көзгесеннән күреп бара иде.

— Минемчә, бирегә туктамаска да мөмкин, монда комиссия килергә

тиеш иде,— диде Воронцов ярым йомык күзләрен күтәрмичә, гүя бу промысел аны бөтенләй кызыксындырмый иде.

— Кереп чыгарга кирәк,— дип, Бакир Әхәткә карады.

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде Әхәт.

Диспетчерлык идарәсе дә, контора да, промыселның геология службасы да урнашкан ике катлы бина янына райком «Волга»сы килеп туктауга, тәрәзәләрдә хатын-кыз йөзләре күренде. Бакир, Әхәт, Воронцов, алар артыннан Рифкать, машинадан төшеп, туп-туры ачык ишеккә таба киттеләр. Ишеккә җитәрәк Воронцов алгарак чыкты һәм ишек янында туктап,ниндидер белдерү укый башлады.

— Бүген җыелышлары була. Комиссия килү очрагы беләндер инде...

Әхәткә Василий Ивановичның озын сөйләве ошамады, ул кырт кына:

— Иптәш Воронцов, тоткарламагызчы безне, вакыт тар,— диде.

Воронцов, Әхәтнең бу сүзләрен ни дип юрарга да белмичә, тизрәк бина эченә ашыкты.

Промыселга комиссия килеп җитмәгән булып чыкты. Әмма аны көтәләр, конторда, өлкән инженер кабинетында, участок начальниклары, мастерлар, берничә оператор утыра иде.

Бакир кызлар кебек чибәр йөзле өлкән инженердан авариянең сәбәбен сораштырып торды. Инженер, күзлеген төзәтеп, имән бармагы белән чигәсен кашып бер тын уйланып утыргач:

— Минемчә, авторитетлы комиссия бу мәсьәләне җентекләп тикшерер, ә минем бәям субъектив булуы бар. Ник дисәң, авария безнең участокларның берсендә, коммунистик хезмәт участогы исемен йөрткән коллективта булды. Күрәсез, мәсьәлә җитди, бер сүз белән генә җавап биреп булмый,— диде.

Янәшә утырган Воронцов аның җиңенә кагылып алды. Инженер, бераз борылып, аңа күз кырые белән генә карады да:

— Гомумән, ачыклыйсы мәсьәләләр күп әле. Аннары, бу минем шәхси фикерем, әллә ни күп ужым әрәм булмаган анда, минемчә...— дип куйды.

— Ә сез җирне күрдегезме соң?.. Авариядән соң булдыгызмы?

Инженер Воронцовка һәм кабинеттагыларга күз йөртеп чыкты. Аның бу карашы: минем аннан кайтканым бармы, иптәш беренче секретарь? ди иде кебек.

— Мин анда һәр көн диярлек булам. Скважинаның бер атна авариядә торуы безгә шактый зыян китерде,— диде ул, сүрән генә.

— Сезгә генә түгел, колхозга да,— диде Бакир һәм тора башлады. Монда вакыт үткәрүнең мәгънәсе юк иде, аның участокларны, башка промыселларны күрәсе бар бит әле.

Бакирның авария участогында кәефе нык кына кырылса да, соңгы ике промыселда чисталык, пөхтәлек күреп, бераз күңеле күтәрелде, һәм юлда ул бер фикергә килде: коммунистик хезмәт коллективына лаек булу өчен нефтьчеләргә бик күп хезмәт салырга кирәктер, бәхәссез. Инде нинди дә булса коллективка бу югары исем бирелгән икән, ул башкалар өчен өлге булырга тиеш. Авария булган участок коллективына зур исемне биргәннәр, ә анда эшләр башка коллективлар белән чагыштырганда әллә ни шәп түгел диярлек. Скважина тирәләре пычрак, станоклар буялмаган, күп кенә скважина яннарында аккан нефтьне җыярга чокырлар ясалмаган. Бу коллективка ни өчен югары исем бирелгән?.. Воронцов, даими төстә планны үтәгәне һәм меңнәрчә тонна өстәмә нефть чыгарганы өчен бирелде, дип бара. Элек бу участокта алай түгел иде, ди. Ни өчен элек алай булмаган да хәзер алай? Димәк, коллектив исем ышыгына качып яшәү юлына баскан. Кем аларны даими тикшерергә, ялгышларын төзәтеп, дөрес юлга төшерергә тиеш? Без, без! Участокта дүрт-биш коммунист, комсомолец бар. Алар ни

караган? Подгруппалар сүлпән эшлиләр. Һәр участокта, бригадада шуларның эшен яхшыртырга кирәк. Минә шуны йөкләргә тиеш мин Воронцовка. Атна саен, өч көн саен, көн саен очрашып сөйләшсеннәр, кимчелекләрне күреп, белеп, партоешмага, парткомга, райкомга, промышленность бүлегенә, минә җиткерсеннәр. Барысын да түгел, җитди мәсьәләләрне. Ә без аны тиз генә хәл итәргә тырышырбыз. Элемтә, иң кечкенә звенодан алып, райкомга кадәр ныклы элемтә булдырырга...

Күп йөреп, арып-алҗып кайтса да, Бакир, бераз ял итеп алгач, Эминәсенә хат язарга утырды. Утырды, әмма башлар сүз таба алмады. Нигәдер күңел теләми иде. Нигә булыр? Ул үз-үзенә нык ышанып, киң колач белән җәелеп эшләп киттеме соң әле? Биредәге эшнең очы-кырые бармы?.. Нигә очы юк? Районда промышленность предприятиеләре булгангамы?.. Алай дисәң, промышленность бүлеген алып баручы икенче секретарь бар. Әйтеп булмый, җаваплылык беренче секретарьдан да алынмый. Мөршидә юк бүген, минә кем җитми икән Бакирга. Тиздән ул кайтачак һәм барысы да үз сукмагына, үз юлына төшәр.

Ике кулын баш астына куеп — ул һәрчак шулай уйланырга ярата иде — түшәмгә карап ятканда әнә шул турыда уйлады Бакир. Бу бүлмәгә ул бик соң кайта һәм берүзе калгач тынычлап уйлана, иртәгесе көнгә планнар кора иде.

Комиссия нәтиҗә ясауга һәм бюрога материаллар әзер булуга карамастан, Бакир бюроны һәркөн кичектерә килде. Сәхаб очрашкан саен аның исенә төшерә торды. Ә бер көнне иртән иртүк райкомга килде дә беренче булып Бакир янына керде:

— Тимерне кызуында сугасы иде бит, Бакир Әхтәмович,— диде, әнә шул бюроны искә төшереп.

— Бераз сабыр итик, Сәхаб Вәлиевич. Икмәк тапшыру тәгәлләнсен, кукурузны силослап тәмамлыйк, аннары карарбыз. Тагын бер атна түзеп булырдыр бит?

— Бер атнага мөмкин, шуннан соң да булмаса обкомга язам,— диде Сәхаб авыз чите белән елмаеп.

«Арырак язсагыз да була. Кем язалмый аны»,— дип әйтәсе килде Бакирның каны кыза барган председательгә, әмма әйтмәде.

— Бер атнадан соң, Сәхаб Вәлиевич,— дип кенә кабатлады.

Сөт савуда Сәхаб җитәкчелек иткән колхоз районда беренче урында бара, сүз әйтерлек түгел иде, шулай да яхшылыкны онытмадылармы икән дип, Бакир председательгә клапаннар турында искәртеп алды.

— Ферма мөдирегез клапаннар алып кайттымы? Кем әле ул?..

— Габдулла абзый,— диде Сәхаб һәм, чыраендагы тирән җыерчыклары җәелеп, аның йөзенә елмаю чыкты.— Клапаннар өчен рәхмәт. Тәэминатчы булырлыгыгыз бар икән,— дип өстәде Сәхаб.

«Шунда да кинаясез әйтми калмый»,— дип уйлап алды Бакир, Сәхаб иреннәрендә тагын елмаю күреп.

Сәхаб беренче секретарьга зур эш белән килгән иде. Колхоз дәүләткә икмәк сатуны ике нормадан да арттырып җибәрде. Исәп-чамасы — арткан ашлыкны фуражга калдыру иде. Шуны секретарь белән киңәшмәкче, аның уй-ниятен белмәкче иде. Ләкин әйтергә өлгерә алмый калды, кабинетка рөхсәтсез-нисез Воронцов килеп керде.

— Гафу итегез, Бакир Әхтәмович, Сәхаб Вәлиевич. Хәерле иртә!

Ул икесе белән дә кул биреп күрешә дә Бакирга мөрәҗәгать итеп:

— Ходайбирдин унбиш көнгә ялга китә, Бакир Әхтәмович, нишлибез? — диде.

Бакир өчен бу яңалык түгел иде, Ходайбирдин аңа моннан ике көн элек үк бу турыда әйтте. Ә менә Сәхаб өчен бу һичшиксез яңалык иде. Шуна күрәме, «Ленин юлы» колхозының председателе бу сүзне ишетү

белән урыныннан тормакчы итте, ләкин, секретарьның Воронцов белән сүзе бетмәвен күреп, кире утырды һәм, калтыраган бармакларын кая куярга белмичә гасабиланып, Воронцовның сүзе беткәнен көтә башлады.

Воронцов чыгып киткәч, Сәхаб белән Бакир икәүдән-икәү генә калдылар. Сәхаб беравык дәшми утырды, күрәсең, әчерәк, үткенрәк сүз эзли иде. Бакир кичәге сводкаларны караштыра башлады, газета битенә күз төшерде.

— Таярга маташа, сволочь,— диде Сәхаб, капыл гына кузгалып.— басуга нефть агызды да качып котылмакчы. Җибәрмәгез бюро үтмичә, Бакир Әхтәмович. Хакы юк. Коммунист, бюро члены... Хакы юк аның китәргә!..

Бакир Сәхабтан нәкъ шуны көткән кебек кәгазьләр актаруында булды. Аннары бөтен нәрсәсен читкә этәреп:

— Аның сәламәтлеге шәптән түгел, Сәхаб Вәлиевич, әйдә китә бирсен. Моның белән Ходайбирдин өстеннән җаваплылык төшми бит, шулаймы?.. Юк бит? Ә врачлар аңа дәваланырга кушалар, юкса күзен сукырая, дип справка биргәннәр,— диде.

Сәхаб, янә ирен чите белән елмаеп, утырган урынында борсаланып алды.

— Хатыны күз врачы бит, Бакир Әхтәмович! Нигә сез ул сорнайны, дәүләт корткычын яклыйсыз, мин әнә шуны аңламыйм... Справканы аңа үз хатыны язып биргән ләбаса!..

— Ләкин ул коммунист, бюро члены. Сез дә коммунист һәм бюро члены. Авырмаган хәлдә сез шуңа барыр идегезме, Сәхаб Вәлиевич?

Председатель шап итеп урындык башына сугып алды.

— Ярый. Калдырыйк Ходайбирдинны, ягъни Ходай сукканны. Туйдырды ул, гарык мин аннан... Минем киңәш бар иде сезгә, Бакир Әхтәмович.

— Менә монысы башка мәсьәлә,— диде Бакир елмаеп, кулындагы ручканы читкә куйды.

— Эш моннан гыйбарәт. Без, сводкадан күренгәнчә, дәүләт амбарларына ике нормадан артык икмәк озаттык. Менә шул. Кичә идарә членнары белән киңәштек тә арткан икмәкне фуражга калдырырга булдык. Ягъни хөкүмәткә икмәк сатуны туктатырга исәп...

Бакир бермәл эндәшми утырды. Ул уйлады. Сәхаб житәкчелек иткән колхоз районда иң алдынгы хуҗалыклардан берсе. Ул икмәк сатуны туктатса, райондагы барлык колхозлар да шуны эшләячәк. Ә икмәк сатуны планга караганда кимендә ике ярым нормага җиткерәсе иде. Күрше районнар кебек. Мондый уңышны һәр елда алып булмас. Аннары мин яңа кеше, һәм мин житәкчелек иткән район ашлыкны шул ук зонадагы башка районнардан ким сатсынмы! Димәк, ашлык тапшыру дәвам итәргә тиеш. Башкача мөмкин түгел.

— Сәхаб Вәлиевич, сезнең колхоз уңышны гектарыннан егерме биш центнер җыеп алды, ә калган колхозлар унтугыз-егермедән дә арттыра алмадылар. Алар бит ашлык сатуны дәвам иттерәләр. Дөрес, терлекләргә фураж, әлбәттә, кирәк. Ләкин бит аны колхоз озаткан ашлык хисабына дәүләттән комбикорма итеп тә алып була. Сез беләсез, Союзның күп кенә өлкәләрендә корылык булды. Әнә сездән пресслап салам алып китәләр. Дәүләткүләм күзлектән караганда, минемчә, сезнең сатасы ашлыгыгыз бар әле...

Бакир, үзенең сүзләре колхоз председателенә ничегрәк тәэсир итте икән дип, бер тын аңа карап торды. Сәхаб җавап бирмәде, башын иеп, күзен-кашын җимереп утыра бирде.

Ниһаять, ул башын күтәрде, туп-туры текәлеп секретарьга карады.

— Үткән елда, авариягә эләгеп үлгәнче, мәрхүм Садыйков нәкъ шул сүзләрне сөйләгән иде, инде быел сез,— дип дәвам итте Сәхаб.— Ба-

хыр, безнең фуражга дигән ашлыкны саттырып, колхозның сөт планын өзүгә илтә язды. Соңыннан бюрога чакырып бик орышмакчы итте, юк, орыша алмады. Чөнки гаеп үзендә дә бар. Менә хәзер дә артельнең терлекчелектә рентабельлеге юк. Бу каян килә дип уйлыйсыз, Бакир Әхтәмович? Малкайларга ашау такы-токы булганга, он-фураж, бөртек ашлыгы күрмәгәнгә шулай ул. Салам да кукуруз белән генә сөт алып булмый бит...

— Җитте! — Бакир уч төбе белән шап иттереп көзге кебек ялтырап торган өстәлгә сукты.— Җитте, Сәхаб Вәлиевич. Әүвәл ашлыкны ике ярым норма итеп тапшырыгыз, аннары фураж турында сөйләшербез. Халыкара хәлләрнең ничек куерганын беләсез. Аннары бераз запаслы да булырга кирәктер дип уйлыйм мин. Кирәкме, юкмы?!.

Сәхаб торып басты.

— Димәк, безнең фикерләр кисеште, Бакир Әхтәмович?..

— Ашлык сатуны дәвам иттерергә кирәк, Сәхаб Вәлиевич,— диде Бакир, тыныч кына.

Янә Сәхаб шуны белеп алды: яңа секретарьның нервлары нык, безнең агай-энене күп күргән икән.

Сәхаб чыга башлады.

— Хушыгыз!

Ләкин Сәхаб чыгып китәргә өлгермәде, кабинетка Бакирның секретаре керде.

— Мөршидә ападан телеграмма бар, Бакир Әхтәмович, каршы алырга...

Мөршидә исемен ишетү белән Сәхабның да колаклары торды. Ул ишеккә җитәр-җитмәс туктап калды һәм телеграмманың соңгы сүзләрен ишетергә теләп адымын баса төште. Ләкин секретарь кыз Гөлсинә, Сәхабның кабинеттан чыгып китмәвен күреп, телеграмманы укымый торды. Сәхаб каударланып ишекне ачты һәм кабинеттан чыгу белән түземсезләнеп Гөлсинәне көтә башлады. Гөлсинә чыгу белән ул аңа иярде:

— Гөлсинә акыллым, Мөршидә апаң ничәдә төшәм дигән әле? — дип, кызга сырлан кебек ябышты.

— Әйтмим,— диде Гөлсинә, уенын-чынын бергә кушып.

— Каян килгән сиңа мондый мәрхәмәтсезлек, Гөлсинә?..

— Сезне яратмый ул, Сәхаб абый, юкка килеп салып йөрмәгез...

— Менәтерәк сиңа, мә! Син каян беләсең аны?

— Ат хәтле ике малаегыз бар, Сәхаб абый. Бүген тотып өйләндерерлек...

— Ә мин бер үзем торып җүләрләнимменни инде?.. Җитмәсә тагын әнкәй дә мин сине карый алмыйм инде дип теңкәгә тия.

— Китсәнә, Сәхаб абый... Ә нигә соң мине алмыйсыз? — диде Гөлсинә, мутланып.

— Сине?! — Сәхаб Гөлсинәгә карап, ниндидер әчке ләззәт тоеп, няген сыпырып торды. Юри булса кирәк, Гөлсинә симез янбашларын уйнатып аның каршыннан үтте.

— Әһ-ма, Гөлсинә җаным, бер ун яшькә яшьрәк чакта әйтсәң икән син миңа бу сүзләреңне!..

Гөлсинә аның каршына ук килеп басты һәм калкып торган янбашларына таянып:

— Әллә өйләнер идең, Сәхаб абый? — дип, кулындагы телеграмманы Сәхабның йөзенә тидереп диярлек җилпеп алды.

— Кем белә, бәлкем, шайтанның бисмилла дигән чагына туры килеп, пар күгәрченнәрдәй торып китәр идек...

— Һәй, бу ирләрне, билләһи...

Сәхаб Гөлсинәнен җилкәсенә кулын салды.

— Я, әйт инде, Гөлсинә җаным, кайчан төшә Мөршидә апаң?

— Сәхаб абый, Бакир Әхтәмович аны алырга Фәатны җибәрергә кушты бит,— диде Гөлсинә, кисәк йомшарып китеп.
— Ә сәгать ничәдә төшә?
— Ансын әйтмим.
— Нигә?
— Син беләсеңме, Сәхаб абый, Бакир Әхтәмович кеме аның?
— Кеме соң?
Гөлсинә бармак изәп аны янынарак дәште.
— Тик беркемгә дә әйтмә, Сәхаб абый,— диде ул, Сәхабның йөзен чәче белән кытыклап, муенын сузып колагына үрелде.— Бакир Әхтәмович Мөршидә апа кызының әтисе була, беләсең килсә...
Сәхаб үз колагына үзе ышанмады.
— Дөресме бу, Гөлсинә?
— Әйе, Сәхаб абый...

...Сәхаб райком бинасыннан чыкканда төш вакыты үтеп, кояш авыша башлаган иде инде. Эше муеннан булса да, ул бүген авылга ашыкмады. Киоскка тукталып газета-журналлар алды да ашханәгә керергә булды. Ләкин тәрәзәдән үк кеше күплекне күргәч кузгалып китте.
ГАЗ-69 акрын гына Бөгелмә юлына юнәлде. Сәхаб теләсә-теләмәсә дә, аны ниндидер күзгә күренмәс көч шул якка таба тарта иде.
Юлда машиналар күп. Ашлык тапшыру айлары, кызу эш өсте. Сәхаб уң якка чыкты да, тизлекне тагы да әкренәйтә төшеп, уйга чумды.
Кайчан башланды соң әле бу?
...Алар өлкәдән бергә кайттылар. Районнан машина көтеп, Мөршидә белән аэропорт ресторанында утырырга туры килде. Сәхаб ашарга-эчәргә заказ бирде. Мөршидә винодны эчмим димәде, кирәкми димәде, бер салган рюмкадан әз-әз генә капкалап утырды. Ә бераз кыбрәгән авыз иткән Сәхабның исә кыюлыгы артты, теле языла төшеп китте.
— Мин сезнең белән бергә булыр өчен Казан юлыннан кайтмаска да риза, Мөршидә. Мин, ни, мин бит тол ир, Мөршидә, ә син, гафу ит, мин син дим сезгә, ә син, Мөршидә, тол хатын. Нинди генә ир эзлисең икән син?!. Ник миңа күз дә салмыйсың?
Берәү булса ачуланыр, Сәхабны тиргәр, оялтыр иде, Мөршидә исә авыз кырые белән елмайды гына.
— Син миннән көләсең, Мөршидә. Их, Мөршидә! Әллә ходай миңа ике гомер бирер дип яшисеңме?
— Сәхаб абый,— дип дәште Мөршидә йомшак, ягымлы итеп,— житте, житте!.. Тыңлыйсым килми минем кызмача ирләрне, кызганам мин аларны, мәлҗерәп төшкәннәре өчен түгел, телләре белән ярма ярганнары өчен кызганам. Әйе, Сәхаб абый, әйе, күрәсең, мин ике гомерлемендер, ахры. Үзем зурлык кызым бар бит, Сәхаб абый, авыл хуҗалыгы институтында укый.
— Ә минем үзем хәтле ике малаем бар.
— Әнә шулай булгач, Сәхаб абый, аларны гына карыйк инде. Тагын яңа семья төзергә мин соңга калдым инде. Күрәсең, язмыштыр. Үзем теләп алган язмыш түгел,— Мөршидә башын ия төште,— әмма мин килештем инде аның белән...
— Юк, юк, килешмәдең! Тыштан гына шулай уйлыйсың, килешмәдең!..
— Сакла йөрәгеңне, бу заманда икенче берәүгә алып куюлары бар дисең инде,— диде Мөршидә һәм тыенкы гына көлеп алды.
Аннары ул кәгазь тастымалга авызын сөртте дә тора башлады.— Әйдә, китик, Сәхаб абый. Сез миннән жиде яшькә олы бит. Шулаймы? Шулай булгач, дөрес сөйлим булып чыга.
Сәхаб та торып басты.

— Усал син, Мөршидә, ай-һай, усал! Мин хатынымны талак әйтеп аерган кеше түгел бит. Кадим заманыннан калган йөрәк чире белән дөнья куйды... Ә ялгызлык йөрәкне талый, ялгызлык рәнҗетә мине. Җан җылысы тапмаммы дип шулай ачылган идем, ә син...

Сәхаб ничектер кимсетелгән кешедәй башын иеп ишеккә таба атлады.

Машинага утыргач, ул:

— Дөрес әйтәсең, Мөршидә,— диде күзләрен тәрәзәдән алмыйча,— агым су болганчык булмый. Сине мин үтә пакь хатын-кызлар рәтенә куям...

Мөршидә аның кулына кагылды. Йонлач каты кул өстенә йомшак, җылы кул тиюгә Сәхаб тетрәп китте.

— Синең вөҗданың тыныч, Сәхаб абый. Син тәҗрибәле, күпне күргән кеше, зинһар, ачуланма миңа. Мин хәзер берни дә әйтә алмыйм. Минә Нәзиләм институтта төпләнеп, ныклап укып китсен әле. Аннары уйлашырбыз. Иң мөһиме безгә бер-беребезгә ярдәм итү, якын булу, абынганда булышу, ялгышларны төзәтү...

Кайтып җиткәч, Сәхаб аны өенә кадәр китерде. Машинадан төшкәч, ул Мөршидәне култыклап алды һәм караңгы подъездга кадәр озата килде. Мөршидә аңа якын тора, Сәхаб аның җылы тәнен тоя иде, шунамы ул мутланып китеп, дуамал яшьлеген уятып куйган йөрәген тыя алмыйча, Мөршидәне кочты да кайнар иреннәреннән үпте һәм гаепле кеше сыман читкә тайпылды, аннары, тыныч йокы теләп, китеп барды. Мөршидә подъездга кереп югалды. Сәхаб, капкадан чыккач, кинәт туктап калды.

Шушы минутта гына Мөршидәне тәмләп үбүен күз алдына китергә, Сәхаб күңелендә әллә кайчангы› яшьлек дәрте кузгалды: йөрәк түрендә сүнеп-сүрелеп калган гыйшык уты яңадан бөркелеп кабынды. Сәхаб үзен шундый җиңеләйгән кебек хис итте, әйтерсең, илледән өскә таба талпынган йөрәген унҗиде яшьлек егетнеке белән алыштырдылар. Һәм ул, яшәүнең серенә яңа төшенгәндәй:

— Бу дөньяда мәхәббәттән дә шифалы дару юк, булса да кешегә бу тикле куаныч-шатлык бирә алмас иде, мөгаен,— дип уйлады.

Шушы хәлдән соң Сәхаб өчен Мөршидә, әйтерсең, яшәү мәгънәсе генә түгел, хәтта яшәүнең хикмәте булып тоела башлады.

Күрешкән, күргән саен Мөршидә дә аңа элеккечә үк якты йөз күрсәтте, үз итеп: «син» дип дәште.

Әйе, Сәхабның дөньясы киңәеп киткәндәй булды. Чөнки бит Мөршидәне үз итте ул. Мәгәр бу турыда беркемгә берни белдермәде, әйтмәде. Көтте, сабыр итте. Мөршидәдән нәрсәдер ишетергә теләде... Һәм менә шундый канатлы хыяллар белән йөргәндә аның башына кинәт тәпәч белән китереп суккан кебек булдылар: Бакир Мөршидәнең элекке ире, имеш. Моны ишетүгә Сәхабка дөнья кинәт тарайды да калды. Әйе, киңгә кин дөнья, тарга тар икән ул...

Сәхаб, аэродромга килеп җиткәч, туктаган машиналар рәтенә килеп урнашты да, моторын сүндереп, аэродромдагы ыгы-зыгыга карап тора башлады.

«Нигә аның башында Мөршидә турындагы уйлар чуала соң әле? Нигә? Бишенче дистәнең беренче яртысын ваклап бара бит инде? Ниһаять, олыгаерга вакыт түгелме инде сиңа, Сәхаб!..»

Күп тә үтми аэровокзал каршына райком «Волга»сы килеп туктады. Рульдәге кешене күрүгә Сәхабның тәне эсселе-суыклы булып китте. Машинада райком секретаре үзе генә иде.

Мөршидә кайту белән башыннан эшкә чумды. Ужымны әрәм итү, җирне эштән чыгару мәсьәләсен ахырынача ачыклау тулысы белән аңа

йөкләтелде. Ул бөтенесен янабаштан диярлек, энәсеннән-җебенә кадәр тикшереп чыкты. Бу көннәрдә Бакир колхозлардан кайтмады. Чөнки, үч иткән кебек, менә бер атна инде яңгыр ява. Лафет белән актарган бодай үрә, муртая, шыта, чапмаганы ята башлады. Ләкин бер атна буе зәңгәр күк йөзен томалап, кояшны күрсәтмәгән яңгыр болыты сентябрьнең икенче ункөнлегендә төньяктан исә башлаган салкын җил белән алышынды, куе кара болытлар сыектылар, уңып-шиңеп калып, кире көньякка агылдылар. Өченче көнне салкын җил дә туктады, бөтен дөньяны нурга күмеп, кояш та чыкты. Күңеле шуңарчы шактый борчылып йөргән Бакир, Бөгелмә юлында яңадан икмәк илтүче машиналар күренгәч, тынычлана төште.

Бераздан бәрәңге алуга керештеләр. Районда аның мәйданы ун мең гектарга якын иде. Шуны аласы, озатасы, сатасы бар. Әлбәттә, колхозчыларның гына моңа көче җитмәячәк. Предприятиеләрдән, мәктәпләрдән колхозларга бәрәңге, чөгендер алырга кешеләр җибәрелде. Шимбә, якшәмбе көннәрдә үткәрелгән бу өмәләргә меңләгән кеше катнашты. Һәм атна дигәндә район дәүләткә бәрәңге сату планын үтәде. Өстән янә бер йөк төште. Бәрәңге, чөгендерне эшен бетереп өч-дүрт көн үтүгә, ниһаять, икмәк тапшыру да тәгәлләнде. Район өлкәгә ике ярым норма ашлык сатылуы турында хәбәр итте. Партиянең өлкә комитеты секретаре Бакирны бу уңай белән бик җылы итеп тәбрикләде. Бәрәңгене терлекләргә дә күпләп калдырырга, ашлыкны, әрәм-шәрәм итмичә, фуражга тотарга киңәш итте.

Икенче көнне Бакир партия өлкә комитетының һәм республика министрлар советының тәбрикләү сүзләрен республика газетасында укыды. Анда райком белән райбашкарма комитеты адресына матур сүзләр әйтелгән иде. Мондый сүзләрне ул тыныч кына кичерә алмады, Мөршидә янына керде.

Мөршидә шул ук газетаны укып утыра иде. Ул, Бакир килеп керүгә, утырырга үтенде һәм тәбрикләү сүзләрен яңадан кычкырып укып чыкты.

— Оһ, бәхетле дә соң сез, Бакир Әхтәмович! Котлыйм сезне! Кулыгызны гына һәм менә... Ике ярым план!

— Без анда да, Чүпрәледә дә начар эшләмәдек...

Мөршидә Бакирның бу сүзләреннән соң, кызыксынып, аңа карап алды. Ул белергә теләп иде: бу сүзләр уйнап-шаярыпмы, әллә чын-чынлап әйтелдеме? Әгәр дә мәгәр чын күңеленнән әйткән икән...

Әмма Бакир, Мөршидәнең йөзендә үзгәреш күреп, әйткән сүзләрен уенга борды.

— Анда чүпрәсен салган идек, менә биредә ипиен пешердек,— диде.

Мөршидә моңа җавап итеп:

— Редакторга шалтыраттыгызмы? — дип сорады Бакирдан, тыенкы-коры гына.

— Юк әле.

— Район газетасына да бирергә кирәк. Бөтен район хезмәт иярәренең уңышы бит бу, Бакир Әхтәмович.

«Аңламады, уенга ала белмәде»,— дип, Бакир эченнән Мөршидә өчен рәнҗеп алды. Сүзне икенчегә борырга кирәк иде. Ул бюро турында сорады.

— Материаллар әзер, әйдәгез, кайчан карыйбыз ужым мәсьәләсен?

— Ифрат җитди мәсьәлә ул, Бакир Әхтәмович. Ниһаять, барыбыз да өйдә, карыйк,— диде Мөршидә.

— Сезне көттек,— диде Бакир, көлемсерәп.

Мөршидә аны тагын аңламады шикелле. Әллә тел төбен аңларга теләмәдеме?

— Сәхаб Вәлиевич кереп чыккан иде миңа. Хәзер инде карамасак

та була, тимерне кызуында сугып булмады,— ди. Ачуы йөзенә үк чыккан...

Бакир тезен тез өстенә куеп, бераз дәшми утырды.

«Бу ни бу? Нигә шулай сөйләшәбез әле без? Ниндидер бушлык бар төсле безнең арада»,— дигән уйлар борчыды Бакирны. Бит Бакир аның янына шатлыгын уртаклашырга дип кергән иде. Ә ул?..

— Мөршидә Хәбировна, ләкин бит Сәхабның үзбаш фикере белән генә ул мәсьәлә ачыкланмаячак. Аны хәзер аеруча кискен итеп куярга тиешбез. Авыл яңа устав кабул итү алдында тора. Колхозчылар җирнең кадерен белергә, аны яратырга өйрәнәләр һәм аны бозучыларга каннары кайный икән — моңа шатланырга кирәк, минемчә.

«Ник сөйлим соң әле мин аңа? Әллә шул ук акыллы сүзләрне үзе дә әйтмәс идеме ул?» — дип, шунда ук үз-үзен тиргәп тә алды Бакир. Ике арада ниндидер табигый булмаган салкынлыкны тою иде бу.

Мөршидә, телефон трубкасын алып, Воронцовны чакырды.

Бүлмәгә килеп кергәндә Воронцовның йөзе җилсенгән, күз алмалары кызарган иде. Бүлмәдәгеләр, берсенә берсе сораулар биреп, берничә нәрсәне бик тиз ачыкладылар.

— Ни булды сезгә, Василий Иванович?

— Салкын тигән, ахры, Мөршидә Хәбировна. Кичәгенәк салкын җилдә бәрәңге алган идек, юкарак киенеп баруның «файдасы».

— Авырсагыз, врачка күренегез, юкса өзлегеп егылуыгыз бар.

— Узардыр кебек...— диде Воронцов, кул селтәп. Аннары Бакирга мөрәҗәгать итте: — Бакир Әхтәмович, бәрәнгегә үткән якшәмбедә мең кеше катнашты. Киләсе атнага өмә оештырылачакмы, юкмы?

— Өмә башка булмый. Колхозчылар үзләре дә җитешәчәкләр дип уйлыйм.

— Яңгырлар китсә?

— Синоптиклар яңгыр булыр дип әйтмәделәр. Аларга ышанып карыйк.

Воронцов тагын Мөршидәгә карады.

— Ни әйтәсегез бар иде, Мөршидә Хәбировна?

— Бюро утырышы чакырыла, иптәшләргә әйтеп куегыз. Ә Ходайбирдиннан хәбәр юкмы?

— Юк. Шушы көннәрдә кайтып җитәргә тиеш ул...

Соңгы сүзне Бакир әйтте:

— Бюрога өлкәдән дә ике вәкил киләчәк. Берсе — промышленность, икенчесе — авыл хуҗалыгы бүлегеннән. Күрәсез, эш зурдан кубарга чамалый...

Соңгы араларда ял-йокы тәмнәрен рәтләп татымаган Василий Иванович чыгып киткәч, Бакир күз тутырып Мөршидәгә карады. Карады һәм, әйтерсең, алдына егерме ике яшьлек элекке Мөршидә килеп басты. Ул ояла, ул елмая. Озын керфекләрен еш-еш кагып аңа карап тора. Күзләре гүя: «Бакир, нигә син ул вакытта миннән йөз чөердең?» — дия иде.

Чынында исә Мөршидә яшь түгел, керфекләрен дә каккалап утырмый. Аның чигәсенә агара башлаган чәчләре төшкән, күз төпләрендә җыерчыклар да юк түгел. Ә үзе өстәлдә яткан газетаны караштыра.

Ә аңа күз дә алмыйча карап торган Бакир күңелендә исә менә нинди хис дулкыннары тирбәлә: «Мин аңа әйтергә, мин аның белән сөйләшергә тиеш. Без, безнең мөнәсәбәтләр... Бала...»

— Сез шактый арыгансыз, кайтып ял итәргә кирәк, Бакир Әхтәмович.

— Әйе, әйе, бераз арылган, ахрысы. Сезгә дә шуны киңәш итәм,— диде Бакир, эчкерсез елмаеп.— Шәплэп ял итеп куясы бар. Сизәм, авыр һәм усал сөйләшү булырга тиеш бюрода.

Бюро иртәнге сәгать унда башланды. Гөлсинә янындагы шау-шу, кул биреп исәнләшүләр, кисәк тынып, беренче секретарь кабинетына күчте. Барысы да урында иде, бер Сәхаб кына килеп җитмәгән. Бакир бераз көтәргә, башка мәсьәләләрне карый торырга дигән тәкъдим кертте. Кабинетта тыныч, әшлекле сөйләшүләр башланды. Ләкин... Давыл алдыннан була торган тынлык иде бу.

...Сәхаб утырышка соңга калмаска бик тә тырышты. Иртән иртүк колхозга өч-дүрт машина белән хәрбиләр бәрәңге алырга килделәр. Аны алырга председатель имзасы кирәк. «Рөхсәтне өенә барып алыгыз», дип җибәргәннәр. Иртә таңда ишек шакучы хәрби шактый әрсез булды, ишектән тәрәзәгә күчте. Сәхаб: «Инәй кая икән соң, нигә ишекне ачмый?» дип урыныннан торды да инде сиксән яшен тутырып узган әнисе янына килде. Ул мич буендагы сәкедә йоклый иде. Сәхаб «сәкене алам» дигәч, әнисе:

— Мин дөнья куйгач, мәрхүм атаң янына киткәч чыгарып ташларсың, ә мин исән чакта алсаң, һич бәхиллегем юк,— диде. Шулай итеп алты почмаклы яңача җыештырылган өйдә иске тормышның бер сәкесе генә торып калган иде. Мөршидә килүгә өмет тотып, Сәхаб сәкене берничә тапкыр чыгарып ташларга да итте, әмма әнисе һаман риза булмады да булмады.

Сәхаб мич янына яланаяк көе генә килде һәм тыенкы гына итеп:

— Инәй, инәй дим, тор әле, кеше килгән түгелме анда?..— диде.

Ләкин былтыр үзе алып кайткан атлас юрганга башыннан төренеп яткан әнисе кузгалмады.

— Инәй, инәй дим!..— дип катырак дәште Сәхаб.

Шуннан күңеленә ниндидер шик төште. Тиз генә юрганга үрелде, ачты һәм кулы әнисенең боз кебек салкын битенә тиеп китте. Гүя аркасына салкын су коелды: ул юрганны сыдырып алды да:

— Инәй, инәкәй! — дип Мәстүрә карчыкны уятмакчы булды. Әмма әнисе бу юлы да дәшмәде. Сәхабның шөбһәсе үсте, зиһенен курку томалады.

— Үлгән!

Сәхаб, ачкан авызын яба алмыйча, ишеккә ташланды. Анда ишек шакый-шакый аптырап беткән капитан басып тора иде. Ишекне каерып ачу белән, Сәхаб:

— Әни үлгән! — дип кычкырды.

— Кем үлгән? — дип кайтарып сорады капитан, чыраенда каны качкан Сәхабны күргәч.

Сәхаб аңына килде һәм инде пышылдап кына әйтте:

— Әни үлгән, иптәш капитан, әни!..

Капитан аптырады да калды. Ул көтәргә тиеш иде...

Сәхаб өйгә кереп чалбар-костюмын өс-башына тиз-тиз генә элде дә сәдәпләрен юлда каптыра-каптыра күршеләренә йөгерде.

Мәстүрә карчык мәете янына авыл карчыклары җыелды. Сәхаб исә шул арада капитанга язу биреп өлгерде, аннары карчыклар янына керде. Аңа җеназага кәфенлек, тегесен-монысын хәзерләргә куштылар. Сәхаб, шуларның барысын күңеленә теркәп, машинасын чакырып алды, шоферы Зиннурга йөз сум акча тоттырды:

— Шәһәргә чаптыр, җир астыннан булса да табып кайт, бер сәгатьтән биредә бул!

Үзе кабер казырга кешеләр чакырырга китте. Барысы да төгәлләнгәндә сәгать тугыз иде инде, ә машина һаман юк та юк. «Әллә бара алмыйм дип хәбәр итәргәме?» Ләкин күз алдына кара көйгән басу килү белән: — «Юк, барырга кирәк, барырга»,— дигән катгый фикергә килде.

Ул ашыгып өйгә кермәкче итте, лэкин ишектәге бер карчык аны туктатты.

— Сабыр ит, улым, җеназа бетмәде бит әле.

Сәхаб сәгатькә карады. Сәгать теле, рәхимсез рәвештә ашкынып, унынчы яртыга таба шуыша иде. Китәргә бик вакыт инде. «Инәйне күмәргә бюродан соң кайтырмын. Бюро үткәч. «Их, инәй, инәй...»

Ул тагын өйгә кермәкче итте. Карчык аны янә туктатты.

— Сабыр ит, улым, сабыр ит, бераз...

Сәхаб аңа: «Әниемнең йөзен генә күреп китәм»,— димәкче иде, әйтмәде, көтәргә булды. Баса төшсәң, районзәккә егерме минутта барып житәргә була. Зиннур, әгәр теләсә, йөреп күрсәтә ул»,— дип үз-үзен генә юатты.

Ләкин сәгать ун тулды, унберенчегә китте. Зиннур кайтмады да кайтмады.

«Әллә ашыгып берәр кая барып чәпәлдеме? Нигә юк, нигә?! Бик кайтып җитәргә тиеш инде!..»

Капка төбенә җыелган картлар белән шулай уйлана-уйлана сөйләшеп торганда, аңы өйгә дәштеләр.

Өй уртасындагы озын эскәмиягә сузып салган әнисе өстенә ак җәймә япканнар. Иягенә кадәр атлас юрган капланган. Сәхаб әнисе йөзендә әллә ни үзгәрү күрмәде, гүя ул күзләрен йомып ятып кына тора иде. Ул эскәмия янына килде, иелә төшеп, әнисенең кипкән йомычка кебек корып калган кулына кагылды. Аннары, авызларын яулык чите белән каплап бер як читтә карап торучы карчыкларга игътибар итмичә, салкын маңгаеннан үбеп алды: берничә бөртек кайнар яшь әнисенең сулган йөзенә тамды.

— Хуш, инәй. Бәхил бул. Үпкәләп, рәнҗеп китмә мин бахырга...

Шул чакта өйгә муенына ике аппарат таккан фотографны ияртеп, шофер Зиннур килеп керде.

— Кибетләр сәгать унда гына ачылды, менә моны да көчкә эзләп таптым,— диде ул, рәсем төшерүчегә күрсәтеп.

— Ярый, әйдә төшерсен,— диде Сәхаб, битараф төстә. Әнисе белән аерылышу аңа кыен иде, күңеле ниндидер төшенкелек тойгысы белән тулган иде.

Фотограф, мәетнең өч-дүрт ягына чыгып, сурәтләрне бик тәфсилләп төшереп алды. Сәхаб чалара башлаган чәчен бит-йөзенә төшереп, әнисенә тагын бер тын карап торды да ишеккә таба әкрен генә атлады.

Дөньядан китәренә атна чамасы элек әнисе аңа әйткән иде:

— Өйлән, булмаса, улым. Күрәм-карыйм, дөнья яме җитми сиңа. Кошлар да бит пар яшәүдән туймыйлар.

Сәхаб аны, нигә инәй минем шәхси эшемә тыгыласың дип, җиңелчә генә орышты да хәтта. Чөнки Мөршидәне аэродромга каршыларга барганнан соң каны кайнап, ачуыннан йөрәге әрнеп, зиһене томаланып йөргән чагы иде. Хәзер ул мәрхүмә әнисенә әйткән шул сүзләре өчен әрнешеп үкенүен, йөрәге сыкравын тойды. «Кичер, инәй, гафу ит мине»,— диде ул ишегалдына чыга-чыга, калтыранган әчке тавыш белән.

Капка төбендәге картларга ул:

— Мин кайтмыйча күммәгез, абзый,— дип, машинасына утырды. Аннары, нидер исенә төшеп, Зиннурга өйдән бер тәенчек алып чыгарга кушты. Тегесе уттай тиз әйләнеп килгәч, төенчекне кадерләп кенә алып, тез өстенә куйды да:

— Йөз чакрымны куып йөри аласыңмы, йөргәнең бармы? — дип сорады.

Зиннур дәшмәде. Чөнки председательнең гадәтен белә иде. Моторын самолетныкыннан битәр үкертеп, урыннан кузгалды.

Сәхаб, бик бәргәләмәсен дип, каршысындагы тоткага тотынды. Уйга

чумды. «Менә әни дә китте... Ә балалар? Балалар синнән читтә инде, Сәхаб, алар да киттеләр...»

Хуш исле жылы төргәкне рәтләбрәк куйды. Итәгендәге шундый зур арыш ипиен ана әнисе пешереп бирде. Әле кичә генә... Бүген үзе юк инде...

Сәхаб, мич төбенә салган зур түгәрәк ипине, әнисенең жылы кулын сыйпагандай, тагын бер кат капшап чыкты. Яңа арыш оныннан шуны пешерергә кушкач, Мәстүрә карчык:

— Нигә арыш кирәкте, бодай оныбыз да бар ич,— диган иде.

— Кирәк, инәй, кирәк. Беләсең килсә, ипинең иң тәмлесе яңа арыш оныннан салганы аның. Мин бит, инәй, шуны ашап үскән кеше, шуңа тансык,— диде Сәхаб.

Зур итеп салынган берничә ипи иеште. Алар күпереп, өсләре кып-кызыл төскә кереп, кабарып, мул булып күтәрелеп уңдылар. Сәхаб шуларның кулны пешереп торган берсен алды да күкрәгенә терәп кисте, аннары шул әчкелтемрәк телемгә май ягып, әллә кайчангы бала чагын искә төшерә-төшерә тәмләп ашап утырды. Ә ипинең берсен ул әнисенә, ашъяулыкка төреп, киштәгә куеп торырга кушты...

Иртәннән бирле авызына бер валчык капмаганга мы, Сәхабның ашыйсы килеп китте. Төргәк исе, аның борынын ярып кереп, авыз суларын китерде, ашказанын ялкынсындыра башлады. Әмма ул ипигә кагылмады.

Сәхаб әле сабый чакта әти-әнисе шушы икмәк өчен муллага ялланып арыш урдылар. Аларның басудан кайтканын малай түр тәрәзәдән карап тора иде. Чөнки ул бердәнбер тәрәзә, калганнары карындык. Ипине алар жомга көнне генә бүлеп ашыйлар. Калганы сандыкта саклана. Сандык гел бикле була. Карыны ачу чиктән ашып, түземе беткәч, Сәхаб сандык янына киләдер иде дә йотыла-йотыла, ашыйсы килүдән елый-елый әчкелтем арыш ипие исен иснидер иде.

Һай, ул чактагы ашыйсы килүләр...

Үсә-исәя төшеп, буй ала башлагач, Сәхаб та әти-әнисенә ияреп басуга йөри башлады. Шунда ул әкрен генә искән жилдә дулкынланган, жилсез көнне дә үзара сөйләшеп-серләшеп торган озын башаклы, үзе кыйеллерлек арыш басуын күрде. Шунда башак уып бөртек кабар, шуны сагыз урынына чәйнәп йөрер иде.

Аннары Кадыйровлар бер ат, бер сука, бер агач тырмалары белән колхозга керделәр. Озакламый тормышлар ничектер жиңеләеп, интегүләр онытылып китте. Тиздән Сәхабның әтисен бригадир иттеләр. Ә ул жәйдә утауга гына йөргән малай дүртенче класста укыганда жир тырмалый башлады. Аннан соң — сабанга, чәчүгә йөрү, жиде классны тәмамлагач исә — тракторга уку һәм... сугыш... Ул аның да иң кайнар уты эчендә булды. Чөнки танкист иде...

Председатель итеп сайлагач,— монысы сугыштан кайтуга ук булды,— Сәхаб эштә тагын да күбрәк тырышты. Аның колхозы бөртеклеләр уңышын һәр елны диярлек башкалардан күбрәк алды. Ә менә бу якларга нефтьчеләр килеп чыккач, ул ниндидер сәер яңалык күреп, шаккатты һәм шул ук вакытта аптырап та калды: нефтьчеләр игеннәр язмышын кайгыртмыйлар икән, хәтта аны бар дип тә белмәгәннәре бар. Бәясен, хакын колхозга түлиләр дә жирне теләсә ничек таптыйлар, пычраталар, актарып, бутап китәләр.

Зиннур, ут өереп, район үзәгенә килеп керде. Юл аркылы чыгып килүче бер карчыкка каты итеп сигнал биргән иде, тегесе, өне алынып, юл уртасында туктап калды, як-ягына төкеренә-төкеренә үзен урап үткән шайтан арбасын орыша башлады. Зиннур аны ничектер итеп урап чыкты да, тизлеген бер мизгелгә дә әкренәйтмичә, өч квартал үтүгә, райком бинасы каршына килеп туктады.

— Унбиш минут! — диде ул. Горурланып председательгә карады.

Сәхаб аның җилкәсенә кагып алды да, кайтып китәргә кушып, машинадан төште, чөнки агрономның кырга чыгасы бар иде.

Бюро утырышында Сәхабны көтмиләр иде инде. Планда карaласы мәсьәләләр: партиягә алу, терлекчелектә рентабельлеккә ирешүнең яңа чаралары турындагы мәсьәләне һәм бу өлкәдә артта барган ике колхозны тикшерү беткәч, бюро членнары Сәхаб дәгъвасы бу бюродан да кала, ахры, дип сөйләнә башладылар. Авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Хәкимҗанов белән янәшә утыручы Ходайбирдин, муенын сузып, идарә начальнигына нидер сөйли. Алар каршында утырган Тимерхан алдындагы кәгазьгә ат рәсеме сызгалый. Аның белән рәттән утыручы Мөршидә кулындагы каләмен бертуктаусыз бөтерә: күрәсең, Сәхабның соңга калуына аеруча борчыла иде. Стена буендагы йомшак урындыкларда район газетасы редакторы һәм кара кысалы күзлек кигән прокурор Кашапов ни турындадыр кулларын селкә-селкә сөйләшеп утыралар. Урам як стена буендагы бер урындыкка райкомол секретаре Беляев, нефть идарәсенең партком секретаре Куклин утырган.

Райком секретаре Бакир Галиев үз янәшәсендәрәк утырган өлкә вәкилләренә таба иелеп чираттагы мәсьәләне карау-карамау турында киңәшә башлаган гына иде, кабинетка Сәхаб атылып килеп керде.

Ул утә-утешли үк барысы белән дә баш иеп исәнләште дә, соңгарганы өчен гафу үтенеп, төенчек тоткан килеш, үз урынына барып утырды. Үндагы буш урындыкка төенчеген куйды да тирләгән маңгаен сөртеп алды.

Шунда барысы да, гүя ки Сәхабны яңа гына күргәндәй, аңа карадылар. Бакир тиз генә өлкә вәкилләренә нидер әйтте дә кызыл карандаш тоткан уң кулын күтәрде.

— Иптәшләр, председатель бераз соңгарып булса да килеп җитте. Бюро членнары һәм өлкәдән килгән иптәшләр карaласы материал белән танышлар. Иң әүвәл иптәш Кадыйровның бюрога соңгару сәбәбен ачыклыйк та мәсьәләне тикшерә башлыйк. Иптәш Кадыйров сез ничек уйлыйсыз?

Сәхаб килеп керү белән үк шундый сорау буласын көтмәгән иде, ни әйтергә белми аптырап калды. Бюро членнарына күз йөртеп чыккан арада бераз тынычлана төште.

— Гафу итегез, иптәшләр... Әни үлде минем...— диде ул һәм, үз тавышының калтырап китүеннән үзе оялып:

— Бүген иртән, кинәттән,— дип өстәде.

Кабинетта беравыкка чиксез тынлык урнашты. Бүлмәдә форточканы таба алмыйча тәрәзә пыяласына бәрелеп бер яшел чебеннең безелдәве генә ишетелеп торды.

— Ярый,— диде Бакир.— Мәсьәләгә күчик. Утырыгыз, иптәш Кадыйров.

— Иптәшләр,— дип, урыныннан Казан вәкиле Насыйров күтәрелде,— бәлкем безгә иптәш Кадыйровны бүген кайтарып җибәрергәдер. Әнисе вафат, аны җирләргә...

Ходайбирдин, учы белән авызын каплап, тамак кырып алды. Янәсе, мин дә бу тәкъдим белән килешәм.

Ходайбирдинның бу хәрәкәте Сәхаб күзенә, әлбәттә, чагылмый калмады. Ул, утырган җиреннән кинәт торып:

— Юк, иптәшләр, минем иптәш Ходайбирдин чыгышын тыңлыйсым килә,— диде.

— Булды,— диде Бакир,— сүзне иптәш Ходайбирдинга бирәбез.

Озын гәүдәле Ходайбирдин бераз иелә төшеп торып басты да, шактый күпшенгән папкасын ачып, кәгазьләр актара башлады.

«Нык хәзерләнгән, шуңа җаны тыныч»,— дип уйлады Сәхаб, нефть идарәсе начальнигының йөзендә бернинди дулкынлану төсе күренмәгәч.

Ходайбирдин сүзне бик ерактан башлады. Совет Татарстаны бөтен Россия уныченче елда чыгарган нефтьне бер айда бирә, дип, республиканың колачлы үсешен күрсәтте. Нефтьне алтын белән тиңләде. Экспортка Татарстан саткан «кара алтын»нан дәүләт алган файданы район колхозлары биргән файда белән чагыштырып карады. Аерманың шактый зур булып, кайберәүләрнең хәтта тел шартлатуларын күргәч, Ходайбирдин мисалларны тагын да дәртләнеброк китерә башлады. Уңышлар турында бик озак сөйләгәч кенә, кайбер кимчелекләрне санауга күчте.

— ...Ләкин, иптәшләр, бездә әле тиешле шартлар житенкерәп бетми. Технология төгәллеге тиешле дәрәҗәдә булмагач, көтелмәгән аварияләр, нефть түгү кебек күңелсезлекләр булгалый. Безнең максат: киләчәктә бу кимчелекләрне бетерү. Һәм без, иптәшләр, бу өлкәдә күп эшләр башкарабыз,— дип очлады сүзен Ходайбирдин һәм сәгатенә карап алды да урындыкка утырды.

— Скважиналарга ремонт ясау графигын төгәл үтәп барсагыз, бәлкем, бу бюро булмас та иде,— дип куйды ачуы чыгып утырган Воронцов. Бу сүзләрне әйткәндә ул бурлаттай кызарып чыкты.

Ходайбирдин нефть идарәсе парткомы секретаре Куклинга күз ташлады. Янәсе, әйдә син дә кушыл. Графикны бит бергә киңәшеп күчерттек. Ләкин Куклин дәшмәде. Һәм дөрес эшләде. Бит бюрода караласы мәсьәлә буенча ул бер генә бәхәсләшмәде Ходайбирдин белән.

Ходайбирдин тагын үзе торып басты.

— Василий Иванович, бюрода сез хәзер күтәргән мәсьәлә каралмый ич, нигә аны кузгатасыз?! — дип, әүвәл Воронцовка үпкә белдерде ул. Аннары тезеп китте: — Әгәр колхоз җирләрен алабыз, кайчакта ничектер пычратабыз, бозабыз икән, иптәшләр, без бит аларга бу җирләр өчен дәүләт акчасы түлибез. Идарә тик быелда гына колхоз-совхозларга егерме мең сумга якын акча түләде, шул исәптән, иптәш Кадыйров җитәкчелек иткән колхозга җиде мең сум. Бу — аз акча түгел, иптәшләр. Хәзер нефть чыгару автоматка көйләнә, скважина тирәләре кечерәйтелеп, шактый җир колхозларга кире бирелә. Быел без бер «Ленин юлы» колхозына гына ике гектардан артык җир кайтардык.

— Һәм утыз гектар уҗымын юкка чыгардыгыз,— дип өстәде моңа кадәр тыныч кына тыңлап утырган Сәхаб.

Беразга тынлык урнашты.

— Утырыгыз, иптәш Ходайбирдин,— диде Бакир.— Кем нәрсә әйтә, кем сөйләргә тели?

Мөршидә үзе торып басты һәм сөйләп китте.

— Мин, иптәшләр, идарә начальнигыннан иң кирәк нәрсәләрне ишетмәдем. Әйтик, ул скважинага ремонт үз вакытында ясалганмы? Тикшерү күрсәткәнчә, нефтьне мул биргән скважина булгангамы, скважинадан файдалануга ике срок үтүгә карамастан, аңа ремонт ясалмаган. Аннары «Ленин юлы» колхозының утыз гектар уҗымы ни хәлдә бүген, идарә берәр төрле ярдәм күрсәтергә уйлыймы-юкмы икән?

Ходайбирдин белә иде, болар барысы да Мөршидәгә, әлбәттә, билгеле.

— Партком белән администрация гаепләләрне тикшерде. Промысел мөдиренә каты шелтә, өлкән инженерга шелтә бирелде, участок начальнигы һәм оператор эштән алынды,— диде Ходайбирдин, коры гына үҗәтләнеп.

Аннары Сәхаб сүз сорады. Һәм урыныннан торып, алга узды. Ул гадәттән тыш дулкынланган, аның хәрәкәтләре кискен, әмма төгәл иде. Газетага төргән нипне алып, бюро членнары тезелеп утырган өстәл башына таба үтте. Ходайбирдин Сәхабтан уңда утыра. Председатель өстәл уртасына зур түгәрәк икмәк китереп куйгач: «Нәрсә кылана бу, төргәгендә нәрсә аның?» — дип, ирен кырые белән генә елмаеп алды

ул. Ләкин икмәкне япкан газетасының бер почмагын Сәхаб күтәреп җибәрүгә, аның йөзе очлая, сузыла барды, кашлары җимерелде. Кабинеттагы бөтен кеше, кайсы үрелеп, кайсы урыныннан торып ук, шул икмәккә карады. Шуның тәмле исе, борыннарны кытыклап, бөтен якка таралды. Икмәк эре хәрефләр белән «Сельская жизнь» дип язылган газетага төрелгән, аның бер битендә авыл хуҗалыгы артеленең яңа устав проекты күренеп тора иде.

Бер мизгелгә урнашкан тынлыкны Сәхабның көчле, әмма тыенкы катгый тавышы күмде.

— Кем таптый ала шушы икмәкне?! Кем?! — Сәхабның борын яфраклары калтырап, агарып китте. Ул кабинеттагыларга күз йөртеп чыкты да, ачуын тыя алмыйча, Ходайбирдин белән Куклинга төртеп:

— Ә менә болар таптыйлар, ике аяклап менеп таптыйлар!..— диде.

Сәхаб колхозчылар үстергән икмәкнең кадерен белмәүчеләр турында нәфрәтләнеп сөйләде, нефтьчеләрнең иген чәчкән басулар белән рәхимсез кыланууларын искәрде.

Колхоз председателе икмәк турында сөйли башлагач, Ходайбирдин башта җилкәсен сикертеп, нигә бу кәмит уены дигән кебек, беренче секретарьга, өлкә вәкилләренә, бюро членнарының һәммәсенә күз йөртеп чыкты. Ләкин ул берсенең карашында да үзенә тотнаклы яклаучы тапмады. Кешеләр, әйтерсең, ипине күрү белән, шушы ризыкка бәйләнешле хатирә-истәлекләргә чумганнар иде.

Икмәк һәркемне уйга калдырды. Сәхаб сөйли башлагач та Мөршидә үз әнисен исенә төшерде. Аның күнеленә сугышның икенче елы килде. Кышны алар бик авыр чыктылар. Бәрәңге кәлҗемәсе ашап шешенә башлаган унҗиде яшьлек Мөршидә һәм үпкәсе чирле әнисе яз җитеп, басулардан кар китә башлау белән кырга башак җыярга киттеләр. Эзли-эзли торгач, бер чиләк ризык җыелды. Аны киптерделәр һәм, кул тегермәнендә тартып, умач уып ашадылар. Иртән әнисе көлчәләр пешерде. Өйләдән соң әнисе аяктан егылды, температурасы күтәрелде. Икенче көнне Мөршидә дә шул хәлгә калды. Аларны, кем хәбәр итептер, больницага алып киттеләр. Мөршидә күп тапкыр аңын югалтып, бер тирләп, бер өшеп ятты. Яшь организм җиңде. Мөршидә аякка басты, сәламәтләнде. Әлегә кадәр: «Әниең икенче палатада ята»,— дип барган врач, чыгарга вакыт җиткәч, аны үзенең бүлмәсенә чакырып алды һәм каршысына утыртып:

— Нык бул, Мөршидә акыллым! — диде.

Мөршидә барысын да аңлады. Әнисе, тамагы шешеп, икенче көнне үк үлеп киткән һәм аны Мөршидә больницада ятканда җирләп тә куйганнар. Ярый әле: сугыш башлангач та фронтка киткән әтисе шул чакны күкрәк тулы орденнар белән исән-сау әйләнеп кайтты һәм кызны ул укытты, ул кеше итте.

— Мин, Ходайбирдинның шәхси делосына язып, каты шелтә бирүне таләп итәм,— диде Сәхаб, бар булган сүзен әйтеп бетергәч.

Ходайбирдинның «Ленин юлы» колхозы председателенә ачуы кабарса да, ул сабырын җыярга тырышты. Үзен партиядән чыгарырга торган Кадыйров шундый тәкъдим әйткәч: «Курыкма, Ходайбирдин, иң күбе кисәтү булачак,— дип, Вәкил үз-үзен юатып, тынычландырып куйды. Ул сәгатенә карады. Сәгать унбер тулып килә иде. «Бу ипие тагын... Барысы да шуңа бакканнар, әйтерсең, күргәннәре юк. Хәзер икмәк безнең өчен проблема түгел. Кемне шаккатырмакчы була бу Кадыйров?! Нигә шул тамаша тузына?! Әйтик, миңа кисәтү ясадылар, ди, югарырак алсак — шелтә бирделәр, ди. Моңардан минем берәр җирем кимиме? Юк бит. Күпме кеше вакыт сарыф итә»,— дип утырды Вәкил.

Ходайбирдин үзе җитешле семьяда үсте. Гаилә өстәлендә сугыш вакытында да ипи, хәтта ак ипи өзелмәде. Әтисе гражданнар сугышы инвалиды иде, Ватан сугышына алмадылар, икмәк заводында директор

булып эшләде. Вәкил мәктәпкә өчәр-дүртәр телем ипи китерә торган иде. Аны куштан малайларга гына биреп, гел кәпрәеп йөрде. Аңа һич-кайчан, хәтта зуррак малайлардан да кул җиле тимәде.

«Нәрсә әйтте, нинди тәкъдим бирде соң әле бу Кадыйров? Шулай ук шәхси делога язып шелтә бирерләр микәнни? Тукта! Нигә мин баш алып борчылам әле? Сәхаб нәрсә ул! Ул гомергә мина каныкты. Менә өлкә вәкилләре ни әйтерләр? Алар зур вәкаләт белән килгәннәр бит. Утыз гектар гына түгел, ил буенча елына меңәр гектар җир-басу тапталадыр бәлки. Бирсен дә әле шуның өчен эштән куганнары юк. «Цивилизация корбансыз булмый»,— дип, Ходайбирдин һаман үзен юата торды.

Ләкин ул бер нәрсәне исәпкә алмады — икмәкне! Аның ничек кешеләргә тәэсир итүен исәпкә алмады.

Сәхаб утыргач, Галиевның кызыл карандашы тагын күтәрелде. — Мәсьәлә аңлашыла бара дип уйлыйк. Тагын кем сүз ала?

Мөршидә Сәхаб ягына карады. Ул аны беренче тапкыр күргән кебек бакты. Сәхаб тирләгән, шуңамы — күлмәк сәдәфләрен ычкындырып җибәргән, йөзе тагы да алсулана, кызара төшкән. Әмма күзләрендә һаман да усал чаткылар уйный иде әле. «Сүзе калган, тагын сүз алачак», дип уйлады Мөршидә.

Һәркемгә үзе житәкчелек иткән хуҗалык кадерле. Биредә бер Ходайбирдинны да гаепләп бетереп булмый. Әлбәттә, нинди күзлектән карап хөкем йөртәсең. Ходайбирдин дәүләткә күбрәк нефть чыгарып озату өчен тырыша, Кадыйров күбрәк икмәк үстереп сатарга тели. Бер уйлаганда икесе дә бер үк эшне башкаралар кебек. Ә инде әйләндеребрәк уйлаганда, әлбәттә, Сәхаб хаклы. Күпме яшелләкне корыттылар, күпме елга-суларны пычраттылар, күпме җирне үлән үсмәс иттеләр Ходайбирдин кебекләр. Мин шул турыда торып сөйләргә тиеш. Хәзер үк торып сөйләргә тиеш. Мөршидәнең уйлары шулай дәвам итте. Алар бит эштән чыгарылган басуны атна буена фотоларга төшереп, тикшереп йөрделәр. Фактик материаллар житәрлек.

Бакир исә үз сүзен иң соңыннан әйтергә тиеш иде. Әле өлкә комитеты вәкилләренең дә сөйлисе бар.

Сүзне Тимерхан алды. Ул әйләнә-тулгана бер тирәдә йөрде-йөрде дә, Сәхабның идарә начальнигын өстәл сугып сүгүен якламыйча, шул җәһәттән Ходайбирдинга да бик үк каты бәрелмичә, Кадыйров тәкъдиме белән килешү турында әйтте. Бу фикергә редактор белән прокурор Кашапов та кушылдылар.

Әлегә кадәр фикер әйтмәгән авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Хәкимҗанов шелтә бирү белән генә чикләнергә дигән тәкъдим кертте.

Сәхабка бу чыгышлар, әлбәттә, ошамады. Күңел төбендә нидер кайный, әйтеп бетермәгән сүзләре тел очына килә иде. Ходайбирдинны күрәләтә яклашып, мәсьәләне йомшартып сөйләүләр аның тынычлыгын бөтенләй бозды. Ул сүз сорады һәм тагын торып басты. Һәм менә ике ел инде болыннар нефть белән пычранудан юньләп печән алмаулары, күп кенә операторларның авылда яшәп, нефть эшендә эшләп йөрүләре, үзләре колхоз җиреннән түләүсез-нисез файдалануларын, ниһаять, колхозның балык үрчетү күленә нефть җибәреп ике меңгә алган маймычларны үтерүләре, колхозга егерме-утыз меңгә төшкән күлнең шуннан соң яраксыз хәлгә килүе турында әйтте. Скважина тирәсендәге дегет күлләренә бызел да колхозның дүрт бозавы, унҗиде колхозчы сарыгы батып үлүен дә калдырмады. Аннары ул, әнисен җирләргә дип, кайтып китәргә рөхсәт сорады. Бакир бюро членнарына күз йөртеп чыкты.

— Җибәрергә кирәк,— диде Мөршидә.

Барысы да шул фикергә ризалашып кул күтәрделәр. Сәхаб өстәлдәге ипигә тагын бер карап алды да чыга башлады. Шунда кинәт Ходайбирдин аңа:

— Иптәш Кадыйров, иписгезне алып китегез, монда ач кешеләр юк,— диде.

Сәхабның йөзе бурлаттай кызарып чыкты, күзләрендә зәһәр чаткылар күренде. Ул бурсынып, тәмам җан ачуы чыгып, бер мизгелгә генә туктагандай итте дә киң итеп кулын селкеп, ишеккә юнәлде һәм чак кына нелә төшеп, саубуллашмыйча чыгып китте.

Кинәт бүлмәдәге һава гына түгел, тыштагы атмосфера да кызып киткән кебек тоелды. Бакир, торып, үз янындагы тәрәзәнең бер канатын ачты. Кабинетка урамдагы машиналар гүләве, бала-чага чыр-чуы, бина түбәсендәге күгәрченнәр гөрләве, саф һава җиле агылып керде. Ләкин тәрәзәне ачу белән генә бүлмәдәге кызган атмосфера сүрелмәде, бәлкем минут саен кызганнан-кыза гына барды. Ходайбирдинның соңгы сүзе бюро членнарына ошамады, алар урыннарында борсаланып, Вәкил өчен кызарып утырдылар.

Ходайбирдин, Сәхаб сөйләгәндә йөзенә бәреп чыккан ачуын көчкә тыеп, мыегын чәйнәп утырган иде, ул чыгып китүгә, тирән сулап, урындык аркасына ауды, бер тын ярым йомык күзләре белән түшәм астындагы бронза люстрага карап торды. Шулай бераз утыргач, аның күнеле тынычлана төште, йөрәге тигез ритм белән тибә башлады. Ул яңадан тураеп утырды да янә кабинеттагыларга күз йөртеп чыкты. Әмма тагын берсендә дә тотнаклы яклау һәм аны кызгану карашы күренмәде. Шуннан соң вәсвәсәгә, шик-шөбһәгә калды. «Әллә чынлап торып каты шелтә бирергә уйлыйлармы тагын?»

Вәкил калтыранган куллары белән кесәсеннән бер кап сигарет чыгарды, кабызды, пистолет сыман зажигалкасын кесәсенә салмыйча күрше Хәкимҗановка тәкъдим итте. Хәкимҗанов рәхмәт белдерде, сигаретны алмады. Вәкил, төтен сөреме зиһененә җитеп, берничә секунд үтүгә, тынычлана башлавын тойды.

Өлкә вәкиле Насыйров сүз сорады. Ходайбирдин аңа текәлде, нәрсә әйтер икән дип, кулын янагына куеп тыңларга җыенды. Насыйров исә гел зурдан купты. Ул куенындагы блокнот эченнән берничә фоторәсем чыгарды, аларны бюро членнары алдына өстәлгә салды. Биредә нефтьчеләрнең гөнаһлары шактый җыелган иде. Фотолар өстәлгә куелу белән Ходайбирдин озын, сөякчел кулын янагыннан алды да фотоның берсенә үрелде.

Рәсемдә ике «С-100» тракторы лафет чабып үткән бодай тезмәләре өстеннән парафин чанасын тарталар иде. Менә бусын Вәкил белми иде әле, чөнки дәгъва белән килүче булмады. Ә менә монысын белә: ниндидер дуамал бер шофер, яңгыр явып узгач, сазлык-урман аша салган юлдан үтмичә, машинасы белән яшел уҗым өстенә кергән, әмма аннан да үтә алмаган. «Каян туры килеп төшереп алганнар?» — дип уйлап алды Вәкил, ниндидер саннар китергән Насыйровның сүзләренә колак салып. Соңгы рәсемгә Вәкил карамады, күршесе Хәкимҗановка шуышытырды. Бу фотода «Ленин юлы» колхозының пычратылган утыз гектар уҗымы иде. Картина матурдан түгел, аннары Ходайбирдин ул рәсемне күргән иде инде.

Насыйров, «Ленин юлы» колхозына нефть идарәсе ясаган зыяннарны искәртү белән генә чикләнмичә, район, республика күләменә дә күчте.

— Минемчә,— диде ул, һәр сүзенә басым ясап,— табигать байлыкларын бозып әрәм-шәрәм итүче, ул нинди генә яхшы җитәкче булмасын, әйтик, сәләтле инженермы, мактаулы эшче-хезмәткәр булсынмы, каты җәза алырга тиеш. Каш ясыйм дип, иптәш Ходайбирдин кебек, күз чыгаручы — скважинаны ике ремонт срогын үткәреп файдаланучы, нефть бирәм дип, кадерле икмәкне юк итүче коммунистка партия сафында урын булмаска тиеш. Мин, иптәшләр, җир бозу, сулар пычрату, табигать байлыкларын корытуга гамьсез караган Ходайбирдинны пар-

тиядән чыгарырга дигән тәкъдим кертәм. Һәм без аны идарә начальнигы урыныннан алу турында «Татнефть» берләшмәсенә киңәш бирүне дә кирәк таптык.

— Дөрес,— диде Насыйровның тәкъдимен куәтләп икенче вәкил Камалов.

Өстәлгә шап итеп ниндидер әйбер төште. Барысы да тавыш ягына карадылар. Өстәл уртасында Ходайбирдинның пистолет сыман зажигалкасы ята иде. Ходайбирдин аны үрелеп алмады, агарып киткән йөзен түбән иде дә бер мәл өнсез утырды.

— Скважинаны ике срок эшләтергә иптәш Ходайбирдин үзе кушкан. Кушып кына калмаган, хәтта приказ язган. Аның рөхсәтеннән башка өлкән инженер скважинаны ремонтка туктаткач, аңа шелтә биргән. Менә ул приказ, иптәшләр...

Сәгать уникене сукты. Мөршидә, торып, әле генә әйтелгән сүзләрне куәтләде. Чөнки эшнең куелышы бик житди һәм бик урынлы иде. Сәхаб хаты белән өлкә комитеты секретаре үзе кызыксынган һәм мәсьәләне тикшерергә үзе үк кешеләр сайлап жибәргән. Алар бюро членнары хокукында тәкъдим кертә һәм кул күтәрә алалар.

— Иптәшләр, тагын кем сөйләргә тели? — дип сорады Бакир гадәттәгедән кискенрәк тавыш белән.

Ходайбирдин белән янәшә утыручы авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы көтмәгәндә:

— Иптәш Насыйров тәкъдименә мин дә кушылам,— дип әйтеп куйды.

— Мин дә тәкъдимемне кире алам,— диде Тимерхан.

Ходайбирдинның язмышы ничек хәл ителәсе ачыкланганнан ачыклана барды.

Ходайбирдин исә артык түзеп утыра алмады, сүз сорап тагын кул күтәрде.

— Әйдә, сөйлә,— диде Бакир.— Ләкин конкретрак, кыскарак булсын.

Ходайбирдин алдындагы кызыл тышлы папкасыннан ниндидер кәгазьләр сайлап, аерып алды да аларны бер читкә тезеп куйды. Ул ашыкмады. Аңа тынычланырга, фикерен туплап, барысын ышандырырлык җавап бирергә кирәк иде. Ул үзенең көченә, акылына ышана иде.

— Иптәшләр,— дип башлады ул һәм, башын күтәрә төшеп, кабинеттагыларга күз йөртеп чыкты,— мин менә карап-карап торам да бередәге кайбер иптәшләрнең гап-гади хакыйкатьне тиешенчә дөрес аңламауларына шаккатам. Икмәк тә икмәк, дибез...— Ходайбирдин күз кырые белән генә өстәл башындагы түгәрәк ипигә карап алды.— Ә соң, иптәшләр, нефть?! Әллә нефть дәүләткә икмәк кебек үк әһәмиятле продукция түгелме? Әллә дәүләт нефтькә игътибарын киметтеме?!

Вәкил бер тынга сүзсез калып, каршында утырган Мөршидәгә текәлде. Әйтерсең, бу сорауны ул аңа бирде. Мөршидә йөзендә бернинди җавап чагылмады. Кулына кәгазь алып шуңа күз салды.

Бакир, Мөршидә тоткан кәгазь битенең җинелчә калтырап торуын күреп: «Нигә тартына, нигә гаепнең атта да, тәртәдә дә икәнен әйтми? Ходайбирдинның нәрсә эшләгәнен күргән дә, белгән дә бит ул... Әгәр шушы башбаштаклыкны, геологлар белән исәпләшмәүне туктата-тыя торган сүзне вакытында әйткән булса... Әллә Ходайбирдинның үсә-үстерелә барган абруе алдында югалып калган инде. Менә хәзер нәтиҗә ясау бүтәннәргә калды... һәм миңа да...» — дип тә уйлап алды.

Ә Ходайбирдин:

— Бүген Советлар Союзындагы һәр өченче двигатель Татарстан чыгарган ягулык белән эшли. «Ленин юлы» колхозындагы тракторлар да, мөгаен, су ягып эшләмиләрдер?.. Әллә су ягып эшлиләрме икән?! — дип, туп-туры Насыйровка карап текәлде. Гүя ул акыл сатмый, ә үзен-

чә төпле дәлилләр китерә иде.— Безнең идарә коллективы быел планнан тыш уналты мең тонна нефть чыгарачак. Күрәсез, иптәшләр, мәсьәлә җитди. Дәүләт планын вакытында тутырып үтәү, ул гынамы, аны арттырып үтәү — бар коллективка да тәтеми. Ә бит, иптәшләр, без аны айдан-айга, кварталдан-кварталга, елдан-елга арттырып үтәп киләбез. Социализм системасы капитализм белән шулай гына, конкрет саннар белән генә санаша, минемчә. Безнең ил нефть чыгаруда Американы куып җитәргә һәм узып китәргә тиеш! Әнә шуларны исәпкә алып, без өстәмә төстә тагын сигез мең тонна «кара алтын» чыгарырга булдык...

— Ни хисабына? — дип куйды Насыйров.

— Кем әйтмешли, кояшны кул белән каплап булмый, иптәш Насыйров.— Ходайбирдин аның ягына тиз генә карап алды да, уч төбе белән авызын каплап, тамак кырып куйды һәм кулындагы икенче бит кәгазьне күтәрә төшеп, бөтенләй бүтән нәрсә турында сөйләп китте.— КПСС программасында кешенең үз-үзен тотуы... аның коммунистик эшләре белән органик рәвештә бергә бәйләнеп барырга тиеш,— диелә. Ә менә мин «Ленин юлы» колхозы председателендә бу сыйфатларны күрмим. Кыскасы, юк-бар дәгъва белән нефтьчеләрдән кояшны капламак итә ул. Тәүге әйткәнемә тагын шуны өстәр идем.— Ходайбирдин өстәлдән тагын бер бит кәгазь алды.— Техник прогрессны тизләтү, производствога прогрессив технология кертү, скважиналарны механикалаштыру һәм автоматлаштыру җиңел эш түгел, иптәшләр. Күп кенә яңа алымнар безнең промыселларда сынала. Табигый ки, яңа эштә ялгышлыклар да булуы мөмкин. Бер скважина ике срок ремонтсыз эшләгән икән, димәк, ул үзенә киткән чыгымнарны бу вакыт эчендә тулысы белән каплаган... Бүгенге көндә безнең промыселларда туксан процентка якын скважина автоматка көйләнде. Хезмәтне фәнни оештыру нәтиҗәсендә ике йөздән артык тәкъдим производствога кертелде. Рационализаторларыбыз һәм уйлап табучыларыбыз...

Бакир каләме белән графинага суккалап алды.

— Туктагыз әле, иптәш Ходайбирдин,— диде ул идарә начальнигының озын һәм һәркемгә күптән мәгълүм булган нәрсәләр турында сөйләвен күреп,— сез авария турында гына әйтегез хәзер. Ни сәбәпле скважина шартлаган һәм сез өстәмә төстә бирергә җыенган меңнәрчә тонна нефть ни өчен «Ленин юлы» колхозының уҗым басуына аккан? Колхоз сезне шул мәсьәләдә гаепли. Бары тик шуңа конкрет дәлилләп җавап бирергә кирәк. Шул турыда гына. Юкса сез үзегезнең квартал отчетыгызны укый башладыгыз бугай...

Ходайбирдин, кулындагы кәгазьне селеккәләп, беравык ни әйтергә белми уйланып торды. Ул сизде, аңлады: аның чыгышын райком секретаре ошатмады.

— Җыеп кына әйткәндә, комиссия чыгарган нәтиҗә белән мин килешә алмыйм...

— Иптәш Ходайбирдин, тагын ни әйтә аласыз? — диде Бакир, инде түземен җуеп, карандашын күтәреп төшерде. Бу — җитте, артыгын иләүнең кирәге юк, дию иде. Ә тәмам кызып киткән тел тегермәне һаман әле туктый алмыйча азаплана бирде:

— Инженерга каты шелтә бирүем хак. Ләкин ул скважинаны ике срок эшләтеп без, әйткәнемчә, меңнәрчә тонна өстәмә нефть алдык һәм ничәмә йөз метр торбага экономия ясадык. Мин иң әүвәл әнә шул нәрсәләрне исәпкә алып яздым ул приказны, иптәшләр...

— Һәм меңнәрчә тонна нефтьне колхоз басуына агыздыгыз,— диде Бакир торган саен ачуы кабара баруын тоеп. Бәхәсне туктатырга вакыт иде.

— Беттеме сүзегез, иптәш Ходайбирдин?

— Бетте.

— Утырыгыз...

Мәсьәләне тавышка куйган арада Вәкил эчтән: «Мин билетымны бирмим. Мине партиядән чыгарырга хаклары юк!» дип кенә дулап алырга өлгерде. Тавышлар бердәм булгач исә:

— Иптәшләр, нәрсә бу?! Мин Үзәк Комитетка язачакмын... Мин...— дигән булып тәмам тынды.

Ялтырап торган өстәлгә аның кулындагы фото килеп төште. Хәкимҗанов аны сак кына үрелеп алды да беренче секретарьга суздьı.

Ходайбирдин урыныннан сабыр гына торды да, озын кулларын асып куйган казылык сыман салындырып, ишеккә таба китте.

— Иптәш Ходайбирдин,— диде аңа Тимерхан,— зажигалкагызны алыгыз!..

Ходайбирдин дәшмичә генә борылып караган булды һәм бер сүз дәшмичә ишекне ачты. Ишек ачылып ябылган арада бүлмәгә кергән җил ипи астында яткан газета почмагын лепердәтеп, өстәлгә тидергәләп алды. Ходайбирдинга кемдер аның артыннан кул чабып калды кебек тоелды...

— Бюро ябык, иптәшләр,— диде Бакир һәм тирән көрсенеп каршында яткан фотога үрелде. Һәм гүя кулына Ходайбирдинның партбилетын алды...

Секретарь булып эшләү дәверендә Бакир Галиев коммунистларның партия сафыннан чыгарылуларын һәрвакыт авыр кичерде һәм ничектер бу хәлдә үзен дә бераз гаепләде. «Димәк, райком да нәрсәнедер үз вакытында күрми калган»,— дип уй йөртте, партиядән чыгарылган коммунист башын иеп бюродан чыгып киткән саен.

...Сәхабның автовокзалга килеп билет алуы һәм автобуска кереп утыруы булды, авыз эченнән кемнедер сүгә башлады. Автобус кузгалыр алдыннан гына Сәхаб кырына кереп утырган шактый тере карчык тимер теш белән тулган авызын ачып бер тын күршенә карап торды да:

— Җә аллам, нинди адәмнәр генә юк бу дөньяда,— дип сөйләнә-сөйләнә, кулындагы төенчеген җыя төшеп, икенче урынга күчеп утырды.

— Кем тыярга тиеш аларны партиядән башка!? Кем?!.. Кем аларга чик куярга, икмәк бәясен аңлатырга тиеш?!.. Помшак итеп сөйләшергә ярыймы соң андыйлар белән! Моның өчен аны судка бирү дә аз бит!..

Сәхаб бюро нәтиҗәсен белми иде. Ул: Ходайбирдинга хәтта шелтә дә бирмәсләр микән? дип шулай эчтән кычкырып уйлый. Шуңа аның каны кайный, шуңа дулый, шуңа кемнедер орыша, җаны әрнеп сүгенә иде.

Олы юлда автобустан төшеп калгач, Сәхаб тар сукмактан авылга таба атлады. Үтәсе юлы арыш басуы аша иде. Шуны тагын бер кат күреп үтәргә туры килде. Менә ул сортлы арыш кишәрлеге. Туктамыйча, күз ташламыйча үтәргә уйлаган иде дә, булдыра алмады. Туктап, йөрәге кысылып, күзенә яшь йөгергәнче басуга карап торды. Ул, мамыгы чыга башлаган кош баласын кулына алган кебек, иелеп бер уч уҗым алды да дегеткә баткан яшел кыякларга озак итеп, яшь пәрдәсе аша карады. Күз алдына әнисенең йомшак күзләре, салкын маңгае, коргаксыган куллары, шул куллар кичә генә пешергән түгәрәк арыш ипие, уңышка зур өмет баглап, сөйгән кызы белән мәш килеп арыш чәчеп йөргән улы Алик килде.

Аликка һәм аның «кызына» ни дип җавап бирер ул? Үстерә алмадым, саклап булмады сезнең кадерле сортлы арышыгызны диярме? Ата кеше өчен шушы җавап! «Чәчбиен» Мөршидә кызы, диделәр. Улы кызына гашыйк, әтисе кайчандыр әнисен яраткан... Я дөнья, нинди язмышларга гына дучар итмисең син адәм баласын!..

Сәхаб күзләрен кул сырты белән сөртеп алды да янә уҗым басуына күз ташлады.

Ике көн буе әнә шул трубадан нефть катыш су ургылып торды. Ике көн буе уҗым җирендә янгын машиналары, бульдозерлар, кешеләр нефтьне туктатырга тырышып кайнаштылар. Ике көн буе Ходайбирдинны сүгеп кайткан Сәхаб йөрде бирелә. Ике озын көн буе... Аннары дәү-дәү машиналар махсус казыган чокырга җыелган нефтьне суырып алдылар. Скважина тирәсен генә түгел, бөтен сортлы арыш җирен астын-өскә китереп, таш, кызыл балчыкка кадәр казыдылар, чокыдылар, эштән чыгардылар һәм, нефть агымын туктаткач, берни булмаган кебек, кайтып киттеләр... Басу әле булса шулай тора.

Сәхабның күңел хәтеренә ни өчендер мәшһүр рәссам Брюлловның «Помпейның соңгы көне» дигән картинасы килде. Һәм ул аны хәзер генә аңлаган кебек булды. Әйтерсең лә, арыш кырында шуңа охшаш зилзилә, афәт булып үткән иде. Әйе, бик күп еллар берни дә үсмәячәк хәзер бу уңдырышлы басуда. Шунда ул, күтәрелеп, бәлки син безнең кырны ике-өч елдан икмәк игәрлек итәрсең дип, кояшка күз ташлады. Кояш, берни булмаган кебек, үзенең мәрхәмәтле, шифалы һәм җылы нурларын җир өстенә коя иде.

Сәхаб сукмакка төште дә тиз-тиз атлап авылга таба китте. Анда аны, җеназаның бөтен эшен инде бетереп, әнисен күмәргә дип көтеп торалар иде.

Бакир һаман Әминәсенә: «Фәлән числога сезне кайтып алам»,— дип, хәбәр итә алмый торды. Аңа квартира мәсьәләсе хәл ителгән булса да, җылы якка, улларьі янына китәргә җыенган бер пенсионер семьясы, анда бик эсседер дип, китми тора иде. Бакирга райком бинасыннан бер квартал аша гына булган шул квартираны сайладылар. Квартира мәсьәләсен Мөршидә ашыктырды. Сезгә, Бакир Әхтәмович, тизрәк семьягызны китертергә кирәк дип, гел әйтә торды. Әмма пенсионерлар һаман китә алмыйлар иде әле. Әнә шуңа күрә, теләсә-теләмәсә дә, Бакир һаман гостиницада яшәде.

Беркөнне Мөршидә: «Картлар киттеләр, Бакир Әхтәмович, семьягызны кайтып алып килегез»,— дигәч, Бакирның йөрәге тыпырчынып куйды. Шунда ул квартираны буяп, рәткә китергән арада, ниһаять, Мөршидә белән сөйләшергә кирәк дигән катгый бер фикергә килде.

Шул көннәрдә генә терлекчеләрне райүзәккә җыеп киңәшмә үткәрделәр. Соңыннан район культура сараеның үзешчән түгәрәк коллективы концерт куясы турында әйтелде. Бакир Мөршидә янына килеп утырды һәм концертны азагынача карарга булды. Мөршидә бик иркенләп утыра. Хәер, ул бер концертны да калдырмый йөри иде, житмәсә бүген колхозларга бер ай ярдәм иткәннән соң бер атнага ялга дип кайткан Нәзиләсе җырлыйсы икән. Бакирга ул: «Хәзер минем Нәзиләм чыга»,— дигәч, Бакир йөрәгенең еш-еш кага башлавын тойды. Ул янәшәсендә утырган Мөршидәнең терсәген сизеп, сәхнәгә чыгып баскан сылу зифа буйлы, кара кашлы, кызгылт чәчле, римлеләр борынын хәтерләткән төз борынлы чибәр кызны күрде. Күрде һәм гүя, яр өстенә ташланган балык кебек, еш-еш сулыш ала башлады. Бакирның йөрәге бер кысылды, бер бушанып китеп шашынып тибә башлады.

Җырлаучы кыз Бакирга суеп каплагандай охшаган иде.

«Димәк, бала безнеке. Мөршидә беркемгә дә, һичкайчан да кияүгә чыкмаган?!»

Бакирның йөрәге дөрләп янып китте. Юк, ул янып кына калмады, ул чәбәләнде, ул ни кылырга, ни эшләргә белми чарасыз калып дулады.

«Мин хәзер үк аңардан сорарга тиеш, хәзер үк!»

— Мөршидә!

Мөршидә дә бирелеп кул чаба, залдагылар да Нәзиләне гөр килеп алкышлыйлар иде. Ул Бакирны ишетмәде, аңа таба карамады. Бакир ниндидер сәер кимсенү тойды. Бакирга Мөршидә аңардан күптәнге ачуын, үзенең дә кайчандыр кимсенү ачуын ала кебек тоелды.

— Мөршидә!

— Нәрсә, Бакир Әхтәмович, әллә сезгә ошамадымы минем Нәзиләм җырлавы?

— Ошады. Бик моңлы тавыш...

Бакир Мөршидәгә төбәлде. Мөршидә аның күзләрендә яшь элпәсе күреп, көлемсерәп куйды, шунда ук йөзенә курку сурәте чыкты.

— Әллә авырыйсызмы, Бакир Әхтәмович?

— Юк, җыр бик моңлы булды, әллә кайчангы яшьлекне искә төшерде,— диде Бакир, карашын түбәнгә текәп.

— Хисле кеше идегез шул,— диде Мөршидә, кинәт елмаеп.

Бакир дәшмәде. Һәм аның елмаюын да күрмәде. Бу сүзләр артында киная барлыгын яхшы аңлый иде ул.

— Минем кайтасым килә,— диде Мөршидә беренче секретарьның баш иеп утыруын күреп. Күрше-тирәдә утыргannar аларга игътибар итәләр, чышын-пышын сөйләнәләр: Мөршидәнең киту сәбәбе шул иде.

— Мин сезне озатам,— диде Бакир, тавышын шактый күтәреп. Мөршидәнең сыңар кыйгач кашы өскә сикерде.

— Озатыгыз, ләкин сезгә концерт караганда әйбәтрәк булыр иде,— диде Мөршидә.

Бакир тора ук башлады. Мөршидә дә күтәрелде һәм Бакирдан алда ишеккә юнәлде.

Урамга чыгу белән, әдәп йөзенйән дигән булып, Бакир Мөршидәне култыклап алды. Һәм Мөршидәне янында тоюга күңел түренә Казан урамнары, анда кайчандыр бергә йөргән кичләр килеп басты.

— Мөршидә,— диде ул, кинәт йөрәгендә калыккан шул хискә бирелеп,— хәтерлисеңме?!

Шунда ук сискәнеп тә куйды: «Нигә хәтереңдәме, нигә хәтерегездәме түгел?»

— Хәтеремдә,— диде Мөршидә, кус күкрәк тавышы белән.— Ай, ничек хәтеремдә әле, Бакир!.

— Гафу ит мин җүләрне, Мөршидә...

— Гафу итәргә, сине?! Мин?! Ни өчен?!

Бакир ни әйтергә сүз тапмады.

— Әллә син, Бакир, бала синеке дип барасыңмы?..

Күптән көткән иде бу сорауны Бакир, аһ, күптән көткән иде! Әмма болай тыныч төстә, гап-гади итеп бирелер дип һич тә күз алдына китермәгән иде.

— Әйе, Мөршидә. Шулай бит, минеке?!.

Бакир Мөршидә каршына басты, аның ике терсәген кысып, күзләренә туп-туры карады.

Мөршидә, бар җан-сабырын җыеп, тыелып калды, тыныч булырга тырышты.

— Их, Бакир!.. Син бер хакыйкатьне һаман аңламыйсың... Юк, Нәзиләнең әтисе син түгел. Аның әтисе үлде, юк аның әтисе хәзер...

Алар, сүзсез калып, мәйдан аша үттеләр һәм тротуарга төштеләр. Үзәк урам көндезге кебек якты иде. Алар янынннан чыр-чу килеп, уйнап-көлеп, бер төркем яшьләр үтте. Октябрь аенда төннәрен җир туңа, көндез яуган яңгырдан җыелган күләвекләр юка боз элпәсе белән каплана. Ике арадагы киеренкелекне беренче булып эретергә базмыйча атлаган Бакир ялтырап торган күләвек өстенә басты. Һәм аяк астында чылтырап боз ватылганны ишетүгә, Мөршидәдән ишетергә теләгән җавабы да боздай челпәрәмә килүен аңлады. «Баланың кемнән икәнен

әйтергә теләми. Хәер, ул бала хәзер чын әтисе табылуга мохтаҗмы? Әлбәттә, юк. Шуңа күрә Мөршидә әйтми дә...»

Көзге кич аяз иде. Күк гөмбәзендә исәпсез-сансыз йолдызлар җемелди, ерактагы Сөләй тавы артыннан ай кыйпылчыгы калкып килә.

Мөршидә, янында Бакир атлаганда, әчтән янып барды. Аның күз алдыннан бу районга килү чоры узды. Килгәч тә райкомның промышленность бүлегенә инструктор иттеләр. Мөршидә бөтен күңелен, булган сәләтен биреп, күңеленә ошаган эшкә башыннан чумды. Шунда аның артыннан — ул вакытта әле авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы — Сафа Садыйков йөри башлады. Ул шундый булды ки, һәр очрашу әмәленнән файдаланып, Мөршидәгә турыдан-туры мәхәббәте турында белдерде. Бер атна алдан билет алып, театр-киноларга чакырды. Кич йөрергә чыккач, яттан шигырьләр сөйләде, прозадан өзекләр укыды, кайчак кинәт тынып, оялып, Мөршидәнең кулыннан тотарга куркып, янәшә атлый бирде.

Әүвәл Мөршидә берни әйтмәде, сиздермәде. Сафа аннан уңлап яшькә олы иде. Йөрәктәге яра да төзәлмәгән, яңа иде әле. Кемнедер якын итәрлек, кемгәдер сыенырлык көч таба алмам дип тә уйлады Мөршидә. Шул вакытта аның бөтен күңелен бушатасы, кемгәдер бөтенесен сөйлисе, әрнүле йөрәген җиңеләйтәсе килә иде. Күңел тыйнак Сафага тартылды. Ун көн бергә булып, Сафа аның хәтта кулын да тотмады. Аның шундый инсафлыгы, шигърият дөньясын белүе, тормыш тәҗрибәсе, дусларча ышанычы Мөршидә күңелендәге юшкынны чак кына эреткәндәй итте.

Шул чакны Сафа бер атнага Казанга киткәч, Мөршидә үз янында кемнеңдер җитмәвен тойды. Ике-өч көннән ул хәтта аны юксына башлады. Сафаны, аның ышанычлы, садә-гади карашын күрәсе, шигырьләрен тыңлыйсы килә башлады. Сафа да кайтып төшү белән аның янына керде. Ниндидер бүләк алып кайткан иде, аны Мөршидәгә сузды. Өстәл артында нидер язып утырган Мөршидә шатлыгыннан нишләргә белмәде.

— Миңамы? Эчендә ни?..

— Ачып кара, аннан белерсең,— диде Сафа, көлемсерәп һәм өстәл почмагына килеп утырды. Ул елмая-көлә кәгазь тартманы ачучы Мөршидәгә карап торды. Тартма эченнән ут күзле, йонлач эт баласы килеп чыкты.

— Нигә бу миңа, Сафа?

— Туачак бәбигә,— диде Сафа.

Мөршидәнең бит-йөзенә, әйтерсең, ут капты. Ул шул тикле оялды, чак кына йөгереп китмәде, хәтта ул чыгарга теләп, өмсенеп тә куйды. Ләкин Сафа аның кулына кагылды, ялварулы күз карашы белән:

— Гафу ит, Мөршидә, аптыраганнан алган әйбер,— диде.

Мөршидә аның җете зәңгәр күзләренә сынаулы сирпелеп алды һәм Сафа йөзендә чынлап та бүләк өчен үкенү күреп:

— Рәхмәт инде алай булгач,— дип, эт баласын җентекләп карый башлады. Ә үзе уйлады. Мин аңа бала турында әйтергә тиеш. Бүген үк әйтергә тиеш. Мин аны алдый алмыйм. Чынга киткәнче бу турыда белергә тиеш ул!

— Әйт әле, Сафа, уенчык алырга булгач, нигә син миңа эт баласы алдың, нигә аю баласы алмадың?

— Беләсеңме ни өчен?

— Ни өчен?

— Чөнки эт кешенең дусты, ә аю кыргый җанвар.

Мөршидә рәхәтләнеп көлеп алды. Сафаның шаяртуы аңа ошады, ул тынычлана төште, битенең кызышуы сүрелә башлады.

Кич белән алар озак итеп урамнарда йөрделәр. Сафа Казан турында, шәһәрнең исеме каян килеп чыгу турында сөйләде. Ә тулай торак-

а борылып кайткач, кинәт өйләнешү турында тәкъдим ясады. Бу шул адәр гади әйтелде ки, хәтта Мөршидә башта ишетмәгәнгә салышты. Іәкин Сафа чынлап торып аңардан катгый җавап таләп итә иде. Мөрпидә кинәт боегып калды, хәзер, хәзер, хәзер барысын да сөйләп биәм дип, дулаган күңеле нигәдер икеләнә калды.

— Чынлапмы, Сафа?..

Сафа аны үзенә табарак тартты, подъезд күләгәсенә әйдәде.

— Риза бул. Без бик матур яшәрбез,— дип пышылдады ул, Мөрпидәне кочагына алып.

Мөршидә кисәк читкә тайпылды, лампочка яктысына чыкты.

— Сафа!.. Мин сиңа бер сүз әйтергә тиеш...

— Әйт, Мөршидә... мин...

— Тукта! — Мөршидә Сафа янына үтте, шактый караңгы булуга арамастан, егетнең күзләренә карады.— Син башта минем кем икәемне белергә тиеш, Сафа!.. Соңыннан үпкә-үртәштән булмасын...

Һәм Мөршидә энәсеннән-җебенә хәтле барысын да сөйләп бирде. Іерәүне яратуы, ләкин аның белән һичнинди вәгъдәсез аерылышулары ıәм үзенең бала көтүе турында әйтте.

Сафа аны гаять тыныч төстә тыңлады һәм бөтенесен дә алдан уйлаан кебек:

— Моны гомеремдә дә синең исеңә төшермәм, Мөршидә. Шикләнә, баланы мин үземнеке итеп тәрбиялярмен,— диде.

Мөршидә шуңа шаккатты. Әйтерсең, боларның барысын да Сафа ıелгән һәм барысын да «әйе-юк» бизмәненә салып үлчәгән иде. Ул аңа йләнергә риза, ул аңа өйләнә! Күктән ашкан бәхет иде бу Мөршидә чен. Ә бит күпме көйде, күпме кайгырды ул! Ничәмә төннәрен йокыыз үткәрде Сафага бу хәбәрне әйтү-әйтмәү турында икеләнеп! Ә ул, йтерсең, аны белгән, әйтерсең, Мөршидә бернинди ялгышлык та эшләәгән, ул аңа өйләнергә гарьләнмиl..

Мөршидә, чарасыз калып, Сафа кочагына чумды, кайнар иреннәре ıеләп аңа сыенды. Аннары Мөршидә Нәзиләне тапты. Сафа һәр көн ıала табу йортына килде. Һәр көн күчтәнәчләр, «Кагор» виносы китерıе. Шунда ул үз-үзен бер нәрсәгә ышандырды: бала — Сафаныкы. Ул ıның чын этисе.

Кеше йөрәге мәхәббәттә тылсым белми, ул чын күңелдән ярата һәм шуңа кайтаваз табып ышана гына белә. Мөршидә Сафага үзенә ышанандай ышанды. Юк, юк, Бакир, мин сине мәңгегә күңелемнән сызып ашладым. Мин кече күңелле, саф вөҗданлы, миңа булган сүнмәс ıәхәббәтле кеше белән яшәдем. Ул минем өчен изгеләрнең изгесе булып калачак. Инде язмыш кушып, кем белән булса да тормышым бәйләргә уры килә икән, мин бары тик аның кебек кешегә сыеначакмын. Мин дә нде, Бакир, зур тәҗрибәле тормыш мәктәбе үттем. Без барыбыз да тызлардан соң гына тормыш, гаилә, бала турында тирәнтен уйлый, чын ıагънәдә кайгырта башлыйбыз икән. Ә ул акыл миңа хәтта соңгарыбıак та килде бугай. Бәлкем ул сиңа да шулай килгәндер? Юк, Бакир, ок! Бала синеке түгел. Ул — Сафаныкы. Аның әтисе Сафа. Нәзилә ашканы белми. Ә ул үлде. Ул юк хәзер, юк! — дип эчтән өзгәләнде Мөршидә. Аның бу сүзләрне, боларның барысын да кычкырып, күзенә ıәреп, хәтта кирәк кадәр оялтып, Бакирга әйтәсе килде. Ләкин ниндиıер эчке сабырлык, ниндидер көч аны бу адымыннан тыеп калды.

...Кайтып җитәргә ерак калмаган иде инде. Мөршидә әллә култыкерсәгендә Бакирның кулын тоеп, әллә салкынга чиркаңып, калтырап уйды.

— Ә нигә син мине озатасың, Бакир? Әллә мин үзем юл белмимме? ашка берәү булса, мин бәлкем бу сүзләрне әйтмәс тә идем, әмма син улгач?..

— Мин нибарысы синнән мәрхәмәтле булуыңны гына телим.

— Мәрхәмәтле булуымны?! Ярый, сөйләшү кайчан да булса булырга тиеш иде,— Мөршидәнең хәтта сөйләшү тоны да алышынды.— Һәм менә без, ниһаять, бүген төенне чишәргә тиешбез. Шулай түгелме?

Бакир кинәт кенә сүз әйтә алмады. «Күр аны, никадәре һавалылык!..» дип кенә уйлап өлгерде.

Мөршидә чак кына тынып алды да сүзен дәвам иттерде:

— Без бер нәрсәне онытмаска тиешбез, Бакир Әхтәмович: нинди урында утырабыз. Кем булып эшләвегезне искә төшерергә әллә? — дип сорады Мөршидә кисәк кенә «сезгә» күчеп.

— Минемчә, үз хисләрен ачыктан-ачык әйтеп белдерергә һәр шәхес хаклы.

— Юк, Бакир Әхтәмович. Безгә хәзер хисләр яңарту турында уйларга просто оят. Эшебез болай да күп.

Мөршидә бер тын сүзсез барды.

— Ә шәхси мөнәсәбәткә килгәндә,— дип дәвам итте ул,— баланы мин кияүгә чыгып таптым...

Бакир чигә тамырларының дылк-дылк итеп тибүен тойды. Йөзе комачтай кызарды, колаклары шәмдәй янды. Ярый әле, көндезге кебек якты түгел иде, Мөршидә аңа карамады, ә үткән-сүткәннәр күренмәде.

— Кем иде ул?

— Садыйков. Беренче секретарь.

— Садыйков?! — дип кайтарып сорады Бакир, үтә гаҗәпләнеп.— Сез «икенче» идегезме?

— Юк, белгәнегезчә, мин ул вакытта инструктор гына идем. Сафи үлгәч, икенчегә сайладылар.

Беравык икесе дә үз хатирәләренә, үз уй дөньяларына чумып, уйланып бардылар. Мөршидә тыпырдап алды — аның аяклары өши башлады. Бакирның да бармак очларын суык чеметеп куйды. Ләкин өши барган саен, тәненә салкын йөгергән саен ул тынычлана калды. Дулкынланган күңеле, ташудан соң үз урынына төшкән елга кебек, талгынлана, сабырлана төште.

— Ә мин сине оныта алмадым.

Мөршидә җавап бирмәде. Ул бу сүзләрнең мәгънәсендә бераз хаклык ятканны белә, хатын-кызларга хас сиземләү белән тоя иде: Бакир, егерме ел элек булгандагы кебек, икейөзлеләнми. Ләкин Мөршидәнең күңеле, йөрәге аны үткәне өчен кичерми, гафу итми иде.

Сөйләшү торган саен рәсмиләшә төште, әйтерсең, ике арада боз тавы калыкты да һаман үсә, зурая барды. Моны Бакир бик яхшы тойды, бик әйбәт һәм ачык аңлады.

«Ярый, бала турында инде әйтмәсен дә ди. Ләкин ни уйлый, кемне ярата бу Мөршидә? Кемне сайлады бу каһарман хатын?»

Уйларга бирелеп, ул Мөршидәнең сөйләүдән туктап тын гына баруын һәм өенә кайтып җитүен сизми дә калды. Мөршидә: — Менә минем өем. Озатуыгыз өчен рәхмәт! — дигәч:

— Кем? — диде ул машиналь төстә, каһарман хатынның аңардан ни сораганын ачык белүен искәреп...

Мөршидә китә башлады.

«Тукта!» дигәч тә дәшмәде, китә бирде...

Бакир, Мөршидәнең ерагая барган аяк тавышларына колак салып, үзенә бик якын да, шул ук вакытта бик ерак та булган бу кешегә бөтен эче тулы сагыш белән карап калды. Ә сер дигәне, егерме еллар элек булгандагы кебек иде: мәхәббәт йөрәк белән туа, акыл белән үлә, ул беркайчан да икеләнүне кичерми һәм кичерә дә алмый.

## Равил Фәйзуллин

### Вакыт

Вакыт ныгырга,
катыланырга!
Бу дөньяда
атың алырга!

Вакыт, бик вакыт —
бизәп җиренне,
эштә расларга
егетлегеңне!

Вакыт — үз-үзең
булып калырга!
Ил-Ватан кушса,
башың салырга!

Вакыт, бик вакыт
катыланырга!

1970.

●

Сөйли. Җитди. Хак эш өчен
шәһит киткәнмени!
Хәер, үзеңне акларга
дәлил беткәнмени!

Мещан җанның фәлсәфәсе —
кадими фәлсәфә:
«Ничек яшәсәң дә яшә, тик
тук һәм рәхәт яшә!
Борчылулар, көенүләр,
тетрәүләр нигә?
Кеше фани дөньяга
яшәү өчен килгән!»

Куркаклыгын, пошмаслыгын
төбәп әйтсәң аңа,—
дөрес яшәвен исбатлап
ул мең җавап таба.

Ә нәрсә ул акланулар!
Хөкем залларында
«акланыр» сүзләре була
сатлык җаннарның да.

Намуслыга нигә аклану?
Нигә дәлилләрең!
Аклауга мохтаҗмы эше
Тукай, Җәлилләрнең!

Тормышның тәрәккыятен
син Тарихтан сора:
Дөнья — фидаи җаннарның
януында тора!

Яшәсә кеше янусыз,
тик үзе өчен һәм сак,
Битараф та булса, ул —
потенциаль куркак!

Ышанма тасма телләргә,
кылган эшкә кара!
Суфи кук оеп торамы,
көрәшкәме бара?
Үз бурычын үтәгәнме?
Таләп ит һәм сора!
Гөлбакча җиребез әле
кыл өстендә тора...

1970.

●

Ни генә дә җиккесез!
Чапты заман — җиткесез.

Нинди ил юк, нинди җир юк
һәм кемнәр юк җиһанда!
Җисмән, белмим, рухи һаман
бар коллар да, би-хан да!
Тавыш тизлеге таман —
ыргылып чаба заман!
Ә үткәннәргә баксаң,
бүгенге биеклегеннән
киләчәккә күз атсаң,
бер инану — кемнәр белән,
ничек чапса да заман,
асылы шул ук һаман —
бер кайчан кабатланмас,
бер мизгелгә дә тынмас
көрәш! Үзәктә — Кеше —
язмышлар бәрелеше!
Бар үткәннәрне хурлап,
алдагын гына зурлап,
була ул җырлап көйләргә.
«Җиттек әллә ниләргә!»
Җитсәк тә әллә ниләргә,
барыбер иген игәргә,
тынычлык кирәк көйләргә,
бәрәкәт кирәк илләргә...

Куркак кулыннан киләме
Дөрескә юл яра алу?
Заманның һәм Халкының
улы булып кала алу
бик җиңелме?
Бу — бүгенме?
Бу сүз әллә бик борынгы
берәр шагыйрьнең өнеме?

Ни генә дә җиккесез!
Чаба заман — җиткесез!
Төшәрләр айны кысп...
Нур түгеп һәм сагаеп
калды җиһан.

1970.

●

Космополит түгел. Шөкер. Минем
халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын: «татарныкы» диеп
төртеп күрсәтмимен ал таңга.

Минеке дип белмим күкне, айны,
мөһер сукмыйм ел фасылына.
Милләт исемен такмыйм урман-суга,
агач-ташның иң асылына.

Һәммә гашыйк, һәммә халык өчен
бар Табигать — уртак Матурлык.
Барыбызга да газиз Матурлыкны
берәүнең дә
үзенеке ясар хакы юк!

Кояшка һәм Күккә бар да тигез.
Без табигать балалары ла!
Без һәммәбез тигез. Кая? Кемнәр
ак сөякле, зәңгәр канлылар?

Соң безнекеләр Ил-туфрак өчен
яуларда баш салмадылармы?
Уртак Ватан өчен Парижларны,
Берлиннарны алмадылармы?

Шуңа күрә горур, тынычмын мин.
Халкым да бар, ил дә, Ватан да!
Уртак могҗиза дип карыйм мин кояшка,
барыбызныкы дип карыйм ал таңга!

Мина житә — халкым, Ватаным бар.
Матурга да бик нечкә күңел.
Кем кылана, димәк — житми. Ә без?
Без болай да бәләкәй түгел!

1969.

## Идел ага

Идел ага. Пароходтан —
акчарлаклар, таллар кала,
чиркәүле авыллар кала,
карлыгачлы ярлар кала.

Идел ага. Күпме аккан
ул Ра булып, Әтил булып,
Волга булып... Зур дәрьяга
халыклардан вәкил булып.

Идел ага. Кешеләр буса —
җәелеп ага, тулып ага.
Дулкын булып кына түгел,
жыр-дастаннар булып ага.

Идел ага. Без агабыз.
Артта маяк, саллар кала.
Култыкларда пристаньнар,
яулык болгап ярлар кала.

Идел ага. Ул — мәңгелек.
Кай елгалар кибеп кала...
Иделең белән акканда
жанда барыбер өмет кала.

1970.

●

Тугры дусың улмы, бумы?
Бүген кысышкан бу куллар
егылсаң, сузылыр кулмы?
Тайпылсаң, бу нурлы күзләр
ялгышың төзәтер күзме?
Киләчәккә ант-вәгъдәләр
буш авазмы, ихлас сүзме?
Карыйм төбәп, карыйм сынап.
Күзләрдән — күңелгә ара
уйлаганнан күп чак ерак!
...Сындырып сынный дөнья.
Дусларны чәчеп җыям.

1969.

## Этюд

Сина,
Батаман истәлеге итеп.

Адаштык. Төн килә өскә.
Урман — кара, җил — шомлы...
Ни өмет караңгы җирдә?
Күк, табышсана юлны!

Күктә дә капкач болыт шул,
ул да — йолдызсыз, ятим.
Яңгыры кемгәдер шифа,
тик безгә — каһәргә тиң.

Бар тирә-як шомда, ымда,
нидер сагалый сыман.
Кайдадыр Алмазга охшаш
яшь бала елый сыман.

Ниндидер көч кәлә кебек:
«Нишлисез инде, ягез?..»
Куанма: болар сансыз, дип,
без дә кемгәдер газиз!

Адаштык шул. Ярый син бар.
Ярый син янда гына!
Барабыз икәү — йөз ачык —
Билгесез алдагыга.

1970.

## Бу сөю...

Бу сөю — диңгез икән дә,
иксез дә чиксез икән!
Туйганчы талгып йөзәргә
гомер җиткесез икән...

Бу сөю — тормыш-яшәүнең
Тылсымлы Иле икән.

Кешедә гомер картаймас
җанның яшьлеге икән.

Бу сөю — Бөек Мәгънә —
Бәхетнең үзе икән.
Аңа таба онытылып
йөгер, оч һәм йөз икән.

1970.

●

Булчы, зинһар, зәңгәре син
салават күперенең!
Нишләве бу зәңгәр күзнең?
Яндыру-өтүеме?
Бу хисем — үсүемме соң,
әллә дә бетүемме?

...Иң яхшысы бул, зәңгәре
салават күперенең!
Зәңгәрлегең ялкынында
тилермәс, янмас идем.
Күккә төбәлер идем дә
күземне алмас идем.

1969.

●

Хиссият Илендә икәү
әйдә, гизиек әле!
Теләк бакчаларыбыздан
гөлләр өзиек әле!
Иш килгәннәрен аралап,
бергә тезиек әле!

Әйтсәләр әйтерләр инде:
«Ярамый! Тыела!» — дип.
Тик соңыннан әйтмәсеннәр:
«Их, әрәм!.. Коелган...» — дип.

Тартынмыйча хөр йөрик бер
бакчабызда үз булып,

Назга сусаган бер гөл дә
калмасын мәэюс булып.
Рәнҗемәсә кешелегең,
фатиха булса җаннан,—
тыйма мәхәббәт ташкынын
сихерле тыелганнан!
Әйдә, урнашсын бер мәлгә
Синдә шәхси үз әдәп.
Бәлки, мәҗнүни бу мизгел
бүтән кайтмас сәгадәт?..
Онытылып, иркәләп бер,
әйдә йөриек әле!
Серле, тансык гөлләр өзеп,
уйнап-көлиек әле!

1969.

## Соңгарган шаһит

Чабып килгән. Янган-пешкән.
Тормый сүзләр сайлап.
Яралы ярсу җаныннан
чыга сүзләр кайнап.

Ялварамы? Боерамы?
Ләгънәтлиме әллә?
Исәрме? Хәкимме? Сөйли
тетрәндергеч хәлләр!

Сөйли бөтен тәне. Яна,
бер куя күк өшеп.
Сүзе белән сер-төенне
ташлый гына чишеп!

Менә ничек икән бит ул!
Менә ничек булган!
...Вакыт үзе үкенүдән
илереп елар сыман!

Сөйли шаһит. Сөйли. Сөйли...
Һәрбер сүзе — хәнҗәр!
Хак сүзен аның бүләргә
кыймас хәтта әҗәл!

. . . . . . . . . . . .

Их! Ичмасам бер генә җан
тынлый алса икән!
...Беркем юк шул... Карар чыккан.
Хөкемдарлар киткән.

1969.

## Сигезьюллыклар

Язсам гына яшәвемне раслыйм.
Юньле эшем — йөзем аклыгы.
Язсам гына — Җирнең улы булып,
сөелүгә-назга хаклымын.

Язсам гына — бәхетем тулы, бөтен.
Язу эше — намус, кан эше.
Язсам гына — илгә, кешеләргә,
Файда итсәм генә мин кеше.

1970.

●

Мөмкинлегең — чигең узып,
тәкъдирең язганын бозып,
күкләреңне биегәйтеп,
һәммә тарлыкны киңәйтеп,
алга барыш.

«Нинди көч бу?! Каян килә!»
Иш кыланып, син төпченмә!
Иманы, хыял-теләге
көчле булган үзе белә.

1969.

●

Юрадылар: бу — яшь, кайнар —
ерак һәм озак баралмас...
Бәхеттә чыныккан җан мин!
Бәлки, бәла алалмас?

Вөжданым кушканча яшим.
Димим: бар да җай гына...
Бәлки, миһербанлы булыр
миңа язган кайгы да.

1969.

●

«Бу юлларны сагынырбыз әле!
Тик кайтылмас бүтән менә...»
Әйе, сагынырбыз. Вакыт — алла.
Ә без бары кеше генә...

Ә шулай да без без булырбыз гел!
Дәрте калыр, дәрман бетсә!
Эзүләрне чишеп юл чыгарбыз
читтә зарыгып кемдер көтсә...

1968.

●

Бәхетлеләр — ачык, киң күңелле,
риясыз, саксыз, ваемсыз.
Ә бәхетсез купчак көчле көнче,
һәм юкка да үче аяусыз...

Бәхетлеләр оныта, кичерәләр,
хөсетлелек нигә аларга?
Барсын күреп торган, һәрчак аек
бәхетсездән саклан дөньяда.

1969.

●

Курыкма, биек оч, кошым!
Күк чикне беләмени!
Көл, күнел! Дөнья моңы
бер безгә генәмени!

Оч, оч, кошкай, кис җилләрне!
Шаш, Рухым,— дуласын җан!
...Егылсак — белгән-күргәннәр
яхшыга юрасыннар.

1969.

## Ренат Харисов

# ЯФРАКЛАР

## Татарстан җире

Тоткан да гөл чүлмәге
Әзли гөл туфрагы:
«Бусы начар,— ди, —
Кайда соң яхшырагы?..»
Түзмим,

Әйтәм:
«Бер җирдән тот та ал,
Иплән чүлмәгенә сал,
Су сипсәң, сеңелем,
Үзеннән-үзе шытар гөлең!»

## Көзге сурәт

— Мин маңгай була алам,—
Диде карама яфрагы,—
Мин бик җыерчыклы.
— Мине күз дип сана,—
Диде тал яфрагы,—
Мин һәрвакыт чыклы.

— Күзләрен мин алсуланам,—
Диде усак яфрагы,—
Ходай биргән бит алмасы...
Шулай сарылдылар миңа
Яфракларның һәммәсе...

— Мине дә яраклы сана,—
Диде яшел ылыс,—
Портретка мин дә кирәк,
Мин бит һаман
Үз төсемдә калам...

Көзге урман буйлап,
Кеше турында уйлап,
Каядыр барам...

## Өянке

Өскә үсмәсен әле дип,
Баш ботагымны киссәң —
Мин бит як-якка үсәм!..

Киңлеккә китмәсен диеп,
Як-якларымны киссәң —
Мин куелыкка үсәм!..

Куелыкка үсмәсен дип,
Ябалдашымны киссәң —
Мин тамыр якка үсәм!..

Бәгыренә чабыймчы диеп,
Казып тамырыма төшсәң —
Кабереңөстендә үсәм!

## Яфрак

1

Агач — күккә төбәлгән елга.
Агачта бар нәрсә дә киресенчә,
Кеше теләгәнчә·
Диңгез елгага,
Елга тармакка,
Тармак чишмәгә ага.
Агачта иң көчле нәрсә —
Иң кечкенә нәрсә.
Ул — яфрак.
Һәм шул яфрак
Инде күптән
Елгаларны үргә генә түгел,
Агыза күккә.

2

Мин — яфрак.
Тормышны мин
Агач итеп күрәм.
Бик күп ботаклы,
Мәһабәт каусәле,
Калын тамырлы агач итеп.
Аның бер генә ноктасын
Үзем белән төрәм,
Бер генә ноктасын
Кояшка тартам.
Без кубәү —
Кәүсә үрелә безнең арттан.

3

Мин — яфрак.
Йолкыймы давыл,
Кимерәме кортлар,
Яндырамы яшен угы —
Күрәм — кәүсә ныгый.
Тамыр —
Җиргә баткан ябалдаш,
Тик яфраксыз гына.
Мин ябалдашка да охшаган,
Тамырга да!

## Карама яру

Орган саен шылт итәр дип,
Карамага китереп чапты.
Балта ярып кергән турыдан
Чәчрәп чыкты юеш чаткы.
Егеттә ачу кабынды —
Нык селтәнеп тагын сукты.

Күзләренә чәчрәп керде
Караманың җавап уты.
Яру-каеру мөмкин түгел —
Ул имгән Идел җиленең
Һәм ашаган бабаларның
Җиргә сеңгән кан җилемен...
Чыраларын җитен итеп
Балта тетә, балта талкый...
Имән түгел, карамадыр
Батыр аталырга хаклы!
Балтаны үзенә утырта
Утырткандай казыкка кол...
Карамага каен карый,
Тирәк карый җуеп акыл...
Ә ул түзә... һаман түзә...
Аңлашылмый бу минутта:
Әллә балта бүкән яра,
Әллә бүкән балта йота...
Түтәсенә ята балта...
Һәм ботакка балта бата...
Өрәңге сап сынып чыкты
Караманы вата-вата...
Ташлап сынык сапны, күзен
Бүкәнгә текәде егет...
Ә ул?
Балта чәйнәп ята,
Ярсыган ак бүре кебек...

●

Кимерә дә кимерә
Йөрәк саен бар өрәк...
Курыккан саен күбрәк...
Какшаган саен йөрәк
Курку-өркү симерә
Һәм кешедә Кешене
Күзәнәкләп җимерә.
Адым саен мең өрәк...
Ярсы гына — кимрәк!..

## Йола

Түшиләр түшәкне догалап,
Җәяләр җәймәнең яңасын.
Түшәктә аунатып алалар
Бәхетле гаилә баласын.

Һәр яңа гаилә оешу
Йоланы яңадан яңарта.
Күрәсең, халыкның өмете
Һаман да яшидер аңарда.

Яңасе, бәхете мул була,
Баладан да уңа гаилә.
Яңәсе, тормышның һәр юлы
Теләгән теләккә хак килә.

Кияү һәм киленнән дә алда
Ничә кат мин аунап талганмын!
Бәхетләр юраган йоланы
Түшәккә салышкан бала мин.

Ә хәзер үзем дә буй җиткән,
Карыйм да тормышка, дөньяга,
Килә лә Җир буйлап ауныйсым —
Мин һаман тугры шул йолага!

●

Яфракларың — гәрәбә,
Җирдә ята әрәмгә.
Ник чәчеңнән төшердең
Син аларны, әрәмә?

Ботакларда җил улый,
Җилдә ботаклар моңлый,
Китеп барган сыерчык
Оча моң тыңлый-тыңлый.

Барып җиткәч ни сөйләр?
Нindирәк көй көйләр?
Ул кире кайтсын дисәң,
Матур чың тагып җибәр!

Яфракларың — гәрәбә,
Җирдә ята әрәмгә.
Чулпы чыңлатып, кошны
Ник озатмыйсың, әрәмә?

## Чулпы

Таптым идән астыннан.
Аңа кояш йокмаган.
Көнне дә ул төн диеп,
Күпме еллар йоклаган.
Сыпырдым җиңем белән —
Ялт итте!
Тутыкмаган!

Ул карап тора миңа
Сыңар яшел күз белән —
Караңгыда яшел моң
Җыеп яткан үзенә.

Анда — тал чагылышы,
Яшел тау чагылышы.
Кырларына таң чаткысы
Калган аның ябышып.

Үрелгән көмеш җепләр
Күңел кебек катлаулы...
Бизәктә остасының
Тыны калган сакланып...

Ул карап тора миңа,
Мин дә күз ала алмыйм...
Толымын сагына ул,
Мин аңлыйм аны, аңлыйм.

## Көз көне

— Кем күккә таш орды —
Чәлпәрәмә килгән ич күк,
Чәлпәрәмә? —
Текәлеп тәрәзәгә,
Түшәгемнән сикереп тордым —
Кем күккә таш орды?

Ныклап карасам:
Күк йөзендә бары
Шәрә калган алмагачның
Чәчрәп торган ботаклары...

Җәмил Мостафин

# КҮК ТУЛПАР

хикәя

Салават куе чикләвек куаклыгында, корбаның сагалаган бүре төсле, көн озын тыңланып ятты. Тирәяктагы куе агачлар бер туктамый сызланып ыңгыраштылар. Авыр болытлар бүселеп түбәннән генә шуыштылар, кайчагында аларның корсаклары нарат-ларның очлы башларына эләгеп ертылды да, болай да юеш җир өстенә вак тамчылар шыбырдап коелды.

Салават җеп бөртегенә кадәр чыланса да, янгырга бөтенләй игътибар итмәде, дер-дер калтырануын да сизенмәде. Аршын ярымлы туз-баш елан аның күн итекләре өстеннән шуышып узды, әмма таштай каткан аяклар селкенмәделәр. Салаватның кысылган елтыр күзләренә табәнәк кенә шалаш тирәсенә тупланган елкы көтүеннән башка нәрсә күренмәде, ул шикәр төсле ап-ак яшь биядән карашын аера алмады.

Көтү башы — ярым кыргый кара айгыр тирә-якка шом салып, яман кешнәп, алан тирәли вакыт-вакыт юртып әйләнгәли иде. Ул тонык бер бугаз тавышы белән кешнәргә тотына да кыллар өзелгәндә чыңлагандай нәзек, ачы аваз белән тәмамлый. Ак бия дә җавапсыз калмый, аккошныкы төсле коеп ясагандай кечкенә башын күтәрә төшеп, ул да кешни. Тик аның сөенечен яшергәне, дәртен тыя төшкәне күренеп тора. Ак бия елкы көтүендә мондый хокукның бары үзенә генә эләккәнен яхшы төшенә иде булса кирәк.

Галиәхмәт байның елкы көтүенә ак бияне моннан ике атна элек кенә китереп куштылар, шушы арада ул кара айгыр алдында да, башкалар арасында да үз өстенлеген раслап өлгерде. Бия атаклы Орел токымыннан булып, бай аны бихисап акчалар түләп алган иде. Моңа кадәр көтүгә байның ерак кардәше Ибраһим бер үзе чыга иде, хәзер дүрт кеше көтәләр. Дүртәү булсалар да, керфек кагарга куркып, елкыларны көне-төне сагалыйлар. Моннан ярты сәгать элек, ике атнага беренче мәртәбә, төне буе черем итмәгән, чыланган көтүчеләргә Ибраһим шалашка кереп аз-маз хәл алырга рөхсәт бирде.

Уң күзенә ак төшкән шадра көтүче ләчтә кабартмага әйләнгән авыр бишмәтен парлы тәненнән көч-хәл белән аерып:

— Мондый каһәрле көндә шүрәле дә үз баласын һавага чыгармас. Без йөрибез шунда,— дип мыгырданды.

— Телеңә салынма! — Ибраһим, аны бүлдереп, учак утын кузгатты.

ялкын телләре зәпәр, дымлы төтенне басып, Ибраһимның җәлпәк танавын яктырттылар.— Хуҗа сез әрәм тамакларны нигә тыгындыра? Җил куган өченме?

Ибраһимның тавышы да айгыр кешнәгәндәй янап, зәһәр янгырады. Аның үченнән курыккан көтүчеләр бердәм тындылар һәм кулларын җәеп утка таба тартылдылар.

— Мондаен айгыр барында, ай-һай, башы җитеп, берәр тилесе көтүгә якынаермы? — диештеләр алар. Ибраһимның айгырның кыргыйлыгын яратканын беләләр иде.

Карт көтүченең йөзенә елмаю чыкты.

— Кара бүре адәмнәр төсле түгел, хуҗасына турылыклы, анысы хак... Ул барында көтүдән бер баш елкының югалганы юк!

Ибраһим елмаюы явымлы көндәге кояш нуры кебек сирәк булганга, көтүчеләр йөрәксенеп ук киттеләр һәм бер-берсен уздырышып кара айгырны мактадылар. Ибраһим киндер капчыгын чишеп учы белән корт алды һәм көтүчеләрне сыйлады. Тегеләр кашларын җыерып чәп-чәп корт суырырга тотындылар.

Шалаш авызында аларның кыймыл-кыймыл килүләрен Салават дым рәшәсе аша чак аера иде.

«Чыдарыгыз калмадымы, сыпырттыгызмы?.. Инде Кара бүре генә комачауламасын!» диде ул гөбедәй шешенеп каткан аякларын кыймшатып. Чак кына селкенүгә, дымга күбенгән яфраклардан эре-эре тамчылар шыбырдашты. Ул таштай катып калды, күтәрелгән сул кулын кыймылдатмады, шуңа күрә йөрәгенең тыелгысыз дөпелдәвен аермачык ишетте. Яфрак шыбырдавының янгыр тавышыннан аерылгысыз икәненә ышангач кына, айгырның теге яктагы елкылар арасында күмелүен абайлап, ул урман кырлап шуыша башлады. Тагын бөтен нәрсә томаланып, күз алдында ак биянең горур башы гына торып калды, ат та үзен ике кара күз җентекләп караганны сизгән кебек, вакыт-вакыт сангырау гына кешнәп куя иде. «Кара бүре генә сизә күрмәсен! — дип уйлады сазга тирәнрәк чума барган Салават.— Сизмәсен генә! Ул чагында мәнгегә хуш, күк тулпар!»

Баш китәрлек шушындый эшкә тәвәккәлләр алдыннан ул әллә ничә көн елкы көтүен сагалап йөрде. Ярым кыргый тук атларның, бигрәк тә көтү башының холык-гадәтләрен өйрәнде. Көтүчеләрне дә бер урамда уйнап үскән малайларны белгән төсле белә башлады. Аның сак колагы, ак бия көтүдән чак кына аерылып калса да, өлкән көтүченең башкаларны эт итеп сүгеп ташлавын әллә ничә кат ишетте:

— Илла-мәгәр, алай-болай була калса, хуҗа башыгызны катыр җибәрәчәк! Бүре-мазар яралый күрмәсен, күзегез маңгайда булсын, колаклар шәңкәеп торсын, нәләтләр!..

Көтүчеләр карышусыз-нисез бия артыннан чабалар, затлы, иркә малны башкаларга китереп кушалар иде.

Менә хәзер дә ак бия көтүдән аерылырга чамалап иреккә талпынган кош сыман сикергәли, башын чөеп юрта. Яшьрәк айгырлар аңа иярәләр, Кара бүренең юклыгыннан файдаланып, уйнап-кешнәп, кайнар танауларын биянең шома янтыгына төртәләр, өметләнеп аның зәңгәрсу күзләренә текәләләр.

Көтү башы явыз кара айгыр югында да бияне алып китүнең гаять читенлеген Салават яхшы сизенде. Әгәр бия көтүдән шактый читтә булмаса, яшь айгырлар ят кешене таптап-изеп бетерәчәк, тавыш-гаугага сак көтүчеләр йөгерешеп чыгачак, инде иң куркынычлысы — Кара бүре килеп җитәчәк...

«Ничегрәк аерып алырга соң?» дип баш ватты егет.

Мондый сөлек кебек затлы атны аның беренче очратуы иде. Атлас төсле муенында сылу кызлар чәче сыман мул ялы җилферди. Янгырсыз чакта чем-ак бия хәзер чак кына зәңгәрләнеп аяз күк төсенәрәк керган

де. Көн яктырып килә шул, җирдән сыек томан күтәрелә, күктән сүрән урлар коела, шулар биянең төсен зәңгәрләтәләр, ахрысы. Тиңсез сихри амиллек алдында телсез калган Салават бер мизгелгә саклык турында а онытып, кулларына таянып калкынды. Әнә ул, күк тулпар! Әкиятәрдә сөйләнгән чабышкылардан да сылурак малкай... Аның кешнәп уюы да туйда яңгыраган тантаналы курай моңын хәтерләтә иде.

Елкы көтүе сагаеп тынып калды, аннан кинәт хәрәкәткә килде. Яшь йгырлар, куштанлыкларын онытып, тешләрен ыржайттылар, ак бияне рап, шикле тавыш килгән якка борылдылар. Салават шундук җиргә енде, гөлҗимеш чәнечкеләренең битне әрнетеп кадалуларына карамасан, тиз-тиз артка шуыша башлады. Ул арада көтү башы килеп тәкитте, тирә-якны кешнәү тавышлары белән тетрәтеп көтү тирәли чабып йлэнде, күзгә күренмәгән аркан белән аны тыгызлагандай итте, тупады. Урталыкта калып кысылган ак бия түземсезләнеп кешнәде. Шигәйгән Кара бүре әле генә Салават яткан урынга ыргылып килде, ырылдап, көчле тояклары белән җирне казыды. Айгыр сынган ботакарны да, тапталган үләнне дә, ят эзләрне дә аермачык күрде, ләкин эвеф-хәтәр китерерлек ис сизелмәде. Аның куш йодрык хәтле танау ишекләренә гадәти юеш үлән, җир һәм пәжегән яфрак исләре генә ргылып керде.

Моннан ике сажин гына читтә, чәнечкеле гөлҗимеш куелыгында, тын артырга да шүрләп, Салават ята иде. Ул атның кан баскан күзләренә уркынып карады, Кара бүренең күз өстендәге алмасы бер караганда эгалды, икенче караганда каз күкәе сыярлык булып тирәнәйде. Дәү ингез кабырчыгын хәтерләткән борын тишекләре чак кына чал йөгерән сирәк мыек бөртекләрен кыймылдатып киерелделәр, бер чакта да айчы тимәгән ялы учы-учы белән балчык атып торган таба чаклы ояклар янына ук төшеп җилфердәде. Ниһаять, Кара бүре җиңгән ыман һаваны ярып бер кешнәде дә барысы да тынды, тукталырга кыенган яңгырның эре бөртекләре тып та тып җиргә төшкәне ишетелеп горды.

Дымлы җир йоткан тоныкк тояк тавышлары бераздан елкы көтүе ннында ук ишетелде.

«Хәере белән!» дип уйлады Салават җиңел сулап. Ул юеш җине белән маңгаендагы салкын тирне сөртте. Моннан нәкъ биш ел элек, пушының төсле дымлы, явымлы көндә чит кеше кулыннан беренче тапкыр ат урлап чапканда, ул хәзергесенә охшаганрак хис тойган иде...

Барысы да бик гади һәм гадәти башланды түгелме соң?..

Салаватның да башка җан ияләре кебек үк бәхет татыйсы килде. Егеткә нәкъ егерме яшь тулган иде, шуларның биш елын ул Гарифулла байга ялланып эшләп үткәрде. Җәендә сарайда, кышын мич арасында кәеп йоклый торган сәләмә киезеннән һәм бер пар чабатасыннан башка байлыгы булмаса да, хезмәтченең бернигә дә исе китмәде. Күңел түренә ничек булса да акча туплап, ат сатып алырга дигән ныклы уй береккән иде. Үз аты! Шул мал белән аңа бәхет тә, куаныч та килергә тиеш. Ир канаты ат булыр, дип юкка гына җырламаганнар ич!

Бәхетнең ничек, ни төсле буласын яшь егет әле күз алдына китерә алмый, ул хыял, еракта хыял әлегә ачык төсмерләнми иде.

Үз бәхетен Салават бары төшләрендә күрде, авыр урак өстендә дә аның кешнәгән тавышын, чакыруын ишетеп киезеннән сикереп торды. Кырда урак урганда, бөкрәйгән аркасы инде тураймастыр кебек тоелганда, яргаланган учка урак сабы сеңеп береккәндә, кояш нурлары вак энәләр сыман тәнне көйдергәндә, аның күзләренә кыр иңләп килгән канатлы тулпарлар күренде, төрле төстәге яллар җилфердәп, аның тыпылдаган җанын еракларга, күз күрмәгән, колак ишетмәгән илләргә, иәртеп алып киттеләр...

Бу — арыш башаклары бөгелми ич, ат ялы җилферди!..

Кыр гөжләми ич, тупырдап, офыкны иңләп атлар чаба!..

Салават, сабый кебек, үз хыялына үзе ышанып, кипкән иреннәрен ялап куйды, көч белән җилкәсен турайтып, әле генә канатлы тулпарлар кереп югалган офыкка текәлеп торды. Әнә генә ич алар, күк йөзе төсле зәңгәрсу тулпарлар!

— Ни-нәстә караган буласың? — дип сорый иде ачулы хуҗа.— Күзеңә тагын ат күренәме? Дивана, син дә яшәгән буласың бит, иппи чертеп...

— Әйе,— дип көлемсери иде Салават, арганлыгын онытып һәм, бәхетле буласы килеп, элеккедән дә тырышыбрак урырга тотына иде.

Аның җен төсле урырга ябышуын күреп хуҗа башын чайкый, «дивана тек дивана!» дип уйлый иде, ә теле белән:

— Тырыш, Салават, тырыш... Аллаһетәгаләнең рәхмәте киң, синең дә үз атың булыр,— ди иде.

Тик хуҗа үз сүзендә тормады, бу көзгә дә, яренгә дә Салаватка ат алырлык акча тәтемәде. Дөнья үзенең ямен берьюлы югалтты, егетнең зәңгәр хыял белән өретелгән дивана күзләре усалланды, чыкмаган җаны чакма ташы кебек катылана барды. Хуҗасының атларын карагында гына ул үзенең элекке халәтенә кайта иде. Асларын чистарткан-да да, ашарларына салганда да ул һәр хайванны аерым сөеп, ялларын тарап иркәли белде. Әштә алҗыган, нужадан койрыклары сыекланган, бер елда да ябагалары коелып бетмәгән шушы йолкышларга ул күңелендә асраган иркәләү сүзләрен тезде. Тезләре кабарып, шешенеп торган, нечкә муеннарында чак селкенгән кутырлы башлы атлар Салават телендә: «Малкайлар, матуркайлар» дигән исемнәргә лаек булдылар. Гомергә күзеннән эрен китмәгән ала биянең яшьле күзләрен чиста чүпрәк белән пөхтәләп сөрткәндә, Салават, кызганып:

— Авыртамы, сөеклем? Нигә туктаусыз җылыйсың? — дип пышылдый иде.

Бия таш кабак төсле сөякчел озын башын селкә, коры иреннәре белән хезмәтченең тир исе килеп торган киң җилкәсен тешләгәндәй итә иде.

Бер вакыт хуҗасына белеш рус сәүдәгәрләре кереп чыкмаган булса, Салават үз кайгысына үзе томаланып шушында дөмегеп тә калган булыр иде.

— Атларны тугар, әйбәтләп ашарларына сал! — диде бае кунак сәүдәгәр алдында юмакайланып.

— Кара аны, чамалап сугар! — диде сәүдәгәр дә.

Ишек алдына чыккач, Салават тынсыз-өнсез катып калды: чегән төсле кара сакаллы таза кучер ярсыган өч аргамакны чак тыеп тора иде. Мичәүдәгеләр төптәге аттан чак кына кайтышрак гәүдәле булсалар да, биеп кенә торалар, кыңгыраулар өзлексез чылтырыйлар. Төптәге атның тояк астындагы җире яныр, кайнап торамыни, аргамак арт аякларын чүгә-чүгә, алгы аякларын бер тыймыйча тупырдата!

Сакалбай, кәефе килеп, дилбегәсен какты:

— Һай, малай, аргамаклар таптамасын үзеңне!

Салават тилемсә елмаюын тыя алмыйча атларга каршы ук атлады.

— Таптарлар дигәнне ишет, чукрак! — дип кычкырды куркынган кучер. Әле генә мактанып-көлеп торган чыраена ахмак елмаю чыкты. Салават тыныч кына төптәге ат каршысына килеп басты, хайванның тирләгән текә муенын сыйпады, авызлыктагы саргылт күбекне учы белән кагып төшерде. Ат яратмыйча пошкырды, колакларын шомарт-ты. Кыңгыраулар чыңгылдап алдылар да, нигәдер сискәнеп, туктал-дылар.

— Һәй, сылукайлар! — диде Салават, җырлагандай көйләп.

— Әйе, ат диярлек түгел, ерткычлар болар! — диде кучер башкорт егетенең кыюлыгына хәйран калып.

— Ниткән ерткыч булсын болар? — дип гаҗәпләнде егет.— Болар бит, болар.— Ул сүз табалмыйча җөдәде.— Аккошлар диген! Киек казлар диген! Агай, муеннарын гына күрче. Башкайларын! Сылу кызлардан кайсы төшләре ким?

— «Сылу кыз-ла-ар?» Күрегезче бу чабаталы чебешне, кызлар дигән була бит!

Төптәге ат ярсып тибенә башлаганчы көлде кучер. Егет исә, кушылган йомышны да онытып, сихерләнгән күзләрен аргамаклардан ала алмыйча тик катып басып торды. Бу газиз малларны аны тилертер өчен ходай тагәлә үзе җибәргәндер дип тә уйлап куйды...

Төптәге атның югалуын иң әлек кучер хәбәр итте. Ул атның кая киткән сорарга дип печәнлеккә чабып менде, ләкин хезмәтче егет анда юк иде. Үзе дә юк, астына салып йоклаган киезе дә юк. Моңа ышанасы килмәде кучерның, дөнья бетереп ишек алдында әзләнә башлады. Тавышка чәй эчеп кызарынган Гарифулла бай белән сәүдәгәр атылып чыктылар.

Бай агарынды, юан ботларын чабып, чәрелдәвек тавыш белән әле хезмәтчеләренә, әле авылдашларына акырынды:

— Ник карап каттыгыз? Чабыгыз, эзләгез!

Сәүдәгәр үз дәрәҗәсен белеп кенә болдырдан төште, ат тизәгенә басып, ышкып карады, шаккатып:

— Алып качкан!.. Шундый ерткычны алып кача алган!.. Кем диген?.. Бер селәгәй салам торхан бит! «Зөбәрҗәт»не тәртә арасына икә кеше көчкә кертә идек. Әнә, кучердан сорагыз!

Гарифулланың хәле мөшкел иде.

— Ерак китә алмас! Куа чыгарга кирәк! — диде ул.

— Куа чыгарга? — диде сәүдәгәр җәберсенеп.— «Зөбәрҗәт»неме?.. Акылыңа кил, ахмак! Хәзер алар утыз-кырык чакрым элдергәннәр булыр, якын-тирәдә аны куып җитәрлек ат каян табылсын?!

Салават исә бу вакытта туп-турыдан Чиләбегә таба чаба иде. Ике көн ул үзенә дә, хайванкайга да ял бирмәде. Менә-менә куып җитәрләр төсле тоелды. Алда кеше-мазар шәйләнсә шундук урман арасына борылып керде.

Куркынган күңеленә «менә, менә тотып алырлар!» дигән шик килсә дә, теләннән «нигә шулай кыландың, инде үз гомер юлына аркылы балта чаптың?» дигән сорау китмәсә дә, Салават үз-үзеннән гаять канәгать иде. «Мин бәхетле! Бик бәхетле! Янымда атым, хыялымның җимеше бар!» дип кабатлады ул.

«Зөбәрҗәт» Салават урлап киткән беренче ат иде... Моннан соң аның кулыннан нинди генә маллар узмады?! Турылары да, алмачуарлары да, каралары да, аклары да, колалары да. Нинди нәселле атлар, ataклы аргамаклар үтмәде!..

Иң усал атларны да ул уйнап-көлеп кенә йөгәнләде, урлаган атларның һәрберсен сөйгән кызын иркәләгән кебек назлады. Юк, Салават күзенә ни күренсә, шундый малны урламады. Иң әүвәл чираттагы корбанның әлек урланган маллардан ни өстенлеге барлыгын сынады, шуңа инангач кына тәвәккәлләп эшкә кереште. Ул атларны шулай оста, шундый шома алып китә иде, хуҗалары искитеп сөйләрлек була иде. Сылу атны беренче күргәндәге сөенеченә хыянәт итмәс өчен ул бер чакта да төн караңгылыгында урлашмады. Шушы исерткеч татлы мизгелдә ул атны танавыннан койрыгына чаклы, ял бөртегеннән тоягына хәтле туйганчы карый иде. Аның чире-мазары булса, оста белгеч кебек, аны сизенә иде, авыру атларга бер чакта да кул салмады Салават!..

Нәселле мал асрарга яратучылар Салават турында төрле имеш-мимешләр белән дөнья тутырдылар, аңа җен-парилар булышадыр, югыйсә, күз өстендә каш кебек саклаган аргамакларны көпә-көндез ничек алып китсен ул дип шаклар катып сөйләделәр. Күз бууչы убыр-

дыр-ул, кеше түгелдер, дип гайбәт тараттылар. Каракның атаклы нәсел атларын мал бәясен белә торган акыллы кешеләргә юк кына бәһага сатып китүе аларны тагын да ныграк гаҗәпсендерә иде.

Сатып алучылар, сүз арасында гына, Салаватка төрттерәләр дә иде: нәрсә син, исәр егет, баш китәрлек эш күрсәтәсең, сата белмисең, фәлән-фәсмәтән...

Салават һаман диваналарча елмаеп, кызарынып җавап бирә:

— Яратам мин атларны! Җан рәхәте бит ул ат!.. Алар биргән шатлык-куанычым шундый зур, үз бәхетемне, сөенечемне акчага сатарга кызыкмыйм! Языгы булыр!

Үз юлының тугрылыгына ышанган Салават мондый минутларда аерата бәхетле иде. Эшләр гел уңайга гына килеп торгач, ул кәсебенең хәвефле, хәтта ки бик куркыныч икәнен бөтенләй онытып җибәрде. Үзенең мәхәббәтен ул бетмәс дәрт, чамасыз тәвәккәллек белән яулап алды. Җан теләгәне тормышка аша торды, Гарифулла байда урак урганда күз алдына килгән татлы хыяллар чынга әйләнделәр. Салават, һәрбер җан иясе кебек, бары тик бәхетле булырга гына омтылды. Тик ул да, башка бик күп кардәшләре шикелле, үзе кылган эшләрнең тирәнлеген бәяли белмичә, бер минутлык бәхет, бер көнлек ләззәт белән юанып яши бирде...

Урман авызында ак бияне күзәтеп ятканда, бөтен гомере чылбырдай сузылып күз алдыннан узгач, егет хатирәләрдән арынырга теләгәндәй башын чайкап уйлады: «Ни-нәмәрсәгә шулай хисләндем әле? — дип уйлады.— Гомер башка килмәгән уйлар җәфалап бетерделәр!»

Ул сагайды, зиһене ачыкланды һәм утлап йөргән елкы көтүенә карап, «лә-иллаһа-илла алла»сын укыды.

Ак бия көтү башын күзе белән озатты да, усалланмыйча, әмма сизелерлек итеп, янында кайнашкан тайларны тешләштергәләде. Тайлар кешни-кешни читкәрәк чабыштылар. Ак бия башын югары чөеп урманга таба юртты. Елкы көтүе аның шулай ирektә йөрүенә көнләшеп караса да, хайваннар да үз дөньяларында тигез хокук юклыгын аңлаган сыман, берьюлы башларын иделәр, дымлы, татлы үләнне керт-керт ашый башладылар.

Ак бия бая Кара бүре котырынган урынга килеп житте. Куаклыкта куе ботаклар арасыннан елтыраган ике кара күзне күреп алды. Гаҗәпләнде. Аннары пошкырып чабарга җыенганда гына кызыксынып башын сузды. Теге кеше һич куркынычка охшамаган иде. Аның кысылып янган күзләрендә дуслык, чакыру чагылды. Ак бия гомерендә беренче тапкыр шундый карашны очратты.

Үзе дә өнсез калган егет күгәрчендәй гөрләде:

— Тр-р-р...

Тавышсыз гына куенына тыгылды, ничә сәгать яңгыр астында коры килеш сакланган икмәк кыерчыгын алды. Тәнгә тиеп җылынган ипидән кояш исе, кыр исе, тулышкан арыш башаклары исе тагын да ныграк аңкый иде.

«Куркырмы, юкмы?» дип уйлады ул, вак-вак кына атлап биягә якынлаша-якынлаша. Сузылган кулдагы икмәк кыерчыгы сизелерлек калтыранды. «Нигә шулай җебедем соң? Беренче тапкырмы әллә?!» дип әрләде егет үзен. Борчылырлык бер сәбәп тә тапмады, тынычлана төште. Ак бия хәтфә кебек йомшак иреннәре белән икмәккә сузылгач, исерек кебек чайкалды Салават, күз аллары караңгыланды. Гомере буе шушындый атны хыялында асравын аңлады. Шушы, нәкъ шушы аргамак аның төшләренә кереп йөдәтте, Гарифулла байның кырында зәңгәр хыял булып күңелен җирсетте. Менә ул, менә! Яңгыр суында юылган тояклары көмеш кебек ялтырый, очып китәргә торган гәүдәне төп-төз аяклар биетеп кенә тота, озын-мул койрыгы ефәк-алтыннан тукылган хәнчәләр кулмәге төсле!..

күзләреннән акыл, шунын белән бергә буйсынмас шук нур
тора иде.

Кеше белән ат берьюлы көрсенделәр. Арадагы шикләнү шундук юкка чыкты. Салават атның ял астына кулын салды, иркәләп кашыды. Ат күккә атылырга җыенган ук төсле турайды, бәрхет тиресе астыннан вак калтырау йөгереп узды.

— Я, я, нигә курыктың?.. Тр-р, тр-р! — дип гөрләде Салават, атны муеныннан, ял асларыннан чәбәкләп.— Каушама!

Ак бия калтыранып-калтыранып алса да, буйсынган кыяфәт белән тик басып торды...

Аның күздән югалуын иң әүвәл Кара бүре сизенде. Әле һаман ак бия исе килеп торган яшь тайларга беренче җәза эләкте, аннары Кара бүре, чабып барган шәпкә, туры атны умырып тешләде, яман кешнәп урман авызы буйлап очты. Куркынган көтүчеләр шалаштан сикерешеп чыктылар, Ибраһим, ачуына буылып, шадра көтүченең җилкәсенә камчы белән орды.

— Динсезләр, кяферләр! Урманны актарып эзләгез! Хуҗа себер җибәрәчәк!

Көтүчеләр ат менеп төрлесе төрле якка сибелделәр, Кара бүре дә Ибраһим артыннан чапмакчы иде, танавына камчы очы эләккәч пошкырып кире борылды...

Салават хәвефле якка борылып карый-карый атна буе урман эчләп чапты. Шушы вакыт эчендә алар ат белән тәмам дуслашып беттеләр һәм егет моннан ары аннсыз яши алмаячагын төшенде. Иң якын туганы белән сөйләшкәндәй ат белән гәпләште егет, башкортның иң матур, иң озын җырларын аңа җырлады, төнге хәтәр җилләрдә аның өстенә бишмәтен япты, үзе учак җылысында җан саклады.

Төннәрнең берендә ул йокыга талган чегән таборына тап булды. Әгәр дәү, алама колаклы этләр өреп чыкмасалар, ул чегән кибиткалары, балаганнар арасына килеп керүен сизми дә үткән булыр иде. Эт тавышына иске фургоннардан ир-атлар сузылышып чыктылар, алар киерелә-киерелә таң йокысын бүлдергән ят юлаучыга ярсып һәм каһәрләп карадылар. Тавышка балалар уянды, хатын-кыз сөйләшкәне ишетелде. Чегәннәрнең күбесе ялан аяк, кайберәүләре генә ялтырап торган кунычлы итекләр кигән иде. Бәрхет жилетлар, атлас күлмәкләр астыннан йон баскан, күптән сабын тимәгән тән каралып күренде.

Чегәннәр җайдак егетне урап алдылар һәм усал авазлар соклану, гаҗәпләнү авазлары белән алмашынды, чегәннәр кул болгап, тел шартлаттылар, шаярышып бер-берсен этешеп каш сикерттеләр. Кыюраклары сагаеп, шомарып торган ак биянең тешләрен карарга үрелмәкче булдылар, бөтен табор уянып гөр килде, ярминкәгә әйләнде. Шушы сүрән таң яктысында пәйда булган шушы күк тулпар чегәннәрнең йокысын тәмам качырды.

Менә барысы да берьюлы тындылар, чигенеп куйдылар. Уртага олысымак кыяфәтле, сары атлас күлмәк, плис чалбар, лакланган кунычлы итек кигән чегән чыкты. Купшы чегән күз очы белән генә атка карап бер әйләнде дә Салават каршысына тукталды, бөдрә чәч көлтәсен артка чөеп, хәйлә тулы күзләрен кысып чүгәләде, биянең бнек тоякларын карады, аннары исе китмәгәндәй черт итеп җиргә төкерде:

— Бозык ат, әйе, тыштан кәртинкә төсле булся да, яраксыз мал!

Чегән алтын балдаклар белән сырланган юантык бармаклары белән сакалын сыпырып, арткарак чикте. Башкалар шундук җанландылар, һау-һаулап гөрләп, төкеренеп, кулларын бутый-бутый читкәрәк тартылдылар, гүяки алар зыяндашлы куркыныч аттан үзләрен сакларга ниятлиләр иде. Хатыннар изүләреннән сузылып чыккан озынча имчәкләрен дә җыймыйча ишле балаларын кочаклап улаша-улаша балаган-

серәп күзәтеп торды.

— Я, нәрсә шаулыйсыз? — дип кычкырды, ниһаять, Салават. Ат аның тавышына сискәнеп ыргылып алды, егетнең тавышын кешнәү авазлары күмде.— Әй, бөдрәч, тешеңне ыржайтма! Ат сатарга җыенган кеше юк.

Салават тезгенен кагып куюга ак бия язгы ташкындай алга ургылды, чегән балалары чинашып балаганга кереп качтылар.

— Чибәр егет, һәй, тукта әле! — дип кычкырып, юан чегән аның артыннан ташланды.

Эшне болайга китәр дип уйламаган чегәннәр, шаккатып, юлбашчылары артыннан чаптылар, аларга һаулап арык, алама этләр иярде. Купшы чегән бераздан тукталды, арттан килүчеләргә бугаз киереп нидер кычкырды. Кешеләр баскан урыннарында катып калдылар, этләр дә, үзләрен гаепле сизеп, койрыкларын бот араларына кыстырдылар.

— Тукта, егет, көт... Сабыр. Юкка кызасың! — диде чегән авыз эче тулы алтын тешләрен ялтыратып елмая-елмая.— Батыр икәнең күренеп тора, пәһлеван!.. Юлыңда бәхет көтә сине. Абай бул, таптап китеп ялгышма. Туктал, сүземне тыңла.

Чегән атка карап туктаусыз сайрады.

Салаватка кызык булып китте, ул кире борылып килде.

— Ни әйтерең бар?

— Сат, пәһлеван, атыңны, бәясеннән тормыйм! — дип ялынды чегән.— Сиңа төс мал түгел бу. Киракэсә, син табарсың! Бөркет корбансыз яшиме?

Салават башта чегәнне ачуланып китәргә уйласа да, хәйләкәр елмаеп:

— Күпме бирәсең? — дип сорады.

Чегәннең күзендә дөрләп учак кабынды.

— Утыз җәл түгел!

— Адәм көлдермә.

— Илле!

— Ат бәясен беләсеңме әллә дип торам, син дә шул Оренбург базарындагы сала мужигы төсле икәнсең!

Ул тезгенен какты.

— Тукта, егет!.. Йөз!.. Мә! Бөтен таборым ул бәя тормый...

Дәрте кузгалган чегәнне тыярлык түгел иде.

— Үз йөрәгеңне сата алырсыңмы, әй, чегән, әйт! Мәхәббәтеңне сата алырсыңмы? — Салават өзәңгегә басып ук кычкырды.— Дәшмисеңме? Күк тулпарым минем, мәхәббәтем, бәхетем!

Ул биянең касыгына кагылып алды, ат арткы аякларына басып ыргылды, урман куелыгына кереп юк та булды.

...Салкын, күңелсез көз җитте. Әрсез җил, агачларның соңгы яфракларын урлап, үзәннәр, таулар, болыннар буйлап куып йөртте. Күк тулпарга ризык табу көннән-көн кыенлашты. Салават бар булганын сатып, аңа җылы япма сатып алды. Кайсыбер көннәрдә авызына локма аш капмаган Салават бар тапкан икмәген хайванга ашата иде. Авылдан авылга күчә-күчә, илдән илгә йөри-йөри ул үз киләчәге турында түгел, күк тулпарының күрәселәрен уйланды. Аны беркайчан да сата алмаячагын яхшы белгән егет, әгәр атны асрый калса, аны һәлакәткә якынайтуын төшенде. Башкача чара тапмагач, ул бияне элекке хуҗасына кайтарырга булды. Ичмасам анда тамагы тук, асты коры булыр, тормышы рәхәттә узар!

Соңгы чиккә җиткән егет шушы куркынычлы эшкә тәвәккәлләде.

Биянең элекке хуҗасы — ат сәүдәгәре утарына ул иртәнге сүрән яктыда кайтып элгәште. Авыл әле уянып кына килә иде. Кыйшык-мыйшык җимерек читәннәр арасыннан ач этләрнең очлы борыннары күрен-

де, ишек алларында каз көтүләре каңгылдашты. Бәбкәләрне ана казлардан аерып алырлык та түгел иде, үсеп беткәннәр! Салкын жил төтен исе катыш кар исе, кыш исе алып килде.

Салават үзенең бер тамчы да курыкмавын, каушамавын тойды. Моны берничек тә аңлата торган түгел иде. Аерылуны тою, бәхет кояшының батуын сизү, башка хисләргә урын калдырмаган иде бугай.

Ат сәүдәгәре утарына якын гына читәнгә бияне бәйләгәч, ул урман ягына атлады. Ташлап китә алмам, борылырмын, дип куркынганга, әйләнеп карарга да базмыйча шактый барды. Кинәт ак бия тилергән күк ярсып кешнәп жибәрде, үрә басты, туңган жирне тояклары белән кыйнады. Салават тукталды, тыңлап торды һәм борылып килде. Тавышка хезмәтчеләр йөгерешеп чыкты, халык жыелды.

— Тотыгыз үзен, каптырыгыз! — дип боергач, Ибраһим алпан-тилпән килеп хужасы катына чапты.

— Качарга жыенган кеше юк,— диде Салават ваемсыз гына.

Ухылдап бай килеп чыкты. Аның түшәк кебек калын жилкәсеннән янут туны шуышып төште, кәкре аякларындагы читекләре бик хәтәр шыгырдадылар.

— Үзе! «Дулкын» үзе! — дип чәрелдәде бай һәм тыны буленеп йөткеренде. Аннары Салаватны абайлап, яман бакырып жибәрде.— Бәйләгез! Бетерегез башын явызның, терелэй жиргә күмегез нәләтне!

Салаватны ындыр табагындагы дымлы көлтәне суккан кебек әйләндерә-әйләндерә тукмадылар.

Әле өч кеше тотып торган Күк тулпарны күрер хәлдә чакта аңа бик кыен булды, тора-бара күз аллары караңгыланды, ат күренмәс булды. Бер чиләк салкын су коеп, аны каеш дилбегә белән чыбык арбага бәйләп куйдылар.

Гарифулла байда чакта шушындый дәү арба белән көлтә кертә иде ул.

Гарифулла байда урак урганда...

Кайда соң Күк тулпар?

Ибраһим авызын кыйгайтып көлә-көлә аның янында биеп йөрде, егетнең чәченнән эләктереп, хәзер чыннан да дингез дулкыны төсле зәңгәрсу күк төсенә кергән ат ягына таба борды:

— Күр, юлбасар, күр! Бетәрең алдыннан карап кал, хайван да син хәерчедән көлә!

Салават, ирен тирәсенә оешкан канны төкереп, чак ишетелерлек итеп мыгырданды:

— Юк, көлми ул, кызгана.

Баеның күз карашын тоеп Ибраһим тәмам котырды, Салаватның чәченнән тотып башын арба үрәчәсенә бәргәли башлады:

— Кызганамы? Кызганамы?.. Кызганмый торсын!

Ат кинәт үрә сикерде, үзен тотып торган кешеләрне читкә чөеп, тешләрен ыржайтты, ишек алды тирәли чабып китте. Көтүчеләрнең берсе багана артыннан качып бияга берне сыпырган иде, бай:

— Тимә «Дулкын»га!.. Аның нинди мал икәнен онытгыңмы әллә? — дип акырды.

— Жен ияләшкәндер моңа, башкача булмас,— дип зарланыша-зарланыша хезмәтчеләр төрле якка качтылар. Алар биягә тән уртасында күзгә күренгән шәүләгә карагандай куркып карыйлар иде.

— Житәр, чишегез хәерчене, олаксын әйдә! — дип боерды бай. Күк тулпар кыйналган канлы тәне дилбегәгә уралып беткән Салават янына тукталды да үзенең кардай ак башы белән аның жимерелгән, шешенгән битләренә кагылды. Гүяки ул үзенең тугрылыгын тагын бер кат расларга тели иде...

Мөдәррис Әгъләмов

## Уйна, курай!

Уйна, курай, үзәкләрне өздер, курай,
Яман уйларым булганда биздер, курай...
Томырылып чапсын атлар, тынсын ятлар,
Иксез-чиксез сахраларны гиздер, курай...

Тынып торыр бу хәятның зилзиләсе...
Өзелсен лә бәгырьләрнең өзеләсе...
Сөрән суга кем ул анда? Безнең җанга
Ташып керсен далаларның җил-җиләсе.

Бездән киткән ярлар үксеп еласыннар,
Мәнсезләр дә бер калкынып уйласыннар,
Ярты җаным синдә бугай, уйна, курай,
Арага ятлар керергә кыймасыннар...

Синдә җилләр уйнаганнар ярсый-ярсый...
Син җыр башы, табигатьтә моңнар башы.
Уйна, курай, үзәкләрне өздер, курай,
Әйтсен гавам: вәт нәгаләт кыр курасы.

1970

## Таулар

Ир егет, ир булса әгәр,
Яуда торыр тау булып,
Каны агар, җаны китәр,
Даны калыр сау булып.

Ишелеп яңгырлар койганда
Тынланып йөрдем мин Уралда...
Тауларның сүзләрен ишеттем,
Сөйләшә иделәр үзара:

«Уйнаса давыллар уйнасын,
Кагылса яңгырлар кагылсын,
Иннәрдән йөгерә өермә,
Иннәрдән йөгерә агым су,

Иннәрдән йөгерә яшеннәр,
Тик бездән түбәнгә төшмиләр.
Күтәреп торабыз яшенне.
Түбәндә — авыллар, кешеләр».

Иманнәр ваклана чырага,
Кыялар бары тик чылана...
Тауларның һәм батыр ирләрнен
Урыны тарихта — бер чама.

1967

●

Исәнмесез, өлкәннәр! — дим
Йөрәк шашып какканда.
Алар таккан кыңгыраулар
Чеңли безнең атларда.

Чеңли бәйгеләргә дәшеп:
— Толпарынны ияргә!
...Ашыкма, ник бу биеклек
Алынмаган диярга,

Ашыкма сөрән салырга,
Аларны гаепләргә,
Булмагандыр лачынга — күк,
Диңгез җиле — җилкәнгә.

Максатына житү насыйп
Булмагандыр күпләргә:
Хезмәт һәм хаклык төялсен
Без тартасы йөкләргә.

Шауласын, тантана итсен
Җирдә тормышның чыны.
Кушылсын гомум авазга
Безнең кыңгырау чыңы.

1969

## Ай туганда...

Ерак үткәнне
Борчымыйм бүген,
Барып җиткәнне
Борчымыйм бүген.
Яңа тугандай
Күзәтеп торам
Илемнең күген...

Күкнең бер читен
Алам да кыеп,
Җыр язам анда
Йолдызлар җыеп.
Болытлар юкка
Сөенгәнме ай?
Утыра оеп...

Кинәт эшемне
Искәреп ала,
Бизгәк тоткандай
Сискәнеп ала,
Каплый да җирне
Канаты белән
Хисләнеп ала...

Кирәкми, тормыш,
Уютың, җаең...
Ул безнең өчен
Түгел, мөгаен,
Сәяхәт эзләп
Яңадан туам
Ай туган саен...

1970

## Иман

Уралдагы давылларда
Актарылып иман ава.
Кешеләр бит иман түгел,
Өзелмәслек җепләр кала.

Кешеләр шаярып мөнгезеп сипкәнме,
Я җилләр очыртып салганмы орлыгын?
Таш кыя өстендә имәнне күрүгә
Бер мәлгә өзелде бу юлым.

Кордашлар янына якынлык өченме,
Иелгән ул бераз түбәнгә...
Көз саен яфрагын коя ул моңаеп,
Орлыгын коя ул үзәнгә.

Кешеләр шикелле, туган җир туфрагын
Сагына, аңа да бик авыр.
Ташларны ташлар да үзәнгә сикерер
Иде ул... тик тамыр...
Тик тамыр.

1966

## Казан

Тагын килдеңмени, диләр миңа,
Казаныма килеп кергәч тә...
Килү белән китүләрне генә
Кеше аңлый инде бу яшьтә.

Арча кырындагы яшь юкәләр
Яфрак сибә миңа үз итеп,
Җанга тамга салган сагышларны
Хәтерләтте тагын көз җитеп.

Ә җитмәсә килдеңмени, диләр,
Юк, китмәдем Тукай җиреннән,
Агачыннан җимеш өзелгәнме,
Өлгергәнгә күрә өзелгән.

1969

## Каз өмәсе

**Күз саен таратыр авыл**
**Сукмакка каз канатын...**
**Каз канатын таратса да**
**Таратмас яманатын.**

Бүгенге дуслык, бердәмлек
Башлангандыр күк тоелды
Өмәләрдән.
Кызлар белән бергә көлеп,
Ялгызы калган уемны
Җиргә бәрәм.

...Бүлмәсә дә йөрәкләрне,
Кешеләрне бүлә күзләр
Картка, яшькә...
Кабыза сүнгән теләкләрне...
Каз өмәсе... Яңа мендәр.
Яшь кәләшкә...
Яшь кәләшкә!

Канат теләп үсмер кызга,
Юлда ныклы аяк теләп
Малайларга,
Бәкегә эз суза-суза
Каз өмәсе авыл иңләп
Узып бара.

Каз өмәсе. Әнә алдан
Җиңги үзен бик олыга
Санап килә...
«Бу өмәләр артсын һаман!»
Бала-чага су юлына
Канат сибә,
Канат сибә.

1967

# Туй

> Карагайларны кисәбез,
> Кала агач төпләре...
> Киләчәк матур булсын дип,
> Хәтерлибез үткәнне
>
> *Халык җыры*

Безнең халык бирелә дә шундый,
Табигатең нинди булмасын —
Тукайларга, Такташларга тотынып
Гомер итә, саклый йоласын.

Капкаларны киереп ачкан бәйрәм —
Туйлардан соң халык туйганмы?
Тик барыбер олы йола белән
Кыз чеңләтеп башлар туйларны.

Изге юллар өчен пар канатлар,
Пар канатлар оча — пар атлар...
Пар атлардан төшеп мендәргә бас,
Бусагага кадәр паласлар.

Атлап керсә өйнең бусагасын
Карап тора сиңа мең чигеш,
Әйтерсең лә, Урал тавы аша
Көнбатышка карый Көнчыгыш.

...Алгы көнгә атлаганда халык
Үткәненә карый текәлеп...
Үткәннәрнең яхшыларын ала,
Яхшыларын бара күтәреп.

1966

●

Мин шундый жыр язмак булдым сиңа —
Бәгыремнән тамып-тамып төшсен,
Иркенлектән шартлар хәлгә житкән
Тормышыңны ватып, сиңа күчсен.
Ул биздерсен затлы зиннәтләрдән,
Мода турындагы буш гәпләрдән,
Чүпрәк хискә көя булып төшсен,
Сискәндереп сине салсын уйга —
Мин шундый жыр язмак булдым сиңа.

Мин шундый жыр язмак булдым сиңа —
Өч бүлмәле квартирың белән,
Өйгә сыймый яткан байлыкларың,
Зәңгәр машиналы ирең белән —
Бөтенесен, бөтенесен ташлап,
Әшсезлекне һәм биләмне ташлап
Җибәрергә яңа тормыш башлап,
Син килерлек итеп ашыгып миңа —
Мин шундый жыр язмак булдым сиңа.

Ул җыр йөрде телдә, күңелемдә,
Яңа уңышларга әйдәп мине,
Туар җырларыма гайрәт бирде,
Әмма ак кәгазьгә төшмәде ул,
Җырым миннән акыллырак иде.

1969

## Җырчы картым

*Җырчыларны алмый кабер,*
*Алар сыймыйлар гүргә...*
*Сыймый гүргә — шушы җирдә*
*Алар җырга әверелә.*

Карагатлар[1] ял итәме икән
Канатларын салып ак карга.
Күзләремне йомсам, күңел белән
Барып чыгам сезнең якларга.

Җырчы картым, җырлыйсыңмы әле?
Чыкмыйсың бит истән һич кенә...
Урал якларыннан һаман синең
Җыр кайтаваз булып ишетелә.

Сәхнәләрдән синең моңны эзлим,
Кабатлыйсың сыман: яшь үткән.
Мин көнләштем синең моңнарыңнан,
Син көнләштең безнең яшьлектән.

Магнитофон тасмасына гына
Язып буламыни ул моңны...
Мәдрәсәдән мәдрәсәгә куыл,
Халык белән бәйлә юлыңны.

Җырчыларның язмышларын беләм,
Бер син генәмени куылган...
Синең җырдан күпләр сулыш алган,
Синең җырдан күпләр буылган.

Куылганның җаны халык белән,
Буылганның җаны кечкенә...
Урал тауларыннан һаман синең
Җыр кайтаваз булып ишетелә.

1967

[1] Карағат — Себер татарлары карлыганны шулай атый.

## Әфган Гыйззәтов

### Күз яшьләре

Якын кешең белән кавышканда
Үтеп еллар ерак араны,
Ул еласа, мондый шатлык яше
Бәйли сагыш салган яраны.
Була тагын бик әрнүле яшьләр:
Курыккандай сугар яшеннән,
Үксүеннән куркам аналарның,—
Уллырына рәнҗеш яшеннән.
Ләкин беләм башка күз яшьләрен:
Туплар ярылганда җир елый.
Сызлаңудан ташлар ыңгырашканда
Таш бәгырьле солдат ир елый.
Дошманыңа нәфрәт яше ачы
Һәм кургаштай авыр, эссе ул.
Аннан пуля койсаң, бер атуда
Мең дошманга тияр төсле ул.
Күз яшьләре... Химик анализлар
Ясап булса әгәр яшьләргә,
Уйлар, хисләр тирәнлеген аңлап,
Без өйрәнер идек шушы җирдә
Тагы да тугры, дөрес яшәргә.

### Бала йоклый

Бала йоклый. Вакыт-вакыт
Керфекләре тетрәп куя.
Бөре сыман бармакларын
Йодрык итеп бөкләп куя.
Кайдадыр туп шартладымы,—
Ишеткәндәй, күзен ача.
Тоям дөнья язмышын да
Мин бүгеннән кызым аша.

Бала йоклый. Вакыт-вакыт
Төшләр күреп, ул елмая.
Аның шатлыклары аша
Мин елмаям бу дөньяга.
Алышынган постлар кебек,
Төннәр үгә, таңнар ата.
Ак мендәрдә рәхәт сулап,
Җирнең киләчәге ята.

### Яңгыр малай

Шаулап акты язгы ястык бозлар,
Ачылалар шартлап бөреләр.
Ялан тәпи чапкан малаймыни,
Май яңгыры җирдән йөгерә.
Әй йөгерә шыбыр-шыбыр басып,
Кыска гына болыт ыштанлы.

Ул ашыга эшләп өлгерергә
Энкәсе Язбикә кушканны.
Яшен-чыбыркысын селтәп ала,
Һәм шатланып ала, шаярып.
Миңа охшый анын шаянлыгы,
Миңа охшый мондый малайлык.
Басуларны ул кытыклап ява,
Ул кытыклап үтә тауларны.
Ә тегеләр көлә күк күкрәтеп,
Яңгыратып язгы һаваны.
Бу тавышка елмая бар дөнья,
Һәм уяна җирдә тереклек.
Тәүге күкрәү — бөркеткә дә илһам,
Еланны да китә терелтеп.
Яңгыр шаулап чаба, чикләр белми.
Юк дошман да аңа, үги дә.
Яшен-чыбыркысын селти-селти,
Барысын куа җәйгә бер көйгә.

## Беренче кар

Җырлап туялмам
Карның аклыгын.
Кар булып ява
Җиргә шатлыгым.
Керфеккә кунып,
Тирбәлә үзе,
Иркәләп кенә
Йомдыра күзне.
Елмайган ирен,
Йомылган күзләр,
Әйтелми калган
Кадерле сүзләр.
Бәхетле көлгән
Синең тавышың,
Бәхеттән туган
Назлы сагышым,—
Ява да ява
Ап-ак кар булып.
Ята бар дөнья
Шатлыкка тулып.

## Хатлар әйтсен

Капма-каршы һәм күзгә-күз торып
Сөйләшсәң дә серләр калалар.
Аерылышкач, шул серләрне хатлар
Бер-беребезгә алып баралар.
Күңел күтәрәлмәс сүзләрне дә
Ак кәгазьләр җиңел күтәрә.
Ераклашкан саен әйтү ансат,
Карау җиңел күптән үткәнгә.
Мин бит синең өчен учак яктым,
Күмерләрен миңа этәрдең.
Сүрелгәннәр иде...
Китеп бардың
Әзер учагына бүтәннең.
Тик таланган юлчы кебек, аннан
Урап кайттың.
Юлың уңмаган.
Керфекләрең инде түбән карый.
Ә сафлыгың инде урланган.
Без күзгә-күз карап сөйләшкәндә
Үзган белән күңелең кырмадым.
Хатлар туры сүзле. Алар әйтсен:
Үкенечле хатлар — җырларым.

## Флёра Гыйззәтуллина

●

Эшләмәсәң әгәр
　　　　　　　　яманлыклар —
Кермәс төшләреңә;
Якты хисләр, җылы уйлар туа
Бары эштә генә...

Кара уйлар кара урман булып
Адаштырмасыннар.
Тынгы кирәк җанга,—
　　　　　　　　иртә таңда
Юлга чыгасым бар.

●

Үкенерлек ялгышларың булса,
Үткән гомереңне оныт та син,
Өр-яңадан яши башла, дисең.

Үткәннәрнең бер чатыннан гына
Әгәр туры карап торса миңа
Бер ялгышым белгән йөзләп
　　　　　　　　кешем?..

Ялгышларның барысын онытып
Өр-яңадан яши башлау өчен
Үземне мин ничек кичерим соң?

### Югалтырмын кебек...

Кымшанырга куркып
Утырам мин оеп.
Салкын тәрәзәгә
Яңагымны куеп.

Урамнарда халык
Пәри арлы-бирле.
Кеше язмышлары
Ник соң болай серле?

Меңнәр арасыннан
Таныр идем сине.
Тыным белән тартып
Алыр идем сине.

Җилдән сорар идем,
Җил телләрен белмим.
Язмышыммы соң син,
Ялгышыммы минем?

Поклар идем ятып,
Туар көнем — өмет:
Күз йомсам да сине
Югалтырмын кебек.

●

Бәхетнең нинди насыйптыр бу елда?
Тынлыкмы?
Күкрәүле яшенме?
Киләксә, тамакка кисәкле таш торсын,
Күрсәтеп еламам яшемне.

Киләксә, ал димәм, ял димәм, бөгелмәм
Алганчы актыкка сулышны:
Чөнки мин бер сулар сулышым өчен дә
Яшәүгә мең кабат бурычлы.

## Йөк бавымда

Өем-өем кар тавыннан өерелеп,
Буран чыгып, мин үтәсе юлга ята.
Күздә яшьләр, керфекләрдә бозлы бәсләр,
Бер ярдәмчең булса икән шундый чакта.

Әкиятләрдә генә була мондый хәлләр —
Бер мизгелдә карны ярып шыта чирәм:
Бер кулымны бушаттың да йөк бавымнан,
Ялан буйлап атладың син минем белән.

Синең авыр көрәш юлы үткәнеңне
Өстеңдәге соры шинель сөйли иде —
Бергә утлар, сулар кичкән бу юлдашың,
Уң кесәдә иде аның кулсыз җиңе.

Күпме сулар акты инде ул көннән соң,
Кире кайтмый аккан сулар — үткән заман...
Кулымдагы кысып торткан йөк бавымда
Көч бирүче сыңар кулны тоям һаман.

## Җиңеп кайту хакына

*Донбасс истәлеге*

Сорашалар: «Күзләреңнең нурын
Югалттың, дип, нәрсә хакына?»
Әнә үткер күзле бала чыгып,
Көлә-көлә таган атына.

Чәчәкләрен кочып яшьлек аглый,
Тукта кызый, чиген артыңа!
Үтәр юллар өзелгәннәр гүя,
Җир тетрәнә, вулкан атыла.

Юк, мин чигенмәдем, йөгереп барып
Кырыена бастым чоңгылның.
— Кит, саклан! — дип шомлы тирәнлектән
Тавыш биргән кеше син булдың.

Сине тыңламадым, төштем шунда
Авыр хәлен күреп илемнен.
Ул чагында әллә миңа синсез
Җир өстендә җиңел идеме?!

Лесагоннар бар да яшь малайлар,
Такта шудыралар лавада,
Табаннардан очкын чәчелгәндә
Сулышларга ялкын кабына.

Күзләремнең нурын калдырдым мин
Синең җиңеп кайту хакына.

## Кылган чәчле кызкай — бала чак

Кил, үскәнем, утыр яннарыма,
Кылган чәчле кызкай, тартынма.
Киләчәкнең күзләренә кара
Яшеренми еллар артына.

Билең бөгеп ни казыйсың анда,
Томан сарган кырлар түрендә?
Салкын җилләр бүре булып улый
Бишмәтеңнең ертык җиңендә.

Озын саплы көрәк тоткан кулың,
Күптән инде талган... беләм бит!
Хушлашмый да киткән идем синнән
Борылам да кабат киләм дип.

Йөзең сулып беткән көтә-көтә,
Керфекләрең түбән иелгән,
Әгәр мөмкин булса, хәзер сине
Һич калдырмас идем үземнән.

Зинһар, димен, җитәр, турайт инде
Авыр йөкләр баскан җилкәнне!
Яшьләр түгеп анда син тормасаң,
Искә алмас идем үткәнне.

**Нил Юзиев**

# ЯҢА МАТУРЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Һади Такташның исемен халык, Тукай, Ибраһимов, Җәлилләр белән янәшә куеп, үзенең рухи таянычы, милли горурлыгы итеп санап йөртә.

Һәр зур талантлы әдипнең иҗаты кебек, Такташның да иҗаты бай һәм күп яклы. Ул театр һәм драматургия үсеше тарихында тирән эз калдырган драма һәм трагедияләр авторы да, чор таләбен тирән тойган үткен фикерле публицист һәм журналист та, ул — прозаик, ул — балалар язучысы, ул — тәнкыйтьче дә. Әмма барыннан да элек һәм барыннан да бигрәк ул — шагыйрь. Зур шагыйрь. Сирәк очрый торган талантка ия булган шагыйрь. Хәтта хикәя һәм драма әсәрләрендә дә ул — шагыйрь. Шигырьләре «авыр көрәш» елларында, «давыллы елларда» көчле набат булып яңгыраган трибун шагыйрь. Шашкын хисле, романтик шагыйрь.

Һәр дәвер, яңа матурлык өчен көрәшүчеләр белән бергә, шул көрәшнең уртасында кайнаган җырчыларны да тудыра. Такташны да, шагыйрь буларак, поэзия мәйданындагы биеклеккә яңа чор — социалистик революцияләр дәвере күтәрә. Үзе язганча, «еллар аны гәвләр урамыннан алып, җырчы малай итеп» үстерә:

Рәхмәт, әнкәй, сиңа:
Ярый әле мине тапкансың,
Җырлар җырлый-җырлый,—
«Иркәм!» — диеп,
Төннәр йокламыйча баккансың...
Синең авыр, кара тормышыңда
Ярдәмчең булмадым булуын,
Ләкин
Авыр көрәш, беек еллар өчен
Кирәк булган минем тууым.

Новатор шагыйрь. Рухы белән дә, аһәңе белән дә яңа шагыйрь. Тукайдан соңгы шигърият җебен каләмдәш дуслары белән лаеклы дәвам итеп, Такташ татар поэзиясе тарихында яңа сәхифә ача; яңа принципларга таянган поэзиянең нигез ташларын салуда катнаша. Зур талантларга хас булганча, үзенең әле дә көчен югалтмаган шигърият мәктәбен тудыра. Татар поэзиясендә талантлар күп булса да, шундый шигъри мәктәп ачкан, мәктәп программасы һәм поэтикасы һаман да искермичә, берничә буын яшь әдипләр өчен осталык мәктәбе булып хезмәт иткән шагыйрьләр күп түгел. Андый бәхет сирәк кешеләргә эләгә.

«Яңа» һәм «беренче» сүзләре, ничектер, Такташ поэзиясенең асылына ифрат та туры килеп тора. Хәтта шагыйрьнең туу вакыты да әчке бер мәгънә белән тулы

икелле: Һади Сыркыды авы-
ында (Мордва республика-
ының Тарбеево районы)
901 елның 1 гыйнварында —
гъни яңа гасырның беренче
лында, Яңа елның беренче
өнендә дөньяга килә.

Яңа гасыр, ләкин әле ис-
елекләр белән тулы гасыр.
Ігенчелек белән шөгыльлән-
ән әти-әнисе мохтаҗлыкта
өн итә. Такташка да иске
ормышның байтак авырлык-
ларын үз җилкәсендә күтәрер-
гә туры килә. «Үз җилкәсендә»
сүзләре Һади өчен образлы
сыйбарә генә түгел. Ул алпа-
ытның камчысын үз җилкә-
сендә туры мәгънәсендә татый.
Әтисенең бу турыда сөйләве
истәлекләрдә түбәндәгечә тер-
калгән: «Кайсы елда булган-
дыр инде, хәтеремдә калмаган,
Һадины өйләгә кадәр ат аша-
тырга дип җибәрдем. Өйлә
вакыты җитте, ул юк. Ат бик
кирәк иде. Берәр нәрсә бул-
маганмы дип, ат ашаткан җи-
ренә киттем. Барсам, үзе җы-
лап утыра, аты юк. Аты алпа-
ыт Киринның чалуына кер-
гән булган. Кирин этләрен
нәртеп ауга чыкканда моны
күргән. Килеп, башта үзен
камчы белән бик каты кый-
наган, аннан атын хезмәтчеләренә биреп өенә кайтарып җибәргән. Камчы ярлары байтак вакытлар бетми йөрде».



Һ. Такташ үзенең туганнары белән.

Камчы яралары төзәлә, әмма күңел яралары өстәлгәннән өстәлә генә бара. Соң-рак йомышчы малай булып төрле хуҗаларның каралган керләрен, каралган идәннәрен юып көн иткәндә, Бохара кибетчеләренең хезмәткәре булып торганда ул сыйнфый изелүгә нигезләнгән җәмгыятьнең эннан табигатен, кешене рухи һәм физик изүен үз җилкәсендә татый, үз күзләре белән күрә. Тоткынлык дөньясы аны усаллата, әмма ул ак күңеллелеген, пакь күңеллелеген югалтмый.

Заманалар авыр, михнәтләре күп булса да бик вакытлы туа шагыйрь дөньяга. Бу — мәгърифәткә сусаганнарга 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә азмы-күпме иркен-лекләр ачылган вакыт. Такташ та шул мөмкинлекләрдән файдалана. Кечкенәдән ул әдәбият укырга һәвәс малай булып үсә. Кулына эләккән берен — китапмы, журнал-мы — йотлыгып укып бара. Әнисе Шәмсениса апа, улының шундый омтылышларына куанып, китап алып улын шатландырыр өчен чәченә үреп йөри торган кадерле тәң-кәләренә кадәр берәм-берәм сата...

Вакытын белеп туа шагыйрь дөньяга. Бу — татар җәмгыятенең мәгърифәткә генә түгел, азатлыкка да — «хөрлек-инкыйлапка» да сусаган дәвере. Мәгърифәткә генә түгел, азатлык өчен көрәшкә дә уянган, «җирдәге газраилләргә» каршы көрәшүче Х. Ямашев, М. Вахитов кебек революционер улларын тудырган вакыты. «Гакылсызлар йортына» — «алтын сарайларга» каршы киң фронт булып ачылган көрәш үз орбитасына миллионланган халык ташкынын ала. Бу изге көрәшкә зәңгәр күзле Тамбов егете — укытучы, журналист, шагыйрь Такташ та килеп кушыла:

Шулай, әткәй,
Ленин юл күрсәтте
Юлдан язар усал улыңа,
Иптәшләрчә үткен каләм бирде,
— Мә, яз инде! — диеп кулыма.

Юл сурәте шагыйрь иҗатында шактый күп очрый. Аны әдипнең дөньяны кабул итүен аңлатучы үзәк сурәтләрдән исәпләргә мөмкин. Хәтергә төшерик: шагыйрь бит үзен дә «юлчы» дип атый:

Дөнья матур,
Шушы дөньяның мин —
Ирке чикләнмәгән юлчысы;
Давыллы елларның, зур көрәшнең
Матурлыгын җырлар җырчысы.

«Үткен каләм» исемен исеменең исеме дә тирән мәгънәле, җисеменә туры килеп тора. Һади — туры юл күрсәтүче, туры юлга күндерүче дигән сүз. Әлбәттә, исеме җисеменә шулай туры килгәнче, шагыйрьнең үзенә шактый бормалы сукмаклар гизәргә туры килә. Әмма туры юлны бер табып алгач, шагыйрь, ул юлның авырлыклар белән тулы булуына карамастан, читкә тайчанмыйча алга баруында дәвам итә, шул юлга башкаларны да күндерә. Ихлас күңелдән чыккан ялкынлы сүзләре белән, утлы шигырьләре белән күндерә.

Шагыйрь иҗаты өчен үзенчәлекле тагын бер сурәтне искә төшермичә булмый. Бу — «мәңгелек көч белән кайнаучы» янар таулар сурәте. Шул исемдә шигыре дә бар («Янар таулар»). Бу сурәт шагыйрьнең үзенчәлекле фикерләвен ачу ягыннан гына түгел, әдипнең үз образын ачу ягыннан да кызыклы.

Шагыйрь һәм яну сүзләре, аһәңдәш булмасалар да, эчке — шигъри яктан бер-берсенә бик тә якыннар. Әйтергә яраса, алар — синонимнар. Шигърият телендә шагыйрь янып яшәү дигәнне аңлата.

Такташ — пыскып, төтәп кенә янган шагыйрь түгел. Ул бөек инкыйлап кызуы белән гөлт итеп кабынды да шигърият күгендә үз әдәбияты балкышын гәүдәләндергән якты йолдыз, җитез метеор булып балкыды. Бәлки әнә шулай дөрләп-кабынып янганга дә кыска гомерле булгандыр: ул нибары 30 ел яшәде.

Метеор якты яна, ләкин яктылыгы аның салкын. Такташ исә үзенең күңел җылысын, аңа тагын миллион җылы өстәп, яңа төр энергиягә — «мәңгелек көрәш уты белән янган» тылсымлы атом-сүзләргә әверелдерде. Шигырь җылысы белән җир өстен дә, кешеләрне дә җылытты.

Әйе, Такташ — ут шагыйрь, ялкынлы шагыйрь. Замандашларының истәлекләренә караганда, үзенең характеры белән үк ярсу рухлы, давыл табигатьле шәхес булган. Тын бүлмәгә дусты янына килеп кергән икән — «ун баллы давыл кергән кебек», ул үзе белән җанлылык, тормыш тулылыгын, дөнья шау-шуын алып кергән. Каләмдәш дусты Хәсән Туфан язганча:

Гөрләп тора бүлмә, әйтерсең дә,
Тугыз Туфан анда, ун Такташ!

Тынлык һәм торгынлык бәлки Такташ белән килешкән дә, сыешкан да булыр иде, әмма «бунтарь Һади» үзе алар белән гомере буе килешә алмый яши.

Такташ шәһәрдә торса да, туган Сыркыдысын сагынып, авыл кешеләренең йөрәк тибешләрен тыңлап, шуларны җырлап яши. Шәһәрдә яшәвен дә ул йөрәгенең әнә шул акыллы «тилелеге», бунтарьлыгы белән аңлата:

Тамбов урманнарын ташлап китәм,
Нишлим? —
Шау-шуларга күңел чыныккан,
Давылларда туып канатланган
Бунтарь йөрәк кача тынлыктан.

Такташ гомере буена ваемсыз тынлыктан кача, утка ташланган күбәләк кебек, өрәш утына ыргыла, матурлыкны шул көрәштән эзли.

Тынлыкны инкарь итнәгә дә Такташ тормышның мәңгелек кануны булган хәрәкәтне — искелек белән яңалыкның килешмәс көрәшен поэзиясенең таяну ноктасы итеп айлый, шуңа таянып «кояшны атомнардан яшергән көл тавына», «сүнгән атомнар» — тарихның кара көчләренә, халыкны каплаган «черек йөкләргә», «зур пәрдәләргә» каршы давыллы-утлы көрәш ача.

Бөек җиңү алып килгән хисләр
Сыеша алмый таша күңелдә;
Әйтче:
Кайсын шунда җырлап бетереп була
Безгә тигән кыска гомердә?

Хисләре дә аның давыллы, самими һәм гади. Ул хисләргә традицион шигырь калыбы да кысан булып тоела. Шуңа нисбәтән ул шигырь техникасын да үзенчә үзгәртә. Әдәбиятның җанлы практикасында шактый какшый, җимерелә башлаган традиционлыкка: хис-тойгыларны һәртөрле чикләүләргә — композицион-жанр ягыннан бүлсынмы, ритмик-стилистик оештыру буенча булсынмы — каршы чыга, халәте рухиянең иркен агуына нигезләнгән поэтиканы алга сөрә. Аның шигырьләре дә шушы принципка: хис-тойгының иркен агышына корыла. Шагыйрь тойгының бер мизгеле белән генә чикләнми, рухи доньяның бер моментында тукталмый, ә процесс итеп карап, аның төрле яссылыктагы, дәвамлы агышын күзәтә. Композицион бүленештә дә яңа нәрсә күзгә ташлана: шигырь строфалар бөтенлегенә карап түгел, ә лирик кичереш агышына нисбәттән бүлекчәләргә аерыла. Лирик тойгының бер сулыштагы бөтенлеге — үзе бер кечкенә бөтенне тәзи, ә ул бөтен, хиснең эчтәлегенә карап, төрле сандагы юллардан үзенә җыя.

Такташта лирик формалар тагы да төрлерәк һәм хәрәкәтчәнрәк рәвеш алалар. Поэзия эчтәлегенең яңаруына нисбәтән Такташ лирик форманы да яңарта, аны эпиклык һәм тирәнлек белән баета. Шигырьне укучыга тәэсир иттерүнең яңа юлларын һәм серләрен ача, аны сөйләүгә һәм тыңлауга җайлаштыра.

Шигырен язган чакта ук ул аны декламация итеп сөйләүне күздә тота. Язып бетергәч тә берничә төрле рәвештә укып карый, үзенә охшаган бер юлын тапкач, шуңа карап төзәтүләр кертә. Уку техникасына ул нык әһәмият биргән, тамашачы каршына чыкканчы, әүвәле өендә көзгегә карап кат-кат сөйләргә өйрәнгән. Замандашлары Такташта шигырь уку талантының зур булуы турында сокланып хәтергә алалар: «Такташның «Байрак тегәбез», «Мокамай», «Провокатор», «Картайдым шул», «Киләчәккә хатлар»... шигырьләрен укыганын күргән иптәшләр ялкынлы, утлы, чын күңелдәнле Такташны үз гомерләрендә онытa алмаслар. Аның... чын бер җылылык белән көлке итеп укыган кыяфәтен дә, ут кебек янып китеп, уң кулын факел күтәргәндәй югары күтәреп, утлы зәңгәр күзләре өстенә маңгай җыерчыкларын төшереп шигырьләрен укыган чагын да — берсен дә оныта алмаслар...» (Г. Толымбай.)

Таза кешедә таза йөрәк үзен сиздерми диләр. Такташ шигыре дә таза, сау йөрәкнең тибеше кебек. Шундый ук — табигый, шундый ук — хәрәкәтчән... тере... Такташның үзе кебек тыңгысыз, самими һәм гади.

Революция нәтиҗәсендә туган яңа тойгылар шагыйрь өчен гадәти булмаган яңа матурлык чыганагы, бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булды. Такташ үзе язганча, «шагыйрьнең яңалыгы яңа форма уйлап чыгарырга маташуында түгел, шагыйрьнең яңалыгы — аның яңа хисләрендә, яңа уйларында. Шагыйрьнең яки язучының бүгенге яңа хисләрне, яңа уйларны формалаштыруы өстендә эшләве, шул идеяләрнең формаларын таба белүе — бу аның форма яңалыгын тудыру өстендә эшләве дигән сүз».

Такташ поэзиясенең новаторлыгы да, барыннан да элек, аның лирик героеның яңалыгы белән билгеләнә. Такташ үзе дә — яңа чор тудырган яңа буынның талантлы бер вәкиле. Шуңа да яңа кешеләрнең яңа уйларын, яңа хисләрен күреп ала белү аның өчен кыен булмый. Ул «шул уйларны, хисләрне үзенең йөрәгенә сеңдереп, аларны үзенең йөрәк җылылыгы белән тәрбияләп, үстереп, үзендә булган шигъри буяулар белән буяп», массаның йөрәгенә сеңдерә.

Такташның йөрәге — гаҗәп күп сыйдырышлы йөрәк. Искиткеч сизгер йөрәк. Кешелекле йөрәк. Аның йөрәге — кешеләргә тирән мәхәббәт белән тулы. Кешеләрдәге һәр күңел ярасы аның йөрәген дә телгәли. Кешеләрнең шатлыгы — аны да куандыра. Шагыйрь буларак аваз бирүе дә аның халык моңын, кайгысын күрүе белән, халыкны изгән социаль-милли олы афәттән тетрәнүе белән бәйле була. Шушы моң, ачу, нәфрәт аңарда шигырь булып ташып чыга. Халык ачуы, моңы — шигъри вулканны хәрәкәткә китерүче шартлаткыч аммонал кебек. Шушы нәфрәт, ачу тойгысы әүвәле аның бөтен йөрәген тулы килеш биләп ала. «Газраилләр» [1916], «Караңгы төннәрдә» [1916], «Төркстан сахраларында» [1917] кебек шигырьләрендә дөньяны каплаган караңгылык тагы да караңгырак, салкынлык тагы да салкынрак булып тасвирлана. Миллионнар ачуын үзендә туплаган йөрәк ялгызлыктан, «хыялында суык җилләр исүдән» ярсый. Шагыйрьгә җир өсте зиндан, караңгы төн булып, ә үзе «зольмәтләргә йотылып» адашкан юлчы, дөньяны каргыш-сагышлары белән ләгънәтләүче җырчы булып тоела. Җир өстен җәннәт урынына — дәһшәт баскан: сөякләрдән — янар таулар күтәрелгән, каннан күлләр оешкан!.. Әмма бөтен тамырлары белән җиргә береккән, ирекkә сусаган җир улы җирне ташлап китә алмый. Сыйнфый көрәш алгебрасын үзләштергән саен, революциянең якты нурларын күбрәк күргән саен аның алдындагы томаннар тарала, поэзиясе дә яктыра бара. Хәзер аның лирик герое да җирне «еланнардан тазартыр өчен көрәш сафына баса:

Еланнар! Сезгә юк тормыш,
Куып юлдан, буып сезне,
Ачам юллар сәгадәткә!
Җуям җирдән фәхеш эзне...—

дип яза ул «Антым» [1920] шигырендә.

Җир белән бәйләнеш елдан-ел ныгый. Шагыйрьнең күңеле дә, җаны да, иманы да — хәзер җирдә. Алай гына да түгел, элек һәрберсе үз алдына аерым-аерым, бер-берсе белән каршылыкта яшәгән «күңеле, җаны һәм иманы бергә кушылып», шагыйрь эчке рухи бөтенлек һәм даимилек халәтенә күчү эзенә баса. Бу яктан аның «Айның нурлары арасында» [1920] шигыре игътибарга лаек. Кушылган күңел, җан һәм иман айның нурлары белән бергә «дулкынлы караңгылык өстеннән» кемнәрне эзләп оча! Сәгадәт өчен көрәшкән кызыл каһарманнарны. Аларны куе калын томаннар эченнән эзләп табып, сәламлиләр, шәһит каһарманнарының рухларына илнең сәламен ирештерәләр, батырларның «кабер ташларын үбәләр».

Халык күңелендәге тирбәлешләргә үтә сизгер йөрәге 1921 елны Идел буенда җәелгән ачлык күренешләрен дә, ачлык тудырган газапларны да сыйдыра. Үзенең 1921 елгы бер шигырендә ул: «Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны еглатырга; әйе, миндә көчле Байроннар җаны!» — дип язган иде. Халыкның әлеге олы кайгысы шагыйрь йөрәген дә бөтенләе белән биләп ала. Бу олы кайгыны ул шундый ук олы итеп ача, «бар дөньяны еглатырлык» бәла-каза итеп, мифологик образларга төреп күрсәтә. Ачлыкның экономик-социаль сәбәпләре «серле моңнар» томаны эчендә күмелеп калса да, шагыйрь бу дәһшәтнең икенче ягын — аның тормышны сөйгән җир уллары өчен зур фаҗига булуын, кабатланмас матур гомерләрне вакытсыз сүндерүен «көчле Байрон җаны белән», күңелләрне тетрәтерлек итеп сурәтли.

Такташ кешедәге киеренке драматик тойгыларны, фаҗигале хәлләрне аеруча зур осталык белән ача. Аңарда, чыннан да, «бар дөньяны еглатырлык» сәләт бар. Иҗат куәте ягыннан ул — кабатланмас трагик. «Газраилләр» [1916], «Күләгәләр» [1922], «Үтерелгән пәйгамбәр» [1918] ләрдә үк ул — трагик. Талантының шушы ягы «Җир уллары трагедиясе»ндә [1921] тагы да тулырак ачылып китә. Мифологик сюжетка корылган әлеге әсәрендә шагыйрь дини кануннарның җир улларын рухи изүен һәм рухи зольмәткә каршы кешедә акылның уянуын, көрәш башлануын Шекспир, Байроннарга хас колач, драматизм һәм монументальлек белән сурәтләде. Ул — рухи коллыкны ләгънәтләгән, рухи азатлык өчен көрәшкә гимн җырлаган әсәр булды. Талантының шушы көчен иҗатының беренче чоры белән генә чикләү шулай ук дөрес булмас иде. «Гасырлар һәм минутлар», «Мокамай» поэмаларында да, «Югалган матурлык», «Күмелгән кораллар» пьесаларында да аның трагиклык таланты ачык гәүдәләнде. Яңа тип оптимистик трагедия буларак татар совет поэзиясендә яңа сәхифә ачкан «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын хәтергә төшерик. Әсәрдә В. И. Ленинның

үлеме бөтен кешелек өчен нинди олы кайгы итеп сурәтләнә! Шагыйрь Ленинның җанлы образын, катлаулы характерын иҗат итүне максат итеп куймый. Аның максаты башка: Ленинның гасырлар тудырган тарих улы булуын сөйләү, аның бөеклеген ачу, үлем китергән минутларның бөтен җир шарына зур кайгы булуын, әмма Ленин үлсә дә аның идеяләренең яшәүчәнлеген күрсәтү. Шуның өчен дә шагыйрь бу юлы психологик анализ белән мавыкмый, сюжетны вакыйга сурәтләүгә түгел, ә фәлсәфи фикерләүгә һәм Ленин үлү вакыйгасының кешелектә нинди фаҗигале яңгыраш тудыруын ачуга юнәлтә.

Такташ — чор драматизмын тирән ачкан, заманының трагик коллизияләрен оста гәүдәләндергән трагик кына түгел. Иҗатының иң беренче чорында фаҗига төп урынны биләп торса, тора-бара аның иҗатына тормыш бөтен тулылыгы белән керә. Заман һәм тормыш шагыйрьдә төрле яклары белән чагыла: үлемнәре һәм туулары белән дә, кайгылары һәм шатлы[illegible]ры белән дә, сагышлары һәм елмаюлары белән дә, җиңүләре һәм җиңелүләре бел[illegible]н дә... «Соңгы язуларымда минем елмайган йөзем күпләргә күренерлек инде. Чыннан да елмаям. Киләчәктә бәлки бик матур, бик шатлыклы көлә дә алырмын»,— дип яза ул энесенә 1929 елның 9 августында.

Такташ поэзиясе — тормыш кебек күп яклы, тормыш кебек күп тавышлы, тормыш кебек күп буяулы.

Җирдә гыйсьян җыры,
Җирдә тормыш симфониясе,
Җир әйләнә.

Шагыйрь дә үз иҗатында тормыш симфониясен шигъри пафос, югары патетика белән катлаулыгында җанландыруга ирешә. Күп төрле моңнар, күп төрле авазлар, «үзенә башка тавышлар» яңгырый анда. 20 еллардагы татар тормышына хас моңнар... Шул чорга хас авырлыклар... Барлык моңнарын, барлык авазларын үзенә берләштергән бер олы моң бар — бу гыйсьян җыры. Шушы көрәш җыры — Такташ симфониясенең лейтмотивы.

Тарихның агышын ул монументаль бөеклеге, романтик киң колачлылыгы белән дә, тормышчан гадәти чынлыгы белән дә сурәтли. Кайчак аңарда шушы ике як аерылыбрак тора, кайчакта бергә кушылып китә.

«Җир уллары трагедиясе»н тәмамлау белән, Такташ шул ук романтик-символик сурәтләрдә җирдәге тарихи-иҗтимагый үсешне һәм Бөек Октябрь революциясенең җиңүен гәүдәләндергән зур әсәр иҗат итәргә уйлый. Әлеге олы героик циклның аерым шигырьләре дөнья да күрә. «Нәләт» шигыре (1922) — шушы уйланылган әсәрнең беренче өлеше. Аның икенче исеме дә бар — автор җәяләр эченә «Ил трагедиясе» дип куйган. Шушы исем эчтәлеккә бик тә туры килә һәм шагыйрьнең ниятен дә ачыкларга булыша. Янар таулар хәрәкәтен — халык кузгалышын, революцияне сурәтләгәнче шагыйрь ил трагедиясен — хезмәтчел халыкның фаҗигале язмышын тасвирлый, җәмгыять үсешендә эшче халыкка ясалган хыянәтне ача, ханнәргә, алтын сарай кешеләренә — изүче сыйныфка нәләт укый.

Шушы циклга караган «Бакчачылар» (1922) һәм «Гыйсьян» (1923) шигырьләрендә җәмгыять үсешендәге сыйнфый каршылыкны ачу дәвам итә. Лирик герой шигырь саен яңарак яктыртылышта, яңа кыяфәттә ачылып китә. «Гыйсьян»да ул алтын сарайларга нәләт җыры яудыручы яки кайдандыр бакчачыларның килүен өмет итеп пассив күзәтеп утыручы гына түгел инде. Иҗтимагый фикер үз үсешендә яңа биеклеккә күтәрелә, ачу, өмет итүләрдән көрәшкә күчә. Иҗтимагый хәрәкәт үсешен дә үзендә гәүдәләндерә барган лирик образ — инде гыйсьянчы:

Гыйсьян итеп сезгә каршы,
Сорыкортлар, мин менә,
Куркыныч утлар ягып
Чыктым янар тау өстенә.

Әмма әле аның ялгыз көрәше нәтиҗәсез тәмамлана, ул җибәргән ут кабынмый, сүнә... Шулай да символ[illegible]к лирик геройда ышаныч, өмет бар. Хәзер инде ул ниндидер бакчачылар килү иллюзиясеннән азат (чөнки аллаларны утка атты), аның ышанычы — башланасы яңа гасырда — эшне илаһ итеп күтәргән корыч гасырда. «Нәләт»тә

аргамакларга атланган вәхшиләр заманы турында сүз бара иде. Ә хәзер заманы башка — корыч гасыр, XX гасыр.

«Нәләт», «Бакчачылар», «Гыйсьян» шигырьләре, шул рәвешчә, үзләре бер олы шигъри бәйләм булып берләшәләр. Аларда шагыйрь җәмгыятьтә сыйнфый каршылыкларның тууын һәм көчәюен, сыйнфый көрәшнең аерым баскычларын символик образларда, шартлы күренешләрдә гәүдәләндерә. Боларны «Нәләт» шигыре астына шагыйрь үзе куйган икенче исем белән «Ил трагедиясе» дип атарга мөмкин булыр иде. Әмма шагыйрьнең олы шигъри фикере югарыдагы шигырьләр белән генә чикләнми. Шагыйрь сыйнфый җәмгыятьтәге каршылыкларның чишелешен дә — Октябрь революциясен дә гәүдәләндерергә уйлый. Икенче бәйләм «Янар таулар» һәм «Октябрь төне» шигырьләреннән тора.

«Янар таулар»да шагыйрь җәмгыять үсешенең сыйнфый көрәшкә бәйле яңа бер баскычын — әнә шул «корыч гасыр»ны күз алдына бастыра. Бу югарылык ялгыз бунтарьлыктан — ялгыз янар таудан күмәк көрәшкә күчүдә. Хәзер гыйсьянчыларның исәбе-хисабы юк — атомнар шикелле чиксез күп алар. «Октябрь төне»ндә инде «гыйсьян уе»ның иң югары сыйнфый ноктасына җиткән ку[...]еше — халык кузгалышы, революция тасвирлана.

Таң ата...
Гыйсьян явы әкрен генә
Канлы кырлардан басып җырлап килә:
«Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз,
(Кайсылар безне үлемдәй каплаган.)
Ишетәсезме!
Без яңа юл башлыйбыз,
Мәңге утларга, кояшларга табан!»

«Шагыйрь — ул элек шигырьне үзенең тормышында тудырырга тиеш»,— дип язган иде Такташ бер мәкаләсендә. Революция турындагы кичереш-уйланулар аның үз тормышында, әлбәттә, туган иде. Шагыйрь 1917 ел революциясен «марсельеза җырлап каршы алган» икән, Бохара әмиренә каршы мәгълүм сугышта катнашкан икән, коммунистлар органы булган газеталарда эшләгән икән, Ташкент Комуниверситетында укыткан икән — болар барысы да Такташның революция турында зур фәлсәфи-лирик әсәр язарга рухи хәзерлеге булуы турында сөйлиләр. «Ил трагедиясе» һәм «Янар таулар» — шушы уйлануларның шигъри телдәге катлаулы һәм монументаль гәүдәләнеше. Халык революциясен масштаблы итеп күрсәтер өчен шагыйрь зур гомумиләштерү көченә ия булган символик сурәтләргә мөрәҗәгать итә. Бер яктан, мондый шартлы образлар халыктагы «гыйсьян уе»ның үсешен тарихи барышта масштаблы итеп күрсәтергә чыннан да ярдәм итсәләр, икенче яктан, ул сурәтләрнең конкрет эчтәлеген артык гомумиләштереп билгеләү, җәмгыять күренешләрен тарихи-конкрет аңлатучы сурәтләрне табып һәм билгеләп җиткерә алмау аның сәнгатьчә максатын тулырак ачарга билгеле дәрәҗәдә комачаулый да. Әмма бу шигъри ниятнең тормышка ашкан кадәре дә татар поэзиясе өчен гаять зур җиңү, ә шагыйрь өчен кыю эксперимент булды.

Такташ алдагы иҗат юлында шушы лирик симфонияне язу барышында туплаган тәҗрибәсен файдаланды: символик сурәтләрне куллануны ташламастан, аларны иҗтимагый тормыш күренешләренең асылын ачуда үткен корал итте, гомумилек белән конкретлыкның тыгыз бердәмлегенә иреште. Шушы ук теманың дәвамы рәвешендә уйланылган өченче зур лирик симфониядә дә («Давылдан соң», 1924) бу ачык күренә. «Янар таулар»да шагыйрь революцияне — давылны гәүдәләндерсә, «Давылдан соң» әсәрендә Октябрь революциясеннән соңгы дәверне — «үткән күперләрне ягып, якты киләчәккә күчүне», иске тормышның үлүен, коммунизм гиганты күтәрелүен, «табигатьнең иркен күкрәгендә барган мәңге көрәш, мәңге хәрәкәтнең» яңа баскычын конкрет иҗтимагый күренешләрдә, реаль сызыкларда тасвирлады.

«Ил трагедиясе» («Нәләт»), «Янар таулар», «Давылдан соң» — болар бер шигъри теманы чишүгә багышланган өч лирик симфония. Аларның сәнгатьчә тәэсир итү көче әлеге симфонияләрне янәшә эзлеклелектә караганда гына тулысынча һәм бөтен тирәнлегендә ачылып китә.

«Киләчәккә хатлар» әсәре дә әнә шундый грандиоз үйланылган катлаулы лирик
укыма. Аяныклы үлем аркасында гына шагыйрьнең олы шигъри максаты тормышка
шып бетми: үйланылган ун хатның ул тик өчесен генә тәмамлый. Һәр хатның конкрет
игъри максаты, чагыштырмача мөстәкыйльлеге бар. Такташ үзе болай дип яза:
Беренче хатта... мин сыйнфый көрәшнең гомуми фонын бирдем. Икенче хатта...
олхозчы һәм гомумән безнең күчү чоры кешесенең психологиясендәге каршылык-
ар бирелгән күрсәттем. Өченче хатта мин социалистик хезмәт кешенең психология-
ен ничек үзгәртүен сурәтлим». Әмма бу хатлар бер-берсенә олы шигъри фикер
елән тыгыз бәйләнештә яшиләр. Бу бердәмлек шигъри фикернең берлегендә дә
кяңа тормыш-көнкүреш, яңа кеше өчен алып барган көрәшебезне тасвирларга
ырышам», ди шагыйрь үзе], әлеге фикерне билгеле бер эзлеклелектә ачуда да күренә.

Такташ поэзиясендә катлаулы бәйләнештәге һәм зур лирик формаларның киң
рын алуы шагыйрьнең тормышны тикшерүдә лирик типиклаштыру мөмкинлекләрен-
ән осталарча файдалана алуын, бу өлкәдә дә яңа юллар салып калдыруын раслады.
Кешенең җәмгыять һәм тарих белән бәйләнешендәге яңа мөнәсәбәтләре шагыйрь
ижатында лириканың яңаруы рәвешендә дә гәүдәләнде.

Такташ — хыялый шагыйрь, хыялга бай шагыйрь. Аның шигъри фантазиясе коты-
ып эшли. Мондый йөгерек һәм кыю фантазиясе аның кече вакытында ук инде үзен
издерә һәм шул «матур алдаша белүе» өчен аңа эти-әнисеннән дә, иптәшләреннән
дә шактый эләгә. Шагыйрь үзе бу турыда болай дип искә ала: «Алты яшьләремдә мин
язучы булмаганмын, ләкин минем башка һөнәрем булган. Мин ул вакытта үземнең
авылда алдауларым белән мәшһүр булганмын. Бу нәрсә минем эти-әниләр һәм ип-
тәшләрем алдында бик яшьли авторитетым төшүгә сәбәп булган... Кыйналуга сәбәп
булган бу алдаулар, билгеле булмаган вакыйгаларны сөйләү өчен түгел, кайда да бу-
лып үткән вакыйганы үзгәртә төшеп, матурлап сөйләгәнем өчен...»

Кечкенә вакытта гына түгел, шагыйрь булгач та аңа әлеге бай хыялы, кыю образ-
лылыгы өчен нык кына кыйналырга туры килә. Бу юлы инде шагыйрьне аның талант
үзенчәлеген аңларга тырышмаган вульгар-социологик әдәби тәнкыйтьчеләр кыйный.
Тик шунысы шагыйрьне куандыра: аны укучылары аңлый, укучылары кабул итә.

Такташның образлары яңа һәм оригинал булулары белән аерылып торалар. Шул
ук вакытта алар искиткеч халыкчан. Халыкның сурәтле фикерләве белән шагыйрьнең
сурәтләр дөньясы арасында бернинди каршылык юк, киртә юк, әдәби тукыманы
кабул итә алмыйча кире кагу күренеше юк.

Их!
Кичә генә әле февраль иде,
Бүген давыл кырга кар ташый;
Март аеның нечкә билле җиле,
Сузылып ятып җиргә, кар ашый...
Ерак калмый инде майга да,
Яз ясарбыз салкын тайгада,
Җир безнеке булыр!
Ачулансак,
Шлем киертербез айга да!

(*«Нәни разбойник»*).

Халыкчан кыю образлылыкның шагыйрьдә очраган гадәти бер үрнәге бу. Менә
тагын бер мисал:

Кинәт
Гасырларның күз яшеннән
Бомба ясап ыргытсаң да,
Шушы йоклап яткан Европаны
Уятсаң да,
Әйтсәң әгәр:
— Ленин тере! — дип.

(*«Еллар таңында»*).

Шигырьдәге күтелмәгән күчеш һәм сикерешләр, сурәтнең нәфис сыны, тәгъләге
һәм тирән мәгънәлелеге, төп фикернең татар укучысына якын булган гадәти тормыш

күренешләре һәм предметлары аша сурәтләнүе, гадәти сүзнең яңадан-яңа мәгънәләре төсмерләре ачылуы, кирәк урында аны якты йолдыз шикелле балкытып җибәрү, сүзнең колакка ятышлы матур аһәңен табу — Такташ поэтикасына хас үзенчәлекләр.

Такташның образлы фикерләү эволюциясендә халыкның дөньяны кабул итүендә, фикерләвендә туган яңалыклар, үзгәрешләр ачык чагылды. Аңарда фән заманы кешесенең фикерләү стихиясе, бердәнбер фәнни тәгълиматны үзләштерү шигърияте аерую калку булып гәүдәләнде. Шул нигездә аңарда мифологик һәм дини сурәтләр кимүгә таба йөз тотты, җирнең һәм тормышның хуҗасы булган кешене камаган предметлар яңа символика, яңа шигъри мәгънә белән ачылдылар.

Вакытның кодрәтле көчен, кабатланмас гүзәллеген ул татар поэзиясендә моңача күрелмәгән шигърият дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлады. Вакыт үзе дә, аның агышы да конкретрак, җисемлерәк, шул ук вакытта фәлсәфирәк рәвеш ала бара. Вакыт Такташның образлы фикерләвендә үзенчәлекле миссия башкара.

Гасырлар һәм минутлар... Бер яктан шагыйрь гасырларны иңли, бүгенге белән үткәннең, бүгенге белән киләчәкнең катлаулы бәйләнешләрен, алар арасындагы якынлыкны һәм ераклыкны — хәрәкәт диалектикасын үткен акылы белән тикшерә. «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар» поэмасында вакыт белән әнә шулай иркен эш итү, аның кеше акылына буйсынган серләренә төшенү, тарихны «грандиоз итеп аңлау» омтылышы аеруча ачык күренде. Шагыйрьнең күрем офыгына еллар гына түгел, гасырлар, дөньялар, тарихлар сыя, анда да хәрәкәте белән, агышы белән. «Янар таулар» шигырендә шагыйрь турыдан-туры болай ди:

Искереп бетте:
Тарих,
Еллар,
Гасырлар,
Дөньялар...
Искереп бетте гомер,
Барлык
Фаза,
Тормыш...
Алар
Искереп чергән диварлардай аудылар,
(Безнең өскә)
Алар капландылар...

Икенче яктан, гасырларның, елларның, тарихларның минут һәм секундлардан җыелганын, мизгелләрдән оешканын ачык сиздерә шагыйрь.

Такташка кадәрге поэзиядә вакыт, иске тормышка хас булганча, акрын ага, ел әйләнешендәге табигать үзгәрешләре яисә тәүлек эчендәге көн һәм төн алышынулары белән генә күренә иде. Такташта вакыт төшенчәсе яңача ачылып китә. Ул тормыштагы динамиканы да, вакытка бәйле каршылыкларны да, җимерүне генә түгел, төзүне дә сыйдыра. Шагыйрьдә вакыт — тирән мәгънәле, кызу агышлы. Ул үзе бер катлаулы образ, үзе бер шигъри дөнья, җисемле, фәлсәфи дөнья.

Вакытның кеше гомере өчен алыштыргысыз кыйммәте Такташта аеруча бер тирән кичереш белән ачыла.

Канатымны еллар каерса да,
Каерса да,
Ах, үләсе килмәс, үләсе...—

ди ул тормыш матурлыгына сокланып. «Булмаса, дөнья шундый матур, Габидулла, мин әлеге яшемә кадәр аның бу кадәр матурлыгын сизә алганым юк иде. Дөнья үзенең авырлыгы белән матур икән»,— дип яза ул энесенә хатта. Ничек үлсен «берләр меңнәр өчен, меңнәр берләр өчен торганда»! Кешеләр арасында туган шушы эчке матурлык, эчке җылылык шагыйрьнең йөрәген дә, шигырьләрен дә җылыта, вакытның һәм яшәүнең кадерен белергә өйрәтә. Аеруча ул балачак һәм яшьлек хисләрен романтик күтәренкелек, җылылык һәм эчке бер сагыш белән тасвирлый. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында һәм «Зәңгәр күзләр» циклында без моны аеруча ачык күрәбез.

«Зәңгәр күзләр» циклы «Сагыну» шигыре [1923]
редә бала чакның кире кайтмас саф матурлыгына күңелен юнәлтә. «Зәңгәр күзле
ла чак» күңел дәфтәрендә бик томанлы гына булып саклана, әмма ул гомеренең
ре кайтмас матур вакыты булып урын алган.

Бирегез миңа, бирегез
Зәңгәр күзле яшь чагымны! —

п омсына лирик герой. Әмма тормышның вакыт законы кызганучы, шәхеснең күңел
запларын җиңеләйтүне белми. Бу юлы вакыт — каты бәгырьле... Ул үткәнгә кире
йтармый. Тик аңа күңелдә генә кайтып була.

Циклның «Зәңгәр күзләр» шигырендә [1923] лирик герой инде яшьлек елларына
йта. Хәзерге юлында гөлләр үссә дә, бүгенге матурлык урап алса да күңелендә
кән матурлыкны сагыну — яшьлекнең кабатланмас серле очрашуларын, яну-ялкын-
зынуларын сагыну:

Мин сагынам,
Өзелеп сагынам аны,
Тик ул инде минем хәтердә
Бик томанлы, бик томанлы булып калган;
Миңа хәзер дә
Бик еракта, гүя бик еракта
Сихерле сын булып күренә.
Сихерле сын... тирә-ягы чиксез урман...
Төренеп ул сирень гөленә,
Туктап карап тора.
Гүя үзе кешелекнең җанлы сыны кебек,
Күзләрен мәңгелеккә табан төгеп,
Туктап карап тора...

Циклның «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр» шигырендә [1923] күңел түрендә урын
лган иң истәлекле хатирәләрнең чираттагысы — Марияга булган көчле мәхәббәте
(анлана. Бирәдә дә вакытның кырыс чынлыгына үпкә бар. Әмма үпкә генә түгел,
ирик герой вакыт агышының котылгысызлыгын да таный.

Мәхәббәт егет күңеленә матур истәлекләр генә түгел, төзәлмәс тирән яра да
еп уза:

Мария!
Мине синнән дин исеменнән аердылар,
Тартып алдылар,
Милләтләр белән, диннәр белән
Арабызга киртә салдылар.

Араларына киртә булып төшкән кануннарга каршы егет көрәшеп йөргән, аларны
ар-мар иткән. Иске кануннар юк инде, әмма... җир өстендә хәзер аның сөйгәне
дә юк.

Минутлар, секундлар кабатланмаган кебек, кеше гомере дә, аның хис, кичереш-
ләре дә кабатланмый, ди шагыйрь. Һәр кеше — алыштыргысыз, һәр кешенең үзенчә
үзгә рухи дөньясы бар. Такташ шуңа да дөньяның төреклегенә, шул чорның «ямаулы»,
кырыс матурлыгына күзләрен тутырып карый. Шушы зур итеп ачылган зәңгәр күз-
ләргә планетада барган каты көрәш, илнең һәм туган Татарстан көнкүрешенең яңаруы
гына түгел, кешене урап алган табигать тә җанлылыгы һәм матурлыгы белән
күренә. Такташ үзенең характеры белән — табигать улы. Табигатьтәге бар нәрсә аңа
якын. Көчкенәдән үк ул этләрне, каз бибиләрен, песиләрне яраткан. Якыннары шулай
дип сөйлиләр: бер вакытны ул ике каз бәбкәсен куенына куеп йоклап киткән. Уянса —
бәбкәләр изелеп үлгәннәр. Йөрәге әрнеп, үбеп-үбеп җылый да, кабер казып күмә.
Кабер тирәсенә шешәләрдән коймa ясый... Бүтән җәнлек-җанварларны да ярата, ат,
сыерларның күзләрен үбә, йоннарын тарый, сылый-сыйпый торган була. Аның
иҗатында песиләрнең, каз бибиләренең җылы хис белән тасвирлануы һич тә очраклы
түгел.

Такташ чәчәкләрнең дә, җилнең дә, «дөнья җимереп җырлап йөргән әтәч хатыны бибн тавык»ларның да телен белә, алар белән якын итеп сөйләшә, аларга җитди шигъри нагрузкалар йөкли белә.

Ах,
Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен,
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем.—

дип язды ул «Үтеп барышлый» шигырендә. Ул татар поэзиясендә беренче буларак Тамбов урманнарындагы усак һәм каеннарның башкаларга күренмәгән матурлыгын ачты, урман чәчәкләренең керфекләре ачылуын күрде. Идел буендагы кышның, Россия уртасындагы кышкы салкынның аңача поэзиядә күрелмәгән үз шигъриятен тапты. Әллә инде кыш уртасында туганга, ул кышны аеруча яраткан, хәтта кыш көне үләсен дә әчке бер интуиция белән сизенгән:

Ә мин бу ел кышын үләрмен үк,
Сезнең өчен
Бик күңелсез калыр, мин үлгәч...
(«Ертык бүрек»).

Фатих Хөснинең «күбәләк-күбәләк кар яуса, Һади Такташ хәтергә төшә» дигән шагыйрьнең әнә шул сәер мәхәббәтенә ишарә ясый.

Җир әйләнә... Вакытның кодрәтле агышын бер кем туктата алмый кебек. Ә менә тылсымлы көчкә ия булган Такташ заманның кабатланмас сынын шигърият теленә күчерү белән мизгелләрне — минут-секундларны туктата алды. Шуның нәтиҗәсендә без бүген дә шагыйрь иҗат иткән дәвернең җанлы сулышын ишетәбез, шул чор кешеләре белән шигырь телендә сөйләшәбез. Такташ безгә үткән белән бүгенгене тоташтыра. Әмма Такташ үткән чор кешесе, 20 еллар шагыйре генә түгел. Ул бөтен шигъри җаны белән — безнең заман кешесе. Бүген дә ул утлы-хисле шигырьләре белән безнең белән бер сафта атлый, бүгенге матурлыкны күрергә, аның өчен көрәшергә өйрәтә.

Киләчәккә ул «Киләчәккә хатлары» белән генә түгел, бөтен поэзиясе белән бергә бара. Ул — киләчәк шагыйре дә.

# ҺАДИ ТАКТАШ ХАТЛАРЫ[1]

*22 март, 1926 ел, Казан.*

Иптәш Изотов!

Сез «Мәхәббәт тәүбәсе» исемле шигыремне чуваш теленә тәрҗемә итәргә миннән рөхсәт сорыйсыз. Әгәр сез тәрҗемәдә минем авторлык исемемне сакласагыз (бу — гомум кабул ителгән кагыйдә), әгәр эчтәлеген бозмасагыз һәм үзгәртмәсәгез, мин шул шартлар белән үз әсәремне тәрҗемә итәргә рөхсәт бирер идем.

Әсәрнең сез тәрҗемә иткән исеменә карап хөкем йөрткәндә, сезнең татар телен белүегез зәгыйфь булып күренә. Чөнки «Мәхәббәт тәүбәсе» бүтән телгә тәрҗемәдә «Клятва любви» түгел, «Исповедь любви» була. Әгәр сез тәрҗемә иткәндә шундый тупас хаталар ясасагыз, әсәрнең эчтәлеген үзгәртүегез һәм бозуыгыз мөмкин. Шуның өчен дә мин сезгә бастырганчыга кадәр тәрҗемәгезне татар телен яхшы белгән кешеләр белән бергәләп җентекле төстә тикшерергә һәм эшкәртергә киңәш итәр идем.

Сез миңа шундый шартларга күнсәгез, мин үз әсәремне чуваш теленә тәрҗемә итәргә рөхсәт бирәм.

*Иптәшләрчә сәлам белән ТАКТАШ.*

*3 июнь, 1931 ел, Казан.*

Иптәш Новичков!

Рәсемнәреңне һәм хатыңны алдым. Вакытым бик кыска булганга бик кыска гына язам. Чөнки шул көннәрдә отпускага китәм. Эш бик күп. Кичер.

Беренче — рәсемнәрең турында:

1. Бәйрәкә ячейка секретаре рәсеме бу надпись белән баралмый. Ә рәсемнең эшләнеше башка надпись бирүне авырлаштыра. Башка надпись табарга тырышырмын.

2. Кулак хатыны рәсме дә бу надпись белән баралмый. Кызыксыз. Икенче надпись табарга кирәк булыр. Баладан берәр акыллырак сүз әйттерергә кирәк. Замысел матур һәм журнальный.

3. Миңа сорау галәмәте белән ясалган рәсмең плакатный.

Кайбер киңәшләр:

«Чаян»да без мөмкин кадәр плакатный рәсемнәрдән качарга тырышабыз. «Чаян»га кирә торган рәсемнәр, беренче, журнальный, ягъни кешеләр табигый булырга һәм надписьлары кызык булырга тиешле. Шуның өчен иң элек, рәсемнәреңне ясау алдыннан, рәсемеңә матур надпись табып куй. Шундый типларны һәм, надписька карап, типларның физиономияләрен ясарга тырыш.

«Татиздат»ка читтә торып плакатлар ясаудан бер файда да чыкмас. Чөнки ул плакатлар күбрәк «Татиздат»ка аерым оешмалар тарафыннан бирелгән заказлар буенча гына эшләнә. Син күбрәк карикатуралар ясарга тырыш. Бер яктан, аларны бастырырга мөмкинлек бар, икенче яктан, синдә карикатура ясарга зур гына көчең барлыгы күренә. Сиңа, әлбәттә, укырга кирәк иде. Кыскасы, отпуска вакытында Казанга килеп китсәң, бәлки бу мәсьәләне яхшы якка хәл итеп булыр иде.

*Хуш. ТАКТАШ.*

---

[1] Хатларны редакциягә шагыйрьнең улы Аван Такташ тапшырды. Кайбер хатларда берничә җөмлә кыскартылды.



*Ә. Мәҗит, Һ. Такташ, А. Уразаев.*

*Июль, 1931 ел, Казан.*

Кыйммәтлем Гөлчәһрә!

Моннан элек (кайту белән) сиңа хат язып җибәргән идем. Боголомов иптәш аркылы җибәргән хатыңнан ул хатны алмаганлыгың билгеле булды. Аннан соң хатыңны алуга кадәр язган бер хатымны һаман җибәрә алмый йөрдем. Бу хат белән аны да җибәрәм.

Казанда рәтле эш эшләгәнем юк. Ремонт мәсьәләсендә (мичләрне) бөтенләй отказать итәләр. Шулай да горсовет Татжилсоюз аркылы эшләтә алмасмы, дип йөрим. Бүген Горсовет белән Татжилсоюзда булдым. Тиешле кәгазьләрне алдым. Сүтеп булса да ни дә эшләргә тырышырмын. Бүлмәне (зур бүлмәне) ремонт өчен хәзерләнеп торам. Обойлар таптым. Габидуллага да хәзер мел табасы гына калды. Главный эш мичләрдә. Сез Актаныштан туеп та өлгергәнсез, монда Казанда кызыгырлык әйберләр дә юк. Билгеле, мин үз иркегезгә куям. Ә дөресрәге бик сагындым. Бүген кайтсагыз да көтәм. Теләсәгез, 15 ндә кайтыгыз. Булмаса монда мин дә беспризорный кебек йөрим.

Калган нәрсәләр турында киңәшербез. Билгеле, кайткач.

Хәзер үземнең сәламәтлегемне белдерәм. Сине бик сагындым. Юк нәрсәләр белән эчеңне пошырма. Яшьлек үткән, малай. Кызларга башны күтәреп карыйсы килми. Аннан — эш күп. Син мөмкин кадәр күбрәк хәрәкәт ит. Булмаса, малай тазарып, үзеңә авырлык китерер.

*Сагынып, үбеп ҺАДИЕҢ.*

*25 июль, 1931 ел, Казан.*

Гөлчәһрә!

Әле сагынып өлгермәдем үзеңне.

Казанда йөрим.

Ятим бала кебек.

Өйдә теге күршеләрнең үләргә җитешкән песи малайларыннан башка беркем дә юк.

Фәизә ачкычларны үзе белән алып ял итәргә киткән. Васильевкадан эзләп таптым үзен. Гафу үтенә.

Пароходта үземне Хуҗа Насретдин кебек сынап кайттым. Кызларга күз төшерә тырыштым. Хәзер шуның өчен үземне үзем сыйлап йөрим. Молодец дим, үземүл турыда кайгырма.

Актанышның мәхзүн «Идел» суын, андагы тынычлыкны, билгеле, сине сагынам.

Иркәләнергә теләгән минутларымда үземне үзем иркәләргә тырышып карыйм да уланам.

Иркәләргә ялкауланмаган, минем йөрәк тынычлыгым өчен бик күп нәрсәләрне корыткан сине юксынам.

Су кер.

Ял ит.

Мине сагын!

Ямә?

Мин Казанда

Ятим бала кебек йөрим.

Син тагын, кызганып, Мәрзия кебек елап җибәрмә,

Мәскәү «Камил» турында тынычсызланган.

Гомәр мәкаләсе үз тәэсирен иткән.

Вильтмон Казанда. Шул көннәрдә «Восток кино»ның директорын көтәбез. Бәлки көүгә китәрмен.

Мин хәзер алар белән аяк терәп сөйләшәм.

Бәлки Казанга берәр режиссер җибәрүне сорармын. Ни дә булса шул көннәрдә геле булыр.

Вакытым бик кыска булу сәбәпле романтикага да бирелмим, романтика хатларын ына башлагач язармын.

*Сау бул, якыным!*
*ҺАДИ ТАКТАШ.*

*25 июль, 1931 ел, Казан.*

Әни!

Актанышта бөтен авырлыкны сиңа күрергә туры килә инде. Казанга кайткач синеңположениеңне бик яхшы төшенәм. Синең кул аста торганда рәхәт булган, әни. Хәзер ын-җирләрне дә үзем җыям. Чәй дә үзем кайнатам, су да кертәм, идән дә себерәм, скасы — у-һу-һу-һу эш күп...

Кооператив кенәгәләре, карточкаларны да үземә кайгыртырга туры килә, башытөшкәч кирәк икән, ләкин алар, белмим кайда, тәмәке алырга да кирәк булалар. изә Васильевкада ял итә. Минем өчен кайгырмагыз, сезгә тынычлык телим. Хат, әлттә, языгыз.

*Сагыну сәламе белән Һ. ТАКТАШ.*
*Июль, 1931 ел, Казан.*

Әни!

Хатым җылы хисләремне алып барсын. Сезгә сәламнән башка әйбер әле җибәрмыйм. Хәл Германия буржуа хөкүмәтенекеннән әйбәт түгел. Кризис.

Бүлмәләрне ремонтировать итү артыннан йөрим. Кайгылар бик күп. Сезнең белән кайгылар, ничектер, җиңелрәк үтә иде. Алар бар да хәзер бер башыма калды.

Шулай да бик үк өметсез түгел. Берәр нәрсә эшләп булыр, ахры. Сүз ремонтлар рында бара. Әле күзгә күренгән нәтиҗә юк. Шул көннәрдә билгеле булыр. Язармын. з, туйган булсагыз, 15 ләрендә кайтыгыз да инде.

Гөлчәһрә хатында күп кенә нәрсәләр язган. Аларны кайткач сөйләшербез.

*Хәзергә! Бәхет телэп, кияүең.*



*З. Мостафин, Һ. Такташ, Балашов, Исмай.*

*18 август, 1931 ел, Казан.*

**Сөеклем Гөлчәһрә!**

Бүген сагынып көткән хатыңны алдым. Булмаса инде йөрәккә авыр була башлаган иде. Дөресен генә әйткәндә, мин инде 17 ләрендә үзегез килерсез дип көтә башлаган идем. Бүген килмәсәгез иртәгә килерсез дип, бүген идәннәрне дә, бельеларымны да юдырып куйган идем. Хатың бер яктан шатландырса, икенче яктан йөрәккә авыр булып китте. Беренә кадәр әле көтәргә туры киләчәк. Инде акча мәсьәләсенә килгәндә, аны, шиксез, онытмаган идем. Беренче сентябрьләрдә килсәгез, билгеле, 25 ләренә табан телеграмм белән акча җибәрермен... Аннан, монда шул көннәрдә мичләрне үз хисабыма ремонтировать итәргә булдым. Кирпеч кебек кирәкле материалларны табып киләм. Ничек тә бу ел ремонт ясатабыз инде. Зур бүлмәне ремонтировать итәргә кирәк булган, материалларны да җыя торам. Ну болар калып торсын. Инде тагын бер язмый калган нәрсә турында. Син хәтта миңа ул хакта үпкәлисең дә. Мин, җаным, бала турында күп уйлыйм. Билгеле, аның сине нинди положениегә куюын да беләм. Минемчә, Актанышта докторлар бар да, миннән башка тудыру сиңа авыр булыр. Казанда хәзерге көндә бала табу йортлары ачылып килә. Бала тууга кадәр бире кайтсагыз бик яхшы булыр иде. Ә кайчан ул туачак? Бәлки бик тиз, бәлки әле Казанга килеп тә өлгерерсез. Мин бу хатымда әле аңарга сәлам язмыйм, киләсендә язарга туры килмәсен.

Менә нәрсә, җаным. Бу хатымны алу белән юлга чыгарга исәпләсәгез, срочно телеграмма сугыгыз. Мин акча җибәрергә тырышырмын. Аннан Фәйзидән сиңа хат бар. Хатны ачтым, аның өчен ачуланма.

Үзем бер төрле торам. «Киләчәккә хатлар»ның III хатын язып бетердем. Ләкин канәгатьләнерлек булып чыкмады. Үзе ошамый, үзем төннәрне шул хатны язу белән сине уйлау белән уздырдым. Нигәдер бик сагына башладым үзеңне. Минем хакта һичбер тынычсызланма, бәгърем, синнән аерылган минутларымны эшкә күмелеп уздырдым, дөрестән дә элекке балалык беткән, гакыллыланганмын, һәм хатын-кызлар минем өчен үзләренең элекке төсләрен югалттылар бугай. Алар хәзер берсе дә сине һәм үземнең җырларымны алмаштыра алмыйлар.

Йөрәгемнең иң җылы хисләре сиңа, бары сиңа гына булсын.

Камильләр, эниләр, үзләре хат язмаганга аларга бу юлы хат язмыйм. Көтә торсыннар, шулай да сәламемне әйт үзләренә.

*Хуш, бәгърем, сагынам, көтәм.*

***ҺАДИ ТАКТАШ.***

*12 сентябрь, 1931 ел, Казан.*

**Гөлчәһрәм!**

Сине иң җылы хисләрем белән урыйм. Шатлыгым йөрәгемә сыймый. Ну и молодец син!

Таки миңа малай тудырдың бит!

Инде терел, бәгърем!

Сиңа кәгазь, каләм, китаплар алып килдем.

Авыр булмаса малай турында яз әле.

Кемгә ошаган?

Күзләре нинди?

Җылыймы?

Бик дуслашып киттегезме үзе белән?

Яз.

*Икегезне дә үбеп Һ. ТАКТАШ.*

*15 сентябрь, 1931 ел, Казан.*

**Галочка!**

Сиңа һәм нәни Такташка сагыну сәламе.

Син минем хат язмавыма үпкәли дә башлагансыңдыр. Эш күп, бәгърем. Аннан бераз, син больницадан чыккач, сөйләр сүз күбрәк булсын дип язмадым.

Хәлең ничек?

Малай нишли?

Без монда бер төрле торабыз...

Син кайгырма, гомумән тыныч кына ят, малайның туган көнендә ядкарь булсын дип пьеса яза башладым.

Кичә мәкаләмнең күп өлешен яздым. Мәкаләмне бүген бетерермендер.

Ну, бәгърем, малайны үбеп, исемен без «Ван» түгел, «Аван» дип кушарга җыенабыз. Минемчә, бу исем авыз тутырып әйтелү естенә яңгыравыклы, музыкальный да. Син ничек уйлыйсың?

**ҺАДИ.**

Гомәр Бәширов

# «ИСКЕ БУДИЛЬНИК» КӨЙСЕЗЛӘНӘ

ЯҢА ӘСӘРДӘН ӨЗЕК



Бу өзек «Җидегән чишмә» дигән яңа әсәрдән алып бирелде. Журналда өзеге басыла икән, димәк, тулаем бөтен әсәр хакында да нидер әйтергә кирәк була торгандыр.

Иптәшләрем беләләр, язу эшендә мин элек-электән җитезлек белән мактана алырдай әдипләрдән түгел. Гомумән, ашыкмыйча, озак язам. Бу әсәремне язу исә шулкадәр озакка сузылды, ахырын көтәргә хәтта үземнең дә түземлегем җитми башлады, арага кертеп икенче бер әсәр — «Туган ягым — яшел бишек»не язып алдым.

Кайбер укучылар очрашу вакытларында һәм хатларда: «Шулай да нигә алай?» дигән сораулар биргәнлектән, бәлки моның кайбер сәбәпләрен аңлатып бирергә кирәктер?

«Җидегән чишмә»не мин замандашларыбыз тормышыннан алып язам. Һәркемгә мәгълүм булганча, соңгы елларда КПСС Үзәк Комитетының билгеле пленумнарыннан соң, авыл халкының тормышы бик тиз үзгәрә башлады, күзгә күренеп яхшырды. Ул үзгәрешләр берсен икенчесе шулкадәр тиз алмаштыра, кичә кертелгән яңалык күбесенчә бүгенге яшәеш таләпләренә җавап бирми дә, «бүген» инде кичәгедән дә яңараклы, камилрәкне таләп итә башлый. Хезмәткә яңалык керә икән, ул инде гомумән тормышка да, кешеләрнең хезмәткә, бер-берсенә мөнәсәбәтләренә дә ничектер тәэсир итмичә калмый дигән сүз. Андый шартларда бу үзгәреш һәм яңалыкларның кайсылары озын гомерле һәм яшәргә хаклы икәнлекләрен өйрәнмичә, аларны ачыкламыйча язу һич мөмкин түгел. Чөнки әдәби әсәр кыска гомерле узгынчы фактларга түгел, бәлки бөтен кешелеккә, һич булмаса, җәмгыятьнең зур бер катлавы тормышына хас җитди мәсьәләләргә нигезләнсә генә озын гомерле була ала.

Бу әсәремдә мин замандашларыбыз, бигрәк тә яшьләр арасында интим һәм төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне, аларның хезмәткә, туган җирләренә, табигатькә мәхәббәтләрен, гомумән рухи дөньяларын көчем җиткән кадәр тирәнрәк һәм көчлерәк итеп тасвирламакчы булам. Вакыйгалар «кара алтын» чыккан якларда булганлыктан, табигый, нефть кешеләре дә катнаша.

Әсәрнең язылу процессында моннан берничә ел элек тә, әле күптән түгел генә дә зета һәм журналларда «Таң беленгәч», «Яхшы түгел», «Еллар үткәч» һ. б. исемнәр тында өзекләр басылгалады. Романның эчтәлеге ниндирәк икәнлеген шул өзекләрән чамаларга мөмкин. Тәмам булмаган әсәрдән өзек бастыру кайбер очракларда лаем бөтен әсәр хакында ялгыш фикердә калырга сәбәп тә булгалый. Әмма мин кучыларыбызның зәвыгы һәм әдәби әсәрне аңлау дәрәҗәләренең югары булуына ич шөбһәсез ышанам. Әгәр дә бу өзек кайсы ягыннан булса да канәгатьләндермәсә ки ризасызлык тудырса, укучылар аңа карап кына бөтен әсәргә карата ашыгыч этиҗә чыгармаслар дип уйлыйм.

**АВТОР.**

# I



Камил Байгузин бөтен тәне манма тиргә батып, йөрәге чәнчешкәнгә уянды. Юк, чәнчи генә түгел, йөрәккә әллә ни булган, ул атылып чыгарга житеп чамасыз дулый, тасырдый башлаган иде. Байгузин селкенмәскә тырышып пинжәк кесәсеннән валидол алып капты, аяк-кулларын сак кына үз җайларына сузды, тирәнрәк, иркенрәк сулыш алырга тырышты.

Ләкин бүлмә эче ифрат тынчу, һава житми иде. Тәрәзәне ачып жибәрәсе иде дә бит, бу караңгыда аңа ничек барып житәсең? Түрдәге зур телевизордан башлап ишеккә кадәр һәр төрле кыйммәтле жиһаз — сервантлыр, буфеттыр, аквариумдыр, фәләндер кебек нәрсәләр тезелеп киткән. Шуларның берәрсен аударып, верандада йоклаучы хуҗаларның йокыларын бүлдерүең мөмкин бит...

Байгузин бу юлы колхоз председателенә туктавына үкенеп бетә алмады. Башка вакытларда ул иркенрәк өйле берәр әбигә төшә дә печәнлектә, я чоланда-мазарда йоклый торган иде. Ни житкән саф һавада йоклауга, ни житкән шундый әбиләрнең сөтле ашына, чикмәнле бавырсагына! Ашамаган тавыкмы! Чурмантаевның үтенүен кире кага алмады шул, яхшысынмады.

Менә ун минут та, унбиш минут та узды, йөрәк һаман да тыпырчына, жилкенә иде әле. Дөрес, бу аның беренче көйсезләнүе генә түгел иде инде. Шул сәбәпле Камил аны юри, шаяртып кына «иске будильник» дип атый иде. Бу юлы, күрәсең, эш зургарак киткәндер. Нидән, ничек башланып китүен Камил бик яхшы белә. Ләкин шунысы гаҗәп, мондыйга шатлык та сәбәп була аламы икәнни соң?

Кичә Байгузинны колхоз клубына үзешчәннәр концертына дәшкәннәр иде. Башта колхозның үз һәвәскәрләре чыкты, алар кайсы жырлап, кайсы шигырь укып халыкның ярыйсы гына күңелен ачтылар. Әмма алардан соң «үзешчән композитор» дип тәкъдим ителгән «бабочкалы» бер егетнең чыгышы Камилнең бөтенләй кәефен бозды. Ул егет сәхнәгә бозау кадәр баян күтәреп чыкты да үзе уйнап, үзе үк бөгелә-сыгыла жырлап та жибәрде:

Матур Ыкның буйларында
Йөри колхоз маллары,
«Ямьле тугай» кызларының
Кайнар икән каннары.
    Таңнарда, кичләрдә,
    Гашыйк булдым чибәргә,
    Инде миңа мишләргә?
    Нишләргә?
    Нишләргә?..

Жыры шундый котсыз, мәгънәсез бер такмаза булса, көй дигәне төрле халык көйләреннән укмаштырган зәвыксыз бер винегрет иде. Соңыннан әйтүләренә караганда, моның өчен әлеге егет «тавык һәм савыт»лар белән сыйланып, бер-ике атна чамасы колхозда кунак булып яткан, әле өстәвенә гонорар да алган булса кирәк.

Чурмантаев үзе кулларын югары күтәргән хәлдә залга борыла-борыла бик тырышып алкышласа да, халык җырны ошатмады, әдәплелек саклап, берәр генә шапылдаттылар да яңа «көйне» шунда ук оныттылар.

Байгузин, музыка дигән бөек тылсымчы белән шулай оятсыз рәвештә сату-алу итүгә кәефе кырылып, кузгалырга булды.

Клуб мөдире дә кичәне шуның белән тәмамларга дип сәхнәгә чыккан иде дә зал аны тыңларга да теләмәде.

— Җитмәде! — диделәр.

Төрле яктан:

— Япма кичәне, Мәдәния апа биесен!

— Мәдәния апа чыксын! — дип кычкырырга тотындылар.

Байгузин сагая төште. Тукта әле, ничек бу? Нинди Мәдәния, кем ул? Әллә югыйсә...

Әлеге тәкъдимне бөтен зал күтәреп алды.

— Биесен, биесен! — диделәр.

Бераз гына көткәннәр иде, пәрдә ачылуга гармун уйнап та җибәрде, сәхнә артыннан бөтерелеп Мәдәния килеп тә чыкты. Чәч толымнарын алмаш-тилмәш аркасына чөеп ыргыткандай итенде дә, җиңел, зифа гәүдәсен ифрат килешле уйнатып китте биеп, Камил кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калды. Биюче ул иде, аның егет чагында сөйгән кызы Мәдәния иде. Ничә еллар эзләгән иде аны Байгузин, ә ул менә кая килеп чыккан. Ничек, кайчан?..

Мәдәния әллә күрде аны, әллә юк. Ул хәзер шактый ук яшьтә булуына карамастан, кыз чагындагы җиңеллеге белән сәхнәне зырылдап кына әйләнде дә какча гәүдәсен бөгелдереп, сыгылдырып «урак урды», кайта-кайта чүгәли биреп, «көлтә бәйләде». Аннары алъяпкыч итәге белән маңгай тирен «сөртә-сөртә» йөзен кояшка юнәлтте. Аннан үзенә бетмәс-төкәнмәс дәрт һәм көч алган сыман бөтен гәүдәсе белән балкып, чиксез бер куанычка омтылгандай, күбәләк булып очып-очып китте дә «ашлык сукты», аны «җилгәрде», тагын әллә ниләр биеде.

Бөтен залны шулай өнсез калдырып һәм сокландырып бөтерелде-бөтерелде дә, Мәдәния, килеп чыккандагы кебек, кинәт кенә юк та булды.

Соңыннан Камил кеше җибәргәндә Мәдәния сәхнә артында юк иде инде.

Менә кайда сикерә башлаган иде Камилнең йөрәге. Аннан соң инде ул күпме валидол ашады, күпме тамчылы дару эчте. Хәзер аларның гына кодрәте җитми, күрәсең. Аның маңгаена салкын тир чыкты. Хәленең хәтәрләнә баруын сизсә дә, ул, юри белмәмешкә салынып, йөрәген юатырга тырышты.

— Ярсыма алай, ярсыма! Менә Мәдәнияне дә күрәсе бар бит әле, ярамый бит, ярамый! — диде.

Ләкин байтак кына көтеп караса да, йөрәге тынычлана алмады. Байгузин тел астына тагын бер валидол сәдәбе кыстырды. Бераз хәрәкәтсез ятканнан соң, дымлана төшкән күз төпләрен сөртте дә шигәя-шигәя, гүя йөрәкнең үзенә сиздермәскә тырышкандай, сак кына пульсен тыңлап карады. Ул әле һаман да минутына йөзгә якын тибә, шулай да (күз генә тия күрмәсен!) баягыдай сынны катырып чәнчеми иде. Шунда Камилнең күңелендә бу карусыз, тыңлаучан йөрәккә рәхмәт хисе уянды. Ул үзенә-үзе гаҗәеп бер хакыйкать ачып хәйран калды.

Карасана, ана карынында беренче тапкыр тибрәнә башлаганнан соң бу бичараның бер генә сулыш та ял иткәне юк бит! Гомер буе! Арка-җилкә ял итә, йөрәк эшли. Кул-аяк ял итә, ә йөрәк тибрәнә! Хәтта ми белән нервлар да тәүлек эчендә аз дигәндә бер тапкыр «черем итеп» алалар. Ә йөрәк илле ел дәвамына, көннәр-төннәр, айлар-еллар буена, алсыз-ялсыз һаман тибрәнүен белә, бөтен гәүдә өчен батрак урынына эшли. Берүзе тырыша, берүзе казгана! Күпме газаплар күрмәде ул, мескен, ниләр генә кичермәде! Көчәнә-көчәнә авыр да күтәрде, тын да алмыйча әллә ничә чакрымнарга кадәр йөгергәндә дә түзде, үтең сытылырлык әшәке, ачы эчемлекләр дә, әллә ниткән дарулар да эчелде, тәмәке дә тартылды, ул бичараның хәтта үлемнең төпсез, салкын күзенә карап кысылып килгән чаклары да булды.

Камил йөрәгеннән ничек тә булса зарланырга, янсә кайчакларны аксап-туксап тибүенә рәнҗергә тузан кадәр дә хакы юклыгын, хәтта йөрәге каршында үзенең гаепле икәнлеген уйлап, күңеле йомшарды.

Әйе, үзе сәбәпче булды ул йөрәге авыруга!

Йөрәгенең хәлсезләнүен сизеп, быел яз докторга барган иде. Карт врач аны бик җентекләп карады, ничек эшләп, ничек ял итүе, нindirәк шартларда яшәве хакында сорашты.

— Беренче катта,— диде Камил.

— Тәүлегенә ничә сәгать өстәл янында?

— Сәгать исәбеннән түгел. Ничек туры килә бит. Язасы килүгә карап. Язылса, төннәр буе да утырасың.

Соңыннан бик озаклап кулын югач, шуның белән эш беткән кыяфәттә, врач икенче авыру кергәнне көтә башлады. Камил моңа бик гаҗәпләнеп врачка үзе сүз кушты.

— Киңәш нindirәк булыр икән соң, доктор? Дару-дарман эчәргәме, әллә берәр санаторийга барыргамы?

Врач кырыс кына итеп:

— Дарудамыни эш? — диде.— Әгәр дә сезнең йөрәгегез урынында булсам, чын ихлас әгәр, мин сезне әллә кайчан ташлап качкан булыр идем. Шулкадәр дәваемсыз булырга ярыймыни? Йөрәкнең дә бит җаны бар, аңар да хәрәкәт кирәк! Ә сез нишлисез? Матбугат йорты бит әнә генә! Ә сез анда да җәяү бармыйсыз, гел такси да троллейбус! Ә йөрәк нишләгән? Тик ята торгач, ялкауланган, чүпрәк шикелле шәлперәеп төшкән. Беләсегез килсә, утырган тавык та сездән акыллырак. Йомырка өстендә утыра торгач, ул да ишек алдына чыгып бер кагынып керә...

Байгузин авыр сулап куйды. Ни кылмак кирәк? Гаеп аның үзендә, йөрәккә үпкәләп булмый иде.

Әллә уйланырга ярамады, әллә бүтән сәбәбе булды, йөрәк яңадан дуларга тотынды. Аның үз урынына сыеша алмыйча азапланып, ярсып дөп-дөп күкрәк читлегенә бәрелүе хәтта колакка да ишетелә кебек. Камил бөтен тәнендә хәлсезлек сизде. Аяк-кулларын энә белән чәнчегән кебек иде.

Байгузин эсселе-суыклы булып китте. Әллә югыйсә «теге» дошман бәреп ташларга җыенамы? Якыннарыннан читтә, ятлар кулында...

Камил кулларының дерелдәвен сизмәмешкә салышып, чалбарының сәгать кесәсенә сузылды. Нитроглицеринның ясмык кадәр генә кечкенә сәдәбен тел астына салганда «иң актыккы резерв» диде, үзен язмышы кыл өстендә генә эленеп торган, дошман камап алганнан соң, штабны саклаучы иң соңгы ротаны да сугышка ташларга мәҗбүр булган командир белән чагыштырды.

Әгәр ул шушы ятудан тора алмаса? Яңа әсәре язылып бетмичә калса? Камил үлемнең үзеннән курыкмый, чөнки ул яшәешнең зарури бер

кануны. Бу якты дөньядан кайчан да булса бер китмичә хәлең юк. Ә яңа әсәре? Ул бит аның баласы белән хатыны да, иң якын, иң газиз сердәше дә. Ялгыз тормышын яктыртып, бөтен яшәешенә ямь биреп, илһам биреп торучы куанычы һәм юанычы да! Соңгы дүрт-биш ел эчендә бу яңа әсәренә ул никадәр көч салды. Гомер буе җыелып килгән иң тирән, иң нечкә хисләрен, халкына житкерәсе иң мөкатдәс һәм иң әһәмиятле уйларын ул, умарта корты кәрәзгә бал ташыгандай, шушы әсәренә ташыды, аларны халкына булган мәхәббәте белән җылытып, бер бөтен итеп беркетте. Аңа моны очлап чыгу өчен күп тә түгел, тагын ике генә ел кирәк, нибары ике генә ел! Ике генә!..

Юк, үләргә ярамый аңа, ярамый булгач, ярамый! Бу коточкыч гаделсезлек, рәхимсезлек булыр иде.

Мондый вакытта каушап, дерелдәп төшүнең, гасабиләнеп арлы-бирле сугылуның һәлакәткә илтәчәген Камил яхшы белә иде. Ул бөтен ихтыяр көчен бергә туплап, күңелендәге шик-шөбһәне бәреп чыгарырга, гомеренең иң якты, иң куанычлы минутларын күз алдына китерергә тырышты. Иртәгә үк нинди шатлыклы минутлар көтә бит аны! Ул Мәдәнияне иртә белән үк эзләп табачак, һичшиксез, тәгаен! Камил бит аның теге вакытта өйләнешергә дип кенә торганда бик серле рәвештә кинәт кенә юкка чыгуының сәбәпләрен дә белми йөри. Шуның өстенә, Бөгелмәдә аннан пакет алып калучы да ул бит әле. Менә нинди яңа шатлыклар көтә бит аны!..

Аннары аның әсәрен укыганда тын калып тыңлаган зур аудитория күз алдына килде. Һәр яңа әсәре басылып чыкканнан соң, туган илнең төрле почмакларыннан килгән дистәләрчә рәхмәт хатларын исенә төшерде. Депутат итеп сайлаганда карт-карчыкларның аны якын итеп, үз итеп кайгыртуларын, «күпне күрсәң дә биреШмәгәнсең әле, Камил энем!» — дип аркасыннан сөеп калуларын хәтерләде.

Аннары менә яңа әсәр тәмам язылып беткәч, машинкада бастырганнан соң кулыңа карандаш алып, төзәтә-төзәтә тагын да матурайта һәм тирәнәйтә барып яңадан укып чыгулар! Я, нинди рәхәт, нинди ләззәтле минутлар кичерәсе бар әле! Әйтерсең, ул нәни баласының беренче тәпи басуын, чатыйн-чотыйн атлап беренче тапкыр йөреп китүен карап тора!

Юк, шушындый рәхәтләрне татымыйча, иң якты, иң бөек хыялын тормышка ашырмыйча китәргә ярыймы соң?.. Юк, юк!..

Ниһаять, сырхауларны албастыдай басып ятучы хәвефле төн чигенә башлады, тәрәзәдән таң яктысы сирпелде. Йокыдан арынып җитмәгән таң әтәчләренең беренче сүлпән авазлары ишетелде.

## II

Аз гына яктыра башлауга Камил ишек алды белән янәшә үстерелгән җимеш бакчасына чыкты. Өлгереп килә торган алмаларның хуш исен исни-исни, яшеллек эчендә кулларын бер күтәреп, бер төшереп тирән сулады. «Иске будильник» бераз авырыксынып, бераз көчәнебрәк булса да һаман тырыша, эшен дәвам иттерә иде. Камил исән-сау яңадан аякка басуына куанып бетә алмады.

Күп тә үтмәде, бакча уртасындагы беседкада башта нидер шытырдады, аннары микрофонга чиертүләре ишетелде. Шуның артыннан ук мөлаем хатын-кыз тавышы иртәнге әңгәмәне башлап та җибәрде.

— «Тыңлагыз, тыңлагыз! «Ямьле тугай» колхозы сөйли. Хәерле иртә, иптәшләр! Микрофон алдында колхоз председателе Ризван иптәш Чурмантаев!»

Байгузин хуҗаларның шулкадәр иртә эш башлауларын хуп күреп беседкага якынлашкан арада, Чурмантаев сөйли дә башлады. Аның

авышы күтәренке, ул «Ямьле тугай»га кергән өч авылның ...
енгә якын колхозчының игътибар белән тыңлаячагына, аның һәр әйт-
эне закон булып ишетеләчәгенә нык ышанган хәлдә, көр тавыш белән
этынды. Бүген колхоз борчак урырга керешкән икән, председатель
ашта шуны искәртте.

— «...Менә хәзер, шушы минутта, дружно кузгалабыз да кырга
итәбез и башны да күтәрмәенчә эшләйбез. Эш фронтын җәеп җибәр-
екме, анда инде шалтай-балтай йөрүләрне категорически бетерәбез.
.се! Папирос беткән саен, механизатор Салихҗан Әхмәдишин шикелле,
ДТ-74 кә атланып, магазинга чабу фактларына, и шулай ук басу түрен-
эн хатын янына кайнар пәрәмәч ашарга или анда, әйтик, мунча ке-
ергә кайту фактларына категорически чик куябыз. Хатыннар янында
оңыннан иркәләнәбез, уборка беткәч. Аңлашылдымы? Басуда ашайбыз,
асуда эчәбез! И шулай ук папирос белән обеспечить итү проблема-
ын да бүгенгесе көннән башлап, техника кумаенча гына, эш урынында
әл итү чараларын күздән кичерү мәсьәләсе белән оешкан төстә шө-
гыльләнәбез. Аңлашылдымы? Аңлашылды! Всё!..»

Камил Байгузин: «Мал бит бу, мал!» дип кычкырып җибәрде, көлә-
өлә кабаланып күзлеген киде. Чурмантаевның үзенә генә хас интона-
циясен һәм кызык сүзләрен онытмаска тырышып, куен дәфтәрен
чыгарды.

Ризван исә, нигәдер микрофонга өргәләп торганнан соң, көр генә
тамак кырып, янә сөйләп китте:

«— Шуннан ары килеп, заффирме Гөләндәм апасы и терлекче ип-
тәшләр, сезгә дә гәп бар. Гәп шул, бу арада хурлыклы рәвештә сөт
кими. Кими и всё! Как заффирме, как коммунист буларак коммунизм
төзү фронтында янадан-яңа үрләр яулап аласы урында без нишләйбез?
Район сводкасында категорически аска тәгәрәйбез. Нилектән тәгәрәй-
без? Чөнки дә удар темплар белән эшләмәйбез, безгә юл ярктыртып ба-
ручы район маякларыннан үрнәк алмыйбыз! Болай юк-барга мәлҗерә-
мәек, малай укырга кирә алмаганга күрә генә күңелне төшермәек әле!
Андый вакытларда чын коммунист нишләй? Кан түкерсә дә сиздермәй,
эшкә зарар китермәй. Кырыкка ярылса ярыла, иллә мәгәр сөт-май, жон-
кукәй планнарын ничек кенә булса да үтәмәенчә калмай! Азык бит сы-
ерның муеныннан, хет яшеле, хет тегендәе; пожалуйста, хет шартлаган-
чы аша. Ну сөтне дә бир! Бөтен республика каршында «Ямьле тугай»ны
рисвай иттермә! Аңлашылдымы? Всё! Бүтән сөйләшеп тору юк. Әйдәгез
әле, сынатмаек, әйдәгез әле, күрсәтәек матур эш темпларын!»

Байгузин көтмәгәндә үзе кулга килеп кергән бу «табыш»ка куанып
соңгы сүзләрне язып тәмамлаганда, хуҗа кеше кайтып та җитте. Аның
күңеле күтәренке иде. Ул кунакның кәефен сораштырды, юынганда
сөйләнә-сөйләнә каршысында ап-ак сөлге тотып торды, бераздан кунак-
ны беседкага дәште:

— Әйдәгез, Камил абый. Тәнзилә ханымның йомырка тәбәсеннән авыз
итик,— диде.

Чурмантаев бик уңган кешегә охшаган, төскә-биткә дә чибәр иде. Ул
инде яшьрәк кешеләргә хас тән көпшәклегеннән узган, чәчкә сирәк-мирәк
кенә булса да чал керә башлау чорына әле барып җитмәгән. Аның
буыннары ныгып, акыл утыртып, тәмам ир-егет булып өлгергән чагы
иде. Өстендә кич-иртә ап-ак нейлон күлмәк, урамга чыкканда кара
костюм, утырып йөргәне — «Волга».

Байгузин тормышның ифрат дәрәҗәдә тиз үзгәрүенә, шул җитди
үзгәрешләрне үз вакытында сизеп, күреп, бөтен эчке дөньясы белән кү-
ңеленә сеңдереп өлгермәвенә офтанып куйды. Ни генә әйтсәң дә бу инде
яшьлек галәмәте түгел иде.

Чурмантаев алдына япкан ап-ак тастымал белән авыз тирәләрен
сөрткәләп:

— Иҗат эшләре белән йөрисездер инде, Камил абый,— диде.

Байгузин бу сорауны көткән иде. Үзен укымышлы кешеләрдән санаучы һәркем ул хакта сораштырмыйча калуны кимчелек саный иде, күрәсең.

— Безнең халыкның шул инде. Гомер буе эзләнәсең, уйланасың, гомер буе ни дә булса язарга тырышасың,— диде Камил.

— Мөгаен, хәзерге тормыштандыр, әйе бит, алдынгылар хакындадыр? Чөнки дә гәзитләрдә гел шул турыда язалар.

— Ничек дип әйтергә...

— Сез уңайсызланмагыз, Камил абый, пожалуйста, бездә материал җитәрлек. Булышырбыз, уңай геройлар табып бирербез...

Байгузин сагая төште. Иҗат эшләре хакында ничек болай бик ансат сөйли бу, аз-маз булса да белепме?

— Кем ничек аңлый бит... Уңай герой дигәнегез сезнеңчә нинди булырга тиеш соң?

— Нинди дип... хәзергечә безнең маяклар буладыр инде.

— Киңәшегез өчен бик рәхмәт. Йөреп карыйм әле. Авыл һавасын сулыйм. Кешеләрен күрим. Каян беләсең, бәлки нәрсә дә булса йогып та куяр. Бәлки... Кем белә?

— Уңай геройлар янына тискәреләре дә кирәк була инде сезгә. Андыйларга бездә элекке председательләр бик күп. Әллә унбер шунда, әллә унике. Кирәк дисәгез, чакыртырмын. Ниндиен телисез...

Байгузин чак кына көлеп җибәрмәде. Алдындагы йомырка тәбәсен чәнечке белән киткәләп, авыр сулап куйды. Менә бит замана! Синең нәрсә турында гына түгел, нинди геройларны кертеп, ничек язарга тиешлегеңне дә алдан ук әйтеп куялар. Нәрсә дисең, әдәбиятның үзенчәлеген аңлата белмәвебезнең аяныч җимешеме бу?

Бу юлы ул:

— Рәхмәт, карарбыз,— дип кенә котылырга тырышты.

Һм... Уңай герой, тискәре герой, иҗат эшләре...

Бу чибәр кеше телендә шундый җиңел уйнап торган шушы «иҗат эшләре»нең үзенә дә аңлашылмый торган әллә нинди серләре барлыгын, бер үк вакытта газаплы да һәм рәхәт тә булуын, бер утка салып, шунда ук суга ташлый торган «татлы каторга» икәнлеген язучының үзеннән башка кем белә? «Гәзитләрдә гел шул хакта язулары» сәбәпле генә түгел, бәлки халыкка нидер әйтәсе килгәнлектән, язмыйча мөмкин булмаганга күрә язуыңны ничек төшендерергә?..

## III

Кунак белән хуҗа чәй яныннан кузгалып кына торалар иде, капкадан бая радиодан сөйләгәндә председатель телгә алган Гөләндәм килеп керде. Ризван аның болай тиктомалга килүенә сәерсенеп каршысына ашыкты.

— Ни булды, Гөләндәм апасы? Фермада берәр хәл майтардыгызмы әллә? — диде.

Гөләндәмнең йөзе борчулы, иреннәре дерелдәргә генә тора иде. Ул борчуын сиздермәскә тырышып, башын ия төшеп, элек кунак белән, аннан соң Ризван белән исәнләште. Аннары Ризванга туп-туры карап:

— Юк, иптәш председатель, хафаланмаска була. Эшләр тәгәрәп кенә бара! — диде.

— Һе, әйттем бит инде бая кая тәгәрәвен!

Байгузинның үзенә бик кызыксынып карап торуын абайлап, Гөләндәм аңа яны беләнрәк борылды. Шулай да ул: «Кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла!» дигәндәй, председательгә зарланган кебек күренсә дә, мон-

арын депутат иптәшкә житкерәсе килә иде. Улы Бәязнын
лмыйча кайтуына Гөләндәм һаман да күнә алмый, ул хәсрәт төене бу-
ып йөрәк-бәгърәнә кереп утырган да шул кату һаман язылмый иде әле.
Іртә белән Ризванның бу хәлне тискәре ягыннан телгә алып бөтен кол-
оз алдында оялтуы аның үпкәсен генә кабартты. Монда аны шул чыгыш
итергән иде.

— И, җанкисәгем, күз алдында лабаса! Сүз болай да гел шул хакта
ына бара ич инде. Ятсак та, торсак та, утырыш белән җыелышта да гәп
шул ит белән сөт, җон белән йомырка чутында гына бара. Бәй, шулай
була торып та аска тәгәрәгәч, ни эшкә ярай ул?!

Чурмантаев кунак ягына карап: «Менә нindиләре дә бар бит әле
зның!» дигәндәй, башын чайкап куйды.

— Соң радиодан сөйләгәндә мин дә шуны ук кайгырттым түгелме? —
иде.

— Кайгырттың да бит, тик син кире башыннан тотындың. Соң бит,
Ризван туган, ит белән сөттән башка дөнья йөзләрендә менә мин дә бар
бит әле, шуларны булдыра торган теп-тере кеше — Гөләндәм!

— Чү, Гөләндәм апасы, синең барыңны кем белми?

— Белмисез шул, белмисез! Белсәгез, азрак хәлемне сорашыр идегез,
ничек алай, ник алай дип кайгыртышыр идегез.

— Шунсыз булмый, апасы, азрак әйткәләмичә эш бармый. Сөтнең
туктаусыз кимүен беләсең бит!

Хуҗаның Гөләндәмгә урын күрсәтмичә кулларын кесәсенә тыккан ки-
леш түрә булып сөйләшүе Байгузинга ошамады. Ул беседкадан урындык
чыгарып куйды.

— Кем дип әйтим, сеңелем, утырыгыз! — диде.

Гөләндәм утырып тормады. Урындык аркасына нык кына ябышып
сүзен дәвам иттерде.

— Гөләндәм мин, Камил абый, Мингатина. Менә сезне дә борчырга
туры килә. Ун ел буена дүрткә дә бишкә укып йөргән бердәнбер улымны
укырга алмыйча, кире борып кайтардылар. Килеп хәлеңне белсәләр, җа-
ның эреп китәр иде дә бит кана. Кая ул! Аның урынына әле сине «шуның
өчен мәлҗерәймик» дип радиодан әрлиләр.

Чурмантаев иңбашларын җыергалап бакча рәшәткәсе буена барып
басты, тагын борылып килде, ләкин берни дә әйтмәде.

— Әнә күрше колхозларда председатель булган кеше яшьләрне үзе
укырга җибәрә дип ишетәбез. Үз авылыңның суын эчеп, үз буразнаңда
аунап үскән авыл егете я агроном, я инженер булып кайтса, колхозның
эчен тишмәс иде ләбаса!

Чурмантаев шуның белән эшне бетерергә чамалап, кырын-кырын кап-
кага таба атлый башлады.

— Ярар инде, Гөләндәм апасы, әйттең — булды, аңладык. Әнә анда
эшкә чыгасы бар.

Әмма Гөләндәм аның артыннан иярмәде. Ул хәзер кыюлана төшкән,
бит урталары кызарган, түгәрәк күзләре дә еш-рак тәгәри башлаган иде.

Председательнең күзенә карап:

— Бәй, бу эш түгелмени? Беләсең килсә, кеше күңелен табу житәк-
ченең иң зур эше ул,— диде.— Менә шуна башым житми тора, Ризван ту-
ганкай: укырга кертерлек булмагач, ун ел буена ни дип азап чиктем соң
мин? Укысын, кеше булсын, аттестат алсын дип тырыштым бит! Хәзер
инде ул кәгазь кисәген кая куярга, сыер койрыгына тагаргамы? Шулайга
калдымыни инде эшләр?

Чурмантаев кулларын җәеп җибәрде.

— Соң мин ни эшли алам, Бәязның урысчасы йомшак булган түгел-
ме соң?

— Булса, анысына кем гаепле? Әллә минме, я булмаса, баламы?

үзенең дә гаебе бар сыман уңайсызланып башын иде. Хәзерге заманда русчаны теләсә кайсы уку йортына керерлек итеп укыта алмау берничек тә гафу ителми торган гамьсезлек, уңмаганлык иде ул. Юк, алай гына да түгел, бик зур оят иде бу, оят һәм хурлык!

Гөләндәм, авызын бераз каплый төшеп, Байгузинга борылды.

— Сез безнең олы кешебез инде, Камил абый. Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә сүзегез үтә булыр. Җитәкче иптәшләргә шундыйларны әйтеп булмыймы соң? Азрак якларга кирәк иде безнең малай ише буразнадан күтәрелүчеләрне, онытмаска иде Ленин бабай васыятьләрен.

Байгузин кайбер фикергә килгән, кемнәр каршында нинди үтенеч күзгатачагы хакында уйлап куйган иде инде. Бәлки бу хатынның малаена да берәр уку йортында урын табылыр?

— Кулымнан килгәнне кызганмам, сеңелем,— диде.

Бу телдәр хатын аңа ошап куйды. Ул аның үзенә артык сиздермичә генә тәгәрәп торган бик җитез күк күзен, килешле өс-башын, килеш-килбәтен хәтерендә калдырырга тырышты.

Китәр алдыннан Гөләндәмнең бит-күзе ялтырып, түгәрәк күзләре нурланып китте. Әйтерсең, барлык борчулары берьюлы шушы ишек алдында юылып төшкән!

— Әй, Камил абый, туп-туры үз тәрәзәңне кагарга батырчылыгым җитмәгән булыр иде, җил-давылның бер канаты, юл уңаеннан, сиңа да килеп бәрелде инде. Зинһар, гаеп итә күрмә! — Капкага җитәрәк борылды да,— председатель иптәш син дә! — диде.

Саубуллашып башын иде дә, әле һаман да зифалыгын җуймаган төз гәүдәсен мәгърур тотып, сабыр гына чыгып китте.

## IV

Беркөннәрдә Мәдәния клубта кинога кенә килеп чыккач, Байгузин үзенең дулкынлануын бик кыенлык белән генә яшерә алган иде. Халык алдында берәр төрле ахмаклык эшләп ташламас өчен, көлгән булды, шаярткан булды.

Күрешеп сөйләшергә теләвен белдереп икенче көнне үк Мәдәниягә кечкенә генә язу җибәрде. Әмма Мәдәния өч көнсез һич бушый алмавын әйтеп, аннан ял көнне килеп чыгуын үтенде.

Бу өч көнне Камил ничек кенә уздырырга да белмәде. Гаҗәеп очрашу булырга тиеш иде бу! Камил Мәдәнияне ничә еллар эзләгән иде, ә ул менә кайда икән! Әле алай гынамы! Казан арты кызы ничек, ни сәбәпле бу якларга килеп чыккан? Ире бармы, тормышы ничек? Бәлки аңа ярдәм итәргә кирәктер? Бәлки... каян беләсең?.. Язмыш дигәнең тагын нинди гыйбрәтле һәм хикмәтле маҗаралар әзерләп куйгандыр бит.

Мәдәнияне колхоз салып биргән иң беренче таш йортка күчкән, үзе китап магазинында эшли диделәр. Якшәмбе көнне төштән соң, кырынып, төзәтенеп, иң һәйбәт киемнәрен киеп, Камил егет чагы белән очрашырга чыгып китте.

Чупай [1] ташыннан салынган ике катлы зур йортны эзләп торасы да булмады, ул ерактан ук күренде. Ул авылның иң биек урынына менеп алган да янәшә тирәсендәге берәр катлы агач йортларга керфексез күз сымак яңаксыз тәрәзәләре белән, өстән аска таба бик тәкәббер кыяфәттә карый иде.

---

[1] Чупай — авыл исеме. Аның яныннан чыгарылган таш та шул исем белән йөртелә.

Ишек шакыганга чыккан хатын-кызлар Мәдәниянең әле яңа йортка күчеп килмәгәнлеген әйттеләр.

— Монда улы Равил генә күренгәли,— диделәр.

Улы? Димәк, ире бар... Ни сәбәпле шундый һәйбәт җиһазланган яңа йортка күчмәгән? Монысы яңа табышмак иде. Яңа йортның нәрсәсе ошамаган? Шәт, кире беткән тискәре хатынга әверелмәгәндер бит?

Күршеләре өйрәтүенчә, Мәдәниянең үз йорты да моннан әллә ни ерак түгел, инешкә арты белән утырган кырый урамда гына булырга тиеш иде.

Чыннан да якын икән. Камил инешне чыгуга ук күреп алды, Мәдәнияны бакча башында көтеп тора иде.

Озынча ак йөзе, калынча кара кашлары белән балкып кояшка күз салды да:

— Кайда тоткарланды кунак егетебез дисәм, әнә кайлардан әйләнеп килә икән ул! — диде.

Байгузин башын иде. Сиртмәле уенчак адымнары белән җиңел генә атлап килеп кулларын сузды.

— Исәнлекме, Мәдәния? Ни хәлләр?

— Ярыйсы әле, бер көйгә, Камил абый...

Камил аның нык һәм кытыршы кулларын җибәрмичәрәк торып, дулкынланып йөзенә текәлде:

— Ничә ел инде? Егерме елмы? Артыкмы?

— Күп инде, күп, Камил абый, хәтсез.

Кыз вакытта оялып читкә борылучан коңгырт күзләр хәзер Камилгә көлемсерәп туп-туры һәм кызыксынып карыйлар иде. Йөзендә бер генә дә җыерчык юк, тик аңа горурлык бизәге белән берникадәр олысымаклык өстәлгән иде. Камил ничектер, үзе дә сизмәстән, «сез»гә күчте.

— Мин сезне яңа йорттан эзләгән идем дә...

— Ә, шулайдыр. Улым Равилгә фатир биргәннәр иде.

Байгузин аңа гаҗәпсенеп тагын күтәрелеп карады. Ире кайда икән соң? Ай-һай, ире янында булганда дәшәр идеме икән?

Бәрәңге бакчаларыннан менеп өенә якынлаша башлагач, Мәдәния бөтен гәүдәсе белән борылып, «рәхим итегез!» дигәндәй башын иде, кулын өенә таба сузып, Камилне алдан җибәрде.

Байгузинның йөрәге сулкылдап куйды. Сыгылмалылыгын һәм житезлеген әле дә җуймаган, нык һәм чандыр гәүдәсен иеп куюы, кулларын җәеп җибәргәндәге ниндидер нәзакәтлелек Камилне яңадан уятты. Аның күз алдына сәхнәдә очып кына йөрүче нечкә билле, нәфис хәрәкәтле элекке Мәдәния килеп басты. Камилнең: «Син һаман да шул элеккечә матур да, яшь тә икәнсең бит әле!» дип әйтәсе килде.

Дөрес, Камил беренче хатыны үлгәннән соң өйләнмәскә, калган гомерен соңгы сулышына кадәр иҗат эшенә багышларга адарынып куйган иде. Әмма шул карары янында менә хәзер яңа бер фикер борын төртә башлады. Әгәр дә Мәдәния тол калган булса, яшьлек хисләренең уннан бере генә булса да сүнмичә сакланган булса, кем белә, бәлки...

Камилнең кат-кат текәлеп каравыннан Мәдәния дә ниндер сизде булса кирәк. Тик ул ир кунак белән аны каршы алучы хуҗа хатын мөнәсәбәтеннән эчкәрерәк керүне һич тә муафыйк күрмәгәнлектән, әдәпле генә тамак кырып, йөзен читкә борды. Алар бер сулыш кына дәвам иткән шушы күңел зилзиләсен ясалма тынычлык белән бастырып, тегесе-монысы хакында сөйләшүгә күчтеләр.

Камил үзе генә белгән ниндидер уйларына йомгак ясагандай, гадәттәгечә сузып кына:

— Шулай икән...— диде.— Яшәр өчен яңа йорт җайлырактыр да. Газы, суы, электры бар диләр. Бүтән уңайлы яклары да булса кирәк.

— Шулай инде анысы...

— Заманасы шуңа таба бара бит, Мәдәния. Тора-бара бәлки фатирга да иярләшер идегез?

— Һай, алай ансат кына булмый икән шул.

Ишек алдына керүгә Мәдәния туктады.

— Менә шушы инде өебез!

Кайчандыр нарат бүрәнәләрдән салынса да, еллар үтү белән көл тәсенә кергән, түбәсе берничә урыннан ямалган, бераз җиргә иңеп чүгәлдә төшкән иске генә өй икән.

— Шулай икән...

Байгузинның бу «сөземтәсе» Мәдәниягә «йортыңның әллә ни кызыгырлык урыны юк икән югын» дигән мәгънәне аңлатты. Мәдәния ирен кырыйлары белән көлемсерәп кенә куйды. Шәһәр кешесеннән шуннан да артык нәрсә көтәсең? Алар авыл өенең буыннан-буынга, әбисеннән оныгына күчеп килә торган әчке серләрен, күңелгә якын нечкә бизәкләрен аңлый алалармыни?

Мәдәния тәненә суык йөгергәндәй бөрешә төшеп, ике кулын күкрәгенә кысты.

— Ансат кына ташлап булмый шул, Камил абый. Иске булса да төп оя, җиде буынны тирбәтеп үстергән җылы бишек бит ул.

Мәдәния кунакны өйгә алып керде. Түр як тәрәзәләре арасына эленгән көзгене алып, аның астыннан килеп чыккан язуларны күрсәтте. Камил, күзлеген киеп, шуңа үрелде. Бүрәнәнең иң тигез урынына бик борынгыча урап-чолгап түбәндәгеләр язылган иде:

«Елкы елында хут кергәч, Ямьле тугайны абжур команда басты. Сыгырдан сыгыр, сарыктан сарык калмады — һәммәсен кырып ашап киттеләр. Ирен-хатынын барчасын янган ут аша үткәзеп, баш бирмәүчеләрне күпердән аттылар. Ходай түземлек бирсен».

Мәдәния, кулы белән ишарәләп, кунакны өй алдындагы чоланга әйдәде. Ишек артындагы чигүле тастымалны алган иде, аның астыннан вакыт узу белән күренер-күренмәс хәлгә килгән тагын бер язу килеп чыкты.

«Мәүлет башында буйга уздым. Төшемдә атлы-кылычлы яшь егетләр күргәлим. Ярабби, нәзерләрем кабул булып, ир бала гына тапсам икән».

Камил үзе дә сизмәстән, кемнәндер бөтен дөньядан яшерә торган газиз серен ачарга туры килүенә уңайсызланып күзлеген сөрткәләргә керешге.

— Бу минем кайнанамның соңгы язуы. Ул, мескинә, минем ирем буласы кешене тапкан да шул көнне үк үзе дөнья куйган,— диде Мәдәния.— Мондый язулар тагын да бар әле. Менә берсен генә күрсәтим дә.

Анысы өй алды тактасына хәзерге хәрефләр белән язылган иде.

«Августның 4 ендә 41 нче ел сугышка чыгып кителде,— диелгән иде анда.— Фашистларның башына җитеп, исән-имин илгә әйләнеп кайтырга насыйп булса, ике аягымның берсен дә читкә атламас идем, җидегән чишмәнең җидесен дә гомер буе багар идем».

— Монысы минем ирем була инде, Мәрдән. Ул сүзендә торды. Бушрак вакытларында үлгәнче гел чишмәләр янында булды, читәннәр үрде, чыгар юлларын тазартты. Менә бу язуларны да ул саклады, күреп музейларга да җибәреп йөрде.

Кунак кеше әле язуларга, әле Мәдәниягә карап ала, башын чайкый, нидер уйлый да тагын Мәдәниягә карый иде.

— Менә бит, ә! Гаҗәп-хәйран!

— Бәлки безнең заман өчен бик сәердер бу, Камил абый?

— Юк, сәер түгел, без наданнарга ифрат та гыйбрәтле сабак бу. Әйе! Халыкның рухи дөньясы, аның күңел тибрәнүләрен аңларга ярдәм итәчәк бит алар. Менә нәрсә!

Мәдәния өй алдында самовар белән кайнашкан арада Камил түр
мәдә як-ягына карангалап арлы-бирле йөренде. Хәзерге алдынгы
хозчы өендә ни булса, алар монда һәммәсе дә бар иде: яхшы радиоал-
ı, һәйбәт өстәл, кыйммәтле сервант, көзгеләр. Ләкин Камилнең болар-
ісе китмәде. Чөнки өй эчен кыйммәтле җиһазлар белән тутырып та үз
ынында җилләр уйнаучы наданнар бетәсе түгел иде әле. Бу өйдә
ап шкафы булу да ул кадәр гаҗәпләндермәде. Әмма шкафка китап-
ының билгеле бер зәвык белән тезелүе, иң затлы һәм тирән мәгънәле
ны әсәрләр генә туплануы Камилне куандырды. Кыз чагында әдә-
ітка ул кадәр исе китми иде түгелме Мәдәниянең? Аның эше булса,
и генә авыл кызы өчен ифрат та зур үзгәреш иде бу. Каян беләсең,
ıки...

Мәдәния табынга сый-хөрмәтен матурлап тезеп чыкты да өстәлгә
лтерәтеп кенә ап-ак самовар алып кереп утыртты.

— Рәхим ит, Камил абый. Озак көттердем бугай,— диде.

Еераз тамак ялгаганчы ара-тирә бер-берсенә караштыргалап, те-
ен-монысын сорашкалап утырдылар. Ләкин Мәдәния озак түзмәде,
сен дә дулкынландырган, менә ничә еллар буе сер булып сакланган
өнче аерылышуны, аннары бераздан көтмәгәндә Бөгелмәдә очрашуны
ıгатып җибәрде:

— Менә бит ничек тә була икән дөньяда. Исең-акылың китмәле. Син
не таныдыңмыни? Станцада дим.

— Әйе, таныдым.

— Битемне каплап бетергән идем бит.

— Гәүдәңнән.

— Ай-ай, күзең үткен икән, Камил абый. Өстемдә калын иде бит.

— Булса да. Син миннән хатны, нәкъ биегәндәге сыман, бөтен гәү-
н белән матур гына бөтерелеп, бөгелеп килеп алдың да ничектер,
әе көмештәй агып кына китеп, юкка да чыктың. Шуннан таныдым.
ınары керфегеңнән.

— И, анысы хыялдыр инде.

— Юк, хыял түгел! Хәзер дә күз алдымда. Керфекләреңә ап-ак бу-
ın бәс кунган иде.

— Казан арты кызы ничек бу якка килеп чыксын икән? — дип тә
ıгаймадеңме?

— Юк, гәүдәң күземә чалынуга, һичбер шигем калмады. Хәер, мин
вакытта могҗизаларга ышана башлаган идем инде. Мине коткарыр
н, рәхмәт фәрештәсе булып, Казан артыннан очып килгәнсеңдер дип
ладым.

— И, шулайдыр инде...

Мәдәния кыенсынып башлап иде. Әле хәзер дә матурлыгын җуймаган
еренке ирен кырыйларында моңсу гына, оялчан гына көлемсерәү
ренде. Ире үлгәннән соң берәүнең дә аңа шундый сүзләр әйткәне,
лай оялтып караганы юк иде әле. Яхшы да түгел инде бу, килешми
Балаларың үсеп беткәч... Әмма кул аркасындагы юанайган зәңгәр
мырларга күзе төшкәч, Мәдәния, авыр сулап, аларны икенче кулы
ән каплады.

Камил аннан һаман да күзен алмый иде әле.

— Тотып алырлар дип курыкмадыңмы соң?

— Юктыр, ахрысы.

— Бик четерекле еллар иде бит.

— Шулай инде...

— Ирең ишеттергән булсалар?

— Бер сүз дә әйтмәгән булыр иде. Минем шикелле китап укырга бик ярата иде, мәрхүм. Без аның белән шул китап аркылы танышты та.

— Бик рәхмәт сиңа, Мәдәния. Бөгелмәдә очравың минем бәхетем инде.

— Бәлкем шулайдыр да. Станцада шундый хәлдә күргәч, күз алларым караңгыланып, башларым әйләнеп китте. Кулында хат күргәч үйладым инде: «Бу актык өметедер, бичараның», дидем. Андый чакта нинди курку инде ул?!

— Алай димә, Мәдәния. Ни әйтсәң дә бик тәвәккәл, ифрат та йөрәкле икәнсең.

— Юк, бик куркак мин, Камил абый, куян йөрәк. Хатны күкрәгемә кыстым да чаптым гына авылга.

— Ничек — авылга?

— Мин аны ул көнне салмадым бит.

— Шулаймыни? Сәбәбе булгандыр инде, күрәсең.

— Каян хәтерләп бетерәсең инде...— Мәдәния, алдына караган килеш, алъяпкыч итәген бөтергәләп, тагын көлеп куйды.— Юләр булгач! Очкан җиреннән чыпчыклар егылып үлә торган чатлама суык иде бит. Өстең-башың юкалыгын күреп, мин сине бик кызгандым. Ичмасам, хатың гына булса да җылы өемдә кунсын дидемме икән соң?! Әллә тагы!..

Мәдәния кызарып урыныннан торды. Әллә кайчан ук йоклап беткән татлы серенең һич көтмәгәндә шулай уянып китүе аның үзенә ук ошамады. Самоварга тотынды да:

— И, күрми дә торам! Сүнеп беткән икән ләбаса! — дигән булды, нәкъ кыз чагындагы кебек җилтерәтеп, өй алдына алып чыгып китте.

Камил уларлы-бирле йөргәләргә тотынды. Өй алдында чарт та чорт чыра сынганы ишетелде. Каян беләсең? Әнә шул сөйкемлелеге, очрарга торгандай җиңел гәүдәле булуы, сәхнәдә булсын, тормышта булсын, тере көмештәй тәгәрәп кенә торуы истән чыкмыйдыр бәлки?!. Әйе, һаман да якын, һаман да үз итәсе килә.

Мәдәния самоварын яңартып урынына кереп утыргач, алар беразга сүзсез калдылар. Хәер, алар бер-берсен сөйләшмичә дә аңлыйлар иде. Дөрес, аларга бергә яшәргә насыйп булмады. Ләкин яшь чагында урлап калган кайнар мәхәббәт ялкыны аларны читтән генә булса да гомер буе җылытып килде. Алар моны күз карашларыннан ук сизәләр иде.

Кыз чагында бу иреннәр юкарак та, алсурак та, бу күзләр үткенрәк тә, тылсымлырак та иде. Тормышның иң караңгы көннәрендә алар Камилгә бердәнбер юаныч булдылар. Дөньясына иманы какшап, тәмам өметен өзгәч, кагъбәсен югалта язган чакларында, ул, Мәдәнияне күз алдына китереп, сүнә башлаган яшәеш шәмен яңадан кабызып җибәрә торган иде.

Болар өчен бәлки Мәдәниянең алдына тезләнеп мең-мең рәхмәт әйтергә кирәктер. Ләкин бөтен барлыгыңны тотырып торган ул кайнар хисне әйтеп бирергә нинди сүзнең генә көче җитәр икән?

Кунак кеше үзе башлап берни дә сорашмады. Аның уенча, гомер буе саф булып сакланган ул газиз тойгылар, хәзер, тау башындагы тегө чишмәләрдәй, үзләреннән-үзләре бәреп чыкмый хәле юк иде.

Шулай булды да.

Кунак алдына кайнар чәен ясап куйды да Мәдәния тагын үзе башлады.

— Теге вакытны миңа юкка чыгарга туры килде. «Ничек болай җир упкандай кинәт кенә югалды икән бу?» дип уйлыйсыңдыр инде син.

— Әйе шул. Минем өчен һаман да сер әле ул.

— Хәтерендәдер, безнең Мәңгәрдә Казан студентларының зур кичәсе булды.

— Әйе. Сугыш вакытында инде бу. Иген җыешырга баргач.

— Менә шул инде. Синең иптәшләрең шигырь сөйләделәр, син, үзең әйтмешли, «чыпчык борыны тикле» генә хикәя укыдың.

— Дөрес, хәтерлим. «Безнең әниләр» дип атала идеме?

Мәдәния тыныч булырга тырышса да, сизелерлек дулкынлана, кулындагы тастымалы белән әле самовар борынын, әле поднос кырыен ышкып ала иде.

— Нәкъ үзе... Анда сугыштагы улларын төшләрендә күргәнгә дә куанып, аларны көтә-көтә ачлы-туклы колхоз эшендә йөрүче нечкә күңелле аналар хакында язылган иде. Андыйлар белән авыл тулган, кәгазьгә язмасаң да алар гел күз алдында инде югыйсә. Шулай да елый-елый тыңладылар, рәхмәтләр әйттеләр.— Мәдәния туктап бер көрсенеп куйды.— Мин дә куандым. Тик миңа кызарып утырырга туры килде. Ник дисәң, ул хикәя миңа атап язылган иде бит. Андагы озын керфекле, алтын куллы җитез кыз Нәгыймә мин идем бит? Син үзең шулай дигән идең. Син хикәя укыганда иптәш кызларым, миңа күз кыскалап, көнләшеп тә утырдылар.

Камил, «әйе, дөрес» дигәндәй, башын игәләде. Шул ук вакытта әле бер кесәсеннән, әле икенчесеннән, күптән түгел генә тәмәке ташлаганлыктан, өендә калдырып килгән тәмәке савытын эзләмәктә булды.

— Мин, юләр, шушы минутларда куанычымны минем белән дә уртаклашырсың дип көттем. Күземне алмыйча, йотардай булып, йөзләреңә текәлдем. Бер дә чыктың, ике дә чыктың сәхнәгә. Залга баш иеп рәхмәтләр яудырдың, шук сүзләр әйтеп көлдердең. Ә мине оныттың.

— Ничек инде ул «оныттым»?

— Шулай! Каршыңда күзләрен мөлдерәтеп утырган сөйгән кызыңа, ичмасам, күңел өчен генә, ичмасам, бер генә тапкыр да күз төшереп алмадың!

Кунагының кызарып йөзен каплавын күргәч, Мәдәния каушый төште.

— Ай, Камил абый, ялгыш ычкындырдым, ахрысы, юкка кузгаттым! — диде, коңгырт-яшел күзләрен мөлдерәтеп, кызганып карап торды да ашыгып Камил янындагы тәрәзәне ачып җибәрде.— Шайтан гына теләмнән тарттымыни соң?!

Шушындыйрак игътибарсызлыгы өчен Байгузинга күп мәртәбәләр кызарырга туры килгәне бар иде. Шулай да үзен шундый фидакарь бер мәхәббәт белән сөйгән шушы саф күңелле яшь йөрәккә мондый ук авыр яра салганмын дип кем уйлаган? Шул кадәр үк ваемсыз, шундый ук мәрхәмәтсез булдымы икәнни соң ул? Оят бит, оят!

Камил читкәрәк карап кулын селтәде.

— Әйтеп бетер, Мәдәния, күңелеңдә калдырма. Соң булса да сабак булыр,— диде.

Мәдәния «тагын берәр күңелсез хәл булмасмы икән соң?» дигәндәй, Камилгә шигаебрәк карап алды да яңадан самовары янына килеп утырды.

— Хәзер әйтеп тә ни файда инде. Күңелдә төен булып калмасын дисәң генә... Шул кичне минем беренче тапкыр күзем ачылды. Синең берьюлы ике яр сөюеңне белдем.

Камил сикереп торды.

— Юк, юк! Монысы дөрес түгел! Ул нинди сафсата? Каян башыңа килде, Мәдәния? Ни сөйлисең?

Мәдәния, йомшак кына көлеп, аңа утырырга ишарә итте.

— Әһә! Авырткан җиргә барып тидеме? Шулай да хак сүз ул, Камил абый, һич ялгансыз!

— Юк та, ышанмыйм да! Син мине ике йөзле дип уйламыйсыңдыр бит?

Мәдәния, коңгырт нокталар сибелгән нурлы күзен кыса төшеп, тагын бер көлде дә, кинәт җитдиләнеп, авыр сулап куйды.

— Ышанмыйча хәлең юк, Камил абый, шулай ул, дөрес ул! Синең иң өзелеп сөйгән ярың мин түгел, язган әйберләрең булып чыкты. Ул төнне мин менә шуны төшендем.

Байгузин, хәйран булып, авызын ачып калды.

— Ә? Әсәрләремме? Гаҗәп! Әсәрләрем миңа чыннан да бик газиз. Ләкин алар мәхәббәткә нишләп комачауласын икән? Менә монысын уйлап та караганым юк иде.

— Башыңа төшкәч, үзәк-бәгырьләреңә кадалып кергәч, уйлыйсың икән шул. Андый көндәш тә була икән дөньяда.

— Арттырмыйсыңмы икән, Мәдәния? Мин бит сине бик нык сөйдем, чын күңелдән, бөтен дөньямны онытып!

Мәдәниянең күзләре елтырап, иреннәре дерелдәп китте.

— Сүздә, хыялда, әйеме? Язучы халкы хыялга зерә дә бай бит ул. Ә чын тормышта нәрсә килеп чыкты? Синең хәтереңдә дә юктыр бәлкем, Камил абый, әллә кайчан оныткансың. Ә минем менә хәзергедәй күз алдымда. Кичә беткәч, мин сине клуб ишеге төбендә көтеп тордым. Ул чагында вәгъдәләр дә бирешкән идек инде, кич белән син шул турыларда нидер әйтер дә шикелле идең, бик серле генә итеп. Өзелеп көттем дә бит, миңа орынып кына да уздың, ә күрүен күрмәдең!..

Камил, идән астыннан килгәндәй тонык тавыш белән:

— Шулай ук булдымыни? — дип сорады.

— Әйе. Клубта шулай күкләргә чөйгәннән соң башлары әйләнеп, җирдән гүпчи дә очып китте бу дип уйладым инде мин.

— Сине эзләп чыктым шикелле бит!

— Килмәдең! Күрмәдем...

— Мине, сөйрәп диярлек, шигырь укырга алып киттеләр. Хәтерлим... Ә үзең килгән булсаң? Язучы халкының шундый хыялга бирелеп оны-тылучан икәнен дә белгәч...

— Кечтеки генә булсам да кеше бит мин, Камил абый, җитмәсә әле кыз кеше! Ә көндәшем ни тикле шәп булса да, нибары кәгазь генә, сүз генә!.. Бармадым шул. Соңыннан ишеттем, укытучылар белән төн буе шигырьләр әйтешеп утыргансыз, җырлар җырлашып.

Камил ике кулы белән чигәләрен уарга тотынды. Соңгы елларда аның колак мембранасы йомшак, ягымлы дулкыннарга гына көйләнеп, кискен сүзләр ишетүне онытып бара иде инде. Шунлыктан, аңа боларны ишетү ифрат та кыен булды. Оятына каршы, ул Мәдәниянең бер генә дәлилен дә кире кага алмады. Бар иде шул андый чаклар, бар иде ул шигъриятнең исерткеч томаны эчендә башлар әйләнеп сәмаларда очкан чаклар. Хыялга шулай артык бирелеп реаль тормыштан аерылып китү нәтиҗәсендә, аның бик һәйбәт идеяләре дә кайчакларны җир белән күк арасында эленеп тә калгалады. Тик моны берүк масаю дип кенә аңлама-масыннар иде. Ә ул көнне тиңе булмаган яңа шигырь туган иде. Алар шуның белән исерешеп, бөтен дөньяларын оныттылар.

Камил Мәдәниянең каршысына килеп башын иде.

— Бик зур гөнаһлы мин, Мәдәния, гөнаһлы. Мин сиңа ифрат та зур җәбер салганмын. Булдыра алсаң, соңгарак калып булса да, кичер син мине, кичер!

— Нинди гөнаһ булсын ул, Камил абый? Юри эшләмәгән бит. Сез шулай аңлаган, ә мин бүтәнчә.

Мәдәния башын иеп бераз уйланып утырды. Камилгә аның аз гына сипкелле йөзендә керфекләренең ара-тирә селкенгәләп китүе генә күренгәли иде.

— Ярлы тәкәббер идем шул. Тик үзем ярлы булсам да, намусым ай иде. Бәлки аңлый да алмаганмын, башыма сыймагандыр: ничек нде ул үзен уйлап чыгарган язу-сызуны кеше тикле кешедән өстен күрәк кирәк? Әнә ул бик акыллы да, зерә мәгънәле дә язылган булсын, и. Шулай да сүз генә бит ул, нибары кәгазьгә төшерелгән хыял гына! үз алдына китереп кенә кара, Камил абый, син шулай, үз хыялыңа үзең аклар катып, дөньяларыңны оныттың, ди, ә синең янәшәңдә, җанын рып бирердәй, суырып алырдай булып унсигез яшәр тап-таза чибәр ыз тора, ди. Җитмәсә, өздереп-өздереп бии бит әле. Ник бии, нәрсә дип ии? Аякларын уйнатып, буй-сынын биетеп йөрәгенең дәртен, күңеленең илкенүен әйтеп бирмәкче була. Ә аңа күз дә салмыйлар! Я, әйт, Камил бый, кыз баланы гарьләндерергә шул җитмәгәнмени?

Камил, идәнгә текәлгән килеш:

— Ай, Мәдәния! Сорап торасың тагын! — диде.

— Менә шул, хурлыгымнан төн буе җылап чыктым. Кимсенә-кимсенә улса да шундый уйга килдем: мин аңа тин түгел, кияүгә чыксам да очаклап йоклаудан башкага ярамам. Нишләргә иде соң миңа, газиз ашларымны кая куярга? Җылый-җылый тилерә башлагач, кайнар баш еләп чыктым да киттем. Башта Бохарадагы апамнарга барып сыенным. Дөньяда безгә тиңнәр дә бар икән, миңа дигәне госпитальдә очады. Танышып бер-беребезне яратыша башлаганнан соң, мин аңа еренче мәхәббәтемнең ничек җимерелеп төшүе хакында да сөйләдем. 'азарып чыгар алдыннан Мәрдән әйтте:

— Күк бик әйбәт, кәнишне, күк матур. Тик синең белән без җир кеәләре бит! Китап кешесе күгендә йөри бирсен. Ул язсын, без укырбыз. инең белән без җирдә дә күктәгедән начар яшәмәбез. Әйдә, язмышлары бергә кушыйк! — диде.

Шулай итеп, Урта Азиядән без ирле-хатынлы булып кайттык. Ирем еләп бик яратышып яшәдек, акыллы гына балалар да үстердек. Мин эмне һич тә бәхетсезләр рәтенә кертмим. Җирдә туган, җирдә үскән ыл кызына тагын ни кирәк?

Камил тагын торып йөргәләргә тотынды. Әле моңарчы күңел түренә зәгыйфь кенә булса да «бәлки... бәлки...» дигән өмет чаткысы бар иде. әзер ул да сүнәрме икәнни?

Камил өметен бөтенләй үк өзеп бетерәсе килмичә, авыр гына итеп:

— Ул вакытлар матур төш кенә булып калдымыни инде? Яңадан айтмасмы икәнни? — диде.

— Күрәсең, шулайдыр инде, Камил абый. Бер күргән төшне яңадан үреп булмый бит...

**Галимҗан Ахунҗанов,**
филология фәннәре кандидаты

# И ТУГАН ТЕЛ...

Тел, сүз — куәтле корал ул. Яхшы сүз — җан азыгы, яман сүз — баш казыгы; үтергән дә — тел, терегезгән дә — тел диләр. Гасырларга девиз-васыять итеп әйткәндәй, халкыбызның бөек шагыйре Тукай да: «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!» дип калдырган.

Язучы ул — тел остасы. Әмма бармаклар тигез булмаган кебек, бу осталарның да осталыгы бер дәрәҗәдә булмый. Оста барда телең тый, остаз барда кулың тый дигәндәй, бу хакта сүз алып баруы да бик җиңелдән түгел. Бигрәк тә сүз сәнгатенең аксакалларыннан берсе булган Гомәр ага Бәширов турында.

Бу мәкаләдә «Туган ягым — яшел бишек» романы турында сүз булачак, чөнки авторның матур сөйләм остасы булуы шушы әсәрендә аеруча калку күренә.

Борынгы грек риваятьләрендәге Антей батыр турында ишетмәгән укучы юктыр. Ул — җир улы булган, һәм җир-анасыннан аерылмаганда, җирдә торганда аны берәү дә җиңә алмаган. Шуның кебек, Гомәр аганың да уңыш сере — аның үз халкына, үз ана теленә, Тукай тәгъбиренчә, «әдәбиятыбызның җәүһәре — Казан теленә» таянуындадыр бәлки?!.

Безнең матур әдәбиятыбыз — бай әдәбият, мавыктыргыч әсәрләр дә аз түгел. Әмма «Яшел бишек»нең үзенчәлеге шунда: ул эчтәлеге белән генә түгел, теле белән дә мавыктыра. Кайбер язучыларда без сүзләр белән коры уйнау, «телгә салыну» кебегрәк бер нәрсәне дә очраткалыйбыз, бу күренеш еш кына үзмаксатка әйләнеп китә яза. Гомәр ага әсәрендә исә эш бөтенләй башкача тора.

Ярый, әсәрнең үзенә киик. Монә автор туган телебезнең төрле кеше авызында төрле стильләрдә ничек ялык-йолык килүен, төрлечә җемелдәвен күрсәтә. Кырыс холыклы, ләкин гадел Бәшир карт «ачуланып йодрык күрсәтте: — Барасы булмагыз! Яки: «Йәрисе түгел! Ят тә йокла! Иртәгә тырмага чыгарсың!» дип, кискен, өзек-өзек кенә сөйләшә. Сүзләре дә коры, кырыс, тавышы да боерулы аның.

Яки менә «мәзәк кенә сөйләп, ике сүзнең берендә бик озын итеп и-и-и дип сузып сөйләүче» Җиһан апа теле: «Ай аллам, Гүмәр түгелме соң бу, Гүмәр үземе? И-и-и ходаем, танымыйлар да торам!.. И-и-и гомерләр, гомерләр! Әле кайчан гына бишек баласы иде».

Менә якын, үз итеп тасвирланган керәшен карчыгының кычыткан белән сөйләшүе: «И җүнсез! Шул тикле көйдереп алмасаң! Бигрәк тә зәгарьләнәсең. Карт көнемдә ачуымны алыем, чагып калыем дисеңдер инде».

Тел булгач, барысы да була: оста сөйләүчесе дә, сөйли белмәүчесе дә, сөйли белмәүчедән көлүчесе дә: «Нимҗан әйтми торгач, Шәйхи аны якасыннан тотып селекте:

— Йә, әйтәсеңме, юкмы? Кү-лә-гә!
— Кү-гә-лә!
— Кү-лә-гә!
— Кү-гә-лә!
— Әйбер диген!

— Әрбир...
— Ни-ках!
— Ни-хак...»

Бусы халыкның шаяртулы, үзенчә ironияле әкият сөйләме: «Менә, падишаһым-лтаным, итегемдә олтаным ди бу, патша булгач, безнең Яңасалага да баргансыңдыр, ы гына беләсеңдер, бездә бит җир кытлыгы, ашарга җитми. Тудыйм-судыйм сугыл-лап, ялланып эшләмичә тамак туйдырып булмый. Бер елны, әти тумас борын, бабай лән алпавытка ялланырга бардык. Нәкъ мин сиңайтим, синең бабаңның алпавытта ңгыз көткән чагы...»

Яки менә иске мәдрәсә-китап теле: «...җирдә дә дәгелдер, күктә дә дәгелдер» 23). Мондый сүзләр шәкертләрнең җанына тигән: «Кыш буена без бу куян тиресе лән сыгыр тиресенең байтакка кадәр башларын әйләндердек. Алар, эт эчәгесе икелле, хисапның һәр гамәле саен диярлек һаман ияреп йөрделәр. Сыгыр дигән-әре дә үзебезнең абзар тәрәзәсеннән башын сузып ашарына сорап мөгрәп торучы леге шул гап-гади сыерларыбыз иде югыйсә. Ләкин ул вакытта халык сөйләгәнчә нә язу килешмәгән, күрәсең, алай «фәнчә» булмаган»,— ди автор.

Мәдрәсә «фәнен» аңламаган бәләкәй Гумәр, хәзерге хөрмәтле Гомәр Бәшировка йләнгәч, андый «фәннәр»нең асылына төшенеп кенә калмый, бәлки аларны иҗат түчеләрнең берсе булып китә.

Халык зур ул, әдип ул, шагыйрь ул дип юкка гына әйтмибездер. Менә шушы агыйрь-әдип булган халыктан алынган сүзләр, тәгъбирләр үзләре генә дә, урынлы улланылып, энҗе кебек җем-җем итеп әсәрне бизиләр. Саф халык сөйләме үрнәк-әре әсәрнең һәр битендә мул очрый: «Әйттер шуны, сиптер шуны!.. Инде лә, инде ә! Аргы якның керәшен кызы бу. Кем генә соң әле, аты җиткере!» Халык әйтсә, аты әйтә, тупаслыгы-килешмәслеге белән бик артык исәпләшеп тормый: «Әй-яй, таза у, үләт еккыры! Кара ул муенны! Кара ул беләкләрне! Бот юанлыгы!»

Гомәр аганың халыкчан, җанлы сөйләме бүтән телләрдән кергән сүзләрне, тәгъ-бирләрне чын үзебезчә бирүдә дә чагыла. Хәзер әдәби телдә, бигрәк тә язма телдә шартлы, ясалма булып киткән күп кенә сүзләр һәм тәгъбирләр бу романда чын халыкча бирелгәннәр: **пирчәткә, дисәтник, урәтник, пичәт басу, бүлнис, кантур, скрипкә, купис, маладис, Әчтерхан чикләвеге** һ. б.

Автор гарәп-фарсыдан кергән сүзләрне дә чын халыкча яңгырашлы иттерә: пигамбәр (пигәмбәр), **мөнәҗәт, сәлам, хәрәм, Гумәр** (Гүмәр), **әдәм, үнәр күрсәтү** һ. б. Халыкча дигән сүз — ул фәнчә, ягъни дөрес дигән сүз. Чөнки тел фәнендә инде күптән урнашкан, күп халыкларда гамәлгә дә тулысынча ашырылган шундый кагыйдә, закон бар: әдәби телнең нигезе — гомумхалык теле, әдәби сөйләмнең, әйтелешнең нигезе — гомумхалык сөйләме, әйтелеше.

«Яшел бишек» романының теле җанлы яисә матур гына түгел, бәлки көчле дә. Автор моңа төрле сурәтләү-сәнгатьләү чаралары, шул исәптән, мәкальләр куллану ярдәмендә дә ирешә: «Ташы мәгърифәтне авылга, Хәнәфи абый, кашыклап кына бул-са да ташы, күп тамчыдан күл булыр»; «Билләһи, зәрәгә генә сүз катмый бу мыш-тым! Җилсез яфрак селкенми, мин дә ишеттем андый... хәбәрне.»

Сүз җаена карап, мәкальне җыр да бик урынлы алмаштыра. Мәсәлән, кунак кызы, чын халыкча дипломатия саклап, егеткә җыр белән җавап бирә.

**Иеләдер, бөгеләдер су буенда тал тирәк;**
**Сезнең белән сөйләшергә сандугач теле кирәк.**

Егет кызга үпкәләп-төрттереп җырлап уза:

**Йөгереп төштем су буена, кереп киттем таллыкка;**
**Егеттән егет ким түгел,— кимсетәләр мал юкка.**

Сөйләмен бизәү һәм аның көчен куәтләү өчен Гомәр ага бәетләр, алардан өзек-ләр яки Тукай шигырьләрен дә бик уңышлы куллана. Сөйләмнең төмен җибәрмичә, чаманы белеп кенә кулланган әйтемнәр һәм бүтән тел чаралары шулай ук әсәрне бизәп, аның тәэсир көчен арттыра: «Әти, нидер төшенә башлаган сыман: — Ә-ә-ә! — дип сузды.— Юкәдә икән чикләвек!» «Аңа хәзер ике чабата бер кием, ике дөнья бер тиен!» Гомумән, халык теленнән алган яки автор үзе әйткән күп төрле гыйбрәтле үткен, тапкыр сүзләр аның сөйләмен бизи, яңгырашын куәтли, җылысын арттыра.

Гомәр ага телебезнең сурәтләү-сәнгатьләү мөмкинлекләреннән бик оста файдалана, сүз дигәнебездәге энҗеләрнең иң матурларын сайлый, телне бер көченә эшкә җигә. Әйтик, мәсәлән, аның чагыштыруларына гына карыйк. Алар шулай ук халык теленнән яисә авторның үз сүз хәзинәсеннән алынганнар: **әвен тикле балык, келәт хәтле үгез, атна буе вак иләктән иләгәндәй тәтәсләп яуган яңгыр, бозау хәтле гармун, җиз ләгән төсле сары салкын кояш, түшенә ак алъяпкыч бөркәнгән төсле ала-кола ат, агач ботакларында, койма өсләрендә начар хатыннар шикелле ярты гомерен үзара әрепләшеп, ызгышып уздыручы чыпчык халкы** һ. б. ш.

Язучының карап торуга гап-гади генә күренгән сөйләме дә үзенчә матур, йөрәккә кереп кала. Хәтта гади сөйләм сүзләре-тәгъбирләре, ягъни әдәби тел өчен норма булмаган сөйләм дә, шушындый матур чигешле җирлеккә килеп кунгач, бик үз, бик урынлы булып чыга. Урман чытырманы белән күңелле диләр бит! «Тормыш сине кырык сират күпереннән кичерә. Әле иркәли ул сине, әле яңаклап ташлый, бер келдерә, бер елата, бер алдын күрсәтә, биш артын күрсәтә».

Сүзләрнең-тәгъбирләрнең үзләреннән генә түгел, бәлки аларның мәгънәләреннән дә бик оста файдалана белә Гомәр ага. Мәсәлән, **бер җирдә сандугач сайрый, икенче җирдә кошлармы, бөҗәкләрме сайрый, өченче җирдә матур тавышлы кунак кызы сайрый, тагын бер җирдә су китерүче кызларның чиләкләре сайрый, салкын иртәдә кышкы юлдагы чана табаннары сайрый...**

Төрле сәбәп-сылтаулар табып, без кайбер сүзләрнең яки формаларның матбугатта кулланышын чикләргә тырышабыз. Әмма каләм иясенең оста кулына эләккәч, алар да җанланып китәләр, алыштыргысызга әйләнәләр. Ул гына да түгел, әдәби тел өчен норма булмастай сөйләм элементлары да бу әсәрдә үз урыннарында бик нык утыралар, үзләренчә балкыйлар. Мәсәлән, «нәрсә» сүзе Бәшир карт һәм башка кайбер персонажлар телендә ниямәрсә, ниястә, нәмәстә, нәстә формаларында бик матур килгән. Фразеологик тәгъбирләрнең дә җирле төрләре әсәргә сафлык, теленә оригинальлек бирәләр.

Гомәр ага моңа кадәр гомуми кулланыштан, бигрәк тә язма телдән читтә кала килгән күп төрле аваз ияртемнәрен, ымлык сүзләрне бик уңышлы китерә, кулланышка кертеп җибәрә. Хәтта мал, кош-корт сөйләшүен дә ишетә ул. Менә ояда утырган каз «шыпырт кына, үз алдына сөйләшкәндәй, пышылдап кына: «кый-га-га» ди: ишек алдында ялгыз калган ата каз, ишекне кагып ачтырып «сыңар күзен әнигә текәгән дә шул бер үк сүзне кабатлый: ка-га-га!»; өй эчендәге ана каз «нәни бәбкәсенә кый-гый-гый дип тавыш биреп күкәйдән чыгарга булыша»; кыр казлары очып узганда «авылдагы туганнары алар белән кыйгак-кыйгак дип сөйләшеп алгандай итәләр» һ. б.

Сүзне йомгаклап әйтсәк, туган телебезнең шундый бай мөмкинлекләрен ачып күрсәтүе белән Гомәр ага аны тырышып пропагандалый. Шул ук вакытта ул телебезне алга сөрү эшен турыдан-туры да алып бара: әдәби әсәрләрендә дә, махсус фәнни мәкаләләрендә дә ул аерым сүзләрне, тәгъбирләрне яки формаларны яклап, күтәреп чыга. Бу романында да ул әле ничектер киң кулланышка кереп җитмәгән кайтаваз, борыннан сөйрәп йөртү кебек сүзләрне, тәгъбирләрне, җон уңаена сыпыру кебек халыкчан формаларны, шулай ук соңгы елларда матбугатта кулланыштан чыгарып ташланган җәзбә кебек сүзләрне үз урыннарына утыртып, кыйммәтләрен күрсәтә.

Әдәби әсәрләрне тикшергәндә тәнкыйтьчеләр гадәттә тип, персонаж, пейзаж кебек образлар турында сөйлиләр. Тел хакында исә шул образларны иҗат итү чараларының берсе буларак кына искә алып үтелә. Ә Гомәр аганың бу китабын укыгач шундый тәэсир дә кала: монда тел үзе дә мөстәкыйль бер образ дәрәҗәсенә күтәрелгән, төгәлрәк әйткәндә, халыкчан җанлы, туган тел чын мәгънәдә матур тасвирланып, күп яклырыннан күрсәтелгән.

Кояшта да тап бар дигәндәй, бу зур күләмле, киң профильле әсәрнең телендә сирәк-мирәк кенә «тешкә тиярдәй» урыннар, ягъни саф халыкча яңгырамаган сүзләр, тәгъбирләр, формалар да юк түгел. Ләкин бу очраклы кытыршылыклар гына булса кирәк.

Әдәбиятыбыз хәзинәсенә кереп, тарихта кала торган бу романында Гомәр ага Бәширов гүя замандашларына да, киләчәк буыннарга да чын халыкча, гади, саф булганда гына сөйләмең матур, көчле һәм бай була, ди. Җыеп әйткәндә, ул чын халыкчан сөйләмне яклый, туган телебезне күтәрә, данлый.

# ИЛ БЕЛӘН ГЕЛ БЕРГӘ

Кешелек җәмгыяте тормы-
ында әдәбият, сәнгатьнең гөрләп
әчәк аткан чорлары була. Бөек
ктябрьдан соң татар мәдәнияте
згап даплы юл — шуның бер ми-
алы. Революция безнең сәнгать-
ә яңа сулыш өрде, аны моңарчы
үрелмәгән биеклекләргә күтәрде.
Іоны, барыннан да бигрәк, татар
алкының музыка сәнгате үсешен-
ә ачык күрергә мөмкин. Моннан
рты гасыр элек безнең бу өлкәдә
актанырлык нәрсәбез генә булды
кән?!. Бүген татар халкының гү-
әл опера һәм балет әсәрләре
өнья сәхнәләрен гизә. Әле кайчан
ына Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Иб-
аһимовлар татар халкы арасын-
ан чыккан тере композитор кү-
ергә хыялланганнар иде. Хәзер
езнең гаять үзенчәлекле һәм сә-
этле дистәләрчә композиторлары-
ыз бар. СССРның халык артисты,
Дәүләт һәм Тукай премияләре
лауреаты Нәҗип Җиһанов — шун-
дый композиторларның берсе.



Нәҗип Җиһанов татар профессиональ музыкасын тудыру һәм үстерү эшенә якыннан торып катнаша. Музыка сәнгатебезнең иң кызыклы сәхифәләре аның исеме белән бәйләнгән. Татар дәүләт опера һәм балет театры 1939 елда Н. Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла. «Качкын» җитди таләпләргә җавап бирерлек беренче татар операсы санала. Шуннан берничә ел узуга, 1941 елның җәендә, мәшһүр «Алтынчәч» сәхнәгә менә. Һәм шуннан бирле төшкәне дә юк.

Рус һәм дөнья классиклары туплаган бай тәҗрибәгә, шулай ук татар халык иҗаты традицияләренә таянып, композитор бер-бер артлы яңа сәхнә әсәрләре иҗат итә. Хәзер аның уннан артык опера һәм балеты бар.

Төрлесе төрле характерда, төрле югарылыкта эшләнгән ул әсәрләргә күп кенә уртак сыйфатлар хас. Күзгә ташланган беренче үзенчәлек шул: композиторның барлык әсәрләре диярлек халык тормышындагы зур вакыйгаларга багышланган. Н. Җиһановның сәхнә әсәрләренә зур колачлылык һәм эпик киңлек хас, алар дра-

матик ситуацияләр, кискен конфликтларга корылган булулары белән аерылып торалар. Кайсы гына чорга карамасыннар, аларда ирек һәм азатлык өчен көрәш мотивлары, Ватанга мәхәббәт хисләре өстенлек итә.

Нәҗип Җиһановның сәхнә әсәрләре татар музыка сәнгатенең үсешенә көчле йогынты ясады, аның әсәрләре үрнәгендә меңнәрчә тамашачылар тәрбияләнде. Лә-кин композитор эшчәнлегенең әһәмияте бер татар сәнгате белән генә чикләнми. Билгеле булганча, композиторның герой шагыйребез Муса Җәлил белән ижат дуслыкта язылган «Алтынчәч» операсы бөтен совет сәнгатенең уртак казанышы булып тора. Заман темасына багышланган уңышлы опералар иҗат итүче автор буларак та Нәҗип Җиһанов исеме киң билгеле. Аның «Җәлил» операсы заман темасына язылган иң уңышлы совет опраларының берсе исәпләнә. Үзебезнең Ка-заннан тыш, бу әсәр СССРның Зур театры һәм Прага милли театры сәхнәләрендә уңыш белән барды.

Нәҗип Җиһанов музыка сәнгатенең төрле өлкәләрендә нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән, киң диапазонлы композитор. Эре күләмле сәхнә әсәрләре язу белән, ул Татарстанда симфоник музыканың үсешенә дә сизелерлек өлеш кертте. Аның иң яхшы симфоник әсәрләре чын милли колорит һәм халыкның җыр традицияләренә нигезләнүләре белән аерылып тора, ул әсәрләргә хис-кичерешләр сафлыгы һәм көчле шигърият, оптимизм һәм тормышка мәхәббәт хисләренең көчле булуы, алынган теманы ачуда эзлеклелек һәм сәнгатьчә бөтенлек хас. «Кырлай», «Татар көйләренә сюита», «Нәфисә» увертюрасы, «Симфоник җырлар», «Симфоник но-веллалар», «Сабан туе» кебек әсәрләре әнә шундыйлар.

Үзенең 60 яшен Нәҗип Җиһанов иҗатта яңа уңышлар белән каршылый. «Сабан туе» исемле симфониясе өчен аңа Дәүләт премиясе бирелде. Йөз меңнәрчә укучыларыбыз исеменнән яраткан композиторыбызны чын күңелдән котлыйбыз һәм аңа яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

# ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ТАЛАНТ

Сәнгать остасының үз гомерендә талантының көчле якларын бик калку һәм тулы итеп ача, кичергәннәрен гомумиләштереп бирә торган әсәрләре була. Минем-чә, Нәҗип Җиһановның күптән түгел генә язылып беткән Икенче симфониясе шушы әсәрләр рәтенә керә.

Н. Җиһанов үзенең Икенче симфониясенә «Сабан туе» дигән исем куйган. Бер уй-лаганда, бу исем авторның төп максатын — татар халкының борыннан килгән сабан туе бәйрәме атмосферасын тудыру максатын ачык билгели кебек. Чынлыкта исә, һәрбер чын сәнгать әсәрләрендәге кебек, музыканың һәм музыка тудыра торган кичерешләрнең реаль эчтәлеге әсәрнең исемендә әйтелгәннәр белән генә чикләнеп калмый. Шуңа күрә Н. Җиһановның «Сабан туе»н татар халкының тормышына багышланган бәйрәм симфониясе дип атарга мөмкин.

«Сабан туе» тынлы җиз коралларның яңгыратып кычкырткан авазлары белән башланып китә — бәйрәмгә өндәү, бәйрәмгә чакыру бу. Шуннан соң бер-бер арт-лы ике төп тема тасвирлана.

Беренчесе — стихиядәй көчле, киң эпик колачлысы — ритмик сурәтләренең үзенә бер төрле салмаклыгы белән аерылып тора. Икенчесе — татар халкының озын көйләре рухында язылганы — гүяки нәфис бер аваз җырлагында «җем-җем итеп» бара кебек.

Бу музыканы тыңлаган чакта күңелгә нинди охшашлыклар килә соң? Иң элек күз алдына халык батыры Җикмәргән белән алтын чәчле гүзәл кыз образы

...леп баса. Шул ук вакытта «Сабан туе»ның (беренче кисәге) Бородинның симфониясе, Римский-Корсаковның «Снегурочка»сында яки «Китеж»ындагы табигать лирикасы белән уртаклыгы да сизелә. Кыскасы, Н. Җиһанов үзенең татар халык сәнгате һәм рус классикасы традицияләре җирлегендә формалашкан индивидуаль язу ысулына турылыклы булып калган.

Икенче симфониядә экият-дастан образлары белән бергә республиканың авыл тормышы тасвирлары да бирелгән. Бу уңайдан бигрәк тә төрле-төрле бию темалары — дәртле, шаян, тыйнак-лирик бию көйләре (симфониянең азагындагы вальс) игътибарга лаеклы... урында кала.

Композитор драматик элементлардан да читләшми (өченче кисәктә, азакгы эпизодларның берсендә). Бу нәрсә симфоник хәрәкәт сөрешенә кирәкле күп планлылык бирә.

Борынгының бүгенге белән, экиятнең чынлык белән, традицион милли үзенчәлекләрнең тормыш тудырган яңа сыйфатлар, бүгенге заман тойгысы белән органик кушылуы бу симфониянең яхшы бер сыйфаты булып тора.

ЮРИЙ КОРЕВ,
«Советская музыка» журналы
редакторы.

# ГОРУРЛАНАБЫЗ

Кошның ике канаты бар. Берсе белән генә оча алмый ул. Иҗат кешеләренең дә шундый канатлары бардыр кебек тоела миңа. Яраткан композиторыбыз, СССРның халык артисты Нәҗип Җиһановның андый канатлары киң, колачлы. Аларның берсендә халыкның көченә, гүзәллегенә, матурлык һәм бәхет өчен героик көрәшенә олы мәхәббәт булса, икенчесендә — шул юлда каршы торган кара көчләргә, явызлык һәм һәртөрле ирексезләүгә рәхимсез нәфрәт хисләре. Шушы ике көч композиторны һәрвакыт уйландыра, иҗат мәйданына чакырып тора.

Композиторның беренче зур әсәре «Качкын» операсын гына алыйк (аны иҗат иткәндә ул әле консерватория студенты гына була!). Сюжетның нигезендә — Пугачевка кушылган Идел буе татарларының авыр тормышы, батыр көрәше. Ярлы егет Булат авылда азатлык өчен башланган көрәшнең башында тора. Аның сөйгән кызы Рәйхана, алпавытлар никадәр генә җәзаласа да, Булат һәм аның тарафдарларының көрәш планнары турында бер сүз дә әйтми...

Әсәрнең кереш өлешенең беренче тактларыннан ук халыкның кайгысын, борчылуын да, ирекко омтылышының, ашкынуның нинди зур көч икәнлеген дә — барысын да тоясың. Бу тема, музыкада үсә килеп, кайгылы характерын әкренләп югалта бара һәм көрәш символы булып яңгырый...

Композиторның күренекле шагыйрь Муса Җәлил белән тыгыз элемтәдә булуы бигрәк тә дулкынландыра мине. Ике зур художникның иҗади дуслыгы һәм бергәләп эшләве безнең татар культурасын гына түгел, ә бөтен совет культурасын алга үстерүдә зур роль уйный. Халыкның азатлык хыялын чагылдырган кыю егет Җикмәргән һәм матурлык идеалы, яктылык, сафлык символы булган сылу кыз Алтынчәч турындагы гаҗәеп легенда Җәлилгә поэма, Җиһановка опера язу өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булып хезмәт иткән. Шунысын да сокланып әйтергә кирәк, алар бабаларыбызның көчен хисләрен чагылдырган бу тарихи әсәргә бүген без яши торган чорның нурын төшерә алганнар. Шул сәбәпле әсәр безгә бигрәк тә якын тоела, чын ләззәт белән кабул ителә.

Музыка гаять зур сихри көчкә ия. «Яхшы музыка тыңлаганда минем уйланым ачыклана, күңелем сафлана һәм гаҗәеп күтәренкелек белән эшкә тотын...

нам»,— ди бер француз язучысы. «Җәлил» операсын тыңлаганнан соң моның шулай икәнлегенә тагын бер кат ышанасың. Казанда татар телендә, Мәскәүдә рус телендә, Прагада чех телендә һәм башка сәхнәләрдә яңгыраган «Җәлил» операсы, оптимистик трагедия буларак, совет музыка сәнгатенең алтын фондына керде. Аны тыңлаганда күңелдә совет кешесенең тимердәй көчле ихтыяры, хәтта үлемне дә җиңә белүе өчен горурлык хисе тулып ташый. Кеше буларак, коммунист буларак, үз көченә ышаныч арта, җаваплылык арта. Дус, фикердәш буларак, композитор Җәлил белән башлаган эшне дәвам итте. Гаҗәеп зур осталык һәм кыюлык күрсәтеп, шагыйрьне кабат терелтте. Җәлил бүген дә исән, ул илебезнең иң зур сәхнәләреннән атлый.

Яки концерт залында композиторның «Кырлай» исемле симфоник поэмасын тыңлыйсыз, ди. Көчле, салмак һәм моңлы булып аккан көйләр сезне каядыр еракка, матурлык дәрьясына — кырларга, кошлар сайрап торган урманнарга алып китә. Күңел рәхәтләнеп ял итә. Соңгы вакытларда иҗат ителгән «Симфоник поэмалар», «Симфоник җырлар» цикллары да зур тәэсир итү көченә ияләр.

Сүз юк, композиторның хыял канатлары нык, алар әле талмаганнар. Без, нефтьчеләр, хезмәттә яңа җиңүләр яулау өчен зур көрәш алып барабыз. Булат һәм Рәйхана, Сөембикә йөргән җирләрдән, торба сузып, Идел буенда чыгарылган нефть чишмәсе белән Европага барып чыктык. Нәҗип Җиһанов исә анда безнең борчу, шатлык һәм уйларны җиткерде. Һәм хәзер дә шушы өлкәдә армый-талмый хезмәт итә. Шундый композиторыбыз булу белән горурланабыз без.

ҮЗБӘК САТТАРОВ,
«Татнефть» берләшмәсе начальнигының
урынбасары.

**Анатолий Тяпаев,**
мордва шагыйре

## Ленин янында

Шундый тынлык! Сизелә йөрәк тибеше.
Тын да алмыйм, карыйм тирә-якка мин:
Һәр әйбере шул килеш. Чыккан гына,
Керә ул, дип, хис итәм шул чакта мин.

Менә кием элгече, зонт, таягы...
Ачык китабы укыган җирендә...
Ленин исән! Тәрәзәдән кара син!
Ал йолдызлар балкый аның илендә.

Дәвам итә ил көрәштә көннәрен,
Иркле җир балкый хезмәт нурыннан.
Һәрбер яңа буын даһи Ильичның
Атлый туры, изге, якты юлыннан.

Бүген тып-тын аның гади бүлмәсе.
Биредә ул күп уйланган, кичергән.
Илгә икмәк даулаган, ә дөньяга
Ирек яулау турында уйлап йөргән.

Ватан көрәш уйларында янганда,
Тилмергәндә һәр патронга, кадакка,
Күргән Ильич киләчәк еллар аша
Туган җирнең нур сибүен һәр якка.

Юллар кайтып тоташа Кремльгә,
Даһи Ильич эзләреннән башланып.
Канлы көрәш кырларында җиңделәр,
Комдивлар аннан зур киңәшләр алып.

Нинди тынлык! Биредә һәр нәрсәне
Тиңсез хөрмәт белән искә алабыз.
Менә карта, телефон. Безнең белән
Сөйләшә бүген дә Ленин бабабыз!

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәсе.

**Иван Пиняев,**
мордва шагыйре

## Көн килер

Көн килер бер — кояш нурларында
Ап-ак карлар янып көл булыр.
Күзләр кебек балкып, кырларымда
Чәчәк атып торган көн булыр.

Мин кайтырмын тагын бал җыйганда,
Балга бай ул Сура буйлары.
Килә-килә кычкырырмын картка:
— Яле, дус, куй балың-сыйларың!

Килеп чыгар өйдән ул каршыма,
Сакалында алтын корт булыр.
Кулын куяр минем иңбашыма,
Күзгә карап бераз тын торыр,

Элеккечә елмаер ул шуннан,
Елмайгандай сабый балага:
— Кайттым диген, ярый. Әйбәт булган!
Онытмадым диген калада...

Мин шикләнеп карыйм умартага,
Рәхәтләнеп миннән карт көлә:
— Корт ул пуля түгел, курыкма аннан,
Кемгә,
кайчан тиясен ул белә...

Утырышабыз өстәл тирәсенә,
Гәпләшәбез — сүзләр бал сыман.
Туган ягым!
Картның сөйләвеннән
Хәл-әхвәлнең ачыла барысы да.
Ул тәрәзә ача — кошлар тавышы,
Төтен һәм бал исе һәр яктан
Өйгә тула...
Татлы яшьлек сагышы
Төер булып утыра тамакка.

Искә төшә барысы: алтын комда
Алтын бала чаклар күмелгән...
Черки тавышы, тын төн уртасында,
Чыңлап үткән колак төбеннән.

Истә, истә: болын сукмаклары...
Алып китте зәңгәр бер төндә
бер кыз мине,— алка чыңлауларын
Ишетәм мин әле бүген дә.

Мин хәтерлим барысын: болыннарны,
Сура буен, чалгы чыңнарын...
Хәтерләмим ләкин
дәртле җаны
Бу картның бер тынып торганын.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе

**Малик Хәмитов**

# ТЫНГЫСЫЗ КӨННӘР

ОЧЕРК

**«Халык хуҗалыгының бу тармагының торышы, аның үсеш тенденцияләре һәм андагы кыенлыкларның характеры шуны күрсәтә, безгә авыл хуҗалыгының материаль-техник базасын тагы да ныгытырга кирәк. Хәзер бу авыл хуҗалыгы производствосының үсеш темпларын һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең үсешен тәэмин итә торган хәлиткеч фактор булып тора».**

*Л. И. Брежнев. КПСС Үзәк Комитетының июль (1970 елгы) Пленумындагы докладтан.*



Узган елның 7 июнь көне Крупская исемендәге колхоз кешеләренең хәтеренә тирән урнашты.

Иртә белән күк йөзендә дә, офык тирәли дә бүрек кадәрле дә болыт әсәре күренми иде. Һава тып-тын, идарә тирәсендәге бакчада урман кебек куе булып үскән өрәңге, каен агачларының бер генә яфрагы да селкенми. Әмма кайбер йортларның морҗаларыннан чыккан төтен туп-туры булып өскә күтәрелми, ә бакчадагы агачларга урала, җиргә елыша. Димәк, һава басымы зур, җилле яңгыр буласы.

Гашикъ Хәмидуллин өстәл өстендәге кәгазьләрне, наряд кенәгәсен тартмага салды да стенадагы барометрга күтәрелеп карады: әйе, басым зур, яңгыр буласы. Аның бу фикеренә кушылып, репродуктор да телгә килде: «Тыңлагыз, Казан сөйли. Бүген 7 сентябрь... Һава торышы белән таныштырабыз... Республикада — кыска вакытлы яшенле яңгыр...»

«Булсын сон,— дип уйлап куйды Гашикъ,— әле яңа гына борын тёрткән сабан игеннәренә дым кирәк. Яусын әйдә...» Ул бүлмә ишеген бикләде дә идарә ишек алдына, рәшәткә буенда торган «Волга»сына юнәлде.

Шоферы Илдуска ул яп биргән иде. Язгы эшләр вакытында көн-төн рульдән төшмәде, яшь кеше, семьясы да бар, өйдә хәл җыйсын, йорт эшләрен дә җайга салсын...

Председатель Гашикъ Хәмидуллин иртәнге нарядтан соң, һәркөнне диярлек, башта җәйләүләрне, фермаларны, аннары басуларны йөреп чыга.

Биш мең ярым гектарга якын җир биләгән Крупская исемендәге колхозга Кече Бакырчы, Югары Балтай, Урта Балтай, Түбән Балтай, Шәмәк авыллары керә. Бу авыллар (Шәмәктән башкалары) Чиремшән елгасы үзәнлегенә, елганың сул ягындагы тауларга сыенып урнашканнар. Җәйге чилләдә тавык тезеннән генә калып, ә язгы ташуда котырып, дулап ага торган Чиремшән буйларында ике кеше колачы җитмәслек юан өянкеләр үсә. Авыллар да яшеллеккә бик мул, калай, шифер түбәләр, җәмәгатьчелек бинаралы, терлекчелек каралтылары тау өстеннән караганда аеруча матур булып күренәләр, мул табигать кочагына урнашкан ял йортларын хәтерләтәләр.

Елга үзәнлекләре киң түгел. Чиремшәннең ике ягында да берсеннән берсе биегрәк калкулыклар, таулар тезелеп киткән. Менә шуңа күрә дә елга яз көннәрендә шулай котырып, дулап ага. Хәер, эш елганың ничек агуында түгел, эш шунда: ул калкулыклар туфракның уңышын күтәрүдә, язгы һәм көзге кыр эшләрен башкаруда зур кыенлыклар тудыралар. Әлбәттә, тигез, киң дапаларда тракторларның, комбайннарның — гомумән, барлык кыр эшләре машиналарының эффекты зуррак...

Гашикъ иң элек урман янындагы җәйләүгә юл тотты. Анда Кече Бакырчы һәм Югары Балтай фермаларындагы сыерларны кул белән түгел, машина белән, «УДС-3» маркалы күчмә саву аппараты белән савуга күчкәннәр иде. Көтү шартларында, җәйләүдә машина белән саву!.. Әле күптән түгел генә (хәтта хәзер дә!) бик күп колхоз, совхоз җитәкчеләре, белгечләре, авыл хуҗалыгы, терлекчелек белән шөгыльләнүче кайбер галимнәр машина белән савуның кимчелекле якларын күпертеп күрсәтергә яратәлар иде. Янәсе, сыерлар сөтләрен киметә, аның өчен махсус биналар, белгечләр, механиклар кирәк һ. б.лар, һ. б.лар. Бәлки, моның сәбәбе элеккеге «Елочка» тибындагы аппаратларның артык катлаулы булуындадыр. Менә бит кыр шартларында да бик уңай машина белән саву. Савучы кызый махсус патроннарны сыер имчәкләренә кидерә дә (бер савучы берьюлы дүрт сыер сава) шланглар буйлап бидоннарга мелт-мелт итеп сөт ага. Кыр шартларында движок, ә фермада электромотор, насослар ярдәмендә трубаларда вакуум (бушлык) булдырыла. Сыерлар исә бик гамьсез кыяфәттә алдындагы азыкны күши биреләр. Артка таба борылып та карамыйлар. Дөрес, моның нәни генә бер кыенлык ягы бар: барлык сыерларның да имчәкләре бер зурлыкта булмый бит, шуңа күрә патроннар төшеп киткәли. Моннан котылуның ике төрле юлы бар: беренчесе — промышленностьтан төрле размердагы патроннар эшләп чыгаруны таләп итү, икенчесе — кечерәк имчәкле сыерларны аерып алып, хәзергә кул белән сава тору.

Әйе, терлекчелек, шул исәптән сөт җитештерү, авыл хуҗалыгының зур тармагы. Терлекчелек хәзер үк инде, бөтен ил буенча, авылда җитештерелә торган продукциянең яртысын диярлек бирә. Ә киләчәктә терлекчелек продуктларын җитештерү тагы да артачак.

Әмма терлекчелек продуктлары җитештерү, галимнәр исәпләп чыгарганча, хәзерге вакытта әле авыл хуҗалыгына тотыла торган хезмәтнең өчтән икесен диярлек таләп итә. Моның сәбәбе шунда: терлекчелектәге бик күп хезмәтләр кул көче белән башкарыла.

Ашлык җитештерүдә: җирне эшкәртү эшләрен дә, чәчүне дә, игеннәрне тәрбияләүне дә, уру-сугуны да, ашлыкны чистарту, калибрлау эшләрен дә — барысын да машина яки электр энергиясе башкара.

Терлекчеләргә хезмәт күрсәтә торган машиналарны да промышленность шактый чыгара. Ләкин эш шунда: алар күп вакытта хәзерге таләпләрне канәгатьләндермиләр яки билгеле бер климат шартларында гына эшләргә яраклы булалар. Шуңа күрә еш кына яңа гына кайтарылган кыйммәтле машиналар эшкә яраксыз тимер өеменә әвереләләр. Экономика фәннәре докторы, Ленинград галиме П. Игнатовский әйткәнчә, сыерлар савуны машинага көйләү темпы хәзергечә барганда, моны якынча гына гамәлгә ашыру өчен дә ун елдан артык вакыт кирәк булачак. Ерак барасы түгел. Менә биредә, Апас районында гына да, машина белән сыер саву бары тик ике колхоз-

—Ленин исемендәге, Крупская исемендәге колхозларда гына — тормышка ашырылган.

Ә бит моның экономик эффекты хәзер үк инде күз алдында. Әйтик, кул белән сауганда бу җәйләүдәге 278 баш сыерга 18 кеше хезмәт күрсәтә иде. Ә хәзер бары 4 кеше. Бу елга 12 мең сум өстәмә файда диган сүз. Машина белән сауганда, кул белән саугандагыга караганда, сөт чистарак та, майлырак та була. Сыерның җилене дә авызлымый, чөнки машина сөтнең тамчысына кадәр суырып бетерә. Ә талган беләкләр белән 15 сыерның имчәк төбе сөтен суырып кара син!..

Кызлар, сыерларны савып бетереп, аппарат җайланмаларын юалар иде инде.

— Машинага өйрәнәләрме инде,— дип сорады председатель, кызларның хәл-әхвәлләрен белешкәч.

— Өйрәнмәгән кая ул — диде Нәзирә исемле кыз.— Гомер буе машина гына саусаң диярсең, бакчи...

Алда — Югары Балтай авылы. Шуның белән горурлана Гашикъ: Крупская исемендәге колхоздагы һәр авыл төзек һәм матур. Һәрберсендә мәктәп, клуб, китапханә, медицина пункты, балалар бакчасы. Ә колхозның үзәге булган Урта Балтайда исә урта мәктәп, участок больницасы, Культура йорты, автомат телефон станциясе, радиоузел, кирпеч заводы һ. б.лар, һ. б.лар. Барысы да колхоз көче белән, колхоз акчасына салынган. Крупская исемендәге колхозда балалар турында туганнан башлап (хәтта тумыштан элек) армиягә яки кияүгә киткәнче (хәтта армиядән кайткач та әле: зурлап каршы алына, һәрберсенә бер юлы 50 сум күләмендә ссуда бирелә, йорт-җир җитештерүгә ярдәм күрсәтелә.) колхоз кайгырта.

Менә Югары Балтай авылында сыерлар абзары салынып ята. Әмма абзар дип буламы соң аны?

Стеналары — кирпеч һәм бетон, тәрәзәләре зур, эче якты, киң, биек. Кыш көне пар белән җылытыла. Сыерлар өчен дүрт йөз аран дүрт рәт булып тезелгән, идәннәре — бетон, вентиляция туктаусыз эшләп тора. Ләкин иң мөһиме шунда: монда барлык эшләрне дә машина башкара, азыкны да машина әзерли, машина тарата, су белән дә машина тәэмин итә, терлек асларын да машина чистарта һәм махсус транспартерлар тиресне махсус урынга чыгара. Сыерларны да инде, әлбәттә, машина сава.

Бинаның уң ягында, нәкъ уртада — ишек. Ул ишектән зур бер коридорга барып керәсең. Сул яктан беренче ишек саву аппаратларын вакуум белән тәэмин итә торган моторлар һәм приборлар урнашкан бүлмәгә алып керә, аннан сөт саклагыч суыткыч, кызыл почмак, ял итү урыны. Уң якта пар казаннары бүлмәсе, душ бүлмәсе...

Техниканың бүгенге казанышлары белән җиһазландырылган сөт фабрикасы ул! Сыер савучыларны да машиналарның, приборларның төгәл эшләвен күзәтүче операторлар дисәк, дөресрәк булыр. Вакытында эшкә киләләр дә, урамга чыга торган киемнәрен салып, сөт кебек ап-ак халатлар киялар. Эшләре беткәч, душ керәләр, юыналар. Фабрика яки завод эшчеләреннән нәрсәләре белән ким?..

Юк, бу хыял түгел. Быел көздән үк биредәге ферма нәкъ шул рәвешчә эшкә башлаячак. Ә хәзергә әле монда кызу төзү эшләре кайный. Стеналары тезелеп беткән, түбәсен шифер белән ябалар, идәнгә бетон түшиләр, араннар ясыйлар, трубалар сузалар. Бу эшләр белән механик Мәхмүт Сәләхов җитәкчелек итә. Әйткәнне көтеп ята торган егет түгел ул Мәхмүт, эшне үзе эзләп таба, идарәгә текъдим белән керә. Әллә ничә мең төрле фикер кайный аның башында. Эшне җиренә җиткереп кенә түгел, үзеннән нинди дә булса яңалык кертеп башкара ул. Ә ул керткән яңалык һәрвакыт файдалы була.

Мәсәлән, күптән түгел шундый хәл булды.

Машина паркы янындагы су башнясы барлык фермаларны да су белән тәэмин итә алмый башлады. Идарәдә фермалар янында артезиан коесы бораулырга, тагын бер башня салырга карар кабул иттеләр. Мәхмүт бу турыдагы фикер алышуларга катнашмады, нәрсәдер уйланып, дәшми генә утырды. Ә иртәгесен, председательгә кадәр үк, ул идарәгә килеп җиткән иде инде.

— Иртәләгәнсең, Мәхмүт, ни булды?

— Бүлмәгезгә кергәч әйтермен, Гашикъ абый, аяк өсте генә сөйли торган сүз түгел.

— Өйләнергә җыенмый торгансыңдыр бит, бакчи — председатель елмаеп, тез

гәүдәле, киң җилкәле егетнең бер караганда, кызларныкы кебек сөйкемле, малаен бер караганда, үзенә буйсынуны таләп итеп, кырысланып китә торган йөзенә карады. Аның куе, саргылт каш аралары җыерылган, зәңгәр күзләре җитди, ирләрчә матур, калын иреннәре кысылган иде.

— Өйләнү качмас, Гашикъ абый. Мәһимрәк тәкъдим бар иде.

Мәхмүтнең тәкъдиме шуннан гыйбарәт булып чыкты: су кудыргыч башняны салмаска, артезиан коесы борауламаска!.. Тау башыннан тегермән кизләве ага, ул ферма янында гына. Кизләү чыганагы турысында чокыр казырга, аның эченә юка бүрәнәләреннән бура бурарга (аның үзенең сере бар!). Кизләү суы башта шул чокыр эченә җыела, аннан трубалар буйлап фермаларга агып төшә. Бернинди насос, электр көче кирәкми. Шунысы да бар: ике километр трубаларга экономия, ике километр траншея казыйсы хезмәткә экономия.

— Кое казуга, башня салуга китәсе акчаны, Гашикъ абый, урамнарга, колхозчы йортларына су үткәрү өчен тотыйк,— аның тавышында үз фикеренә нык ышанганлык та, бер үк вакытта үтенеч тә сизелә иде.— Мин исәпләп чыгардым: су фермага гына түгел, авылның барлык урамнарына үз агымы белән барып җитәчәк, бернинди насос кирәкми. Менә бу схемага, саннарга игътибар итегез...

Председательнең каратут йөзле кешеләрдә генә була торган чия кебек алсу иреннәре елмайгандай итте. Минем тәкъдимне санга сукмыйча көлә инде ул, дип уйлап куйды Мәхмүт һәм үз фикерен яклап тагын бер мәртәбә дәлилләрен кабатларга әзерләнде. Гашикъ башын өстәл өстендәге кәгазьләрдән күтәреп, күзләрен Мәхмүткә текәде. Аның коңгырт-кара күзләре, калын кашлары астыннан аталарча якын итеп, үз итеп карыйлар иде.

— Син нәрсә аяк өстендә торасың, Мәхмүт. Өйдә утыр бирегә, диванга,— һәм ул үзе дә өстәл яныннан торып, диванга барып утырды, уң кулын Мәхмүт җилкәсенә салды.— Чокыр бурасын юка бүрәнәдән бурыйк дисең инде син, кизләү суының тәме китмәсен, саф булып колхозчы йортларына барып җитсен, дисең. Изге күңелле егет син, Мәхмүт... Ә мин урамнарга колонкалар утыртырга, колхозчы йортларына су кертергә быел кул җитмәс, дип уйлаган идем, ни дисәң дә, бер быел гына да утыз объектта төзү эшләре алып барабыз бит. Рәхмәт сиңа, ярдәм кирәк булса, туп-туры үземә кил... Ә укулар ничек бара?

— Киләсе елга дәүләт имтиханнарын бирәсе.

— Димәк, дипломлы механик буласың, аннан инженер...

— Мин җирне яратам, Гашикъ абый, агрономическийга керергә исәп.

— Бик әйбәт. Механика белән агрономия бер-берсенә каршы килми алар...

...Гашикъ шул вакыйганы исенә төшереп елмаеп куйды.

Гашикъның күз алдында үсте Мәхмүт. Кече Бакырчыдан Урта Балтайга йөреп сигезне бетерде. Колхозда эшләде. Армияга китте. Германиядә танкист булып хезмәт итеп кайту белән, тракторга утырды. Ике ел аның рәсеме Апас районы Почет тактасыннан төшмәде. ВЛКСМның өлкә комитеты Мәхмүтне, колхоз кырларында ирешкән уңышлары өчен, Венгриягә туристик сәяхәткә путевка белән бүләкләде. Анда да ул күбрәк авыл хуҗалыгы белән танышып йөргән.

— Венгр дусларыбыз «СК-4» комбайнын мактап бетерә алмыйлар,— диде ул, үзенең сәяхәте турында колхоздашларына отчет биргәндә.— Аны бүтән илләрнең комбайннарына караганда ике-өч мәртәбә озагракка чыдый һәм эш нәтиҗәсе дә яхшырак, диләр...

Менә хәзер Чистай авыл хуҗалыгын механикалаштыру техникумының 5 курсы студенты, егерме биш яшьлек коммунист Мәхмүт Сәләхов терлекчелек буенча механик, колхозда техника куркынычсызлыгы буенча инженер.

...Әнә ул стена буенда идәнгә чүмәшкән дә, алдындагы зур гына битле кәгазьгә бармагы белән төртеп, янындагы төзү бригадасы бригадиры һәм слесарьларга нәрсәдер аңлата.

— Исәнлекме, егетләр...

Председатель барысы белән дә кул биреп исәнләште.

— Менә, Гашикъ абый, сез ничек уйлыйсыз,— дип сүз башлады Мәхмүт һәм яңадан идәндә яткан сызымлы кәгазьгә иелде,— минемчә, анкерный блокларны проекттагыга караганда зуррак итәргә һәм аны тирәнгәрәк беркетергә кирәк. Ник

сәгез, Шәмәктә дуңгызлар абзарында проект буенча эшләгән идек, бик тиз сафтан ікты. Булгач булгач, нык булсын... Аннары тирес чыгару транспартеры планкарын алыштырсак әйбәт булыр иде. Нарат урынына имәнне. Эше шактый шактаен, әкин ел саен алыштырасы булмый.

— Хуплыйм. Ничә планка кирәклеген, озынлыгын-киңлеген әйтеп, агач цехына каз бир. Хәзер кая барасың?

— Урта Балтайга. Анда Нәбиулла траншеяларга труба суза бит. Ничек бара икән нда эшләр?

— Әйдә утыр алайса, илтеп куям.

— Минем «кәҗә тәкәсе» бар. Аны калдырып булмый бит,— диде Мәхмүт, якында ына торган «Иж» маркалы мотоциклны күрсәтеп, һәм кульяулыгын алып, тиргә аткан тирен сөртеп алды.— Ай-һай бөркү бүген, ахры, яңгыр булыр.

— Радиодан «яудырабыз», диделәр...

Гашикъ «Волга»га утырды, Мәхмүт мотоциклына атланды. Тиздән алар, берсе басу гына, икенчесе Урта Балтайга таба китеп, күздән югалдылар...

Быел яз соңарак килде. Башка елларда инде кыр эшләре беткән вакытта гына әчүгә чыктылар быел. Эшне кыска тоттылар һәм җиренә җиткереп башкардылар. Механизаторлар көнен дә, төнен дә кырда булды. Менә аларның эш нәтиҗәләре: табан игеннәренең нәни үсентеләре нәфис хәтфә кебек басу өстен каплап алган. өтен тирә як — ямь-яшел. Барлык орлыклар да бердәм тишелеп чыккан. Гашикъ машинасын туктатты, моторны сүндерде. Бөтен кыр тынып калды, бары тик күктә очынып-очынып тургайлар сайрый. Биектә-биектә тилгән оча. Кинәт тилгән канатларын еш-еш кага башлады, урман ягына борылды да күздән югалды. Тургайлар да, нәрсәдер котеп, тынып калдылар. Кинәт яшь үсентеләр җиргә егылды — кисәк көчле җил исеп куйды. Гашикъ артына борылып карады: оһо! көньяк-көнчыгыш яктан аралып болыт килә. Җил көчәйгәннән көчәйде, менә инде кояш та болыт астында калды, җир өсте караңгыланып китте. Гашикъны ниндидер шомлы, хәвефле хис биләп алды, тиз генә машинасына кереп утырды да ашыга-ашыга моторны кабызырга керешге, үч иткәндәй мотор эшләргә теләмәде, бер-ике мәртәбә төчкерде дә тынды. Ул арада булмады, чиләкләп яңгыр коярга тотынды. Ике-өч метр арада берни күрерлек түгел иде — тоташ ап-ак стена. Туктаусыз яшен яшьни, күк күкри. «Яшен сукмасын тагын»,— дип, Гашикъ машинаны кабызу уен ташлады. Кинәт, вак таш сипкәндәй, кабина өсте дөбердәргә кереште, Гашикъның чәчләре үрә торды: димәк, боз ява. Дөбердәү тавышы ешайганнан ешайды. Гашикъ, рычагны борып, кабина тәрәзәсен ачты — юл өсте, машинаның бөтен тирә-ягы ап-ак боз белән капланган иде. Күз аллары караңгыланып китте, сулыш алу кыенлашты. Машинасыннан чыкты да, ишекне дә ябып тормастан, яңгыр катыш боз астында, ботинкалары белән үзле балчык ера-ера, авылга таба атлады. Ул авылга кайтып җиткәнче, яңгыр бер явып үтте дә тагын кире әйләнеп яварга кереште. Әле генә ямь-яшел басулар өсте, күптән түгел генә сөрелгән кебек, кап-кара булып калган иде.

Гашикъ тәмам хәлдән тайды, сулышы капты, йөрәге еш-еш типте, башы чатнады. Өч басмалы баскычтан менәрлек тә хәле юк иде, рәшәткәгә сөялеп хәл җыйды. «Кеше күреп, көпә-көндез, шундый хәвефле вакытта исереп йөри, дип уйламасыннар тагы»,— дип, артына әйләнеп карады да, тезенә кадәр пычракка буялган чалбарларын да чистартып тормастан, коридор буйлап бүлмәсенә юнәлде. Керү белән телефонга ябышты.

— Өченче бригада кирәк... Сездә ничә гектар?.. Әллә йокыдан яңа гына тордыңмы, төнлә туган... Ничә гектарны боз сукты дим... Биш йөздән артык дисеңме?..

Икенче бригадада да алты йөз гектар чамасы иде. Иң күп зыян күргәне беренче бригада булып чыкты: анда җиде йөз гектарга якын язгы һәм көзге бодай, борчак, арпа басулары әле генә явып киткән боздан зыян күргән иде.

— Мең сигез йөз гектар!

Күз алдына китерү дә кыен. Дөрес, страховой акчасын түләрләр, ләкин эш андамени?..

* * *

Әйе, эш андамени?..

...Борын-борыннан Урта Балтай крестьяннары җирдән рәхәт күрмәгән. Бернинди агротехниканы, чәчү әйләнешен белмәгәннәр. Җитмәсә, ел саен ясмык чәчеп, җирне тәмам җимен суырып бетергәннәр. Җирдән игелек күрмәгән авыл кешеләре төркемләп-төркемләп читкә, зимагурлыкка киткәннәр, кустарь һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр: агачтан кашык, чүмеч, бал савыты, куас чиләге кебек көнкүреш әйберләре ясап сатканнар...

Әллә ни ерак заманнарны искә төшерәсе юк, әле моннан унбиш еллар гына элек, Гашикъ Хәмидуллин председатель булып сайланган елларда гына да, уңыш гектарыннан уртача биш-алты центнердан артмый иде. Ә 1957 елда гектарыннан бары тик 3,3 центнер уңыш чыкты. Шуннан артык көтәрлек тә түгел иде, чөнки җир инде кешегә бирәсен биреп бетергән, хәзер үзе азык таләп итә, үзенә карата гаять сак караш таләп итә иде. Кеше җир каршында муенга кадәр бурычка баткан иде. Җитмәсә, Крупская исемендәге колхоз кырлары тигез басу түгел, кая карамә — калкулык, тау. Тау, сөзәк калкулык битләрендә, итәкләрендә уңдырышсыз әрләнә туфрак, язгы сулар белән юылып, җир өстенә үк бәреп чыккан. Алар өстенә культуралы катлам кундырырга кирәк иде. Кыскасы, җир тире белән сөяккә генә калган, хәлсез, авыру җан иясен хәтерләтә иде. Барлык колхозчыларга, механизаторларга, белгечләргә, идарәгә, председательнең үзенә ай-һай кыенга килде ул хәлсез сөякләргә ит кундыру. Идарә карары нигезендә махсус җирне ашлау бригадасы булдырылды. Аның бригадиры Вәгыйз Вафинга бернинди нарядсыз-нисез барлык төр транспорттан файдалану хокукы бирелде. Органик һәм минераль ашламалар чыгару елдан-ел арта барды. Язгы ташу вакытында барлыкка килеп, елдан-ел зурая барган ерганаклар читәннәр белән буылды. Механизаторларның да җиргә карашы үзгәрде. Эш нәтиҗәләрен даими тикшереп тору, материаль кызыксындыру чараларын куллану үзенекен итте — механизаторлар «көн узсынга» түгел, булсын дип эшләргә керештеләр, гектар санын куу бетте, эшнең сыйфаты беренче урынга чыкты.

Шулай итеп, туфракның культуралы катламы калыная барды. Кешеләр, үзләренең җир каршындагы гаепләрен аңлап, аны фән кушканча эшкәртергә керештеләр. Ләкин моның өчен күп белергә, укырга, өйрәнергә кирәк иде. Кешеләр дәреслекләргә ябыштылар, читтән торып техникумнарда, институтларда укырга керештеләр. Председатель үзе, эшем болай да тыгыз, дип тормады, Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетын тәмамлады һәм алай гына да түгел, үзенең әллә ничә еллар дәвамында күзәтүләрен, тикшеренүләрен фәнни тәртипкә китереп, фәннәр кандидаты исеме алу өчен диссертация әзерләде...

Җир игелекле ул, юмарт ул, үзенә күрсәткән тәрбиянең кадерен бик белә. 1969 елда дүрт мең биш йөз гектардан артык җирнең һәр гектары 22 центнерга якын уңыш бирде. Ә тәҗрибә өчен 300 гектарга чәчелгән «Мироновка — 808» сортлы көзге бодайдан гектарга 40 центнерга якын, «Казанская — 38» сортлы борчактан 35 центнер уңыш алынды.

Әйе, уңышны күтәрүдә сортларны яхшыртуның әһәмияте гаять зур. Ләкин, ни генә әйтсәң дә, уңыш алуның чикләнмәгән резервлары җирне фән кушканча эшкәртүдә, аны мул итеп ашлама кертүдә. Гашикъ фикеренчә, җирне эшкәртү — уңыш күтәрүнең базасы булса, орлыкларның сортларын яхшырту өскорма. Җиренә җиткереп эшкәртелгән, тиешенчә ашлама кертелгән туфракка төшкән яхшы сортлы орлык кына күтелгән, хәтта көтелгәннән дә артыграк уңыш бирә ала.

Илебез колхозларындагы алдынгы тәҗрибәгә таянып, Крупская исемендәге колхоз игенчеләре, җирне фән кушканча эшкәртү нәтиҗәсендә, соңгы ун ел эчендә уңыш алуны ике-өч мәртәбәгә арттырдылар. Туңга сөрү, мәсәлән, аларда бары тик 27—30 сантиметр тирәнлектә башкарыла. Димәк, туфракның культуралы катламы хәзер шул калынлыкта. Зур казаныш бу! Әле кайчан гына 18—20 сантиметр тирәнлектә сөргәндә дә гомердә кояш нуры күрмәгән уңдырышсыз әрләнә туфрак каерылып өскә чыга иде.

Менә шуңа күрә дә, Апас районы җитәкчеләре ел саен туңга сөрү чорында җир эшкәртү буенча район семинарын Крупская исемендәге колхозда оештыралар. Монда

лхоз председательләре, авыл Советы председательләре, партоешма секретарьлары, рономнар чакырыла. Алар барысы да Крупская исемендәге колхоз механизаторланың тәҗрибәсен өйрәнәләр. Әмма шулай да алар үрнәгендә эшләүче колхозлар үп түгел әле. Мисал өчен күршедәге Вахитов исемендәге колхозны гына алырга була. ер үк шартлар, бер үк төрле туфрак. Ә аларда уңыш ел саен Крупская исемендәге олхозга караганда ике мәртәбә кимрәк алына. Сәбәбе бары тик шуңа кайтып кала: ларда җир эшкәртүгә, аңа ашлама кертүгә мондагы кебек итеп игътибар бирмиләр.

...Ә быел нәрсә булыр?..

— Мең сигез йөз гектар...

Әйтергә генә ансат: никадәр кешенең ничә еллык хезмәте җилгә очты, никадәр ича җилгә очты. Дөрес, республикадан инспекторлар килерләр дә акт төзерләр, траховой акчасын түләрләр... И-их, эш анда түгел бит! Кул кушарып, инспекторлар илгәнне көтеп утырыргамы? Берәр чарасы юкмы икән?..

Шул вакыт идарә алдына ниндидер бер машина килеп туктады. Коридорда салмак кына атлап килгән аяк тавышлары ишетелде.

— Председатель мондамы?

Таныш тавыш. Гашикъ тиз генә торып, бүлмә ишеген киң итеп ачып җибәрде.

— Монда, монда, Гурий вичче, әйдә түрдән уз.

Илле биш — алтмыш яшьләрендәге, таза гәүдәле, киң җилкәле, битен вак җыерчыклар баскан бу кеше — күрше Чувашстан республикасының Кече Яльчик колхозы председателе Гурий Васильевич иде.

Гурий Васильевич диванга җәелеп утырды да зәңгәр күзләрен Гашикъка текәде.

— Ну, председатель юлташ, ни хәлләрең бар?

— Хәлләр бик шәп түгел шул әле, Гурий Васильевич.

— Ишеттем, ишеттем. Кайгыңны уртаклашырга килдем. Ни кылмак буласың?..

— Шул турыда баш ватам. Ни эшләргә дә белгән юк.

— Пирешмә, дускай. Палтаң суга төшмәсен. Чара юк түгел.

— Нишләргә соң, Гурий вичче?

Гурий Васильевич диваннан торды да өстәл янына килеп утырды. Аннары, ниндидер зур сер сөйләргә җыенгандай, Гашикъка таба сузылды:

— Нишләргәме? Кул кушырып утырмаска. Бароновать кирәк. Бүген үк, иртәгә соң була.

— Файдасы булырмы, Гурий Васильевич?

— Булыр. Соңга калмасаң.

— Гаепләмә, Гурий Васильевич, син утырып тор. Мин хәзер радиоузелга...

Радиода музыка тынып калды, Гашикъ тавышы колхозның биш авылындагы барлык өйләргә таралды:

«Барлык тракторчылар, бригадирлар, бригаданың партия оешмасы секретаре, идарә членнары игътибарына.

Ярты сәгатьтән чираттан тыш идарә утырышына килеп җитүегез сорала.

Көн тәртибе: ашыгыч мәсьәлә.»

Бу белдерүне Гашикъ өч-дүрт мәртәбә кабатлады...

Гурий Васильевич белән Гашикъ идарә бинасы алдына чыктылар. Күк йөзендә болытның әсәре дә юк иде инде. Күптән түгел генә яңгыр булганын, боз яуганын уйсу урыннардагы күлләвекләрдән, юлдагы пычрактан гына белергә була иде. Элеккечә үк кояш кыздыра, җир өстеннән кое булып пар күтәрелә. Һавада элеккечә үк тургайлар сайрый, Чиремшән елгасы буендагы тирәктән күке кычкыра, идарә бакчасында сыерчык балалары чыркылдаша.

— Юлташ, хуҗа кешегә болай йөрү килешми,— Гурий Васильевич Гашикъның пычракка баткан чалбар балакларына, ботинкасына күрсәтте.— Утыр «Газикъка, өеңә илтеп куям, киемеңне алыштыр.

— Әйдә, Гурий вичче, кешеләр җыелганчы капкалап та алырбыз...

* * *

...Мин Крупская исемендәге колхозга сентябрь башында килдем. Август азагына таба, сентябрь башында яңгырлар ешайды. Бер-ике көн тоташ яңгыр ява да тагын

ике-өч көн кояш көлә. Җир өсте кибеп, җиңнәр сызганып эшкә тотынгач кына, ул тагын явып китә.

Дөрес, урып-җыю эшләре нигездә тәмамланган иде инде. Бары тик ике йөз гектарлап бодай һәм аннары кара бодай, тары кебек соңгы культуралар гына сабакта калган иде. Бәрәңгегә, чөгендергә әле иртәрәк — тамыр азык культуралары көннәр кыскарып, төннәр озая башлагач нык үсә бит ул.

Бу тынгысыз көннәрдә председательне идарәдә очратуы кыен. Ул, иртән иртүк радио буенча наряд бирә дә, бригадаларга чыгып китә. Эзләп Шәмәккә барасың — Кече Бакырчыга китте, диләр. Ә аннан Югары Балтайга киткән булып чыга.

Без, партком секретаре Хәйдәр Гатин белән, ындыр табагына киттек.

Кичә көне буе яңгыр яуган иде — юл аяк басарлык түгел, пычрак. Чирәмлерәк җиргә басарга тырышып, сөзәк калкулыкка күтәреләбез.

Хәйдәр читтән торып Казан университетының тарих бүлегендә укыган, җиде ел Урта Балтай урта мәктәбендә завуч булып эшләгән. Менә быел аны колхоз парткомы секретаре итеп сайлап куйганнар.

Колхозда 500 гә якын хезмәткә яраклы кешенең йөзе коммунист. Аларның барысы да хезмәтнең алгы сызыгында: механизатор, терлекче, төзүче.

Хәйдәр яңа секретарь. Шулай да аңа колхоздагы эшләр, кешеләр, аларның тормышы һәм эшләре яхшы таныш. Хәер, башкача булуы да мөмкин түгел, ул ничә еллар шушы авылда яшәгән, шушы колхозның партия оешмасында торган.

Менә ындыр табагы. Урып-җыю эшләре тәмамланмаган булса да, биредә ыгы-зыгы юк. Әйе, әллә кайдан күренеп тора, тир түгеп үстергән ашлыкның кадерен беләләр монда: ачык урында яңгыр астына бер генә бөртек ашлык та калдырылмаган. Кырдан кайтканын шундук эшкәртеп, калибрлап амбарларга озатып баралар икән. Әлбәттә, бу эшне кул көче белән генә шулай тиз башкару мөмкин түгел. Машиналар, электр энергиясе, моторлар башкара аны. Ә бу машиналарга хезмәт күрсәтүчеләр бармак белән генә санарлык. Хәйдәр менә шундыйларның икесе — ирле-хатынлы Рәхилә һәм Шәриф Хәбибуллиннар белән таныштырды. Рәхилә — учетчик, ындырдагы бәрлык иген аның җаваплылыгында. Ире Шәриф — «ОВП-20» машинасы белән идарә итә. Сәгатенә 20 центнер ашлык эшкәртә бу машина. Машинаның маңгаена унҗиде йолдыз төшерелгән. Мин Хәйдәрдән ул йолдызларның мәгънәсен сорадым.

Хәйдәр өчен Рәхилә җавап бирде:

— Мең гектар чыгарган саен, бер йолдыз төшереп куябыз,— диде ул.

Әйе, хәзер колхозлардагы кыр эшләрен, урып-җыю эшләрен крестьян хезмәте дип күз алдына китерү чынбарлыкка бик үк туры да килми. Чын-чынлап индустриаль хезмәт ул: җирне трактор эшкәртә, трактор чәчә, трактор үсентеләрне тәрбияли, комбайн өлгергән ашлыкны тезмнәргә сала, җыеп суга; ә суктырылган ашлыкны машиналар ындыр табагына ташый, җитез транспортерлар буйлап ул «ОВП» бункерына ага, аннан чистарып чыкканын да транспортер көтеп тора...

Тигез ритм белән дәвам итә торган бу хезмәт процессы завод яки фабрика производствосыннан нәрсәсе белән аерыла!

Колхоз кешеләре өчен бу бик гади күренеш. Бу табигый дә, хәзерге заманда башкача булуы мөмкин түгел...

Мин шулар турында Хәйдәргә сөйлим. Хәйдәр хәйләкәр генә елмая да:

— Әйдә машина паркына да кереп чыгыйк,— ди.

Машина паркы якында гына. Нинди генә машиналар юк анда! Әмма без алар янында тукталып тормыйбыз, озынча итеп кирпечтән салынган зур гына бер бинага керәбез. Монда инде чын-чынлап завод: тимер чыңы, станоклар гөрелтесе... Мастерскойлар икән биредә.

Иң башлап Хәйдәр мине тимерче Зөфәр Хәйбуллин белән таныштырды. Хәйдәр яшүсмерләр сыман оялып кына исәнләште дә, кызган тимерне тискага кыстырып, эшен дәвам итте.

Утыз яшьләр тирәсе аңа. Монда ун классны бетергәч эшли башлаган. КПСС члены. Хәзер рәсеме — район Почет тактасында.

Ә Габделхак Биктимировны колхозда «алтын куллы токарь» дип йөртәләр. Ул токарь станоклары белән дә, вертикаль һәм горизонталь фрезерь станоклары белән дә бик оста эш итә.

Нәбиулла Нигъмәтуллин исә — бишенче разрядлы сварщик. Автоген белән дә, электр белән дә теләсә нинди тимерне бер-берсенә мәңге купмаслык итеп ябыштыра. Бик кирәкле кеше ул колхоз өчен. Ә хатыны Илсөя — өченче разрядлы маляр.

Крупская исемендәге колхозда мондый индустриаль хезмәт һөнәренә ия булган кешеләр күп. Техника үскән саен белгечләр, махсус һөнәр ияләре тагы да күбрәк кирәк булачак. Менә шуңа күрә дә хәзер 15 кеше колхоз стипендиясе белән төрле уку йортларында белем ала...

Әйе, хәзер колхоздагы эшләрне машиналардан башка, техника куәтеннән башка күз алдына да китереп булмый. Крупская исемендәге колхозда, мәсәлән, хезмәткә яраклы һәр кешегә уртача унике ат көченә тиң машина егәрлеге туры килә.

Күпме бу, азмы?

Бер кешегә унике ат! Семьяда хезмәткә яраклы бер генә кеше түгел бит. Димәк, кайбер семьяларга бер кәтү ат туры килә дигән сүз.

Ләкин шулай да колхозчы хезмәтен машина көче белән коралландыру хәзергә әле тормыш таләпләренә җавап бирел бетерми. Шунлыктан уңыш алу да еш кына елның ничек килүенә бәйле.

Менә ни өчен КПССның июль Пленумы колхозларны һәм совхозларны хәзерге заман машина техникасы белән тизләтелгән темпта тәэмин итү бурычын куйды. Пленум киләсе бишьеллыкта тракторлар, авыл хуҗалыгы һәм мелиорация машиналарын, транспорт машиналарын, аларга запас частьлар эшләп чыгаруны бик күпкә арттырырга кирәк дип тапты...

...Крупская исемендәге колхоз председателе Гашикъ Хәмидуллин ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп, үз-үзе белән хозурлана торган кеше түгел. Ул киләчәккә карап эш итә. Мәсәлән, әле урып-җыю тәмамланып җитмәгән, алда авыр хезмәт таләп итә торган эшләр — бәрәңге һәм шикәр чөгендере алу тора. Ә кичә идарә утырышына көн тәртибе итеп ул терлекчелектә хезмәт бүленешен камилләштерү мәсьәләсен куйды. Чыннан да сыер савучы хатын-кызлар сыерларны сава да, асларын да чистарта, азыгын да ташый. Мондый хезмәт ирләр өчен дә бик авыр. Менә хәзер савучылар сыерларны тәрбияләү, аларны саву өчен генә җаваплы, ә ашату, аларның асларын чистарту эшен башкалар эшләр. Мондый бүленеш, икенче яктан, сөт алуны арттыруны да стимуллаштырачак.

— Җитмешенче еллар авыл хуҗалыгында зур сикереш чоры булачак,— диде Гашикъ, идарәдә икәүдән-икәү калып шулай бер сөйләшеп утырганда.— Шунсыз мөмкин дә түгел; халык саны арта, шәһәрләр үсә, яңадан-яңа калалар барлыкка килә. Тагын шунысы: халык куллана торган товарларның 75 проценты авыл хуҗалыгы чималыннан эшләнә. Шуңа күрә хәзерге чорда авыл хуҗалыгын тиз күтәрү беренче чиратта торган мөһим бурычларның берсе. Ләкин моның өчен нык база, нигез булырга тиеш. Райондагы кайбер колхоз житәкчеләре: «Продукция алу буенча саннарың әйбәт, нигә соң банктагы счетыңда акчаң такыррак»,— диләр. Байлыкны банктагы акча гына күрсәтми. Ул акчаны киләчәк өчен файдалана белергә кирәк. Киләчәк үсеш өчен нык нигез булдыруны акча тотмый гына башкару мөмкин түгел ул.

Әйе, Түбән Балтайдагы сыерлар фермасы — хәзерге заман авыл хуҗалыгы техникасындагы барлык казанышлар белән җиһазландырылган ферма — акча тотмый гына юк җирдән калкып чыкмый, Мәскәү өлкәсеннән кайтарылган «Холмогор» нәселле ике йөз баш сыерны акчасыз гына бирмәгәннәр, «Украина» нәселле ак, эре дуңгызлар да күктән пәйда булмаган, «Прикс» токымлы сарыклар да үзләреннән-үзләре килмәгән.

Хәзер колхозда бары тик сортлы орлыклар гына чәчелә: «Саратовская-29» сортлы сабан бодае, «Мироновская-808» сортлы көзге бодай, «Казанская-38» сортлы борчак, «Льговская» сортлы вика, «Шатиловская» сортлы карабодай, «Казанская» сортлы арыш... Тәҗрибә станцияләреннән яңа сортлы орлыклар кайтару, аларны барлык майданга җитәрлек итеп үрчетү өчен акча кирәк бит.

Ә культура-көнкүреш биналары: клублар, мәктәпләр, медицина пунктлары, тегү мастерское, балалар бакчалары, парикмахерская, гостиницасы булган көнкүреш комбинаты, радиоузел, автомат телефон станциясе. Алар барысы да колхоз хисабына булдырылды.

Терлекләрне культуралы көтүлекләр белән тәэмин итү өчен сугару җайланмалары, насос станциясе төзү өчен дә акча тотылмады түгел. Чиремшән, Бола елгалары буендагы үзәнлекләрдә 150 гектарга якын мәйдан киләсе җәйдән даими сугарылып торачак...

Крупская исемендәге колхозның киләчәктәге уңышлары өчен нык нигез булачак чаралар нәкъ әнә шулар инде. Юк, алар гына түгел икән әле.

...Керсәң адашырлык урман кебек булып үскән кукуруз һәм киндер басуларын карап кайта идек. Юлның сул ягындагы инде икенче кат чабарлык булган люцерна басуы янында Гашикъ шоферы Илдуска машинаны туктатырга кушты.

— Әнә күрәсеңме,— диде ул, басу өстенә күрсәтеп,— люцерна бер урында ямь-яшел, ә тегендәрәк саргылт төстә. Нәрсәдән икәнне беләсеңме? Туфрак бер төрле түгел, ниндидер минераллар җитешми. Без аны өйрәнергә, белергә тиеш...

Идарәгә җитәрәк, әле нигезе генә салынган бер төзелеш янында янә туктадык. Гашикъ әлеге сүзен дәвам итте:

— Менә монда туфракның составын өйрәнәчәкбез инде,— диде.— Агрохимия лабораториясе булачак бу бина. Менә монда лаборантлар эшләячәк. Монда зал, ә бу тештә булачак бүлмәдә үзем фәнни эш белән шөгыльләнергә уйлыйм...

Мин председательнең берничә еллар дәвамында фәнни эш белән шөгыльләнүе һәм үзенең күзәтүләрен гомумиләштереп «Апас районы шартларында сабан бодаен игү агротехникасының кайбер чаралары» диген темага диссертация әзерләгәнә һәм озакламый яклаячагы турында ишеткән идем инде. Шуңа күрә аның бу сүзләренә гаҗәпләнмәдем. Чыннан да туфракның уңыш бирү сәләтен үстерүне, авыл хуҗалыгының һәр тармагыннан продукция алуны арттыруны фәнгә, фәннең бүгенге казанышларына таянып эш кылмыйча гамәлгә ашыру мөмкин түгел. Шуңа күрә практик эш кешеләренең фәнни хезмәт белән шөгыльләнүләре һәм хәтта гыйльми ачыш ясаулары да бик табигый хәл. Кем белә, берничә елдан биредә, Крупская исемендәге колхозда фәнни-тикшеренү институтының филиалы ачылса да гаҗәп түгел. Бу хәзерге хәлнең логик дәвамы гына булачак... Бу уемны председательгә белдерергә базмадым, әллә кайчаннан күңелне кытыклап торган соравымны бирдем:

— Гурий Васильевичның киңәше файда бирдеме соң?

Гашикъның йөзе балкып китте.

— Бик вакытлы киңәш булды ул,— диде председатель, елмаеп.— Барлык тракторларны эшкә җиктек, ике көн эчендә боз суккан җирләрне тырмалап бетердек. Тагын ике-өч көннән басулар кабат яшелләнде. Менә хәзер нәтиҗә шул: быел һәр гектар җир унсигезәр центнер уңыш бирде. Районда без, уңыш алу буенча Ленин колхозыннан кала, икенче урында...

Альберт Мөслимов

# 3309 НОМЕРЛЫ МАНДАТ ИЯСЕ



„Ватан куркыныч астында!» — Бу сугышчан чакыру 1919 елны бөтен ил буйлап яңгырый.

Яшь совет республикасын контрреволюция һәм чит ил интервентлары боҗра эченә алганнар. Үзен Себер хакиме дип игълан иткән Колчак Иделгә омтыла. Аның гаскәрләре инде Кама елгасына җитеп, Чистайга якынлашып килә. Владимир Ильич, борчылып, бу көннәрдә Э. М. Склянскийга болай дип яза:

«Сезгә: 1. Чистайга ашыгыч ярдәм итү турында бүген Көнчыгыш фронтының Революцион Хәрби Советына һәм 6 нчы армиягә телеграммалар җибәрергә;

2. Үзегезгә бүген туры үткәргеч аша Көнчыгыш фронт белән сөйләшергә.

Хәзер үк Гусевка телеграмма язсагыз, яхшы булыр.

Рудзутак белән сөйләштегезме!»[1]

Шунда ук Владимир Ильич үзе дә Республиканың Революцион Хәрби Советы члены В. И. Гусевка түбәндәге телеграмманы җибәрә:

«Чистайга ярдәм итү буенча ашыгыч чаралар күрергә кирәк. Сез тиешенчә игътибар юнәлттегезме моңа! Барлык мөмкинлекләрне файдаландыгызмы! Телеграмма җибәрегез.

Ленин»[2]

Чистайда бу вакытта большевиклар җитәкчелегендә революцион Комитет оештырыла, иреклеләрдән отрядлар төзелә. Бөтен көчләр дошманны тоткарлауга һәм шәһәрдән гаять зур әһәмияткә ия булган байлыкларны: машиналарны, икмәкне, нефтьне һ. б. ларны алып чыгу өчен җигелә. Бу җаваплы бурыч елга эшчеләренә һәм хезмәткәрләренә йөкләтелә. Ә затонда, өсте боз белән капланган суда, ул вакытта 27 пар белән йөри торган, 88 буксир белән йөзә торган суднолар тора. Алар, Кама боздан чистарганчы, ремонтка тукталган булалар.

Шушы гаять киеренке моментта Казанның Идел районы коммунистлары түбәндәге резолюцияне һәм барлык елгачыларга мөрәҗәгатьне кабул итәләр:

«Пролетариат республикасы куйган бурычларны истә тотып, ачлыктан интегүче үзенне һәм безнең барлык фронтлардагы Кызыл сугышчыларны тәэмин итү өчен, нинчек кенә булмасын, навигация ачылуга Казан районында Совет республикасы флотын

[1] В. И. Ленин. Хәрби язмалар (1917—1920). Рус телендә. М., 1957. 114 бит.

[2] Шунда ук, 114 бит.

әзерләп өлгертергә! Нинди генә кыенлыкларга карамастан, безгә йөкләнгән бурычның үтәлесенә тантаналы төстә вәгъдә бирәбез...

Без ышанабыз: бу язны пролетариат, үзенең сөялле куллары белән, Колчакның муенын борып ташлар.

Яшәсен дөнья революциясе юлбашчысы Ленин! [1]»

Менә шундый борчулы көннәрнең берсендә Чистайга бер кеше килеп җитә, ә аның кесәсендә — В. И. Ленин кул куйган 3309 номерлы мандат.

«Моны күрсәтүче иптәш Гаврилов,— диелгән була анда,— пар белән һәм парсыз йөри торган барлык флотны Чистай шәһәреннән һәм аның тирәсеннән Казанга китерү өчен җибәрелә.

Әгәр хәрби шартлар нәтиҗәсендә флотны алып китү эшен уңышлы башкару мөмкин булмаса, иптәш Гавриловка пар белән һәм парсыз йөзә торган флотны, барлык төрле юллар белән, бөтенләй юк итүгә кадәр хокук бирелә.

Барлык учреждениеләргә, оешмаларга, губерна Башкарма Комитетларына, шәһәр Башкарма Комитетларына иптәш Гавриловның барлык боерыкларын кичегүсез үтәргә тәкъдим ителә.

Иптәш Гавриловның боерыкларын үтәмәгән яки аңа йөкләнгән гаять әһәмиятле бурычларны уңышлы рәвештә тормышка ашыруга комачаулык иткән һәркем Хәрби-Революцион Трибунал судына бирелергә тиеш.

Эшче-крестьян оборонасы председателе — В. Ульянов (Ленин)

Оборона Советы члены — Э. Склянский

Секретарь — М. Гляссер [2].»

Ниһаять, көннәр җылыта. Кар сулары Камага таба юл яра. Яңа гына Чистайга килеп төшкән Иван Тимофеевич Гаврилов яр буена ашыга.

Затонда су өстен боз өемнәре каплаган. Пароход түгел, көймә дә йөзәрлек түгел.

Яр буенда, тәмәкеләрен көйрәтеп, елгачылар утыра.

— Нәрсә борын салындырдыгыз, егетләр,— ди Гаврилов, алар янына килеп җиткәч.

— Күрмисезмени! — дип җавап кайтара өлкән яшьләрдәге бер елгачы, Кама өстенә күрсәтеп.

— Күрәм, күрәм. Шулай да борын салындырырга кирәкми. Исемең ничек синең!

— Степан. Атам буенча Андреич...

— Күптән йөзәсеңме инде!

— Егерме биш елдан артык.

— Менә шулай, Степан Андреевич, елгачыларга, яр буенда утырып, һава яхшырганны көтү килешми. Барысын да палубага чакырыгыз.

Берничә минуттан йөзләп кеше палубага җыела. Барысы да күңел биреп Гавриловны тыңлый, ә ул судноларны моннан алып китү планы турында сөйли.

— Баржаларга ашлык төягез,— ди ул.— Ашлыкны акларга калдырырга һич тә ярамый. Барыгызда да багорлар булсын... Сезнең арада механиклар, слесарьлар бармы!

— Бар, бар.

— Сезгә приказ: әгәр дә пароходларны алып китә алмыйбыз икән, машиналарны сүтегез дә баржаларга төягез. Ул вакытта аларны батырабыз. Ләкин кайда туры килде, анда түгел, тирән җирдә, тиз агымлы урында, аклар күтәртә алмаслык булсын!

— Ә затоннан ничек чыгарбыз!

— Менә болай. Җир казыгыч пароходлар әзерме! Әзер! Аларны бозваткыч урынына файдаланабыз. Кирәк урында суны бозлардан да чистартырлар. Кама уртасына чыгабыз да юлны дәвам итәбез...

Гавриловның боз белән беренче бәрелешкә керүе түгел. Революциягә кадәр үк инде, Балтик диңгезендә хәрби хезмәтне үткәннән соң, ул Кронштадта бозваткыч командиры булып эшли...

Колчакның көчле чагы. Кызыллар, аклар басымы астында, акрынлап чигенәләр. Сугышлар инде шәһәр тирәсендә бара.

---

[1] «Совет Татарстаны». Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1964 ел. 72—73 битләр.

[2] «Ленин һәм Татарстан». Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1964 ел. 72—73 битләр.

— Ни эшлибез, Иван Тимофеевич! — дип сорыйлар Ленин фәрманы белән килгән Гавриловтан.

— Судноларны монда калдырып булмый, егетләр,— ди ул.— Дошманны берничә сәгать булса да тоткарларга кирәк, бары да тәртиптә булыр...

25 апрельгә каршы төндә Чистай янында сугышлар аеруча көчле була. Судноларны алып китәргә вакыт оту өчен безнең гаскәрләр иртәнге сәгать 3 тә контратакага күтәреләләр һәм дошманны алты-ун километрга чигенергә мәҗбүр итәләр. Җиде сәгатьтән соң гына Колчак гаскәрләре, аңнарына килеп, кабат һөҗүмгә күчә.

Ә затонда пароход казаннары кичтән үк кабызылган була инде. Ләкин утын юеш. Кочегарлар аңа мазут сибәләр. Төн уртасында гына манометрлар басымның артуын күрсәтә башлый. Туплар залпы астында иң беренче булып «Волжская-4» җир казый торган пароход кузгала, ул, гигант чүмечләре белән су өстен боздан чистарта-чистарта, бүтәннәргә юл сала. Аның артыннан, ашлык һәм нефть төялгән баржаларны тартып, буксирлар юлга чыга.

Ниһаять, менә су уртасы. Ләкин шул вакыт көчле җил күтәрелә һәм «Волжская-4» ярган юлны кабат боз өемнәре күмеп китә. Атыш тавышлары да якынлаша — сугышлар инде Чистай урамнарында бара. Ә пароходлар ташбака тизлеге белән генә хәрәкәт итәләр.

Бүтән җир казыгыч пароходлар да эшкә керешә. Карван ут капкан шәһәрдән ераклашканнан-ераклаша.

Судноларны дошманнан коткарып калу турында Су транспорты идарәсе В. И. Ленинга махсус телеграмма белән хәбәр итә. Бу җаваплы эшне уңышлы үтәп чыгулары өчен елгачыларга Владимир Ильич рәхмәт белдерә. Бу уңай белән су транспорты хезмәткәрләре союзының Казан комитеты түбәндәге мөрәҗәгатьне кабул итә:

«Кадерле юлбашчыбызның бу рәхмәте елгачыларның рухын тагын да күтәрер һәм аларның контрреволюция аждаһасы белән көрәштә болай да киеренке энергиясен тагын да көчәйтер.

Иптәшләр! Бик күп, бик күп нәрсәләр безнең эшебез белән бәйле... Кызыл Армия сугышчылары үзләренең күкрәкләре белән пролетариат казанышларын саклыйлар. Безнең бурычыбыз, транспорт бурычы, аларны кирәк булган барлык нәрсә белән тәэмин итү. Алардан тыш, иптәшләр, үзәк губерналарның эшчеләре өчен икмәк кирәк; безнең бурычыбыз, транспорт бурычы, аларны икмәк белән тәэмин итү.

Пролетариатның тулы җиңүенә ышанган хәлдә... су транспортының район комитеты сезне, кадерле иптәшләр, үзегезнең фидакарь хезмәтегез белән пролетариатның бөек юлбашчысы иптәш Ленинның тагын бер рәхмәтенә лаек булырга чакыра»[1].

1919 елның 16 маенда Казан районы елга идарәсе коллегиясендә Чистайдан пароходлар карванын алып чыгу турында И. Т. Гаврилов отчеты тыңлана. Иван Тимофеевич үз эше турында мактанып сөйләргә яратмый. Аның отчеты бары тик ике минутлык була:

— Ярты миллион пот ашлык, йөз мең пот нефть чыгардык.— ди ул...

Кама аръягы районнары азат ителгәч, Гаврилов кабат Чистайга җибәрелә. Бу юлы ул анда су транспортының Чистай участогы коллегиясен оештыра һәм шул ук вакытта аклар һөҗүм иткәндә суга батырылган машина частьларын күтәрү эшләре белән дә җитәкчелек итә.

Гавриловка күп мәртәбәләр катлаулы һәм җаваплы эшләр тапшырылар. Казан, Ульяновск, Астрахань, Куйбышев, Мәскәү, Ленинград архивларында аңа партия һәм совет оешмалары тарафыннан бирелгән утыздан артык мандат саклана. Үзенә тапшырылган һәр эшне ул үз вакытында һәм уңышлы итеп башкара. Мәсәлән, Кама елгасының югары агымында баткан корабларны өскә күтәрү операциясе. Бу эш 1919 елның көзендә башкарыла. Су транспорты союзы үзәк комитеты члены Зайцев Камадагы асыр хәлне аңлатып, В. И. Ленинга доклад яза. Шушы доклад нигезендә Владимир Ильич Я. Э. Рудзутактан Камадагы эшләрнең торышы турында сораша. «Өч атнадан бирле,— дип җавап бирә Я. Э. Рудзутак,— Камада батырылган судноларны күтәрү, җимерелгәннәрен төзәтү буенча махсус комиссия эшли...

---

[1] «Знамя революции» газетасы. 1919 ел. 8 май.

Аның эшләре белән аклар һөҗүм иткән вакытта Чистай районыннан карваны коткаруны оештырган Гаврилов җитәкчелек итә»[1].

Суга баткан корабларны Гаврилов җитәкчелегендә күтәрү командасының фидакарь хезмәте Пермь губернасы хезмәт ияләре өчен үрнәк була. Партиянең Пермь губерна комитеты бу көннәрдә хезмәт ияләренә болай дип мөрәҗәгать итә:

«Ак гвардиячеләр пароходларның төп частьларын һәм механизмнарын узларе белән алып киттеләр. Ләкин, шуңа карамастан, елгачылар иплелән артык пароходны төзәттеләр һәм сегмергә якынын су астыннан күтәрделәр, йөзгә якын баржа һәм дебаркадерларны ремонтладылар. Елгачылар революцион энергиясенең бөек көче могҗизалар тудыра»[2].

...Идел ярына урнашкан Югары Осланда туып-үскән Гавриловлар, гомумән, бөтен Балтикага таныш була. Иван Тимофеевичның олы абыйсы Степан 1906 елны анда «Память Азова» крейсерында матрослар восстаниесенә җитәкчелек итә һәм патша палачлары тарафыннан моның өчен атып үтерелә...

1917 елда, патша хөкүмәте бәреп төшерелгәч, Иван Тимофеевич РСДРП(б) сафларына керә һәм аны крейсердагы башлангыч партия комитетына сайлыйлар. Озаклямый ул Кронштадтның матрос һәм солдат депутатлары Советы составына кертелә. Шул ук елның апрелендә ул инде — диңгезчеләр отряды командиры. 25 октябрьда аның отряды беренчеләрдән булып Кышкы Сарайга бәреп керә[3].

Иван Тимофеевич күп мәртәбәләр В. И. Ленин белән очраша, Владимир Ильич та аны белә. 3309 номерлы Ленин мандаты әнә нәкъ шул турыда сөйли.

Гаврилов Советлар Россиясе елгачыларының Беренче, Икенче, Өченче съездларына катнаша, Ленин чыгышларын тыңлый.

1918 елны партия аны, Идел флотилиясен национальләштерү буенча комиссар итеп, Казанга җибәрә!

Комиссар!

Онытылмас гражданнар сугышы чорының гомумиләштерелгән онытылмас образы ул — большевик-комиссар. Бу образ революцион халык мәхәббәте белән сугарылган. Ул образ революция дошманнарының йөрәген тетрәткән.

Большевик-комиссар!

Ул революция солдатларына Ленин эшенең хаклыгын аңлаткан, ул сугышчан коллективларның зирәк акылы һәм намусы булган, шул ук вакытта партиянең үткен, уяу күзе булып та хезмәт иткән: дошман хыянәтен үз вакытында ачкан, контрреволюцион фетнәләрнең юлын каплаган. Ә сугышта комиссарның урыны — иң куен, ут иң кызган җирдә, ул, иң беренче булып, үлемгә каршы чыга, үз үрнәге белән бәрлык сугышчыларны рухландыра.

Иван Тимофеевичның комиссар булып кайткан көннәре турында аның туганы Василий Тимофеевич безгә менә нәрсәләр сөйләде:

«Иван кайтып төшү белән иң башта безгә, Югары Осланга, килде. Вакытлы хөкүмәт министрларын ничек итеп әсир итүләре, аларны крепостька озатулары турында сөйләде. Мин шунда әйттем дә куйдым аңа:

— Вань, син хәзер дә нәкъ электәге кебек, — дидем. Моны мин шуңа әйттем: ул әледән-әле урыныннан сикереп тора, гел каядыр ашыккандай ашкына иде. Шуннан соң минем яныма килеп утырды да җилкәмнән кочаклап алды. Аннары:

— Баржада, соңыннан «Соликамск», «Черных» пароходларында бергәләп эшләгән чаклар хәтереңдәме! — дип сорады.

— Ничек инде хәтердә булмасын! — дидем мин.

— Ә аларның хуҗасы кайда хәзер!

— Мөгаен, дачаларындадыр.

Ә хуҗаның дачасы нәкъ безгә каршыда — Иделдәге утрауда иде.

— Мин Казанга нигә кайтканны беләсеңме!

— Юк.

---

[1] «Советская Татария» газетасы. 1969 ел. 13 июнь.

[2] «Красный Урал». 21 ноябрь. 1919 ел.

[3] Ленин һәм Татарстан. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты. 1964 ел. 338 бит.

— Мине флотны национальләштерү буенча комиссар итеп җибәрделәр. Әшне малай чакта ук канны суырган хуҗадан башларга исәп...

Бик кыен туры килде аңа ул көннәрдә. Төннәрен дә йокы юк иде. Хуҗалардан тартып алынган судноларны саклап, бервакыт шулай, дозорда торабыз. Безнең белән тагын ике егет бар. Алар да Осланныкылар. Хуҗа безгә каршы бандитлар җибәргән. Атыш китте. Ваня инде мондый атышуларга күнегеп беткән. Ә егетләр курка калдылар. Шулай да судно янына бандитларны җибәрмәдек. Ләкин бандитлар, төнлә, өйгә кайтканда саклап торып, аның башына суктылар, аркасына пычак кададылар. Исәпләре барып чыкмады — терелде Иван, эшне ахырына кадәр башкарды».

1923 елда флотны национальләштерүгә 5 ел тулу уңае белән Иван Тимофеевич Гавриловка Хезмәт Герое исеме бирелә һәм аңа түбәндәге адрес тапшырыла:

«Иван Тимофеевич Гавриловка.

Казан су транспорты районы комитетына кергән биш мең елгачылар сәүдә флотын национальләштерүгә һәм безнең Союз оешуга биш ел тулу көнендә, сине сәламләп, синең пролетар революциясенә, су транспортына һәм аның Союзына чын күңелдән бирелгәнлегеңә соклананалар! Эшчеләр эше өчен, аларның киләчәккә якты идеаллары өчен үләргә дә әзер торуың, национальләштерелгән су транспортын торгызу буенча фидакарь хезмәтең синга үзләренең каннары һәм тирләре белән властьны яулап алган, массаларны экономик һәм рухи изелүдән, коллыктан алып чыгарга оештырган мәңге үлмәс данлы исемнәр белән рәттән үз исемеңне куярга хокук бирә. Су транспорты һәм аның Союзы каршында синең хезмәтләрең гаять зур. Баррикада туплары гөрселдәве астында, үзеңнең батыр үрнәгең белән эшчеләрне рухландырып, син, бик кыю рәвештә, коллектив хуҗалыкның актив хуҗасы, су транспортының җитәкчесе һәм эшче массаларын оештыручы була белдең. Хәзер дә син революция тапшырган бурычларны намус белән үтисең һәм ахырга кадәр үтәячәксең! Һәм биш мең елгачы эшчеләр, дәүләт һәм Союз каршындагы хезмәтләреңне хөрмәт итеп, сине су транспортында Хезмәт Герое итеп раслый. Чүкеч белән тагын да ныграк сук, иптәш, барлык елгачыларны революцион Союзның Кызыл Байрагы астына берләштер!

Яшәсен дөнья хөкемдары — Хезмәт!

Яшәсен Коммунистлар партиясе!

Яшәсен Транспорт, Транспорт Союзы һәм Хезмәт Герое»[1].

...Хезмәттәшләренең әйтүе буенча, Иван Тимофеевич 1930 елга кадәр бер мәртәбә дә ялга чыкмаган. Шулай да ул зарланмаган, һәрвакыт кешеләр язмышы, революция язмышы хәл ителә торган иң кыен участокларда эшләгән.

...1921 ел. Кояш үзенең кайнар нурларын җир өстенә көннән-көн мулрак сибә. Ләкин ул җир белән дус булмый бу елны: барлык нәрсәләрне көйдерә, кыра. Фән ул вакытта табигать белән якага яка килеп көрәшә алмаган әле. Идел буе басулары эсседән яргаланалар, айлар буена бер тамчы яңгыр да күрмиләр алар. Халык ачлыктан бик күп кырыла...

Ләкин яшь Советлар иле ачлыкны җиңә. Ачлык елны Иван Тимофеевич та бөтен көчен биреп балаларны коткаруны оештыра, ачлыктан интегүчеләргә ярдәм комитетлары төзи. Спекулянтлар, кулаклар белән көрәш алып бара.

Бу хезмәтләре өчен Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты Гавриловны Грамота һәм «Ачлыкка каршы көрәшче» билгесе белән бүләкли.

Бу билгене иптәш Гаврилов түшенә тагып йөрергә хаклы. «Ачлыкка каршы көрәшче» билгесе положениесе буенча иптәш Гаврилов Татарстан республикасы территориясендә, ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм аның Президиумының махсус карарыннан башка, кулга алынырга да, судка бирелергә дә тиеш түгел...

Бөек Ватан сугышының авыр көннәрендә дә, үзе Союз күләмендәге персональ пенсионер булганы хәлдә дә, ул һаман эшли, карточка белән алган икмәкне бүлеп-бүлеп балаларга өләшә торган була.

Иван Тимофеевич Гаврилов 1943 елда вафат булды. Аның исемен Казан елга порты хезмәткәрләре дә, Татарстан республикасы хезмәт иялəре дә хөрмәт белән искә алалар.

---

[1] «Советская Татария» газетасы, 14 июнь, 1969 ел.

Нигъмәт Ихсанов

#ҺӘРВАКЫТ ЮЛДА



Көн үзәгендә, карьерда эшнең иң кайнаган вакытында, Рәисне диспетчер туктатты:

— Заһидуллин! Хәзер үк машинаңны гаражга кайтарып куй да конторага чап. Анда сине көтәләр.

— Ничек? Ничек инде?! — дип аптырап калды Рәис.— Шулай буш кузов дыңгырдатыпмы? Бөтен шәһәр буйлап буш машина куаргамы?

— Аңысы минем эш түгел,— диде диспетчер, кырыс кына.— Үзең берәр мөгез чыгаргансыңдыр әле. Әле генә Исмәгыйлов шалтыратты.

...Менә сиңа мә! Автобаза директоры үзе чакыра.

Исмәгыйловның әле күптән түгел генә җыелышта сөйләгән сүзләре Рәиснең хәтеренә төште. Ике-өч чакрымга буш машина куган өчен гравий ташучы бер шоферны тәмам кызган табага бастырдылар бит.

— Гравий! Гравий! Гравий! — дип, өзеп-өзеп кабатлады директор.— Нәрсә соң ул гравий?.. Асылын аңламаганнар өчен гравий — гади чуерташ кына. «Биш таш» уенчыгы. Башында мие булган кешегә исә гравий — бетон. Гравий яңа йортлар, яңа мәктәпләр, ферма каралтылары, яңа юллар. Үзегез уйлап карагыз, без бер сәгатькә кичексәк, бер сәгать буе бетон заводы эшсез тора дигән сүз. Бетон булмагач, төзелешләр туктала. Безнең аркада йөзләгән эшчеләр кул кушырып утыра. Әнә шундый ваемсыз егетләр аркасында кемнәрдер хезмәт хакын кимрәк ала, кемнәрдер яңа фатир көтеп, начар торакта яши бирә...

Кызып-кызып, рәнҗеп-үртәлеп сөйләде директор. Ахырда, кылыч белән һаваны кискәндәй, уң кулын селтәп куйды:

— Бетте! Мондый башбаштаклыкка чик куярга вакыт. Сиңа, иптәш, бу юлга каты шелтә. Тагын бер шулай кыйлансаң, үзеңә үпкәлә!

Ә бүген менә һич көтмәгәндә Исмәгыйлов үзе Рәисне Дербышка ягыннан шәһәр үзәгенә чакыра. Тикмәгә түгел инде. Нәрсәгә икән соң шул кадәр?..

Рәис карьер ягына борылып карады. Таш табак кебек түгәрәк чокыр төбендә машиналар, машиналар... Бульдозерлар, тракторлар, экскаваторлар. Кышка хәзерлә-



нүчә эшчән кырмыскалар кебек, туктаусыз кайнашалар. Төрле авазлар чыгарып гүелдиләр, тырылдыйлар, үкерәләр:

— Гр-равий!.. Гр-равий!..

Рәиснең һаман аптырап торгачын күргәч, диспетчер җәһәт кенә башын күтәрде:

— Син нәрсә оедың, Заһидуллин? Кара аны, мин вакытында әйттем. Соңыннан сүз булмасын...

Машина кузгалып киткәндә, диспетчер, будка тәрәзәсеннән башын сузып, кычкырып калды:

— Оныта язганмын. Автобиографияңне әзерләп килергә куштылар. Җиде бабаңны җентекләп, егетем.

«Автобиография» дигәч, тагын сәерсенде Рәис. Нәрсә язсын, нәрсә сөйләсен.

1932 елда туган. Апас районында, Олы Кайбыч авылында, хәрби хезмәткәр семьясында... Соң... Соң бит болар барысы да билгеле. Эшкә кергән вакытта анкеталарга бәйнә-бәйнә язылган. Инде тагын нәрсә естәсен икән...

Юлда кайтканда Рәис үзенең тормышын тагын бер кат күздән кичерде... Олы Кайбыч. Гади бер татар авылы. Салам түбәле каралтылар, җил капка, тузанлы урам. Малайлар кайнар тузанда ялан тәпиләрен пешерә-пешерә авылның бер очыннан икенче очына чабалар. Әрекмән яфрагына туфрак төреп «бомба» чөешәләр. Колак тишекләренә, борыннарга балчык тулып, хәтта сулышлары буыла башлагач, җыйнаулашып Бәрле елгасына йөгерәләр. Бала йоннары кабарганчы суда чупырдаганнан соң яшел чирәмдә ауныйлар, кәҗә сакалы, какы, кузгалак җыеп ашыйлар. Куак артларына качып барып, су коенучы кызыйларның күлмәк җиңенә кычыткан тыгалар...

Кызык, бик кызык иде хафасыз, гамьсез бала чак. Хәтта ачлы-туклы узган авыр сугыш еллары да үзенең күп кенә яклары белән күңелдә якты истәлекләр калдырган икән ләбаса. Менә алар абыйсы Вил белән таңнан торып әлеге шул Бәрле елгасына юнәләләр. Хәзер инде су коену, үрдәкле уйнау кайгысы түгел, ничек тә тамак ялгау, җан асрау. Елганың уйдык урыннарында ару гына чабак балыклары каба. Ара-тирә алабуга, бәртәс кебек затлыраклары да эләккәли. Елга ярына чиләк асып пешергән тозсыз балык шулпасы әле аннары көзен, кышын да төшләргә кереп йөдәтә. Ә инде җәйге җылы төннәрдә яр буенда төн кунулар... Һай, ул төннәр, ул сихри төннәр! Күктә дә йолдызлар, су төбендә дә миллион йолдыз. Күктән дә йолдыз атыла, учактан да учма-учма йолдызлар чәчелә. Якында гына тартар кычкыра:

— Тар-р, тар-р...

Шундый матур, шундый киң дөнья аңа ничек тар тоеладыр, аңламассың!..

Елга аръягындагы куе тирәкләрне аралап, ай башын калкыта. Көзгедәй су өстеннән аръяк камышларына кадәр нурлар сукмагы сузыла... Менә хәзер йөгереп төш тә китеп бар шул көмеш күпердән. Таңгача әлгерә калсаң, һичшиксез, Ай иленә, әкиятләр дөньясына барып чыгачаксың... Әмма, китим дисәң, менә бу... менә шушы дөнья әрәм кала. Кечә Кайбыч ягындагы очсыз-кырыйсыз урманнар җәл кала. Ай-һай-һай, ул урманнар! Барып күрсәң бер кавым һушыңны җыя алмый торасың. Тирә-ягың тын, тып-тын... Әмма әз генә җил исеп куйдымы, моңа кадәр йокымсырап утырган җилбәзәк усаклар «дерт» итеп уяналар да бөтен урманга шаулаша башлыйлар, пышынпышын килеп, тынгысыз җилнең гайбәтен саталар. Ә чыршы мондый гына җилне санга сукмый. Әкрен генә чайкалгалап, гамьсез генә гүелдәп утыра... Тагын бераздан карт имән уяна. Һәм озакламый урмандагы бөтен агачлар берсен-берсе бүлә-бүлә шаулашырга, ухылдашырга керешәләр. Күңелдә шом туа. Нинди генә хикмәтләр булмас бу урманда... Әнә бит күрше авылның Сафиулла абзыйга юлыккан ди шулай...

«Ухалла» арбасын тартып, телен аркылы тешләп утыннан кайтып килә икән, каршысына бер шүрәле карты килеп чыккан.

— Минем йолдыз кашлы ай йөзегемне син тапкансың. Яхшы чакта бир, Сапый,— ди икән бу.

— Эч пошканда ачуны китереп йөрмә әле, карт тиле,— ди икән Сафиулла абзый.— Эшең булмаса, әйдә, тартыш бераз!

— Бирмәсәң, кети-кети итәм,— диген ди шүрәле һәм килеп кытыклый да башлаган ди. Уң ягыннан да кытыклый, сул ягыннан да төшә ди. Әмма ник кенә бер көлеп карасын Сафиулла! Соң инде... көләрлек ди анда. Иртәдән бирле сыңар бәрәңге көлҗемәсе белән йөреп кара әле син. Тырыша торгач, үзе телен асылындырган ди шүрәле.

— Булмады, Сапый, бирешмәдең. Егет икәнсең,— дип әйткән ди.

Шактый җир аның «ухалла»сын тартышып килгән ди шүрәле. Урман авызына чыккач, өрәңгә яфрагы болгап, озатып калган ди...

Рәис үзалдына елмаеп куйды... Менә сиңа автобиография! Сөйләп бир идең шуларны. Нәрсә әйтерләр иде икән?.. Ә шулай да уттай эш вакытында әкият сөйләтер өчен чакырмаганнардыр бит. Нәрсә сорарлар икән соң, әкәмәт. Казанга күчеп килгән чаклардан башласаң... Анда да шул бер балык башы ләбаса! Сугыш, авыр еллар... Хәзерге цирк урынында иске тегермән. Баржа белән җитен, көнбагыш түбе китерәләр. Көн буе йөк бушатырга булышкан булып чуалсаң, берәр такта түп эләгә. Анысы ярап куя. Рәхәтләнеп кимер! Туклыклы да, тиз генә бетеп тә китми...

Абыйсы Вил унөлты яшеннән шофер булып эшли башлады. Әнә шул чак Рәискә дә машина җенә кагылды. Тик руль тотарга аңа иртәрәк иде шул әле. Сирәк-мирәк кенә, кыр юлына чыккан чакларда гына беразга үз урынына утырткалый иде абыйсы.

Башыңа төшсә башмакчы булырсың, дигәндәй... Рәискә дә башмакчы булып китәргә туры килде. Уноч яшендә укуын ташлап, инвалидлар артеленә итекче өйрәнчеге булып керде. Күн кисү, чүәк, башмак тегү эшенә өйрәнде. Сугыш беткәч, ФЗӨ да укый башлады. Кырык тугызынчы елда дүртенче разрядлы токарь булып чыкты. Аэродромда токарь булып эшләде, шуннан армиягә китте, Молдавиядә чик сакчысы булып хезмәт итте. Аннан кайткач, шоферлар курсын бетерде...

Күпме генә уйласа да, менә мин болай эшләдем, дип сөйләрлек нәрсә таба алмады Рәис. Барысы да шул гап-гади тормыш, барысы да шул бер буын язмышы.

Исмәгыйлов белән партоешма секретаре Костромин Рәисне гараж капкасы төбендә үк каршы алдылар. Йөзләре җитди, әмма алай пешереп ашарга теш кайрап торгандай күренмиләр.

— Кул-битеңне генә юып ал да, әйдә. Обкомга чакыралар,— дип каударланды Костромин.

...Партия өлкә комитетына! Бусы тагын да бер табышмак. Гади бер шоферны ул зур йортка ник чакырдылар икән? Җитмәсә тагын майга баткан киемнәр белән барып керергә туры киләчәк. Өйгә кайтып өс-башны алыштырырга да ирек бирмичә, җиңел машинага утыртып алып киттеләр.

— Уйлабрак бар, Сафиуллин. Эшең турында төпченебрәк сөйләргә туры килер,— дип, янәдән кисәтте Исмәгыйлов.

Рәис тагын баш ватарга кереште.

...Эш турында... Димәк, шушы соңгы еллар... Шоферлар курсын тәмамлагач, таныклыгын тотып, автохуҗалык начальнигы кабинетына барып кергән иде Рәис. Керде дә ничектер кинәттән хәрбиләрчә ярып салды:

— Мин сездә шофер булып эшләргә телим.

Начальник, өстәлдә өелеп яткан кәгазьләрдән күзен алып, башын күтәрде һәм егетне баштанаяк күзләп чыкты:

— Я, хуп. Шуннан,— дип, мөлаем гына елмаеп куйды ул аннары.— Нишләп кадрлар бүлегенә сукмыйсыз?

— Мин анда булган идем инде,— диде Рәис.— Хәзергә машина юк, диделәр.

Начальникка Рәиснең буй-сыны ошадымы, үз-үзен тотышы күңеленә хуп килдеме, ул урындык артына авып, көр тавыш белән көлеп җибәрде.

— Карасана! Алдаганнар икән бит сине, егет!..— Аннары җитди төс алып, экран

генә әйтеп куйды.— Мин дә шуны әйтәм шул, туганкай. Юк машиналар. Җитми. Берне икегә ярырга торабыз да бит...

— Мин яңаны сорамыйм,— дип үзсүзләнде Рәис.— Хәзергә берәр калтырча булса да ярап торыр...

Бу сүзләрне ишеткәч, начальник тагын көлеп җибәрде:

— Калтырча дисең гыйса. Әллә ишетеп үк килдеңме? Бар бездә андый нәрсә. Шоферлар телендә күптәннән «Калтырча» исемле. Әнә, кара...— Начальник, тәрәзә чаршавын читкәрәк тартып, ишек алдына күрсәтте.— Анда бер почмакта урынына агач бүкән кыстырылган «Калтырча» — «ЗИС-150» машинасы янтаеп тора иде.— Әнә ул, таныш бул! Әмма дуслаша алмассың шул, туганкай. Бик күбәүләр кул селтәде инде аннан. Металломга озатырга туры килер, ахры.

— Рөхсәт итсәгез, мин тырышып карармын...

Начальник бераз вакыт Рәискә сөзеп кенә карап торды да, кабат бер сүз дә әйтмәстән, гаризасының почмагына кыйгачлатып кул куйды.

Ул көнне көн буе машина тирәсендә бөтерелде Рәис. Дөресен әйткәндә, машина дияр җире юк иде моның. Яраса шул кысасы белән кабинасы гына. Калган барлык өлешләрен юктан бар итәсе...

Башта бераз каушап та калды малай. Әмма кире чигенергә хурланды. Иртә таңнан күз бәйләнгәнчегә кадәр шунда казына башлады.

Инде тәмам беттегә саналган «калтырча» тирәсендә җан-тән белән тырышып азапланган егетне күргәч, күбәүләр мыек астыннан көлеп йөрделәр. Беренче атналарда хәтта килеп танышучы, киңәш бирүче дә булмады. Усал телле шоферлар «калтырча»-га ишләп тагын бер кушамат атый башладылар:

— Патриот!

Тик Кәрим исемле өлкән яшьләрдәге слесарь гына үтешли-сүтешли Рәис янында туктап, тәмәке тартып киткәли иде.

Шулай бер көнне Кәрим агай эштән соң озак кына Рәиснең карбюратор сүткәнен карап утырды.

— Күрәм, син, энекәш, чынлап тотынгансың, ахры, бу эшкә,— дип куйды ул.— Ай-һай, барып чыгарлыкмы икән? Бигрәк бетешкән бит.— Үзе шунда ук, Рәисне юаткандай, өстәп куйды:— Тырышкан табар,— диләр бит. Бер башлагач, тырышып кара, әйдә. Кабинаңны төшергәндә миңа әйт. Булышырмын. Алай-болай йомышың төшсә, тартынып торма. Эш итеп чыксаң, уен түгел. Машина бит!

Шуннан соң Кәрим агай Рәискә еш кына ярдәм иткәләп торды. Я авыр детальләрен күтәрешергә килә, я мастерскоенда вак-төяк частьлар ясап бирә. Тәҗрибәле, өлкән кешенең киңәшләре дә күп чак урынлы була. Бигрәк тә янында бер терәктәшең булу — үзе бер таяныч. Рәиснең ФЗӨ да алган слесарьлык һөнәре дә бу эштә бик ярап куйды. Күп кенә вак детальләрне ул Кәрим абзый мастерскоенда үз кулы белән ясады.

«Патриот»ның уен уйнамаганын күргәч, элек авыз ерган кайбер шоферлар да килгәли башладылар. Кайберсе төпле генә киңәшләр бирә, кайберсе үзенең «кара көнгә» саклап торган запас частьларыннан өлеш чыгара. Мир төкерсә, күл булыр дигәндәй, «калтырча» дигәнебез әкрен-әкрен машина кыяфәтенә керә башлады.

Ниһаять, дүрт ай буе бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләгән эшнең нәтиҗәсен күрер көн җитте. Дөресен әйткәндә, ул көнне эшкә килгәндә Рәиснең җаны уч төбендә диярлек иде... Әгәр кабынмаса? Кабынып та кузгалмаса?.. Капканы чыгу белән юл уртасында утырып калса?.. Әле авыз еручылар хәзер дә җитәрлек. Шулар алдында оятка калсаң...

Моторны кабызганда «калтырча» янына бер төркем халык җыелды.

— Заводтан яңа чыккан бит. Обкатка нык кирәк инде моңа,— дип, дусларча гына шаяртып куйды арадан берәү.

— Буксирга ДТ чакыртырга кирәк,— дип авыз ерды икенче бер әче теллесе.

Әмма «калтырча», тигез генә гөрелдәп, капкадан чыгып китте. Ул көнне көн буе Рәиснең күңелендә күгәрченнәр гөрләде кебек. Әйтерсең, ул автобаза ихатасындагы чүп-чарны түгел, алтын таулары ташып йөри...

Обкатка вакытында Рәис машинаның тагын күп кенә урыннарын көйләде, клапаннарын яңадан җайлап куйды, сцеплениесен рәтләде. Бер атнадан исә «калтырча»-

сын гараждагы башка машиналар рәтенә илтеп туктатты. Шулай итеп, автохуҗалыкта бер машина юктан бар булды.

Дүшәмбе көн иртән Рәис Заһидуллин чын путевка алып, чын эшкә — тимер юл станциясеннән товар ташырга җыенды. Грузчиклар шактый сүлпән, берән-сәрән генә килделәр.

— Болай ярамас, егетләр,— дип шаярган булып кисәтте аларны Рәис.— Минем «калтырча» ике ел буе ял итеп ялыккан инде. Эшкә атлыгып тора. Сезгә бераз өлгеррәк булырга туры килер!

Станциядә йөк төяргә ярты сәгать вакыт китте. Бу юлы инде Рәис беркинди шаяртусыз-нисез әйтеп салды.

— Бу эшкә унбиш минут җитә. Алдагы рейста шуңа сыешыгыз, егетләр.

— Ничек инде? Тик торган кеше юк бит,— дип чыраен сытты грузчикларның бригадиры.

— Син, Камил дус, тәмәкене эш вакытында түгел, юлда тарт,— диде Рәис.— Анары ник ул әрҗәләрне берәмләп җилкәдә ташырга. Әнә теге арбаларны нәрсәгә дип тезеп куйганнар?!

Дөрес сүзгә җавап юк, ди. Камил каршы әйтмәде. Алдагы рейста йөк төяү унҗиде минутка, ә аннан соңгыларында нибары ундүрт-унбиш минутка гына сузылды. Бу көнне алар тугыз рейс ясадылар. Шулай итеп, норма 160 процентка үтәлде.

Эш бетереп кайтып китәр алдыннан Камил аңа үзе килеп кул бирде:

— Болай булса, Рәис абый, синең белән куллар да буш тормас, кесәләр дә буш булмас. Ку әйдә шулай!..

Бер ай үтте. Күрсәткечләр тактасында Заһидуллин фамилиясе турында 140 проценттан ким сан күренгәне булмады. Әкренләп «калтырча» дигән кушамат та тәмам җуелды. Хәзер инде шоферның үзен дә, машинасын да кинаясез-нисез «патриот» дип йөртә башладылар.

Көннәрдән бер көнне Камил Рәисне кинода очратып сүз катты:

— Гомер буе җилкә белән йөк ташырбыз микәнни, Рәис абый,— диде ул, кыюсыз гына.— Заманасы ул түгел бит. Машинага үрмәләп булмасмы икән?

— Менә тагын! Теләгең булса, әйдә, үзем өйрәтәм,— дип хуплады аны Рәис.

Шуннан соң берничә ай буе Камил машина тирәсендә кайнашты. Ә көзен шоферлар курсына укырга керде. Стажерлыкны да Рәис янында узды. Мөгаллиме яңа машинага күчкәндә, «патриот»ны кабул итеп алды.

Партия сафына керү һәркемнең күңелендә онытылмас бер якты сәхифә булып кала. Рәис тә бу көнгә озак һәм дулкынланып хәзерләнде. Беренче рекомендацияне аңа автохуҗалык начальнигы Кадыйров үзе бирде.

Җыелышта сүз бирелгәч, Рәис дулкынланудан тотлыгып калды. Сөйләргә дип әллә кайчан өзерләп, кат-кат тәкърарлап куйган сүзләре бөтенләй хәтереннән чыктылар. Аның каушап калганын күргәч, партоешма секретаре ярдәмгә ашыкты:

— Автобиографияңне сөйлә, Заһидуллин. Кайда тудың, кайда үстең, ничек укыдың...

Автобиография... Анда үзе ничектер шома гына чыккан иде кебек:

— 1932 нче елгы... ФЗӨ. Армия. Токарь булып эшләдем. Өченче класслы шофер булып чыктым. 13—82 номерлы машинаны кабул итеп алдым...

Шунда кемдер берәү арткы рәттән кычкырып куйды:

— Машинаны түгел, «калтырчаны».

Зал гөр килеп көлеп алды. Дусларының шулай үз итеп, якын итеп көлүеннән Рәиснең күңеле иркенәеп китте, каушавы кимеде. Һәм ул шома гына итеп сөйләп бирде.

— Хәзер мин «калтырча»ны Камилгә тапшырдым. Ә миңа «МАЗ-200» машинасын бирделәр,— дип, елмаеп ул сүзен тәмамлады...

Җыелыш ярыйсы узды. Анда барысы да көн саен бергә эшләп, бергә шаярышып йөргән дус-ишләре, үзе кебек шоферлар иде шул. Ә бирегә, партия өлкә комитетында, нәрсә сөйләр менә...

Ни әйтсә дә урынсыз, ни әйтсә дә тозсыз чыгар сыман тоелды Рәискә. Җитмәсә әлегә шул билгесезлек күңелне туктаусыз тырнап тора...

Тик барысы да бик гади килеп чыкты. Уртача гына буйлы, коңгырт чәчле бер кеше аларны аягүрә басып, кул биреп каршылады. Аягүрә үк хәл-әхвәл сораша башлады, урын күрсәтте. Бер дә кыенсынырга урын калдырмыйча, тормыш, семья хәлләре, фатир яклары белән кызыксынды... Эш турысына килгәч, шунда ук Исмәгыйлов белән Костромин ягына карап елмайды:

— Ягез, житәкче иптәшләр, кешенең артында гына сөйләп йөрмәгез, күз алдында, йөзенә карап әйтегез. Әшендә ничек Заһидуллин?

Шул сорауны гына көтеп торган кебек, тегеләр берсен-берсе бүлә-бүлә сөйләп киттеләр:

— Мондый коммунистлар күбрәк булса, дөнья актарырга була, иптәш Троицкий,— диде Костромин.

— Күрсәткечләре буенча, үзегезгә мәгълүм,— дип ялгап китте Исмәгыйлов,— республика автохуҗалыгында ун меңнән артык шофер арасында безнең Заһидуллин иң алдынгы...

Мондый мактау сүзләрен ишеткәч, Рәис уңайсызланып, кызарып китте.

— Арттыралар инде бераз,— дип уйлады ул күңеленнән һәм, каушавын сиздермәс өчен, башын тагын да түбәнрәк иде.

Сүз үзе турында түгел, бөтенләй башка чит бер Заһидуллин турында баргандай, битараф булып тыңларга тырышты.

Әнә ул Заһидуллин дигән кеше «МАЗ-200» машинасында, прицеп белән эшләп, хезмәт житештерүчәнлеген 80 процентка үстергән. Тагын да зуррак уңышларга омтылып, ул үзенә самосвал бирүләрен сораган. Ник дигәндә, «МАЗ» машинасында эш кына аның кулы йөк төяүчеләргә, йөк бушатучыларга бәйле була икән. Билгеле инде, яңа техника тагын да югарырак белем, тагын да зуррак осталык сорый. Заһидуллин төн йокысын йокламый, укый, өйрәнә. Икенче класс шоферлыгына имтихан бирү турында хыяллана. Һәм 1956 елда бу теләгенә ирешә. Әнә ул Заһидуллин шуннан соңгы елны ук беренче класска укып имтихан тота. Беренче класс дәрәҗәсен дә ала, бер үк вакытта автомеханик квалификациясен дә үзләштерә.

Ул Заһидуллин иптәшләренә карата һәрчак игътибарлы, һәрчак ярдәм кулы сузучан икән. Экономия өчен көрәштә ул башкаларны әйдәп бара, һәр литр бензинның, һәрбер эш сәгатенең кадерен белергә өйрәтә. Камил кебек яшьләргә кулыннан килгәнчә файдалы киңәшләр бирә:

— Машинаның үз теле бар аның. Өйрәнергә кирәк аны. Аңа кайчан яхшы, кайчан кыен икәнен аңларга кирәк,— ди.

Тиздән әнә Заһидуллинның тагын бер теләге тормышка аша. Автохуҗалыкка «Татра» маркалы киң күкрәкле яңа самосваллар кайта. Хәзер Заһидуллин карьерлардан төрле участокларга, Идел ярындагы дамбаларга, спорт сарае, цирк, торак төзелешләренә ком, гравий ташый. Еш кына ул арып-талчыгып, кичке сәгать тугыз-уннарда гына кайта. Өстен чишенгәндә ул хатыны Мөнирәгә кичегүенең сәбәпләрен әйтә:

— Ашыгыч йөк илтәсе булды... Бер иптәшкә ярдәм итәргә туры килде... Партия җыелышында тоткарландым...

Мөнирә, борчылып, ялыгып көткән булса да, үпкәләми, Рәисе йөрәгенең түземсез, ашкынулы икәнен белә.

Иртән аның эш көне сәгать алтынчы яртыдан ук башлана. Алты тулганда ул инде әле уянып кына килә торган Казан урамнары буйлап махсус автобуста гаражга бара. Янәшәсендә утырган иптәшләрен шаян сүзләр сөйләп көлдерә, аларның кайгы-шатлыкларын уртаклаша. Гаражга килгәч, күңеленнән ул машинасын сәламли:

— Хәерле иртә, хезмәттәш дустым. Әйдә, кузгалдык. Бүген дә безгә эш җитәрлек. Юллар көтә, заводлар, төзелеш мәйданнары материал көтә...

1960 елдан бирле Заһидуллин «Татра-III» машинасында эшли. Норма буенча капиталь ремонтсыз 130 мең километр узарга тиешле машина инде 250 меңне каплаган...

Менә инде тугыз ел Заһидуллин таш базлары хәзинәсен ташый һәм елның елында икешәр норма үтәп килә.

Ө күңел, тынгысыз күңел һаман да яңа юллар яра, һаман эзләнә, һаман таба. Кайчандыр шулай Уралга алдынгылар киңәшмәсенә баргач, Заһидуллин үзенеке кебек үк бер машинаның прицеп тагып узганын күреп кала. Һәм инде шундый әкәмәт аның

төшләренә керә башлый. Озаклamый ташландык «Татра» кузовыннан прицеп ясатып, шуны тагып та чыга.

Тагын сынау! Унбиш тонна, унсигез... Егерме тонна!

Тарта кугәрченкәй! Гөрелдәп тарта. Бер юлда ике рейслыкны алып бара.

Шагыйрь әйтмешли:

**Үзем сөю генә җитми әле,**
**Дусларым да мине сөйсеннәр...**

Үзе яхшы эшләү белән генә канәгать түгел коммунист йөрәге. Ул дусларының да алгы сафта булуын тели. 1964 елда ук бригада методы белән, күмәкләп эшләү принцибын алга куя. Һәм менә аның бригадасындагы сигез егетнең сигезе бер тиң булып хезмәт җитештерүчәнлеген 14 процентка күтәрәләр. Сигезе тиң бер үк вакытта диярлек бик күпкә алдан бишьеллыкны тәгәллиләр. Коллективта да Рәис йөкнең иң зурысын үзе тарттыра: ул, җидееллык нормасыннан тыш, бер үзе генә дә кырык сигез мең тонна йөк ташый. Өеп куйсаң, очы күренмәслек биек тау диген сүз бит бу!

Автохуҗалыкта, беренче буларак, аларга коммунистик хезмәт бригадасы исеме бирелде.

Рәис — автохуҗалыкның партбюро члены.

Рәис — машиналарның техник торышын тикшерү буенча комиссия члены.

Рәис — автоинспекциядә җәмәгать инспекторы.

Рәис — Киров район советы депутаты...

Тынгысыз йөрәкле бу кешегә игътибар беләнрәк караган саен аның яңадан-яңа кешелек, гражданлык сыйфатлары ачыла... Менә ул көзге салкын бер көндә машинасы белән Аккош күле буеннан узып бара. Аңа бөтенләй таныш булмаган бер кеше бәхетсезлеккә юлыккан. Кеше бата. Кемнеңдер карт анасы улсыз каласы... Кемнеңдер баласы ятим, хатыны тол буласы...

Рәис, һич икеләнмичә, кием-салымы белән үк, суга ташлана. Ярга чыккач, кешенең исән калуына ышангач, үзенең исемен дә әйтергә онытып китеп бара...

...Озак, бик озак сөйләделәр автохуҗалык җитәкчеләре Рәис Заһидуллин турында. Ә Рәис ничектер гаҗәпсенеп тә, дулкынланып та тыңлады. Чыннан да... Бер карасаң, кыска гына гомер эчендә шактый эш эшләнгән түгелме соң? Икенче карасаң, бездә теләсә кем башкара алырлык эшләр бит бу. Гайре табигый бернәрсә дә юк...

Троицкий да ничектер тәэсирләнеп Рәискә дәшә:

— Әйе, иптәш Заһидуллин!.. Я инде үзегез әйтегез. Ничек ирештегез мондый уңышларга?

Гаҗәп! Шундый гади генә сорауга берничек тә җавап биреп булмый икән. Күпме генә тырышып караса да, әйтеп бирә алмады Рәис. Күрәсең, аның сере йөрәкнең иң тирән, иң изге урынындадыр. Күрәсең, аның сере халкыңа, Ватаныңа булган мәхәббәт ɵрлыгы төшендәдер.

...Аннары, һич көтмәстән, куанычлы, шатлыклы хәбәр килде.

Якшәмбе көн иде. Иртән иртә үк Мөниреңең туганы Сания апа йөгереп керде дә:

— Ишеттегезме?! Радио... Указ бар. Герой син, Рәис җаным!.. Социалистик Хезмәт Герое!..— диде.

Әйе, шул ук минутта алып кергән «Правда» газетасында ул көнне шундый Указ эре хәрефләр белән басылган иде.

* * *

Әгәр юлыгыз уңай төшеп, Казандагы автокомбинатның икенче филиалына килеп чыксагыз, сез анда уртача гәүдәле, калку маңгайлы, коңгырт чәчле, калынчарак иренле, җитез хәрәкәтле бер кешене очратырсыз. Юк, ул сезнең алдыгызга фотодагы кебек ыспай костюмнан, галстуктан, күкрәгенә Ленин ордены һәм Алтын Йолдыз медале тагып килеп басмас. Ул бензин исе сеңгән спецовкадан булыр. Ул машиналар арасында кайнашыр. Хәер... ай-һай! Рәис Газизовичны анда очратуыгыз бик икеле. Сез аны шәһәр читендәге карьерлардан, берсен-берсе куып, «МАЗ»лар, «Татра»лар чаба торган юллардан, төзелеш мәйданнарыннан эзләгез. Ул җир хәзинәсе ташый. Ул һәрвакыт юлда, һәрвакыт эштә, һәрвакыт төзелештә.

## Леся Украинка

*Шушы елның февраль аенда алдынгы кешелек дөньясы, Совет иле украин халкының бөек кызы, революцион көрәш җырчысы Леся Украинкага йөз ел тулу көнен билгеләп үтә.*

*Леся Украинка (Лариса Петровна Косач) Новоград-Волынск шәһәрендә 1871 елның 25 февралендә туа. Кечкенә яшеннән үк Украинаның искиткеч матур табигатенә, урманнарына, елга-суларына, болын-кырларына сокланып, халык әкиятләрен, легендаларын, җырларын тыңлап, шул ук вакытта әлеге матур табигать фонында кешеләрнең коточкыч авыр тормышта газап чигүләрен, Украина крестьяннарының ярлылыкта, мохтаҗлыкта интегүләрен күреп, сызланып үсә.*

*Леся Украинка бала чактан ук яза башлый. Иҗатында беренче әсәр булып калган «Өмет» дигән шигырен ул 1880 елда яза. Аның «Җырлар канатында» исемле, заманның алдынгы демократ язучылары яратып кабул иткән беренче җитди поэтик китабы 1893 елда Львов шәһәрендә басылып чыга.*

*Леся Украинка, авыру булуына карамастан, бик күп укый, иҗат осталыгын күтәрүдә армый-талмый эшли, бөек кобзарь Тарас Шевченко җәүһәрләрен күңелдән ятлый, бөек замандашы, демократ язучы Иван Франко әсәрләре белән рухлана. Рус теленнән тыш, немец, француз, инглиз, латин, поляк һәм башка телләрне белә һәм дөнья поэзиясе классикларының иҗатларын оригиналдан өйрәнә. Әнә шулай итеп, ул заманының алдынгы революцион идеяләре белән коралланa, бөек азатлык эше өчен көрәш сафына баса. Аның сугышчан шигырьләре, йөрәкне тетрәтерлек лирик җырлары, көчле рухлы, революцион романтика пафосы белән сугарылган поэмалары, драмалары киләчәк революцион давылларны көчәйтергә ярдәм итә. Ул, хезмәт кешесенә дан, халык дошманнарына ачы нәфрәт белдереп, халыкның кара көчләрне җиңеп яктыга чыгачагына тирән ышаныч белән җырлый. 1905 ел революциясе аның иҗади рухын тагын да күтәрә. Бу революцияне ул «Ирек турында җыр», «Хыял», «Хыянәт итмә» һәм башка берсеннән-берсе көчле патриотик шигырьләре белән каршы ала. Соңыннан да үзенең көрәш коралын ташламый, «Ирек турында җырлар» циклы, «Баһадир турында», «Бер сүз», «Урман җыры» һәм башка революцион рухлы шигырьләр, поэмалар иҗат итә.*

*Леся Украинка 42 яшендә, 1913 елда вафат була. Большевистик «Рабочая Правда» газетасы үзенең некрологында аның гүзәл иҗатына югары бәя бирә.*

### Өмет

Тормыштан ирек тә, бәхет тә тапмадым,
Бер генә кадерле өметне сакладым:
    Күрсәмче сине бер, Украинам, тагын да,
    Һәрнәрсә ягымлы туган җир ягында.

Зәңгәрсу Днепрны бер генә күрсәм дә,
Аннары бары бер — риза мин үлсәм дә.
    Телим мин даланда курганнар карарга,
    Тынычлап соңыннан хыялда янарга.

Язмышым бирмәде бәхет тә, ирек тә.
Күңелем яшидер ышанып өметкә.

1880.

●

Кайчагында кулга каләм алганда,
Яки инде соңгы юлны язганда,
Күзгә күннең болытыдай, нигәдер,
Җанга тирән кайгы-хәсрәт киләдер.
Ачы уйлар кулны тота шул чакта,
Җәфа чигү, кайгы, кан-яшь һәр якта...

Шөбһәләнеп сызлый башлый йөрәгем,
Белсәң иде хезмәтеннең кирәген?!
Газапларны җинә алмаган менә
Хәтта ирләр. Минем көч күпме генә?
Әрнеп читкә куя белән эшемне,
Тирән уйлар арттыралар көчемне.

Шулай да, дим, бәлки минем бу җырлар
Гади кеше йөрәген юатырлар,
Йөрәк җырым йөрәкләргә керерләр,
Алҗыганга уй, көч-куәт бирерләр.

Җырым белән ирешермен хөрмәткә,
Ярап куяр, бәлки, минем хезмәт тә.

Шик-кайгыдан мин яңадан котылам,
Ачык күңел белән эшкә тотынам.

1888.

●

Бөтен җирдә елау, ыңгырашу,
Тоньк тавыш, хәлсез сүз генә.
Язмышыңнан юкка гел зарлану,
Хәсрәт тулы сары йөз генә.

Синең кайгың өчен, Украина,
Туктамыйбыз сыкрау, елаудан.
Без көтәбез, кан-яшь коеп бергә,
Котыласы елны богаудан.

Яраларга яра өстәп тагын
Кан-яшь коя халык күзләре.
Богауларны кан-яшь күгәртсә дә
Өзелмәсләр алар үзләре.

Елап кына коллык нигә бетсен,
Без бергәләп эшкә керешик,
Бергә яулап алыйк киләчәкне,
Якты, яңа көнгә ирешик!

1890.

## Юлым

Юлга чыккач язның башында ук
Тартынып тын гына җырладым,
Очратканда ялгыз юлаучыны
Чын йөрәктән котлап җырладым.
Юлың туры — бергә барганда,
Адашасың ялгыз калганда!

Үзе озын, үзе авыр юл бу,
Ялгыз читен, ялгыз калмыйм мин,
Авыр юлда кеше аз булмый бит,
Яктылыкка ялгыз бармыйм мин.
Ялгыз — юлдан язып каласың,
Бергә булсаң — дөрес барасың!

Алга атлый-атлый җыр чыгарам,
Хикмәт сүзләр анда булмаслар.
Тавышым да көчле түгел минем!
Ә колакка керсә елашлар,
    Бергә елыйк, диеп, юлдашка,
    Мин кушылам үксеп елашка.

Уртаклашсаң газап җинеләя...
Туры килеп озын юлларда,
Ишетсәм мин азат һәм шат җырлар,
Кушылырлар минем җырлар да.
    Ачы хәсрәт белән янмам мин,
    Азат җырга агу салмам мин.

Мин күзәтмим күкнең гөмбәзендә
Яңа яктырткычлар калкуын.
Болыт аша ирек, тигезлекнең,
Туганлыкның телим балкуын!
    Шул өч йолдыз — алтын йолдызлар,
    Кеше өчен яңа мең еллар!

Чәнечкеле киртә очратаммы,
Чәчәк-гөлләр каршы аламы,
Максатыма ирешкәнче юлым
Кинәт туктап, өзелеп каламы,
    Үзем белән, барыр юлымда,
    Бергә булыр минем җырым да!

1890.

## «Моңнар» дигән циклдан

●

Бер тыныч караңгы төн иде.
    Мин сиңа, дускаем, янында
    Өзелеп караган чагымда,
Бер тыныч караңгы төн иде.

Кайгыдан җил тынды бакчада.
    Җырладың, мин дәшми тыңладым,
    Ул җырың йөрәктә чыңлады.
Кайгыдан җил тынды бакчада.

Ажаган кабынды еракта,
    Йөрәгем китте лә калтырап,
    Пычакмы чәнчеде ялтырап,
Ажаган кабынды еракта.

●

Бу җырны җырламыйк, кирәкми,
    Өзмәгез, өзмәгез үзәкне.
Хәсрәтләр торсыннар тын гына.
    Кузгатмыйк газаплы йөрәкне.

Бер сүзсез сез нәрсә аңлыйсыз
    Моңаеп агарган йөземдә?
Хәсрәтле ул җырым әчемдә,
    Кычкырып елый ул үземдә.

Мин бүген яз белән серләштем,
Яз миңа күп нәрсә сөйләде,
Сихерләп карады тын гына,
Чыңлатып бер көен көйләде.

Аннары сөюне, яшьлекне,
Шатлыкны, кайгыны җырлады.
Хыялым күптәннән белсә дә,
Аларны кабатлап тыңладым.

Яшисе иде бер искиткеч җыр булып,
Шунда ук яктырып китәрлек,
Иректә, биектә, киңлектә очарлык,
Яңгырап еракка җитәрлек.

Менәсе иде бер йолдызлар янына,
Көеңне чыңлатып-чыңлатып,
Яшисе иде киң диңгезгә кушылып,
Дулкыннар шикелле җырлашып.

Тик төштә күренгән зур бәхет һәм хыял
Тормышта чыңламый калмасын,
Йолдызлар нурыннан яктырак балкысын,
Дулкыннан көчлерәк шауласын!

Шималда кара төн калыкты
Тылсымлы киң кара җәймәсен
Йоклаган авылга япкандай.
Аҗаган күк йөзен балкытты,—
Тыныч бер тирән күл өстендә
Нәкъ аккош канатын каккандай.

Аккошым канатын кагынып,
Сүнәргә җиткән бу йөрәккә —
Арыган йөрәккә көч бирде.
Ялгызым арыдым көрәштә.
Җырлыйм мин аккошны сагынып,
Күңелгә аккоштан җыр килде.

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәләре

## Җиңү

Елмайды яз җыры, нуры белән,
Яратырга үзен димләде.
Теләмәдем аңа буйсынырга,
Бирешәсем минем килмәде.

Әйттем язга: «Җылың миңа түгел,
Балкымыйсың миңа кирәккә.
Берни бирми синең елмаюлар,
Кап-караңгы булгач йөрәктә».

Ә яз әйтте: «Күр син, әнә ничек
Җир яшәрә миңа буйсынып.
Урманнарда җылы җилем сыйпый
Куакларның зифа буй-сынын.

Бакчада гөл, болыннарда чәчәк —
Минем бизәк болар барчасы.
Йөрим җиргә яшел келәм җәеп,
Күкләрдә мин күкрәү патшасы.

Йөрәгеңнән кара төнне ку да,
Җавап бир син минем җырыма.
Дөньяда бит бөтен тере нәрсә
Йөзе белән миңа борыла!»

Пышылдавым юкка гына булды:
«Ышанмыйм, дип, сиңа, яз җиле» —
Йөрәгемдә кинәт җыр кабынды...
Җиңә алдың, димәк, яз, мине!

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе

# ДӘРДЕМӘНД ШИГЫРЬЛӘРЕ РУС ТЕЛЕНДӘ

Дәрдемәнд иҗаты үзенең нәфислеге белән генә түгел, гаять каршылыклы булуы белән дә XX йөз башы татар поэзиясендә үзенчәлекле урын тота. Соңгы елларда әдәби тәнкыйть, 20—30 еллардан аермалы буларак, «Кораб» авторының иҗатын бөтен катлаулы каршылыгында бәяләргә омтыла, ягъни Дәрдемәнднең иҗтимагый идеалы сыйнфый чикләнгән булуны күрсәтү белән бергә, иҗатының гуманистик һәм сәнгать кыйммәте бәхәссез икәнне дә икърар итә. Шуңа күрә Дәрдемәнд иҗаты белән кызыксыну табигый. Хәлбуки, Дәрдемәнднең гадәти булмаган шигъри синтаксисы хәзерге яшьләргә аңлау өчен шактый кыен. Әле әдәбият фәне өчен дә аның иҗаты һәрьяклап ачылып җитмәгән хәлдә кала бирә.

Менә шушы шартларда Дәрдемәндне икенче бер телгә тәрҗемә итәргә алыну үзенә күрә иҗат батырлыгы дип саналырга лаек.

Дәрдемәнд әсәрләре русча чыкканы бар барын. С. Липкин, Р. Моран, В. Ганиев тәрҗемәләре инде безгә күптән таныш. Алай гына да түгел, С. Липкин 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате унköнлегендә Дәрдемәндне аеруча яратып тәрҗемә иткәнен сөйләгән иде. Тәрҗемә остасы татар шагыйренең иҗат йөзен нечкә абайлаган: ул Дәрдемәнд шигырьләрендә Фетка һәм Тютчевка аваздаш мотивлар күрүен әйтә. Шагыйрьнең иҗаты каршылыклы булуын һәм поэтик мәктәбенең кемнәргә якын торуын дөрес тотып алган ул. Шушы төшенү тәрҗемәләрнең оригиналга якын яңгыравында чагылган. Моңа ышану өчен «Без» яки «Илдә» шигырьләренең тәрҗемәләренә күз салу да җитә. Менә берсе:

**Илдә бер дус булмаса гәр,**
**Ил бөтен дошман түгел.**

**Пусть друга нет в стране ни одного кругом,**
**Но вся страна тебе не может быть врагом.**

Дәрдемәндне тәрҗемә итүгә хәзер республиканың иҗат яшьләре алыну үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Ниһаять, безнең кулыбызда шундый тәҗрибә үрнәге дә бар инде. Сүз әле күптән түгел Татарстан китап нәшрияты рус телендә басып чыгарган Дәрдемәнд шигырьләре җыентыгы[1] хакында бара. Аны С. Хәким һәм Р. Харисов төзегән. Алар элеккеге тәрҗемәләрне дә җыентыкка керткәннәр.

Тәрҗемәче — оригиналның колы түгел, ә шагыйрьнең көндәше яки ярышчысы диләр. Дәрдемәндне тәрҗемә итүдә бу хакыйкать аеруча сизелергә тиеш. Тәрҗемәнең читенлеге шагыйрьнең әле ачылып җитмәгән булуында, дигән идек инде. Бу хәл тәрҗемәчегә үзенчә уку, үзенчә трактовка, үзенчә шәрехләү өчен урын калдыра.

[1] Дэрдменд. Стихи. Перевод с татарского. Татарское книжное издательство. 1970.

Тәрҗемәләрнең бу җыентыгын без әнә шундый «үзенчә укуның» бер үрнәге итеп карарга тиешбез.

Дәрдемәнднең төрле юрауларга сәбәп булган бер шигыре бар:

**Әгәр Лат вә Манат керсә хәрәмгә,**
**Каләм! Гомереңне үткәрмә әрәмгә.**
**Куеп Мәккә, чыгып Йәсрипкә тот юл!**
**Бу бер һиҗрәт... түгел, кәгъбә юлы шул!**

Бу шигырьнең нигезендә мондый метафорик образ ята: Кәгъбәдәге Лат, Манат кебек мәҗүси потларга табынучылар кысуыннан качып, Мөхәммәт пәйгамбәр Мәдинәгә күчәргә мәҗбүр була. Моңа «һиҗрәт» диләр. Тарихтан мәгълүм булганча, бервакыт ул җиңүле ислам гаскәре башында яңадан Мәккәгә кайта һәм кәгъбәне потлардан «тазарта». «һиҗрәт» сүзе кайберәүләрне «шагыйрь эмиграция турында уйламыймы» дигән фикергә дә этәргән. Әмма монда сүз иҗат платформасы хакында бара. Шагыйрь үз фигылен билгеләгән әсәрләрендә үз-үзенә мөрәҗәгать итүчән (хәтерләгез: «Куанды ил...» шигырендәге «Җитәр инде, Дәрдемәнд, сүзне озатма...»), ә монда каләмгә эндәшә. Ягъни каләм хезмәт итеп ята торган мәсләк ялган идеалга илтә икән, мондый очракта ул мәсләкне ташлау бердәнбер дөреслек юлы була, димәкче шагыйрь. Ә тәрҗемәче бу фикерне ничек биргән соң?

**Если язычество в храм ворвется священный,**
**Не разбазаривай время свое драгоценное.**
**Ты углубляйся, перо, в Мекку своих мыслей.**
**Это не бегство — одна из путей к истине.**

(Л. Григорьева тәрҗемәсе.)

Тәрҗемәче «Мәккә»нең кучерелмә мәгънәсен аныклап биргән: «фикерләрең Мәккәсе». Бу шигырьдә бөтенләй булмаган, ләкин Дәрдемәнд өчен хас бер моментны үзеннән өстәгән. «Т ы у г л у б л я й с я, перо, в Мекку с в о и х м ы с л е й». Четерекле очракларда үз эченә бикләнү, үз уй һәм хыял дөньясына чуму Дәрдемәнднең либераль натурасында бар нәрсә. Кыскасы, тәрҗемәче үзеннән өстәгәндә шагыйрьнең гомуми рухына һәм шигырь эчтәлегенә әллә ни хилафлык китермәгән.

Икенче бер мисал.

**Кыеп күкнең йөзен очканда шоңкар,**
**Сала күз авына таулардан аша.**
**Ничек юлдаш аңа байгыш, ничек яр,**
**Күзе нур очкыны күргәндә шаша.**

Николай Беляев аны шулай тәрҗемә иткән:

**Поднебесье сокол режет крыльями,**
**Зорким, сильным быть ему завещано.**
**Никогда с ним не дружить ночному филину,**
**Чьи глаза на солнце вспыхивают бешено.**

Шоңкарның лачын, байгышның ябалак икәнен аңлатып торуның кирәге юктыр. Тәрҗемә шигырьдәге: яктылыкка, биеккә омтылуда гына олы тиңдәшлек булырга мөмкин, дигән идеяне ача, аныклый төшә. Моны ул лачын — ябалак контрастын көчәйтү аша эшли. Тәрҗемәче бу юлда берничә читенлекне җиңә алган. Беренчедән, «Ничек юлдаш аңа байгыш, ничек яр», — дигән юлны өндәү җөмлә итеп, соклану төсмере белән уку куркынычы да бар. Тәрҗемәче аны: «Ничек юлдаш була алсын соң...» — дип дөрес укыган. Аннары яктылык һәм галилекнең түбәнлек, томаналык белән контрастын көчәйтү өчен «лачын» образын «сафландыра» төшкән, оригиналдагы «артыклыктан» арындырган. Чыннан да, «Таулар аша авына күз салу» лачынның мәгърурлыгын гына түгел, ерткычлыгын да күрсәтә.

Без тәрҗемәчеләрдән Дәрдемәнд шигырьләрендәге тирән мәгънәләрне, фикер һәм ис байлыгын гына түгел, ә сәнгатьчә матурлыгын күчерүне дә көтәргә хаклыбыз. сылда боларның бәрсен икенчесеннән аерып алырга мөмкин булмаган кебек, икенэсеннән башка беренчесенә ирешергә дә мөмкин түгел. Поэзиянең сәнгатьчә эшләэше теге яки бу телнең ритмик һәм музыкаль хасиятенә таянганга, аны бер телдән кенчесенә күчерү мөмкин түгел. Ләкин икенче телдә дә адекват чаралар табып ула — һәр телнең ассонанс, рифма (димәк, эчке рифма) кебек музыкаль чаралары ар. Назыйм Хикмәтнең Леонид Мартынов тәрҗемәсендәге мәгълүм шигырен («Кәрәм еби») искә төшерегез әле. Тәрҗемә белән төрекчә оригинал арасында нинди камил индәшлеккә ирешелгән!

Дәрдемәнд шигыренең матурлыгы мәгънә белән форманың тыгыз бәйләнешендә, ваз бизәменең муллыгында, нәзакәтендә.

Дилең өчен телең булсын тозаклы,
Йөз аклыгың өчен аузың йозаклы.
Ил мөмәйез, аңлар ул тиз,
Син аны сизмәс димә.

Эчке рифмалар халык мәкальләрендә дә болай ук ташып ятмый. Шунлыктан мондый шигъри юллар мәкальләр сыман күңелгә уелып кала да.

Безнең тәрҗемәчеләребез исә моны бирүгә ирешә алганнармы? Һәрхәлдә, омтылыш ясаганнар. Менә Николай Беляев тәрҗемәсеннән бер мисал:

Частушкой не части — ни чести в том, ни счастья...
(«Шагыйрьгә» шигыреннән.)

Һәр ритмик буында ч, с, т авазларының уйнап торуы һәм эчке рифмалар шигъри олга җемелдәвек төс биргән. Димәк, Дәрдемәнд осталыгын тәрҗемәгә күчерүнең ачкычы табылган. Кызганычка каршы, мондый үрнәкләр берәмләп кенә санарлык әле. Шушы ук тәрҗемәченең оригиналдагы мәгънәне тирән төшенеп һәм шагыйрьнең образлы телен нигездә саклап башкарган «Прости мне, любимая» һәм «Хаят» тәрҗемәләренә күз салсак, аерым урыннарда рифмага шактый җиңел мөнәсәбәтне күрербез.

. . . . . . . . . . . . . .
О том, как смеялись, играли, любимая,
Не забывай, вспоминай, любимая.
(«Прости мне, любимая».)

Все мои страсти в сладчайщий плен одна улыбка
твоя взяла.

. . . . . . . . . . . . . .
Чтоб на калфак себе, украшеньем, ты хоть одну
взяла.

Рифмалашырга тиешле сүзләрне мин махсус аерып күрсәттем. Чөнки юл азагында бер үк сүзнең кабатлануы татар (гомумән Көнчыгыш) шигырендә үз алдына рифма була алмый, бәлки рифмага рәдиф кенә була ала. Мондый очракта мәсьәләне дөрес хәл итүнең менә бер әйбәт үрнәге:

Песня отчих полей в этом слове живет,
Сила страсти моей в этом слове живет.
(«Отрывок». Вил Ганиев тәрҗемәсе.)

Җыентыкта оригинал белән иреклә эш итүнең төрле үрнәкләре бар. Тәрҗемәчеләр кайчакта үтә кыю тәҗрибә ясыйлар. Бер очракта шигырьнең («Расставание» — «Видегъ») эмоциональ көчен саклаган хәлдә үлчәмен үзгәртәләр, икенче очракта бөтенләй мөстәкыйль ике шигырьне берләштереп куялар. Соңгысының исә акланган очрагы бар, акланмаган очрагы бар.

Дәрдемәнднең шушы ике шигыренә күз салыйк.

●

**Табып ләззәт матур дөнья сүзеннән,**
**Гомерләрдер җилеп йөрдем эзеннән.**

●

**Җилдем, йөгердем, бу җиргә җиттем,**
**Төштем бу чокырга — беттем, аһ! беттем!..**

Ике шигырьне тышкы яктан үлчәм уртаклыгы һәм «җилеп-җилдем» ялгамы бер берсенә якынайта, бәйли. Тәрҗемәче Л. Григорьева шушы тышкы бәйләнеш артында эчке бәйләнешне күреп алган һәм ике шигырьне берләштереп, мәгънәви бөтенлек хасил итүгә ирешкән.

Ә менә «Надежды» («Өмитләр») тәрҗемәсендә Н. Беляевның ике шигырьне берләштерүен берничек тә аклап булмый. «Кил и башчы...» дүртьюллыгын, мәсәлән, «Өмитләр» шигыренә китереп ябыштыру бик ясалма чыккан. Алай гына да түгел, яңа шигырьдә әле телгә алган дүртьюллык башта һәм азакта кабатлана торган строфага әверелгән. Бу дәрәҗәдәге иреклелек, безнеңчә, тәрҗемәче вөҗданына тап төшерәдер кебек.

Шагыйрьнең фәлсәфи-лирик дүртьюллыкларын, афористик икеюллыкларын тәрҗемә итүдә шактый уңышлы омтылышлар ясалган. Аеруча Л. Григорьеваның «Рисунок» («Рәсем») тәрҗемәсендә Көнчыгыш шигыренең колориты яхшы сакланган.

**Тело — белым, груди широкими создал,**
**Завершая лицо, прекрасную родинку создал,**
**Чтобы стан ее стройный уберечь от дурного глаза,**
**Ливень дивных волос, до ступней закрывающий, создал.**

Ләкин бер генә кимчелек эшне боза — ул да булса рифма. Рәдифләр бар («создал»), ә чын рифма тәшкил итүче сүзләр юк. Әйбәт тәрҗемә ителгән кыска шигырьләрдән «Край, в котором родился, рос...», «Не горе, если разорюсь», «Другу, приславшему 1 апреля визитную карточку», «Если можешь...» (Н. Беляев тәрҗемәләре), «Ты на земле» (С. Липкин), «Несчастный осел» (Л. Григорьева), «Язык народа — ухо страны», «Но языки не путай» (М. Зарецкий), «Мольба» (Р. Шагиева) кебек дүртьюллыкларны һәм «Боже...» (Н. Беляев), «О себе» (М. Зарецкий) кебек икеюллыкларны күрсәтергә мөмкин.

Ләкин дүртьюллыкларны тәрҗемә иткәндә шигырь калыбын бозу, симметрияне сакламау тәрҗемәләргә булган гомуми ышанычны какшата. Мәсәлән, «Күзнемнең тамчысы» («О слеза!») дигән дүртьюллык тәрҗемәдә сигез юл булып, «Кыйтга» («Отрывок») — 5 юллы булып чыккан. «Не всякая птица», «Участь моя», «Проповеднику» (Н. Беляев тәрҗемәләре) шигырьләрендә Дәрдемәндкә хас коеп куйган калып, ритмик тәңгәллек бөтенләй югалган. Күрәсең, тәрҗемәче һәм аңа фатиха бирүчеләр шагыйрьнең фикерен тәрҗемә итү җитә дип уйлаганнар. Мондый юлга бассак, Гомәр Хәйямның робагыйларын шәрехли-шәрехли, фәлсәфи поэмалар итеп тәрҗемә кылырга мөмкин булыр иде. Хәлбуки, рус поэзиясенең Жуковский, Державин, Брюсов, Маршак, Ахматова эшләп калдырган тәрҗемә традицияләре Көнчыгыш классикасы белән уңай намуслы эш итү үрнәге булып тора. Тәрҗемәченең таланты шагыйрь әйткән фикерне икенче телгә аның калыбында ук, аның сәнгать куәтенә тиң эмоциональ чаралар белән илтеп җиткерүдә чагылырга тиеш. Ә югарыда телгә алынган башбаштаклык исә, әгәр ул гомуми принцип төсен алса, тәрҗемә практикасында хаоска илтер иде.

Дәрдемәнд шигыренең музыкальлеген саклаган иң әйбәт тәрҗемәләрдән «Колыбельная» («Бәллү») шигырен күрсәтергә кирәк. Р. Моран да оригиналга сукыр иярү юлы белән генә бармый, иҗади тәрҗемә итә. Ул шигырь рухына ятышлы метафоралар таба.

**Колынкаем,**
**Кил, җанкаем,**
**Йоклаек икәү,**
**Йокла, иркә,**
**Йокла, бәбкә,**
**Бәүкәй, бәлли, бәү,—**

дигән өзекне без тәрҗемәдә болай укыйбыз:

**Лэшонок мой,**
**Мышонок мой,**
**Спи, милый, засыпай...**
**Спи, махонький,**
**Спи, яхонт мой,**
**Баю-баю,бай!**

«Тычкан» яки «тычкан баласы» татар телендә бик лирик яңгырый алмас иде. Рус укучысының эстетик зәвыгы исә аны нәнилек, иркәлек гәүдәләнеше буларак сыйдыра. Дөрес, бу тәрҗемәдә дә оригиналдан ераклаша төшкән очраклар бар.

Ә менә оригиналга сүзгә сүз иярүнең кире нәтиҗәсе:

**Овца и с рогами — еще не баран для нас,**
**Не всякая птица зовется орлом у нас.**
**Кто, собственно, в рифму стиха не сложит!**
**Но хромой осел — не Пегас.**

«Кучкар»ның («Мөгезе бар куйның бары да кучкар түгел...») туры тәрҗемәсе чыннан да «баран». Дәрдемәнд куй көтүенең башында тәкәббер басып торучы «мәһабәт мөгезле» тәкәне күздә тота. Рус телендә исә «баран» аңгыралык символы булып йөри. Шуңа күрә «овца» белән «баран» «контрасты» **начар шагыйрь** белән **яхшы шагыйрь** аермасына көтелгән аналогияне бирә алмый. Дәрдемәнд шигырьләрендәге «Кил и...» формасын «приди» («Кил и башчы...» шигыренең «Надежды» тәрҗемәсенә кертелгән юлларын карагыз) дип бирү белән дә шундыйрак хәл. Дәрдемәндтә еш очрый торган («Кил өйрән, әй туган, бер башка телне...», «Кил, әй дустым, хафа булма — бетәр бу...») «кил әй» яки «кил и» формасы һич үз янына чакыруны аңлатмый, бәлки борынгыдан килә торган бер стилистик алым гына. «Кил и башчы...»ны, мәсәлән, «Полководец!» яисә «О полководец!» дип тәрҗемә итү дөресрәк булыр иде.

Дәрдемәндне без сүз кадерен белүче, аз сүзле шагыйрь буларак тәкъдир итәбез. Профессор М. Гайнуллин да җыентыкка сүз башында моны күрсәтеп үтә («Дәрдемәнднең шигъри стиле җентекле эшләнеше, теленең байлыгы, сүзенең төгәллеге белән аерылып тора»). Тәрҗемәдә күп сүзлелек сизелә. Ә артык сүз киттеме — бу инде Дәрдемәндтән ераклашу була.

**Коль не равны у вас богатство и доход.**
(«Твой родственник».)

**О, слеза, поспеши, иди,**
**на цветок души упади,—**
(«О слеза».)

кебек тәрҗемә юлларында «богатство» янында «доход»ның артык икәнлеге, фигыльләрнең күпкә киткәнлеге күренеп тора. Дәрдемәнд исә төшенчәне бирү өчен гадәттә **бер генә** сүз сайлый.

Тәрҗемәдә кайвакыт мәгънәне бөтенләй бозып кую өчен артык бер сүз җитә кала.

Менә Марк Зарецкий тәрҗемә иткән «Корабль» («Кораб») шигыре. Сүз дә юк, тәрҗемә уңышлылардан саналырга хаклы. XX йөз башы татар поэзиясендә зур резонанс тапкан кечкенә күләмле бу шигырьдә һәр сүз, һәр төшенчә исәптә. Шунлыктан тәрҗемәгә кереп киткән артык сүз шундук күзгә ташлана. Ул үзе матур сүз, эмоциональ сүз: «родная».

Волна нагрянет,
Ее кручина
Швырнет корабль страны **родной**...

**Дәрдемәнд:**
Ил корабын җил сөрә...

Менә шушы бер сүз корабның образ көчен юкка чыгара. Дәрдемәндтә кораб образы үзе илне гәүдәләндерсә (шагыйрь «ил» дигәндә халыкны күздә тота), монда туган ил флоты корабларының берсе күз алдына баса. Күрәсез, ничаклы ераклашу!

Н. Беляев тәрҗемәләренә мөрәҗәгать итик. «Проповеднику» («Замана вагыйзына») дигән тәрҗемәнең азагында шундый юл бар:

Весь мир на мусульман и кяфиров
ты готов разделить **мечом!**

Хәлбуки, «кылыч» сүзе Дәрдемәндтә юк. Тәрҗемәче шуны өстәп, XX йөз шагыйрен урта гасырлар җирлегенә күчереп куйган. Кешеләрне диннәре буенча аерып карауны гаепләгән бу шигырь бит «**Замана** вагыйзына» дип атала. Дин мәсьәләләрен кылыч белән чишүнең чоры инде үткәнлеген «вагыйз» да, Дәрдемәнд тә бик яхшы аңлаганнар.

«Время» тәрҗемәсендәге:

«Булат уже **никто** у пояса не носит»,— дигән юлдагы «никто» белән дә шундый ук хәл. Чөнки шагыйрь монда үзен күздә тота. Ягъни «кәмәрләнгән нечкә билдә гайрәтле егетлек билгесе булган кылыч юк инде» («Кылыч такмый кәмәрләнгән конан бил...») димәкче.

«Боже!» тәрҗемәсенә беренче зат алмашлыгы (я) кертеп тә мәгънә бозылган:

Боже! — шептал я, молился древу дремучему.
Думал — цветник, **стою** — перед мусорной кучею.

Өченче затта язылган шигырь беренче затка күчерелгәч, хакны ялганнан, яхшыны яманнан аера белмәүче кеше шагыйрь үзе булып чыккан. Юкса күп тә кирәкмәс иде — «я» урынына «он», «стою» урынына «стоит» дип кенә куясы, һәм шигырь үзенең сатира-һәҗү объектына төбәлгән хәлдә калыр иде.

Басмага кагылышлы кимчелекләрдән шуны әйтәсе килә: рус укучысына аңлашылмый торган сүзләргә искәрмәләр җитеп бетми. Мәсәлән, «Сөләйман» рус укучысы өчен мөселман халыкларына хас гади бер исем генә.

«Дело, достойное Сулеймана»,— дигән юлдан соң («Если можешь» тәрҗемәсе) «Царь Соломон» дигән искәрмә бирелсә, эш бөтенләй үзгәрә. Рус укучысы Сөләйманның, кешеләр генә түгел, барлык җан ияләренең күңеленә юл тапкан мифик Соломон патша, ягъни библия каһарманы икәнен төшенәчәк. Дәрдемәнд аны «Корьән»нән алган.

Җыентыкта мактарлык уңышлар да, күрсәтерлек кимчелекләр дә моның белән генә чикләнми әле. Ләкин хәзергә яңа тәҗрибәнең булуына шатланырга кирәк.

Шул ук вакытта бу тәҗрибә гомумән татар шагыйрьләрен русчага һәм башка әдәбият вәкилләрен татарчага тәрҗемә итүдә гыйбрәт булырга тиеш. Чөнки әле без күздән кичергән тәрҗемә җыентыгы үзебезнең Казанда яшәүче тәрҗемәчеләребезнең татар шагыйрьләре белән хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә дөньяга килгән. Ә тәрҗемәчеләр чит шәһәрләрдә торып, үзәк нәшриятлар өчен шул ук хезмәтне аерым башкарганда тәрҗемә сыйфаты өчен борчылырга тагын да зуррак нигез кала. Менә шуңа күрә дә китап нәшрияты тәрҗемәләрне чыгарганда шагыйрьләр секциясе һәм тәрҗемәчеләр секциясе кебек иҗат коллективлары белән тыгыз элемтәдә торырга тиеш.

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ.

# Журналистика тарихыннан бер сәхифә

Хәзерге газета-журналларны баш мәка-юсез күз алдына китерә аласызмы? Юк-ыр, мөгаен. Чөнки баш мәкалә ул номер-ың байрагы, ул газета яки журналның йөзен билгели, теге яки бу мәсьәләгә кара-а укучының фикерен туплый, аның аңын стерә, тәрбияли.

Баш мәкалә жанры ничек, кайчан, кай-да туган? Аны беренче булып кем язган? Бу сорауларга җавапны күптән түгел Казан дәүләт университеты нәшриятында чыккан «А. И. Герценның баш мәкаләсе» исемле китаптан табарга була. Китапның авторы — журналистика кафедрасы ассистенты А. А. Роот. Рус журналистикасында баш мәкаләнең жанр буларак тууын һәм үсе-шен ул гениаль рус публицисты Александр Иванович Герцен исеме белән бәйләп тик-шерә.

1855 елның 20 августында Лондонда «Полярная звезда» журналының беренче саны чыга. Ул А. И. Герценның тышкы һәм эчке политика мәсьәләләренә багышланган мәкаләсе белән ачыла. Бу — рус журна-листикасы тарихында беренче баш мәкалә. Димәк, чын мәгънәсендә иреклә матбугат һәм аның әһәмиятле жанры баш мәкалә Россиядән читтә туа һәм аңа нигез салучы революционер һәм бөек фикер иясе Алек-сандр Иванович Герцен була. «Полярная звезда» һәм «Колокол»да ялкынлы публи-цист барлыгы йөздән артык баш мәкалә урнаштыра. Ул мәкаләләрдә шул чор идео-логияләренең катлаулы көрәше чагыла, алар буенча А. И. Герценның үз карашла-ры эволюциясен дә күзәтергә була.

Россия шартларында беренче баш мә-кальә 1857 елда «Северная пчела» газетасы-ның беренче санында чыга. Бу — тышкы политика темаларына багышланган баш мә-калә була. Эчке политика мәсьәләләренә караган беренче баш мәкалә «Молва» газетасында урнаштырыла (1857 ел, 12 апрель). Термин буларак та баш мәкалә сүзе шул ук «Молва» газетасында кулла-ныла һәм шул елларда Даль сүзлегендә дә теркәлә. Моннан соң баш мәкаләләр баш-ка газета-журналларда да урын ала башлый. XIX гасырның 70 елларда баш мәкаләләр-не провинция газеталарында да (мәсәлән, Казанда, Одессада, Новороссийскида) та-барга була.

Китапның авторы, XIX гасыр азагына кадәр вакытлы матбугатта чыккан баш мә-каләләрне күзәтеп, шундый нәтиҗәгә килә. Рәсми дәүләт, реакцион һәм либераль прессада 60 еллардан соң баш мәкаләләр-нең язылу осталыгы кими бара. Ә яше-рен — революцион народниклар һәм эшче-ләр матбугатында — киресенчә, баш мәка-ләләр эчтәлек һәм форма ягыннан баеый, камилләшә баралар. Политик публицистика-ның бу жанры марксистик-ленинчыл, боль-шевистик газета-журналларда нык урын ала, көчәя.

Китапта аерым баш мәкаләләргә («По-лярная звезда»да А. И. Герцен, «Земля и воля»да Г. В. Плеханов язган һ. б.) анализ ясала, теоретик нәтиҗәләр практик күрсәт-мәләр белән чагыштырыла.

А. А. Роот хәзерге матбугатка да күзәтү ясый. Баш мәкаләне күңелсез, журналист-ның иҗатын чикли торган жанр итеп күр-сәтергә теләүчеләр белән бәхәсләшә. Баш мәкалә — редакцион мәкалә, шуңа күрә номерның иң яхшы материалы булырга тиеш, жанр буларак аны көчәйтү өстендә эшләргә кирәк, ди автор.

# Якташыбызның уңышы

Җәмил Мостафинның Татарстан язучылары белән иҗади дуслыгы күптәннән килә. Ул аларның әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп Бөтенсоюз укучысына җиткерә.

Татарстан китап нәшрияты Җ. Мостафинның «Кырыс яшьлек еллары» повестен рус телендә басып чыгарды.

Сугыш афәте, Тайшет урманнарындагы янгын һәм Судаковлар йортындагы трагедия әсәрдә бергә үрелеп бирелә һәм укучы күңелендә тәэсирле яңгыраш таба. Пронька, Гоганың әтисе, болан күрә һәм аны атып үтерә. Күршеләр Судаковның җинаятенә гаҗәпләнәләр...

Әсәрдәге вакыйгалар башыннан ахырынача тирән драматизм белән сугарылган. Җәмил, Колька, Гога кебек геройларның характерлары формалашуны мондый конфликтлар аша күрсәтү авторга яңа мөмкинлекләр ача.

Тиздән алар мастерскойларга килеп сугышка киткән әтиләре, абыйлары урыннарына басалар. Никадәр кыенлыклар кичерергә туры килә аларга. Ләкин өлкән иптәшләр — Кузя бабай, слесарь Нуникянов һәм башкалар үсмерләргә ярдәмгә киләләр, аларны эшчеләр коллективында тулы хокуклы булырга өйрәтәләр.

«Кырыс яшьлек еллары» повесте быел СССР язучылары союзы һәм ВЦСПС тарафыннан оештырылган конкурста эшчеләр сыйныфы турындагы әсәрләр арасында кызыксындыру бүләгенә лаек дип табылды.

# Әйбәт традиция

Уфа элек-электән татар культурасының, шул исәптән татар китабының икенче үзәге санала. Әле егерменче-утызынчы елларда да бик күп язучыларыбызның әсәрләре беренче тапкыр шунда дөнья күрә. Сугыштан соң матур әдәбият әсәрләрен татарча басу практикасы вакытлыча тукталып торган иде. Үткән ел бу әйбәт традиция кабат яңартылды: Башкортстан язучыларының әсәрләре татар телендә басылып чыга башлады. Журналыбызның бу санында укучыларны шундый берничә китап белән таныштырып узабыз [1].

**ӘНГАМ АТНАБАЕВ. Пьесалар. Уфа. 1969 ел**

Әнгам Атнабаев шагыйрь буларак та, драматург буларак та әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Татар телендә беренче китабы булган бу җыентыкта аның сәхнә әсәрләре тупланган. Китапка «Ул кайтты», «Ана хөкеме», «Шоңкар» драмалары, «Законлы никах белән» исемле комедиясе кертелгән. Пьесалар җыйнаклык, шигърилек, нәфислек белән аерылып торалар һәм җиңел укылалар.

«Шоңкар» драмасы гражданнар сугышы елларын җанландыра. Вакыйга акгвардиячеләр лагеренда бара. Әсәрдә Шәйхзадә Бабичның фаҗигале язмышы чагыла. Анда акларның мәкерлелеге, икейөзлелеге, халыкка ят, дошман табигате, ерткычлыгы гәүдәләндерелә.

«Ана хөкеме» — Ватан сугышы көннәрендәге вакыйгаларга багышланган әсәр. Драмада илгә, халыкка хезмәт итү, гражданлык бурычы, каһарманлык һәм вак җанлылык, батырлык һәм намуслылык кебек мәсьәләләр кузгатыла.

Үзенең геройлары, күтәргән проблемалары белән «Ул кайтты» драмасы да югарыдагы әсәрләргә аваздаш. Тимербулатның, сугышта әсир төшеп, ерак Америкага илтеп ташлануы, туган җиргә мәхәббәте, тормышының имгәтелгән булуы, һичшиксез, укучыны биләп ала. Аның шул чаклы газап-михнәттән соң да яшәү омтылышын саклап, тимер ихтыяр, ирләрчә акыл белән эш итүе безне үзенә тарта, сокландыра. Драмадагы Мәрзия, Сәгидә, Саҗидә, Шәй-

[1] Теләгән иптәшләр ул китапларны түбәндәге адрес белән сората алалар: **Уфа шәһәре, Октябрь проспекты, 129, Китап йорты, «Китап-почта» бүлеге.**

келислэм кебек образлар да игътибарга лаек. Бу әсәрдә лирик күтәренкелек, шигъри хис өеруча көчле.

Катнашучыларның күп булмавы, катлаулы декорацияләр таләп итмәве белән, бу китаптагы пьесалар авыл сәхнәләре репертуарын шактый киңәйтә ала.

**ӘСГАТ МИРЗАҺИТОВ. Пьесалар. Уфа. 1969 ел**

Әсгат Мирзаһитовның барлык әсәрләре диярлек профессиональ татар-башкорт театрларында куелды, аерым китап булып Уфада башкортча, Мәскәүдә русча басылып чыкты. Һәм менә бу җыентык авторны беренче тапкыр татар укучыларына тәкъдим итә. Китапка «Утлы өермә», «Әниемнең чал чәчләре», «Солдат улы» исемле драмалар кергән.

«Утлы өермә» пьесасында гражданнар сугышы вакыйгалары урын ала. Күн заводлары хуҗасы Карачурин, буржуаз башкорт хөкүмәте вәкиле Мәхмүди, «бердәм, бүленмәс Россия» сагына баскан офицер Зинкевичлар ялчы Ильяс, эшче Денисов, хезмәт иясе вәкилләре Низамов, Нәфисәләр белән рәхимсез бәрелешкә керәләр. Вакыйгалар әле аклар, әле партизаннар штабына күчә, урам сугышлары эчке мәҗлесләре белән алмашына...

Драмадагы вакыйгалар да, типлар да тулы итеп һәм һәр яклап сурәтләнә. Геройлар, шәхес буларак, үсештә күрсәтелә. Низамов, Айсин, Зинкевич, Айтуган Байтиряков барысы да үз холкы, характеры, акылы белән хәрәкәт итә. Автор әсәрендә дәвамлы көрәш елларын оста тотып алган һәм сәнгатьчә итеп сөйләп бирә белгән.

«Әниемнең чал чәчләре», «Солдат улы» пьесаларында кешеләр арасындагы әхлакъ мәсьәләләре яктыртыла. Аларның үзәгенә бүгенге тормыш, замандашларыбызның эшләре, хыяллары куелган. Автор мещанлыкка, мин-минлеккә, түбән омтылышларга каршы чыга.

Шунысы куңелле, Ә. Мирзаһитов үз пьесаларында башкаларны кабатламый, әзер схемалардан һәм штамплардан кача алган.

**ИБРАҺИМ АБДУЛЛИН. Хуш, Рим. Роман. Уфа. 1969 ел**

1941 елгы Бөек Ватан сугышы башланган авыр һәм дәһшәтле көннәр. Ут-гарасат эченә килеп кергән бер төркем совет сугышчылары, тигезсез сугышта җиңелеп, әсир төшә. Аларны ерак Италиягә озаталар. Ләкин совет солдатлары анда да югалып калмыйлар: әмәлен табып, тоткынлыктан качалар, һәм зур кыенлык белән булса да фашизмга каршы көрәшне дәвам итәләр. Ибраһим Абдуллинның «Хуш, Рим» романында сүз әнә шул вакыйгалар турында бара.

Роман үз укучыларын табар дип ышанырга кирәк. Алар анда Ватан азатлыгы өчен барган көрәшнең яңа сәхифәләре белән очрашачаклар. Барыннан да бигрәк, әсәр үзенең материалы һәм яңа геройлары белән игътибарны җәлеп итә. Фашизмга каршы көрәш бөтен дөнья халыкларын бердәм сафка туплады. Ибраһим Абдуллин романында итальяннар Орландо, Джулио, татар солдаты, комиссар Мифтахов, руслар А. Флейшен, Л. Колесников, башкорт Илхуҗа һәм башка антифашистлар зур мәхәббәт белән тасвирлана.

**Булат Галиев**

# ТӨСЛЕ ТАВЫШ СӘНГАТЕ

*1967 елның 21 октябрендә Кремльдәге Съездлар Сараенда илебезнең иҗат эшчеләре союзларының Бөек Октябрьның 50 еллыгына багышланган берләшкән пленумы булып үтте. Җыелышны СССР язучылар союзының беренче секретаре Константин Федин ачты. Аның речендә түбәндәге сүзләр бар иде:*

*«...Язучыларга, сынлы сәнгать эшчеләренә һәм музыкантларга үзен художество чарасы итеп танытырга өлгергән «синтетик тойгылар»ны совет фәне практик яктан тикшерә башлады. «Тавышны күрү» мәсьәләсе хәзер галимнәрне үзенә тартканнан-тарта бара. Әмма бу мәсьәләнең игътибарга лаеклы ягы шул: аның белән әдәбият һәм музыка белгечләре генә түгел, ә техника фәннәре белгечләре дә шөгыльләнә. Менә сезгә кечкенә форматлы анкета. Аңа: «Шагыйрьләргә «күренгәли» торган нәрсәне, махсус инструментлар ярдәмендә, күренмә музыка белән композицияләп күз алдына китерү буенча берничә тәҗрибә ясалды»,— дип язылган».*

*К. Федин әйтеп үткән «төсләрне ишетү» турында бу анкета — СССР иҗат союзы члeннары: язучы, кинематографист һәм музыкантлардан 25 меңләп кешегә Казан шәһәреннән җибәрелгән анкета иде. Казан авиация институты каршындагы «Прометей» исемле конструкторлык бюросы анкетага язылган җавапларны тикшереп чыкты һәм тикшерүне дәвам иттерә. Анкеталар турында өч конференциядә сүз барды[1].*

*Авиация институтының музыка мәсьәләсенә нинди бәйләнеше бар соң? Җитмәсә тагын конструкторлык бюросы ни өчен андый сәер исем белән йөртелә?*

*Моңа җавап биргәнче, бер-ике газетаның вакыт үтүдән саргайган битләренә күз төшереп чыгыйк.*

*1912 елның язында Казан шәһәренә атаклы композитор Александр Николаевич Скрябин гастрольгә килә. Шул турыда «Русская музыкальная газета» менә нәрсәләр яза:*

*«...Дворянское собрание (хәзерге офицерлар йорты) залы яртылаш кына иде. Казан публикасы пианист-композиторны шактый салкын каршылады. Дөресен генә әйткәндә, башкача булырга мөмкин дә түгел иде. Чөнки Казан халкына музыкаль тәрбия аз тәэсир итә».*

*1962 елның язы. Скрябинның Казанда булып киткәненә илле ел вакыт үткән. Казан авиация институтының Актлар залы.*

*«Советская Татария» газетасы анда булган вакыйга турында болай яза:*

*«...Ут сүнде. Залда утырган йөзләрчә тамашачы кинәт тынып калды: капылт кына экранның бер кырыена күз камаштыргыч нур сибелде. Нур экран буенча салмак*

---

[1] «Литературная газета». 1967 ел. 25 октябрь; «Доклады VI Всесоюзной акустической конференции». Мәскәү, 1968 ел; Тезисы и аннотации симпозиума. «Проблемы художественного восприятия». Ленинград. 1968 ел; Тезисы и аннотации конференции «Свет и музыка». Казан. 1969 ел.

*ына хәрәкәт итте һәм бер моментта бу шомлы нур югары-кран кырыендагы портретны яктыртты. Яктылык шул урында тукталды һәм шунда ук репродуктордан: «Бүген, 1962 елның 6 апрелендә, бөек композитор Александр Николаевич Скрябинның «Прометей» исемле симфоник поэмасы Советлар Союзында беренче тапкыр якты белән бергә үрелеп башкарылачак!» — дигән мәһабәт тавыш ишетелде.*

*Музыканың беренче авазлары түбән һәм салмак иде. Тавышларга органик бәйле рәвештә күе зәңгәр төс экранда дулкынлана башлады. Залның стеналары аңа тоныкрак якты белән җавап бирде. Тавыш үскән саен экран да яктырганнан яктырды. Ярсыган көрәш авазлары залга сыеша алмады, яңгыраш артканнан артты. Залның стеналары, күз чагылдыргыч кызыл төсне көчәйткәннән көчәйтеп, тавышның тәэсирен үстерде».*

*Скрябинның «Прометей» исемле симфоник поэмасы, композитор хыялындагыдай булып, СССРда беренче мәртәбә концертта яктылык нурлары белән бәйләнештә башкарылды. Шуның өчен дә «Прометей» конструкторлык бюросы үзенең исеме өчен Скрябинның поэмасы каршында бурычлы.*

*Шуннан бирле Казанда шактый гына концертлар үткәрелде. Ул концертларда Римский-Корсаков, Стравинский, Яруллинның музыкалары «күрсәтелде». Шул ук бюро тарафыннан берничә яктылы музыка инструментлары ясалды. «Прометей» җитәкчелегендә берничә яктылы музыкаль фильмнар төшерелде. Тәҗрибәләрнең кайберләре ачык һавага чыкты, шәһәр архитектурасы белән бәйләнде.*

*Фәнни-тикшеренү эшләре дәвам иттерелде һәм итә. Советлар Союзы масштабында «Якты һәм музыка» темасы буенча ике конференция тикмәгә генә Казанда үткәрелмәде.*

*«Казан утлары» журналы редакциясе бу санда «Прометей» СКБсының җитәкчесе Булат Галиевнең СССРда һәм чит илләрдә яктылы музыка тәҗрибәләре турында язган мәкаләсен укучыларга тәкъдим итә.*

Борынгы грек легендасы раслаганча, Прометей кешеләргә ут алып килгән. Хәзер инде кешеләр Прометейның үзенә ут тәкъдим итәләр.

«Colour music company» фирмасы президентының Токиодан җибәргән хатында (оригиналы конструкторлык бюросында) мондый сүзләр бар:

— ...Мин, Минору Хонда, сугыш вакытында Хиросима шәһәрендә идем. Мин анда дөньяны җимерүче һәм кешелек җәмгыятенә пычрак ыргыткан атом бомбасының шартлавын үз күзем белән күрдем. Яшен һәм гөмбәсыман болыт! Төрле төстәге матур утлар дөньясы! Бу күренеш миндә шундый тәэсир калдырды: хәтта мин аны гомеремнең соңгы көннәренә кадәр оныта алачак түгелмен. Шул моменттан башлап диярлек, мин үземнең гомеремне дөньяда тынычлык юлларын эзләү эшенә багышладым. Хиросима өстендәге күк йөзе коточкыч куркыныч, һәм шул ук вакытта коточкыч матур да иде. Шуңа күрә мин, тынычлык теләге белән илһамланып, үземнең барлык гомеремне чын-чынлап матур төсләрне һәм музыканы иҗат итү эшенә багышларга сүз бирдем».

Бу сүзләр, әлбәттә, шагыйрь кешегә иҗат азыгы була ала. Ул бит әзер образ. Бу образда безнең заманның катлаулы һәм аяусыз чынбарлыгы чагыла.

Прометей кешегә бүләк иткән ялкынның, контрольгә буйсынмыйча, кешеләрне яндыруы, харап итүе, я булмаса, художникның иҗади ихтыярына баш иеп, кеше тормышының һәр өлкәсендә, шулай ук сәнгатькә дә хезмәт итүе мөмкин.

«Коточкыч, куркыныч матурлык!». Дөрес, хәзерге көндә музыка белән яктылык нурлары синтезы өстендә эшләүче кешегә «Прометей комплексы»ның андый «коточкыч куркыныч» булып күз алдына килмәве дә мөмкин.

Әйтик, берәү, поезд тәрәзәсеннән карап барганда, кояш баткач, тегермәч тавышларының үзгәрүен ишетеп, гаҗәпләнеп куя, икенчесе исә, тирәнрәк уйлап, музыканы рәсемгә төшереп булмасмы икән, дигән сорауга җавап эзли.

Бер үк фикер төрле кешеләрнең аңында төрлечә формалаша.

Скрябин бервакыт дуслары белән сөйләшеп утырганда: «...Тавышны ишеткән вакытта сездә шул тавышны «күрергә теләү» тойгысы уянмыймы? Сезгә тавышлардан төсләр барлыкка килгән кебек булып күренмиме?» — дип сораган. Башка күп кенә

композиторлар кебек, аның да «төсләрне ишетү», музыканы (конкрет алганда, билгеле бер тональлекнең төсләр бирүен) «күрү» сәләте булган. Рус композиторы, музыка дөньясында беренче буларак, үзенең бу фикерен тәҗрибәдә сынап карарга булган һәм шул эшкә керешкән. Шуңа күрә дә аның иҗатына күпчелек замандашлары киная белән караганнар, ә хәзерге буын аны зурлый. Ул үзенең «Прометей» исемле симфоник поэмасының партитурасына (күп тавышлы музыкаль әсәрдәге аерым партияләр өчен булган ноталарына) музыкаль тональлекнең үзгәрешен күрсәтүче мөстәкыйль «Luce» (яктылык) партиясен кертқән һәм бу поэмасына «Ут поэмасы» дип исем биргән.

Анатолий Васильевич Луначарский, Скрябин үлгәннән соң берничә ел үткәч, аның әсәрләре белән танышкан һәм: «Без, революционер буларак, киләчәк заманнан революцион дәрт белән тулы гигант җырлар көтәбез. Ләкин моңа кадәр әле без рус музыкасында гына түгел, бөтен дөнья музыкасында да Скрябинның «Прометей» кебек һәм шуңа охшаш дәртле музыкаль әсәрләрне күрә алганыбыз юк»,— дигән.

Композиторның нәкъ менә шушы әсәренә, композиторның үзе әйткәнчә, «Ут поэмасы»на, яңа сәнгатьнең беренче әсәре булу насыйп булды.

Кыю адым ясаган композитор! Ул моңарчы дөньяда булмаган «яктылык органы»н («tastiera per luce») гадәттәге оркестр составына кертте.

Скрябинның әлеге әсәренә кадәр булган сәнгатен һәм иҗат тарихын тикшереп чыксак, композиторның бу әсәре аның биографиясендә очраклы бер эпизод кына булмыйча, объектив зарурлыкның чагылышы икәнен күрербез.

Соңгы гасырда сәнгать һәм жанрларның, үз эчендә бик нык дифференциацияләнүе белән бергә, сыйфат ягыннан да яңача синтезлауга (шуңа охшаш хәл фән дөньясында да бар) омтылышы да ачык сизелә.

Бу процесс әкренләп үсә бара. Шагыйрьләр дә тойгыларын гадәттәгедән башкачарак юл белән синтезларга мөмкин икәнен әйтеп килделәр:

**Флейта тавышы таң кебек зәңгәрсу,**
**Балалар тавышыдай мөлаем һәм нечкә;**
**Барабанныкы исә, тонык, кытыршы һәм ярсу,**
**Литавр тавышы тантаналы һәм алсу.**

(К. Бальмонт. «Томанда» сонеты.)

Шагыйрь тавышны ишетеп кенә калмый, ул аны «күрә».

«Алар — шәмәхә һәм кызыл төстәге хәтфә ямаулар — куе тавыш белән җырладылар».

(И. Бабель. «Король» хикәясе.)

«Берсе утлы-яшелле тавыш белән булса, икенчесе утлы-кызыллы тавыш белән җырлады»,— дигән гади җөмләләр безне гаҗәпләндерми.

«Тавышларны күрү» — ул синестезия (куш тойгы) дигән үзлекнең бер төре. Бу үзлек һәр кешедә булмаса да, сүз художникларының барысына да хас дисәк, ялгышмабыз кебек. Куш тойгылы булу сәләте нинди дә булса даһи кешенең генә капризы дип уйлау дөрес түгел.

Синтетик тойгы — ул, безнең барлык сизү органнарыбызның даими рәвештә берберенә тәэсир итешүе нәтиҗәсендә, танып беленгән дөньяны комплексլы хәлдә күзаллау.

Психологлар синестезияне мөмкин хәл һәм аны куш тойгылар ассоциациясе дип исәплиләр.

Шуның белән бергә, тавышны төсләр, күренмәс сызыклар һәм формалар белән чагыштыру сәләте шагыйрьләргә генә хас нәрсә түгел, ул безнең һәрберебездә дә булырга мөмкин. Юк исә шагыйрьнең:

**Самолет очып китте.**
**Аның артында**
**Билгеле бер ераклыкта**
**Буксирга тагылган кебек**
**Туры почмаклы,**

Артка калган
Тавышы очты,—

(А. Вознесенский. «Оза» поэмасы.)

диган шигырьдәге фикерен аңлый алмас идек.

Метафораны реаль, «җитди» итеп аңларга һәм «флейтаның» таңдай, «күгелҗем» һәм «туры почмаклы тавышлар»ын күрсәтә торган сәнгать итеп күз алдына китерергә мөмкин түгелме? Купринның «Юнкерлар» хикәясендә мәхәббәт белән исергән егет болай хыяллана:

«...гаҗәеп матур вальс агыла бирде. Күз камаштыргыч утларның яктысы эчендә кемнеңдер иксез-чиксез күп бриллиантларны чәеп уйнаганы һәм киң күгелҗем хәтфә җәеп, аның өстенә югарыдан бик күп ялтыравыклар сипкәнен күз алдына китерде».

Менә шуның кебек күренеш реаль экранда реаль төсләр ярдәме белән күрсәтелсә, гүзәл булмасмы икән?

Ләкин очраклы рәвештә генә килеп чыккан барлык якты-тавыш метафораларын формаль, хәрефкә хәреф күрсәтү яңа сәнгать була алмый. Яктылы музыканың килеп чыгуы һәм аның үзенчәлекләре катлаулырак һәм тирәнрәк.

Әгәр XX гасыр башында музыканың һәм сынлы сәнгатьнең нинди хәлгә килеп җитүен тикшерсәк, ул үзенчәлекләрне аңлау җиңелрәк булыр.

Сынлы сәнгатьтә бу вакытта импрессионистлар, Чюрленис һәм башка художниклар форманың һәм төсләрнең, музыка шикелле, кешегә турыдан-туры тәэсир итүенә омтылалар.

Дебюсси, Римский-Корсаков һәм Равель, үзләренең әсәрләренә яңа тембр, яңа гармонияләр кертеп, тавышлар белән сурәтләү юлын табалар.

Сәнгатьтәге шул эзләнүләр Скрябинга «Ут поэмасы»н язарга нигез була.

Тарихтан хәбәре булган кеше моннан өч йөз еллар элек яшәгән монах Кастельның төсләр музыкасының беренче теориясе турында чыгыш ясаганын белсә кирәк. Хәтта ул музыкаль гамманың һәр нотасын спектрдагы аерым төсләр белән бәйләгән. Ул «төс клавесины»н ясаган имеш, дип тә әйтәләр. Ләкин бу төс белән тавышны физик (аның ялгышы да шунда) чагыштыруның сынлы сәнгатькә һичбер бәйләнеше юк. Кастельдан Скрябинга кадәр булган чор эчендә әлеге әләргә охшаш «теорияләр» шактый гына күп булган һәм андый механистик фикерләрдән файдалы нәтиҗә чыкмаган. Алар нәтиҗәсез хәлдә схоластика сазлыгына батып калганнар.

Яңа сәнгатьтә эстетик принципларның үсүе (һәм аның кирәклеге) материаль-техник мөмкинлекләрнең үсүе белән диалектик бердәмлектә. (Аның шулай икәнлеген кинематографның барлыкка килүендә дә күрергә мөмкин.) XX гасыр башына таба гына сәнгатьтә һәм техникада бу мәсьәләне конкрет тәҗрибәдә сынап карарга мөмкин булды. Скрябин моның кебек кайсыбер «теорияләр»не белгән булса кирәк. Ләкин, сәнгать кешесе буларак, ул аңа игътибар итмәгән.

Үзенең төп фәлсәфи идеясе ягыннан да, шулай ук формасы ягыннан да «Прометей» гаҗәеп әсәр. Аның язмышы да гадәттәгечә түгел.

Егерменче еллардагы бер шагыйрь үзенең «Утопия» дигән әсәрендә: «1984 елда «Прометей» Россиянең гимнына әверелачәк һәм ак таш кала — Мәскәүнең барлык кыңгыраулары бәйрәм көннәрендә аны уйнаячак...» — дип әйтә.

Моннан утыз еллар үткәч, зәңгәр тышлы калын энциклопедия «Прометей»ны артык катлауландырылган модернистик әсәрләр рәтенә кертте.

Еллар уза торды.

Ниһаять, «Ут поэмасы»ның да чын кыйммәте ачыкланды. Юк, «Маяк» радиостанциясе ак таш кала урамнарын «Прометей» әсәрләреннән парчалар уйнап уятмый, аны хәтта хәзер дә әле һәр оркестр башкара алмый.

Бу әсәрнең артык катлаулы булуы модернизмнан түгел. Ул халыктан музыкага аеруча дикъкать таләп итә торган тирән һәм кирәкле катлаулылык икән.

«Яктылык симфониясе»нең язмышы «Прометей»га караганда да каршылыклы була. Нәрсә соң ул «Luce» ноталары? Хәтта композиторның якын дуслары һәм хезмәттәшләре дә бу сорауга җавап таба алмаган. Мәсәлән, Танеев: «Сезнең симфониягез бенгаль утлары белән башкарылачакмы?» — дип, кинаяле сорау биргән.

1911 елны «Прометей»ның партитурасы басылып чыга. Композиторның замандаш-

...Скрябинның Мәскәү музыкантларын үзенең партитурасы белән таныштыруы һәм алар арасында С. В. Рахманиновның да булуы турында түбәндәгечә язалар:

«Прометей»ның беренче аккорды Рахманиновны таңга калдырды, хәтта соклandырды да. Ләкин бераздан... тәрткеле сүзләр... аптыраганнан җилкә селкетүләр... мыскыллы елмаюлар күбәйде.

Сергей Васильевич «tastiera per luce» турында ирония белән: «Бу музыканың бу урынында төсе нинди?» — дип сорады.

Аңа каршы Скрябин: «Музыкасы түгел, Сергей Васильевич, тыңлаучыны уратып алган атмосферасы! Атмосферасы миләүшә төстә»,— дип җавап бирде.

Рахманинов, аяусыз рәвештә, композиторның башына чиләклап-чиләклап салкын суны сибә бирде. Ахырда Скрябинның да чыдамы шартлады, ачу белән партитурасын япты, уенны туктатты да теләгән кешеләрне кич белән өенә «Ут поэмасы»н тыңларга чакырды һәм музыканы кабинетында ясалган яктылык клавиатурасы белән үзе башкарачагын әйтте».

Андый кулдан гына ясалган гади «tastiera per luce» белән нәрсәне исбат итәргә мөмкин иде соң? Бернича елдан соң Нью-Йорктагы бер фирма Карнеги-Холның концерт залында «Прометей»ны беренче тапкыр яктылык белән бергә башкарыр өчен махсус инструмент ясау өстендә эш алып бара. Менә 1915 елда булган бу концертны тыңлаган «The musical courier» («Музыкаль курьер») журналы күзәтүчесенең язганы:

«...«Прометей»ны уйнаганда тамаша залында ут сүнгән иде. Уйнаучы музыкантларның башы аркылы, эстрада артындагы экранга, музыкага һичбер бәйләнеше булмаган төрле төстәге якты сызыклар һәм якты таплар төшә башлады».

Инженерлар эшләренә алган бурычларын үти алмыйлар, яктылык аларның ихтыярына буйсынмый. Тамашачылар исә техника ягыннан ярлы булган инструментларның нәтиҗәсен Скрябин фикеренең «чиле-пешле» икәнлегенә сылтап калдыралар.

Әлеге күзәтүче болай дип сүзен дәвам итә:

«Скрябин, бәлки, сәнгатьнең масштабын киңәйттем, дигән хыял белән эшләгәндер... Тамашачының кадаклар өстендә яки кызу мич өстендә утырганда, шигырьне аңлау яки аның турында фикер йөртә алу дәрәҗәсе буламы соң!.. Мондый кинәт кабынып китә торган, тынычлык бирми торган төсләр музыканы тыңлар өчен дикъкатьне тупларга мөмкинлек тудырмый».

«Прометей»ны Англиядә, Россиядә башкарганда да шундый ук хәлләр кабатлана. Ләкин яңа туып килә торган сәнгатьнең язмышы аерым кешеләрнең фикеренә һәм аерым уңышсызлыкларга карап хәл ителми. Халыкның эстетик теләкләре художникларны XX гасырда дөньяга килгән техник чараларның барысын да кулланырга мәҗбүр итте. Тормыш таләбе буенча эшләнергә тиешле булган экспериментлар Россиядә дә, чит илләрдә дә дәвам итә бирде. Менә аның кыскача үсү тарихы:

**1910 ел.** «Прометей» («Ут поэмасы») барлыкка килде.

**1912 ел.** Лондонда А. В. Римингтонның «Colour music» исемле китабы басылып чыкты.

**1913 ел.** Нижний-Новгородта Д. Хмельницкий «Төсләр белән тавышларның охшашлыгыннан файдаланып, инженер һәм художникларның фикерләрен гомумиләштерү, музыка-төсләр комбинациясе юлы белән эстетик ләззәт алу турындагы омтылышлар» исемле китап язды һәм бастырып чыгарды.

**1913 ел.** Күренекле композитор А. Шенберг «Бәхетле кул» дигән пьеса язды. Автор үзенең хезмәтендә: билгеле бер киеренкелеккә җиткән тавыш яктыга әверелергә тиеш, дигән нәтиҗә ясады.

**1914 ел.** Скрябин барлык сәнгатьләр синтезы булган «Мистерия» дигән әсәренең «Кереш пәрдәсе» өстендә эшләргә керешә. Аның фикеренчә, бу әсәрне башкаруга бөтен дөнья катышырга тиеш. Икенче елны, композиторның үлеме аркасында, әсәр тәмамланмый кала.

**1914 ел.** Художник В. Кандинскийның сәхнә композициясе турындагы тикшеренүе нәтиҗәләре басылып чыкты. Анда автор, Скрябин фикерен кабатламыйча, «Монументаль сәнгать» (өзлексез дәвам иткән симфониядә хәрәкәттәге кеше, төсләр, үзгәрүчән тавышлар бер-беренә үрелеп бару) идеясен алга куя.

**1917 ел.** «Оптик музыка»ны барлыкка китерү өчен кинематограф чараларын файдалану турында беренче омтылыш. (Швециядә В. Эггелинг.)

**1917 ел.** Шагыйрь К. Бальмонтның «Табигатьтә яктылы-тавыш һәм Скрябинның яктылык симфониясе» исемле китабы басылып чыкты.

**1919 ел.** Петроград композиторы В. Щербачев «Яктылык пластикасы» партиясен кертеп инструменталь әсәр язды.

**1921 ел.** Америка музыканты Т. Вилфред «Клавилюкс» дигән инструмент ясады һәм аның белән үзе язган яктылык композициясен башкарды.

**1922 ел.** Инглиз художнигы А. Клейн үзенең беренче «Яктылык органы»н ясады һәм берничә елдан соң бу турыда зур монографиясен бастырып чыгарды.

**1923 ел.** Мейерхольд театрында һәм Зур театрда художник В. Баранов-Россинэ «Оптофон» дигән яктылык инструментын тамашачыга күрсәтте.

**1923 ел.** Художник А. Лентулов Зур театр декорацияләрен һәм яктылык техникасын файдаланып, Скрябинның «Прометей»н сәхнәгә куйды.

**1925 ел.** Венгр пианисты А. Ласло Киль шәһәрендә үткәрелгән бөтен Германия фестивалендә үзе ясаган «Яктылык фортепианасы»нда үзенең әсәрләрен уйнады.

**1926 ел.** Данлыклы Л. Стоковский Римский-Корсаковның яктылык белән башкарылган «Шәһризадә» исемле әсәренә Филадельфия оркестрында дирижерлык итте.

**1927 ел.** Гамбургта яктылы-тавыш синтезына багышланган конгресс уздырылды...

Хәзерге көндә синтезланган яктылы-тавышны практикада файдалану шактый югары баскычка менде. Шуның нәтиҗәсендә киләчәктәге музыка һәм яктыны синтезлау проблемасының максатларын ачыкларга һәм ул проблемаларны хәл итүче күренешләрне дифференцияләргә мөмкинлек туды.

Менә ул төп юнәлешләр:

**1. Махсус музыка залларында башкару өчен яктылы-музыка инструментлары ясау.**

Казанда 1962 елдан бирле меңнәрчә кеше «Прометей» СКБсы оештырган яктылы концертларны карый. Харьковтагы М. Горький исемендәге Үзәк ял паркының махсус яктылы музыка залы системалы рәвештә концертлар оештыра. Озакламый Мәскәүдә электроник музыка эксперименталь студиясендә махсус ярымтүгәрәк зал эшли башлаячак. Казанда күп тамашачыны сыйдыра торган концерт залы салу күздә тотыла.

**2. Яктылы музыкаль фильмнарны махсус залдан гадәттәгечә кино күрсәтә торган залларга күчерү.**

Безнең илдә бу юлда, яктылы музыка сөючеләр кулында булган мөмкинлекләрдән файдаланып, Скрябинның «Прометей» фильмы төшерелде (режиссеры Б. Галиев, Казан). Бөтенсоюз масштабындагы Икенче конференциядә Киевтәге «Довженко» киностудиясе популяр симфоник, бию һәм эстрада музыкаларын күрсәтте. Шунда ук Казанлылар «Мәңгелек хәрәкәт» дигән икенче картиналарын (Э. Варез музыкасы) делегатларга тәкъдим иттеләр. Чит илләрдә яктылы музыкага якын итеп эшләнгән кинофильмнар рәтенә канадалы Н. Маклареннның «Горизонталь сызык», «Җемелдәүче бушлык» һ. б., немец О. Фишингерның «Күк төсле рапсодия», «Венгр рапсодиясе», «Сихерче шөкерте», француз Ж. Митриның «Дебюсси образлары», америкалы У. Диснейның «Фантазия»сен, Ф. Стоффайкерның, М. Э. Бьютның һәм башкаларның кинофильмнарын кертергә мөмкин. Яктылы музыка эффектларын нәфис, документаль һәм реклама киноларында (СССРда — «Айболит-66», «Композитор Арам Хачатурян», «Җанварлар карнавалы», «Лачыннар турында җыр», АКШта — «Вестсайд тарихы», «2001: Космос одиссеясе») уңышлы рәвештә файдалана башладылар. Яктылык музыкасы эффектларын төсле телевидениедә дә киң кулланалар.

**3. Яктылы музыка кинетик һәм декоратив бизәү сәнгате булган «биюче яктылык» дигән автоматик җайланмаларны конструкцияләгәндә киң кулланыла.**

Ул җайланмаларда яктылык эффектлары динамикасын билгеле бер программа буенча музыка үзе идарә итә. Ул җайланмалар радиола һәм магнитофонга өстәләләр.

Аңа охшаган декоратив бизәү эшләрен үтәр өчен «бии торган яктылык» җайланмасын тавышсыз да ясарга мөмкин. Моңа мисал итеп Мәскәүдәге «Движение» («Хәрәкәт») исемле художниклар группасы эшләрен күрсәтергә була.

Күләме зур булган мондый «яктылы музыка панельләре» һәм «яктылы панельләр» җәмәгать биналарының эчке ягын гаҗәеп матур итеп бизәргә ярдәм итә ала. Мәсәлән, шундый электроник җайланма яңа салынган «Татарстан» гостиницасында эшли.

«Бии торган яктылык» җайланмасы ролен пыяла һәм бетоннан ясалган биналар

уйный алачак (Бельгия, Льеж шәһәрендәге Н. Шеффер оештырган «Тавыш, яктылык, формалар» спектакле, 1961 ел).

**4. Автоматик җайланмаларны куллану эксперименталь эстетика, инженерлык һәм социаль психологиянең кайбер мәсьәләләрен чишү өчен әһәмияте булачак.**

«Филипс» фирмасы Н. Шефферның «Яктылы панель»ен предприятиеләрдәге фойе һәм ашханәләр өчен сериялап чыгара башлады.

Психологлар бертөсле хезмәттә һаман-һаман эшли биргән кешеләрдә була торган «тою ачлыгы»н киметер һәм эш сәләтен арттырыр өчен югарыда әстәлгән «яктылы панель»нең радикаль чара икәнен исбат итәләр.

Әле әйтелгән принцип һәм җайланмалар башка урыннарда да, мәсәлән, радиолокацион станцияләрдә, электр станцияләрендә кулланыла. Ул космик кораблар эчендә дә кулланылса, бер дә гаҗәп түгел.

**5. Үзенең тәэсире һәм рентабельлеге ягыннан кинематографтан аз гына да калышмый торган театрлаштырылган «Яктылык һәм Тавыш» спектакльләре хәзерге көнне бөтен дөньяда киң колач ала бара.**

Маяковскийның: «Урамнар — безнең пумалабыз, мәйданнар исә — палитраларыбыз», дигән сүзләренә без күнеккәнбез, аны яхшы аңлыйбыз инде. Чынлап та бәйрәмнәр вакытында, самолеттан карaганда, шәһәр мәйданнары чәчәкләр бәйләменә охшый.

Ләкин башкача булырга: мәйданнарның театрга, өйләр, урамнарның катнашучыларга әйләнүе, тамашачының үзенең дә вакыйганың үзәгендә кайнавы, актерга әйләнүе дә мөмкин.

Соңгы елларда дөньяда гадәттә булмаган яңа сәнгать тамашасы — «Яктылык һәм Тавыш» спектакленең гражданлык хокукына ия булып баруы күренә.

Күз алдына китереп карагыз:

Кич, тынлык. Сез үзегезне ак колонналы Казан университеты каршындагы бронзадан коелган яшь Ульянов басып торган мәйданда дип хис итәсез.

Акрын гына, яктырганнан яктыра баручы нур бина кашагасындагы, патша заманындагы тәреле таҗны тоткан кара кошны һәм «Император университеты» дигән язуны яктырта. Репродуктор: «1887 ел, 4 декабрь»,— дип игълан итә. Караңгылыкны ярып, тавыш белән бергә, яктылык бөркелә. Бина вестибюлендә уннарча аяк тавышлары, ишекләрнең ачылу һәм ябылу тавышлары ишетелә. Алда: «Сходкага!», янда: «Безнең белән!»... «Ура!», «Ректорны бирегә!» — дигән авазлар.

Болар унҗиде яшьлек Ульяновның беренче революцион маршруты авазлары.

Әнә, икенче катта, Актлар залы ишеге ачыла һәм аның тәрәзәләре яктыра башлый. Тәрәзәнең тупсалары шыгырдавына кадәр колакка керә. Тәрәзәдән студентлар сходкасын оештыручылардан Николай Алексеевның: «Ура! Без җиңдек, ура!» дип кычкырган авазы яңгырый. Әмма тәрәзәләр ябык, тәрәзәдә берәү дә юк.

Бу безгә күренми торган итеп яшерелгән репродукторлар авазы. Гүя бинага җан кергән, ул яңарган тарихи истәлекләр белән гөрли.

Бердәм схемалы аппаратура, режиссер командасына буйсынып, үткән гасырда булып узган вакыйгаларны, чынлыкта булган тавыш атмосферасын җанландыра. Анда бер генә актер да катнашмый.

Ә мондый спектакльләрнең көче нәрсәдә соң?

Аларның көче шунда: без хәзер **шул вакыйгалар** булып үткән урында: **шул заманда** бина диварлары шаһит булган тавышларны без дә ишетәбез.

«Властьларның миңа биргән вәкаләте нигезендә боерык бирәм, таралыгыз!..» — Бу инде көчсезлеге аркасында хурлыкка калуы белән шөһрәт алган бичара инспектор Потаповның, яңагына бер студент менеп төшкәч, кычкырган авазы.

Ватылган пыяла чыңнары, бина янына килгән полицейскийлар кычкырышуы, университет студентларына ярдәмгә килгән ветеринария институты студентларының ярсулы тавышлары...— боларны без бик реаль итеп күз алдына китерәбез.

Бу сәнгать гадәттәге театр уеннарыннан нәрсәсе белән аерыла соң?

Ягез менә, югарыда сөйләгәнне чынлыкта гамәлгә ашырып карыйк: әйтик, уйнаучы актерлар да булсын, аяк астында пыяла ватыклары да аунап ятсын. Әмма ул чагында «Яктылык һәм Тавыш» сәнгате кирәкле шартлылыктан мәхрүм булыр иде. Гадәти театр сәхнәсенә хас нәрсә безнең спектакль спецификасына каршы чыга. Без хәзер шул

ләрне тыңлыйбыз.

...Менә спектакль финалга якынлаша. Студентлар, үзләренең студентлык билетларын ректор өстәленә ыргытып, тарала башлыйлар. Алар таралалар, шулай да бу кадәресе җиңү — андый укытучыларның итагатьле укучылары була алмаячакларын күрсәтәләр...

Тантаналы музыка уйный. Ике башлы ерткыч каракош та, кашагадагы язулар да югала.

Тәмам. Урам фонарьлары кабына.

Бина кашагасында — «Хезмәт Кызыл Байрак орденлы В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты» язуы.

Шулай итеп, без чынбарлыкка кайтабыз. Колонналы ак бинаның тәрәзәләре, элеккечә, Ленин урамына карыйлар.

Кызганычка каршы, бу спектакльнең куелганы юк әле. Ләкин ул куелырга тиеш...[1]

Биш-ун ел үтәр, «Яктылык һәм Тавыш» спектакльләре безнең илдә гади күренеш булып китәр. Яктылы симфония әсәрләрен куяр өчен заллар да салыныр, кинотеатрларда да оригиналь яктылы музыкаль фильмнар күрсәтерләр.

Без моңа ышанабыз, чөнки бу да сәнгать үсешенең котылгысыз объектив законы.

Кешелек җәмгыяте, кайчан да булса, «Прометей» музыкасы астында төньяк балкышын файдаланырга, аны идарә итәргә өйрәнер (Минору Хонда, ул вакытта 45 нче елның дәһшәтләре сине борчымаслар!).

Әйе, космик очышлар чорында сәнгатьнең чын-чынлап космик гасырга тәңгәл булырга тиешлегенә без ышанабыз.

## «ПРОМЕТЕЙ» СКБСЫ ЭШЕНӘ БЕЗНЕҢ КАРАШ.

*Казан кешеләренә «Прометей» СКБсының музыка белән яктыны бергә кушу өлкәсендә ясаган экспериментлары белән берничә мәртәбәләр танышырга мөмкинлек булды. Ул бюроның эшләре безнең бөтен илебездә мәгълүм булып калды. Яктылы музыка әһелләренең икенче тапкыр булган («Свет и музыка» конференциясе, 1969 ел, февраль) очрашуларын Казанда үткәрергә карар бирелүе — характерлы факт.*

*Тикшерелә һәм эшләнә торган проблеманың специфик үзенчәлекле һәм катлаулы булуы Казан предприятиеләрендә эшләүче төрле белгечләрне һәрвакыт бергәләп эшләргә мәҗбүр итә. Шул экспериментларның нәтиҗәләре акрын-акрын шәһәребезнең уртак байлыгына әйләнеп бара.*

*Бу өлкәдә тикшерену эшләренең фронтын киңәйтү эше аның сыйфатын яхшырту турындагы таләпләр белән бергә барырга тиеш. Хәзерге моментта алда торган проблемаларны институтның СКБ рамкасы эчендәге мөмкинлекләргә таянып кына уңышлы үтәп булмаячагы ачык күренде.*

*Әле сөйләнгәннәргә таянып, без Казанда махсус яктылы музыка студиясе оештырырга мөмкин һәм кирәк, дип исәплибез. Бу студия, концерт бирү белән беррәттән, театрда, кинематографиядә, архитектурада конкрет практик мәсьәләләрне, мәсәлән, экспериментал эстетика, психология һ. б. буенча фәнни тикшеренүне хәл итү өстендә шөгыльләнергә тиеш.*

*Чынлап та хәзер бу өлгергән мәсьәлә.*

**Н. Җиһанов, Н. Рахлин,** СССР халык артистлары, **А. Спорнус,** шәһәрнең баш художнигы; **М. Агишев,** архитектор; **Л. Волович,** консерватория доценты; **Ян Винецкий, Р. Кутуй,** язучылар.

---

[1] Хәзер бу нәрсә киләчәк эше түгел инде. Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 25 ел тулу көнендә Казанда, һәлак булган геройларга куелган һәйкәл янында, СССР да беренче буларак, «Яктылык һәм Тавыш» спектакле күрсәтелде.

Сәрвәр Әдһәмова

# УЛ ШАГЫЙРЬ ЙӨРӘКЛЕ ИДЕ

Шәриф абзый Камал Кави Нәҗми белән безнең озак еллар якыннан аралашып яшәгән һәм күңелдә якты эз калдырган язучылардан берсе булды.

Шәриф абзыйны беренче тапкыр егерменче елларның урталарында язучыларның ниндидер бер җыелышында күрдем мин. Анда һәм аннан соңгы очрашуда ул миңа башкалар белән аралашырга бик үк яратмый, йомылып яши торган кеше булып тоелды. Ләкин бу беренче тәэсирнең дөрес булмавын соңыннан аңладым. Шәриф абзый белән якынрак танышкан саен, аның характерының элек мин белмәгән, абайламаган яклары ачыла барды. Кичен йомылып, таң аткач, беренче кояш нурлары төшүгә ачыла торган чәчәк була. Йомык чакта алар әллә ни күзгә ташланмыйлар, ә инде ачылгач, хәйран калып, сокланып торасың. Бу ошату бик үк төгәл дә түгелдер, бәлки, ләкин никтер Шәриф абзый турында уйлаганда шундый чәчәк күз алдыма килә.

Безнең байтак язучыларыбызның үзара тагын да якынаюына, дуслашуына 1929 елдагы экскурсия дә сәбәп булды, дисәм, ялгышмам дип уйлыйм. Пароходта булсын, поездда булсын, бергә сәяхәт итеп, барган җирләрдә бергә чыгышлар ясап, ай ярымга якын бер семья булып яшәү һәм уртак тәэсирләр безне шулай үзара якынайтты.

Шәриф абзыйның әсәрләре юморга бай булуын белсәм дә, тормышта да уен-көлке яратуын, тапкыр сүзле кеше булуын элек белми идем. Мин аның ул ягын шул экскурсия вакытында күрдем.

Ул елларда пароходлар хәзергегә караганда озаграк йөри иде. Без Казаннан Идел буйлап Астраханьга биш-алты көн төштек. Ул көннәр, бигрәк тә кичләр, үзе бер бәйрәм төсле күңелле үтте. Август ае, көннәр эссе. Көндез вакытны күбесенчә палубаның күләгәле ягында уздырабыз. Ара-тирә теге яки бу каютадан Такташның, Кутуйның шигырь укыганы ишетелеп куя, Демьян Фәтхи дә көйли-көйли нидер укый: тугандаш республикаларда үткәреләчәк кичәләргә әзерләнәләр иде алар.

Ә кичен, һава бераз җиләсләнү белән, барыбыз да салонга җыелабыз. Салих Сәйдәшев, пианино янына утырып, беренче аккордларны алу белән без сихерләнгәндәй булабыз. Аның кайбер көйләренә кушылып җырлап җибәрәбез. Музыка, җыр тавышына пассажирлар да җыела. Салонга сыймаганнары, тәрәзәләр янына өелешеп, палубада тыңлап тора. Идел өстендә Сәйдәшнең тиңдәшсез моңлы көйләре яңгырый. Ул уйнап арганнан соң, төрле уен-көлке сүзләр сөйләү башлана. Такташ та, Кави да, журналист Исмәгыйл Рәми дә, башкалар да тапкыр сүзгә күршегә керә торганнардан түгел. Ә инде артист Шакир Шамильский янсә Кәрим абый Тинчурин сөйли башласа, театрың бер якта торсын!

Шәриф абзый гадәттә мыек астыннан гына елмаеп тыңлап утыра, тик ара-тирә генә нинди дә булса бик урынлы тапкыр сүз әйтеп куя торган иде. Бер кичне аның да теле ачылды. (Иртәгә Астраханьга җитәбез дигән көннең киче иде бугай).

— Мин дә сезгә бер гыйбрәтле кыйсса сөйлим әле, туганнар,— дип башлады ул сүзен.— Борын заманда Иран шаһы: «Минем мәмләкәтемдә исерткеч истигъмал кылу[1] катгыян мәмнугдыр[2]. Бу фәрманны бозган кешенең башы, һичшиксез, чабып өзелергә тиеш», дигән фәрман чыгара. Шуннан күп тә үтми, шаһның сарай капкасына чылбырлап куелган арысланы, чылбырын өзеп, кача. Шаһ, бик хафа булып, тагы бер фәрман чыгара. «Минем яраткан арысланымны тотып китерүчегә теләсә ярты дәүләтемне, теләсә кызымны бирәм», диелгән була ул фәрманда,— ди Шәркф абзый. Җай гына сөйли. Үзе ара-тирә күзлек аша безгә карап ала.— Бер-ике көннән Тәһранның[3] үзәк урамы очында болыттай тузан күтәрелә. Кешеләр, бу ни икән дип, аптырашып торганда, сарай капкасы төбенә арысланга атланган шыр ялангач берәү килеп туктый. Аны шундук, өстенә чапан кидереп, шаһ хозурына алып керәләр. Шаһның күңеле бик шат. «Кызымны аласыңмы, ярты дәүләтемне биримме?» диюгә, теге кеше аның аягына егылып: «Берсе дә кирәкми, шаһым-солтаным, башымны гына чаптырма!» дип ялына. Шаһ бик гаҗәпләнә...

Без дә, әле эшнең нәрсәдә икәнен аңлый алмыйча, Шәриф абзыйның авызына карап утырабыз. Ул ашыкмый гына сөйләвен дәвам иттерә:

Теге кеше арыслан тотарлык кына эчкән идем, дигәч шаһ аптырап кала. Аның башын исән калдырса, беренче фәрман үтәлми. Башын чаптырса, икенче фәрмандагы вәгъдәсен бозган була бит инде. Нишләргә? Шуннан соң шаһ үзенең беренче фәрманының ахырына: «Вә ләкин арыслан тотарлык дәрәҗәдә генә рөхсәт ителә», дигән искәрмә өсти,— дип, Шәриф абзый сөйләп бетерүгә, без салонның түшәмен күтәрерлек итеп шаркылдап көлдек...

Шәриф абзыйның шул вакыттагы кыяфәте, үзе көлмичә генә бик җанлы итеп сөйләве бүгенгедәй күз алдында тора. Соңыннан Бакуда булсын, Тифлиста булсын, бүтән шәһәрләрдә булсын, банкетларда тост күтәргән чакларда, безнең иптәшләр еш кына бер-берсенең колагына: «Куян тотарлык кына!» дип пышылдап, башкаларга сиздерми көлә торган иделәр...

Соңрак Гаспрага ял итәргә баргач, Кәрим абзый Тинчурин Шәриф Камалга:

— Кайчандыр Лев Толстой аяк баскан сукмаклар буйлап йөреп, тирә-юнь белән танышып кайтыйк әле. Юлның теге як читендә, нәкъ безнең ял йорты каршында җыйнак кына бер каһвәханә[4] бар. Анда «Шайтаны кем» дигән татлы шәрап та бар икән. Кичке аш алдыннан куян тотарлык кына татып карасак, ничек булыр, кардәш? — дип теге кыйссаны тагын бер искә төшерде. (Ә аның «Шайтаны кем» дигәне «Шато икем» дигән йөзем шәрабе булып чыкты.)

Шулай итеп, Шәриф абзыйның ул гыйбрәтле кыйссасы бик нык хәтергә сеңеп калды һәм «арыслан тотарлык», «куян тотарлык» дигән сүзләр канатлы гыйбарәгә әйләнде.

Астраханьда ике көн торып, укучылар белән очрашу кичәсе уздырганнан соң, без пароход белән Каспий буйлап киттек. Шунда төнгә каршы шактый көчле җил күтәрелеп, шторм башланды. Пароход чайкалуы безнең иптәшләрнең кайберсенә сизелерлек тәэсир итте. Галимҗан Нигъмәти хатынының Астраханьда яшәүче энисе, диңгездә кирәк булыр бәлки дип, Галимҗанга әче әлү кагы биреп җибәргән икән. (Диңгез буенда торган кеше тәҗрибәле була шул!) Шторм вакытында ярап куйды ул. Шакир Шамильский:

— Галимҗан, җаным! Әз генә как бирче! — дип, бер кисәк какны суыра-суыра, алпан-тилпән атлап, каютасына кереп ятты. Ләкин Такташка какның да файдасы булмады. Палубада утырган иптәшләр янына чыгып бер-ике минут торганнан соң:

---

[1] Истигъмал кылу — куллану, бу очракта — эчү.
[2] Мәмнугдыр — тыеладыр.
[3] Тәһран — Тегеран.
[4] Каһвәханә — кофеханә.

— Айга карый алмыйм, егетләр. Айга карасам күңелем болгана,— дигәч, Шәриф абзый:

— Бер дә гаҗәп түгел. Ул бичара айның шигърияттен сез, хәзерге шагыйрьләр, тәмам бетердегез бит инде, айны аулап токмач итеп тә турадыгыз бугай. Кояш аркасын да бораулыйдыгыз,— дип көлде. Бу аның Кави Нәҗминең имажинизм белән, Г. Кутуйның футуризм белән мавыгып йөргән чагында язган шигырьләренә ишарәләве иде.

Аңарчы йомыкый, мыштым дип йөргән Шәриф абзый шул ук сәяхәт вакытында тагы бер гаҗәпләндерде әле безне.

Батум базарында итәк астыннан контрабанда товарлары сатучыларны да очратырга туры килде. Кави яхшы тәмәке ярата иде, түзмәде, шул сатучыларның берсеннән бер төргәк «Самсун» дигән төрек тәмәкесе алды. «Аны төреп тартырга да мөмкин, гильза алып тутырсаң, менә дигән хуш исле папирос та була» дип куанды һәм бу хакта иптәшләргә дә сөйләгән иде.

Батумнан поездга утырып китеп озак та бармадык, Шәриф абзый, вагонның Кави белән без урнашкан купесына кереп, бераз аны-моны сөйләшеп утырганнан соң, сүз арасында гына:

— Күрше вагонда таможня кешеләре йөри. Контрабанда эзлиләрме шунда,— дип куйды. Шулай диде дә коридор буйлап үз урынына китте.

Кави, бик борчылып, урыныннан сикереп торды:

— Нишлибез, Сәрвәр? — дип, кабаланып, чемоданыннан әлеге тәмәке төргәген алып башта мендәр астына яшерде. Аннан бер-ике адым китеп, кинәт җиргә борылды да, борыны белән тирән сулап иснәнеп:

— Юк! Барыбер хуш исе әллә каян ук борынга бәрелә, каһәрнең,— дип, төргәкне өске өченче шүрлекнең почмагына ыргытты. Ләкин алай да тынычлана алмады. Шундый зур делегациянең сәяси җитәкчеләреннән берсе иде ул вакытта Кави. Җитмәсә тагын өстенә өч шпаллы китель кигән хәрби кеше иде бит. Аңардан ул хәерсез «Самсун»ны табып бәйләнсәләр, адәм хурлыгы ич!

Шулай дип уйлап булса кирәк, ул ахырында төргәкне алып тәрәзәдән ыргытырга җыенганда гына, Шәриф абзыйның:

— Тукта, Кави! Юк сүз булып чыкты ул! — дип кычкырган тавышын ишеттек. Үзе тыела алмый көлә иде.

Таможня кешеләре турындагы хәбәрне ул үзе уйлап чыгарган һәм безнең ыгы-зыгы килгәнне бер читтән күзәтеп йөргән икән.

Шәриф абзый белән шул көннәрдә башланган якын танышлык, дуслык ул үлгәнче дәвам итте. 1935—1936 елларда без җәй көннәрен Түбән Осланда бергә уздырдык. Бер елны дачаларыбыз да өй аша күршедә генә булды. Шәһәрдә чакта да Шәриф абзыйларга еш бара идек. Ул үзе кунакка йөрергә бик үк яратмый, үзләренә кеше килгәнне ярата төшә иде.

Өйләренә барып керүгә, безне якын туганы кебек каршы ала. Шунда ук Хәят ападан самовар куйдырта. Озаклап сөйләшеп утырып чәй эчәбез. Ул безнең иҗат эшләре белән кызыксына, үзе артык күп сөйләшми, башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңлап, ара-тирә генә берәр сүз әйтеп куя торган иде.

Шуны да әйтергә кирәк: яшь ягыннан да бездән күп олы, иҗаты ягыннан да чагыштыргысыз югары булуына карамастан, ул безгә үз тиңенә караган төсле карый иде. Аннан җыр бик ярата иде Шәриф абзый:

Алма бакчасына керсәм,
Алма тия җилкәмә.
Үземә дә бик кадерле
Сүз әйтмәгез иркәмә,—

дигән җырны җырласалар, аның ничектер бераз моңаеп, башын кыңгыр сала төшеп тыңлап утырганы күз алдыма килә.

Нечкә күңелле, шагыйрь күңелле кеше иде ул. Һәм ничә ел якыннан аралашып йөреп, аның бер тапкыр да ачуланганын, тавышын күтәреп сөйләгән чагын күрмәдем.



## Роберт Миңнуллин

*1948 — туган елым.*
*Башкортстанның Илеш районы — туган төбәгем.*
*Нәҗәде авылында тусам да, малай чагым Сөн буенда, Шәммәттә үтте. Биредә авылның кешеләре белән бергә, кабатланмас матурлыгы ягыннан аерылып торган табигате күңелдә якты хатирәләр калдырган. Биш бала белән бер ялгызы торып калган әнкәйнең ихтыяр көчен күреп, йөрәк җылысын тоеп үстем.*
*Урта мәктәпне тәмамлагач, ике ел район «Маяк» газетасында эшләдем. Хәзер Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укыйм.*

## Казан төне

Нинди гаҗәеп дөнья бу!
Юк, төш түгел,
Өн бу, өн бу.
Кочагымда — Казан төне.
Әллә нинди үзгә төн бу.
Бу утлар — төсле музыка.
Төннәр буе сөеп тыңла.
Казан чумган дәртле моңга.
Парлар үтә...
Гашыйклар да
Бәхетлерәк бугай монда.
Йолдызлары да яктырак
Бүген хәтта.
Ае бөтен.
Көндез сизеп булмый торган
Матурлыкны җыйган бу төн.

●

Төнге дөнья,
Төнге хәят,
Йолдызлары күпме!
Ул йолдызлар —
Балкып торган
Тәрәзләре күкнең.

Алар аша
Чиксезлек һәм
Мәңгелек күренә...
Кулларым
Шул тәрәзләрне
Ачарга үрелә.

## Кояш

*Этюд*

Чалт аяз күк.
Офык кырыенда
Алтын кояш тора эленеп.
Гел өлгергән әнис алмасыдай,
Төшәр төсле җиргә өзелеп.

## Беренче кар

Иреннәреңә кунарга
Кызыгып ява кар.
Керфегеңдә, чәчләреңдә
Җылы кар, яңа кар.
Әллә соң татар кызлары
Чәчкәнме чулпылар?!
Бер-берсенә орынсалар,

Валлаһи, чылтырар
Көмештәй чулпылар!
...Беренче карлар юк,
Күптәннән көмелгән,—
Аклыгы беләнме,
Сафлыгы беләнме,
Китмәгән күңелдән...

●

Күз тимәсен күзләреңә,
Бигрәк каралар икән,
Һәрчак шулай матур итеп
Миңа карарлар микән?

Кара төндәй күзләреңә
Күзем төште күптәннән.
Бер үбимче күзләреңнән,
Төсен җуймас үпкәннән.

## Саллар ага

Башны салларга салып,
Китәсе иде агып.
*Р. Фәйзуллин.*

Талгын гына Агыйделнең
Зәңгәр дулкынын кагып,
Киттеләр саллар агып.
Озатып калды салларны
Уралым бөркетләре.
Акчарлаклар йөзә күктә.
Очсыннар, өркетмәле!
Саллар ага,
Ага саллар,
Әйләнеп кайтмас бүтән.
Кайтмасын да белә торып,
Салларга утырып киткән
Малай чагымны көтәм.

Гамил Афзал

# ФЕРЗЬ ГАМБИТЫ

Әлмәтнең Техника йортында шахмат клубы бар. Эч пошканда шунда кереп мин дә бер-ике мат алып чыгам. Бик каты уйныйлар анда. Минем канга тоз салучы «дошманым» Галләмов кичләрен шунда ята. Галләмов сугышка чаклы бик шәп артист булган, сугышта бер аягын калдырып, протез киеп кайткач, сәхнәдә сикереп булмый инде, әллә кайсы конторада кадрлар бүлегендә эш кыра. Галләмовны җиңү — миңа бәйрәм. Бик хәйләкәр, явыз ул Галләмов, минем корган планны әллә каян белеп тора, үзе дә бер пешка өчен җанын бирер, карун.

Бүген дә шул Галләмов белән якалашып алырга исәп бар иде. Клубта бер бәләкәй малай гына ямансулап утыра.

— Нихәл, энекәш, Галләмов абыең күренмәдеме әле?

— Галләмов абый килмәде әле бүген,— ди малай.

— Ә син нишләп утырасың бер үзең?

— Мин дежурный.

— Шахмат уйный беләсеңме?

— Бераз беләм.

— Әллә берәрне сугабызмы?

— Сугабыз аны, абый.

Ашыкмый гына фигураларны тездек. Малай, бүреген салып, буш урындыкка куйды. Чәче такыр итеп кырып алынган, өстәл артыннан ак шалканбаш кына калкып тора. Шушы «дошман» белән алышабыз инде дим, кәеф килеп.

Малай ферзь алдындагы пешкасын кыю гына алга чыгарды. Минем өчен бу көтелмәгән ход иде, миңа король алдындагы пешканы чыгарга ярамый иде. Киттем мин дә ферзь алдыннан. Малай миңа таныш булмаган сәер ходлар йөри. Әйдә йөрсен, кая барыр ул. Мин андый ходларга каршы ничек йөрергә белмим, озаграк уйларга малайдан оялам, бала бит. Малай минем уң флангны пешкалар белән терәтеп куйды, ладьям дә, атым да бикләнеп калдылар. Ә үзе ладьясе, ферзе, аты һәм ике филе белән ябырылып килде дә, шыгырдатып кысты, тын алыр хәл дә юк. Әллә ничек ансат кына мат куйды бу.

— Тагын берне уйныйбызмы?

— Уйныйбыз аны, абый.

Тагын фигураларны тездек. Тагын ферзь алдыннан йөри тегә. Бүтәнрәк вариантта баягы ук ходлар кабатланды. Мин уңны-сулны шәйләп, аңыма килергә өлгермәдем, карасам, гаскәрем тар-мар ителгән. Минем фигуралар арасыннан король янына үтеп кереп, шартлатып мат куйды бу. Мондый уйнаучыны күргәнем юк иде әле. Туктале, дим, итәкне, җиңне җыеп, чамалабрак эш итәргә кирәк моның белән.

— Тагын берне уйныйбызмы?

— Уйныйбыз аны, абый.

Тагын фигураларны тездек. Клубка әллә нинди малайлар, үсмер егетләр кереп тулды. Безне сырып алдылар, кызыксынып күзәтәләр. Кеше карап торганда уйнарга яратмыйм мин, эчтән генә көлеп, мыскыл итеп торалар кебек тоела. Тагын ферзь алдыннан йөреп китте тегә явыз. Малайлар һәм үсмер егетләр аңар көч-куәт биреп, дәртләндереп торалар.

— Ренат, бирешмә!

— Сафуанов, не подкачай!

Малайлар һәм үсмер егетләр, көлешә-көлешә, Ренатка — җиңү, миңа җиңелү телиләр кебек. Мин каушабрак калдым. Мине кызганучы юк монда. Уенга салкын кан белән, төпле анализ ясый алмадым, ни булса, шул булыр, язмыштан узмыш юк, дип йөри бирәм. Мин малайдан курка башладым. Җиңүгә өмет бөтенләй юк. Уенның кызыгы бетте, юкка вакыт әрәм итеп кенә утырам. Суярга алып барган сарык ни хис итә икән дип тә уйлыйм хәтта. Минем фигуралар төрле-төрле якта фронтны тотып торалар. Берсен генә кузгаттыңмы, фронт тишелә. Мин гел оборонада торам. Ниһаять, минем фронт өзелде. Малай минем корольне почмакка куып кертеп, уен-көлке арасында, шаярып кына дигәндәй, хурлыклы рәвештә мат куйды.

Малайлар һәм үсмер егетләр сөенештеләр, көләләр.

— Ну, Сафуанов, молодец!

— Ну, ферзь гамбиты шәп уйналды!

— Ренат, бала-чаганы кыйнарга ярамый, әйбәт түгел!

Монысы минем адреска инде, минем кебек уенчы алар өчен «бала-чага» икән.

— Рәхмәт, егет икәнсең! — дигән булдым мин, Ренатның бәләкәй генә кулын кысып. Егетләр белән саубуллашып урамга чыктым. Ренат та минем арттан чыкты. Кара олтан салган соры киез итек кигән, бот буе малай, бүреге зур, этисенекедер, мөгаен.

— Абый, сез ничәнче категория белән уйныйсыз?

— Минем бернинди категориям юк, болай гына уйныйм.

— Мин өченче категорик, Казанга да барып уйнадым әле.

— Син булдырасың, Ренат,— дигән булдым мин, ачу килеп. Сөенә чучка малай.

— Сау булыгыз, абый, миңа бу якка!

— Сау бул, Ренат!

Болытлы соры кич. Нигәдер кәеф юк. Күңелсез генә өйгә кайтам. Менә бит язмыш ничек шаяра белә икән ул. Чабата калыбы чаклы малай, миңа, югары белемле кешегә, чатлатып мат куя да тора Ә шуның үзен җиңеп булмый, колагын борасыңмыни аның! Неужели шуның йодрык чаклы башы минекеннән шәбрәк эшли?! Эшли шул, брат. Безнең семьяда акыллы кешеләр юк. Минем күсәк тә Ренат исемле, тугызынчы класска чаклы дәресләрен мин әзерләдем. Чәч җилкәгә төшеп тора, чалбар балаклары әллә нинди фасонлы. Караватка кырын-ярын ятып, гитара чиертә: дрын-дрын, дрык-дрык... Бер тиенлек акылы юк. Акчаны миннән сорый, бер сум бирәм. Мин чыгып киткәч, хатыннан сорый икән, ә ул: «Мә, улыкаем, мә, бәбекәем».— Өч сум да биш сум, аңа жалкымыни!

Хатынга да ачу килде. Пан-бәрхет кигән тагын... Ул төшендә дә креп-жоржетлар, нейлоннар, перлоннар, лавсаннар гына күрә. Күлмәктән башка ни кайгысы бар аның!

Кем малае икән бу Ренат Сафуанов? Бик укымышлы гаиләдәндер инде ул. Ничек тәрбиялиләр икән шундый малайларны?

Безнең цехта бер Сафуанов бар, басынкы гына агай. Шул Сафуанов ике айга профвзнос түләмәгән икән, кабинетка чакырып кертеп, әңгәмәләшеп утырдык. Сугышта булган, сапер, орденнары, медальләре бар. Бак кына шадрасы кара кучкыл биттә сизелер-сизелмәс кенә. Миннән ике яшькә генә олы, чәчләре чигәдә генә бәсләнә башлаган. Хатыны көнкүреш комбинатында тегүче булып эшли. Олы малае Казанда укый, кызы медсестра булып эшли, уртанчы малайлары унынчыда, бокс түгәрәгенә йөри. Мине җиңгән Ренат — боларның төпчек уллары, алтынчы класста укый икән.

Мин, зур начальник булмасам да, барыбер башлык кеше, цехком башлыгы булып йөрим. Властьтан файдаланып, Сафуановларга өч бүлмәле квартир бирдерттем. Яңа квартирны котларга барган идем. Кая утыртырга белмиләр, тау чаклы рәхмәтләр укыдылар. Теге мине җиңгән Ренат «Теория вероятности» дигән китап укып утыра. Никадәр гомер яшәп тә, минем ул китапны кулга тотып караганым юк иде әле.

Чәй янында бик ямьле гәпләшеп утырдык.

— Ну, Ренат дус,— дигән булам мин,— берәрне сугып алабызмы әллә?

— Булмый, абый, вакыт юк! — диде дә, китабын күтәреп, күрше бүлмәгә үк чыгып китте. Әтисе алдында мине хур итәргә теләмәде, күрәсең, кызганды.

Шуннан бирле мин шахмат уйнамыйм, доминога күчтем.

# *ДУСЛАРЧА ШАЯРУЛАР*



## *Ибраһим Газига*

«Гади кешеләр» булсак та,
Гаҗәп «Онытылмас еллар»да
Күпне күрде башыбыз.
«Кемеш сулы Нурминкә»дә
«Катя Сорокина» белән
«Без әле очрашырбыз».

Л. Н. эпиграммасы.



## *Риза Ишморатка*

Заман әйтә: пьеса сюжетларын
Гел минемчә шулай иш, брат!
Заман әйтсә дөрес әйтә инде,
Нишләсен соң Риза Ишморат...

## *Нәкый Исәнбәткә*

Үзе нече, олы эше —
Ир ул Нәкый Исәнбәт!
Үз хезмәтләрен үзе дә
Чыгалмастыр исәпләп.

Н. АРСЛАНОВ эпиграммасы.



## *Афзал Шамовка*

Сүзләр сирәк төшә, юкса
Каләм төшмәгән кулдан —
Хәтта ки Афзал Шамов та
Язган заманнар булган!



И. ХАНТИМИРОВ шаржлары.
ЗӨЛФӘТ эпиграммалары.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КУЛЬТУРА РАБОТНИКЛАРЫ ПРОФСОЮЗЫ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ III ПЛЕНУМЫ

Үткән елның июль аенда Мәскәүдә культура работниклары профсоюзының Үзәк Комитеты утырышы булып, анда Татарстан иҗат союзларының (язучылар, композиторлар, художниклар союзларының) профсоюз оешмалары эше дә тикшерелгән һәм яхшы дип табылган иде. Татарстан язучылар союзы профсоюз оешмасының, партия оешмасы белән берлектә, В. И. Ленинның 100 еллык, Татарстанның 50 еллык юбилейларын лаеклы каршылау унае белән башкарган эшләрен һәм язучылар арасында политик уку-тәрбия буенча күрелгән чараларны Президиум аеруча уңышлы дип билгеләп үткән иде. Культура работникларының профсоюз Үзәк Комитеты Президиумы шул ук утырышында Татарстан иҗат союзлары профсоюз оешмаларының бу уңышлы эш алымын илебезнең башка шәһәрләрендәге иҗат оешмалары профсоюз җирле комитетларына да үрнәк итеп куярга карар чыгарган иде.

1970 елның 12 октябрендә үткәрелгән Татарстан культура работниклары профсоюзы өлкә комитетының III пленумында культура работниклары профсоюзы Үзәк Комитеты Президиумының әлеге карары һәм шул карар нигезендә күрелгән чаралар тикшерелде. Татарстан культура работниклары профсоюзы өлкә комитеты председателе Я. С. Шәмсетдиновның докладыннан соң фикер алышуларда катнашкан иптәшләр республикабыз иҗат союзларының профсоюз оешмалары иҗади интеллигенция арасында шактый зур тәрбия эше алып баруларын билгеләп үттеләр.

Пленумда КПССның XXIV съездын каршылауга әзерлек барышында иҗат оешмалары алдында торган бурычлар да билгеләнде һәм шул мәсьәлә буенча конкрет план кабул ителде.

Татарстан культура работниклары профсоюзының III пленумында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре иптәш М. Ф. Вәлиев тә катнашты һәм чыгыш ясады.

## МИНЗӘЛӘ ТЕАТРЫ ТАШКЕНТТА

Узган ел ахырында Минзәлә татар дәүләт драма театры Үзбәкстанда гастрольдә булып кайтты. Театр коллективы үзбәк дусларга драматург Сәет Шәкүровның «Уракчы кыз» исемле әсәре буенча эшләнгән спектакльне алып барган иде.

Артистларыбыз башта ун көн дәвамында спектакльләрен Ташкент шәһәре тамашачыларына күрсәттеләр. Ә сәхнәдән бушаган вакытларында алар Үзбәкстан хезмәт ияләре белән очрашулар үткәрделәр: «Йолдыз» тегү фирмасында, Ахунбабаев исемендәге культура сараенда һәм мамык үстерүче «Кызыл Үзбәкстан» колхозында булдылар.

Аннары театр коллективы Үзбәкстанның башка шәһәрләрендә дә спектакльләрен күрсәтте. Артистларны үзбәк дуслар һәм Үзбәкстанда яшәүче күп санлы якташларыбыз һәркайда бик җылы каршы алдылар һәм, иҗатларында тагын да зуррак уңышлар теләп, озатып калдылар.

## КАЗАКЪ ГАЛИМЕ АКМУЛЛА ТУРЫНДА

Алма-Ата шәһәрендә чыга торган «Ленинишил жас» исемле газетада әдәбият белгече, Казагыстан ССР Фәннәр Академиясенең М. Ауэзов исемендәге әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәре Бөркет Исхаковның татар-башкорт шагыйре Мифтахетдин Мөхәммәдьяров (Акмулла) турында зур гына мәкаләсе басылып чыкты. Ул үзенең бу мәкаләсендә: Акмулла, татар һәм башкорт шагыйре булу белән бер үк вакытта, казакъ шагыйре дә булган, дигән фикерне үткәргән. Беренчедән, ди ул үзенең шул фикерен яклап, Акмулланың атасы Мөхәммәдьяр Казагыстанда туып үскән кеше булган, икенчедән, Акмулла үзе дә казакъ халкы арасында яшәгән, өченчедән, ул шигырьләрен казакъ телендә язган. Шулай итеп, ди мәкаләнең авторы, Акмулла — өч тугандаш халыкның уртак шагыйре дип саналырга хаклы кеше.

## ТРАДИЦИЯЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

Казан художество училищесы республикабыздагы иң карт уку йортларының берсе санала. Үзенең 75 елдан артык эшчәнлеге дәверендә ул сынлы сәнгатебез үсешенә зур өлеш кертте. Бөтен илебезгә билгеле бик күп рәссамнар нәкъ менә шушында тәрбияләнде. Училище үзенең шул данлы традицияләрен елдан-ел үстерә, көчәйтә бара.

Мәсәлән, училищены 1970 елда тәмамлап чыккан кешеләрдән З. Гимаев, Ф. Яку-

пов, Ә. Җәмилова һәм О. Сильяновлар хәзер Репин исемендәге Ленинград художество институтының нәгыш факультетында, ә Е. Дубицкий шул ук институтның графика факультетында укыйлар. А. Гуськов В. Мухина исемендәге Ленинград югары художество училищесына укырга керде.

## ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

РСФСР художество фондының Татарстан бүлеге, КПССның булачак съезды хөрмәтенә җәелдерелгән социалистик ярышта актив катнашып, Россия Федерациясе коллективлары арасында беренче урынны яулап алды. Иҗади хезмәттә ирешкән уңышлары өчен аңа РСФСР художниклары союзы һәм культура работниклары профсоюзы Үзәк Комитетының күчмә **Кызыл байрагы** тапшырылды.

## ТАТАР ҖЫРЛАРЫ КАЗАКЪ ТЕЛЕНДӘ

Казагыстанның «Җазушы» нәшрияты татар язучылары иҗат иткән җырларны казакъчага тәрҗемә иттереп, «Татар җырлары» исемле китап әзерләгән иде. Әле шушы көннәрдә генә шул китап типографиядә басылып чыкты һәм Казагыстан китап кибетләренә сатуга таратылды.

## ЛЕГЕНДАР КОМИССАР МУЗЕЕНДА

Пенза өлкәсенең Сосновоборск районындагы Маркино авылында ике революция һәм гражданнар сугышы герое, тарихи Идел флотилиясенең легендар комиссары Николай Маркин музее эшләп килә. Маркинның керәшташләре, якын-тирә авыллар халкы һәм Пенза язучысы Алексей Назаров булышлыгы белән төзелгән шул музейны узган елда 100 меңенче кеше карады. Музейда һәрвакыт кеше күп була. Анда балаларны пионерга кабул итәләр. Ленин комсомолы сафына кергән яшьләргә комсомол билетларын тапшыралар.

## КҮРКӘМ БАШЛАНГЫЧ

Мәскәү Әдәбият институтында илебезнең төрле почмакларыннан һәм чит илләрдән килгән иллегә якын милләт вәкилләре укый. Алар бер-берсе белән милли традицияләр, милли үзенчәлекләр алмашып, әсәрләрен үзара төрле телләргә тәрҗемә итешеп торалар. Күптән түгел генә әле Алтай һәм Карачай матбугатында студентларның байтак шигырьләре дөнья күрде. Алар арасында якташыбыз Разил Вәлиевнең дә шигырьләре бар. Август аенда Алтай радиосы буенча да яшь шагыйрь иҗаты турында тапшыру булды һәм аның шигырьләре укылды.

Үз нәүбәтендә Разил Вәлиев та иптәшләренең шигырьләрен тәрҗемә итеп «Казан утлары»на тапшырды. Берничә милләтнең яшь шагыйрьләре әсәрләреннән торган ул шигъри букет журналыбызның шушы елгы саннарының берсендә басылып чыгачак.

## УҢЫШЛЫ ЭКСПЕДИЦИЯ

Узган җәй Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан борынгы Болгар дәүләтенә археологик экспедиция оештырылды. Тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдинов җитәкчелек иткән бу экспедиция белән яшь шагыйрь Разил Вәлиев һәм хикәяче Фәрит Гыйльметдинов та барды. Бер ай дәвамында алар әле моңа кадәр игътибар үзәгеннән читтә калган шәһәр һәм авыл урыннарын тикшерделәр. Нәтиҗәдә 7 шәһәрчек, өч зур ныгытма, 37 авыл урыны табылды, өйрәнелде һәм планга төшерелде. Яшь әдипләр экспедициядән зур иҗат материалы туплап кайттылар.

## ИЛЬЯ НИКОЛАЕВИЧ ИНИЦИАТИВАСЫ БЕЛӘН

Ульяновлар исеме белән бәйле урыннар безнең Татарстанда шактый: университет, В. И. Ленин музее, М. А. Ульянова исемендәге мәктәп, Кокушкино-Ленино. Тәтеш районындагы Кошки авылы мәктәбе дә Ульяновлар исеме белән бик нык бәйле.

Элекке Буа өязендәге кечерәк кенә бу чуваш авылы 1920 елга кадәр Сембер губернасы карамагында була. Халык мәктәпләре оештырып йөргән чагында Ленинның атасы Илья Николаевич Кошкига да килгәләп йөри. Бу авылга ул беренче тапкыр 1871 елның җәй азагында мәктәп салдыру уңае белән килә. Шул килүендә Илья Николаевич тарафыннан язылган һәм хәзергәчә сакланып калган актта мәктәп төзелеше турында менә мондый мәгълүматлар китерелгән: «Мәктәп төзү өчен 96 баганa, шуларның 14 е имән, 82 се нарат. Озынлыклары 5—6 сажень, юанлыклары 4,5—6 вершок[1] булган 132 бүрәнә, 5 пот сүс, 4 йөк мүк, 3 пот кадак, шуларның ярты поты кыска һәм ярты поты нечкә. Материал мәктәп төзергә ярарлык. Подрядчикка бура бурарга, идән җәяргә һәм түбәлек такта ярырга тәкъдим итәм».

Икенче архив документына караганда, Илья Николаевич 31 августта подрядчик Иванов Игнатичка 30 сум үз акчасын биргән.

Кошки авылында мәктәп салдыруга әзерлек эшләрен Илья Николаевич бик теләп һәм яратып башкара, чөнки ул авыл укытучы-мәгърифәтче И. Я. Яковлевның туган авылы була. Шул ук 1871 елның 11 октябрендә Илья Николаевич әлеге яңа мәктәпне ачарга да үзе килә.

---

[1] Вершок — 4,4 см чамасындагы озынлык үлчәве.

Ике класслы бу мәктәптә шул елны 14 чуваш малае белем ала башлый. Аннары кыз балалар да укырга керешә.

В. И. Ленинның әтисе тырышлыгы белән ачылган бу мәктәп чын мәгънәсендә караңгы патшалыктагы яктылык нуры була. Ачылган көненнән алып бүгенгәчә, ягъни 100 ел буена, әлеге мәктәп туктаусыз эшләп килә. Меңнәрчә кешеләр шушы мәктәптә белем алып, зур тормыш юлына аяк бастылар һәм аларның байтагы соңыннан бөтен Чувашстанга танылган фән, культура эшлеклеләре булып киттеләр. Мәгълүм чуваш язучыларыннан Александр Алга, Александр Калган, Петр Петров, Георгий Ефимов, Чувашстанның халык артисты һәм драматург Йоаким Максимов Кошкинский — барысы да заманында шул мәктәптә белем алганнар.

Бу ел Кошки хезмәт ияләре, Татарстан һәм Чувашстан җәмәгатьчелеге белән берлектә, Илья Николаевич Ульянов инициативасы белән салдырылган әлеге мәктәпнең 100 еллыгын билгеләп үтәчәкләр.

## ӘДӘБИ МУЗЫКАЛЬ КИЧӘ

1970 елның 9 октябрендә Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм Актерлар йорты советы, республикабызның 50 еллыгына багышлап, әдәби-музыкаль кичә үткәрделәр. Актерлар йортында үткәрелгән ул кичәдә язучыларыбыздан Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Хәсән Сарьян, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Зөлфәт Маликов, артистлардан ТАССРның атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов, Назнина Сабитовская һәм Г. Калашникова катнаштылар.

Әдипләрнең һәм артистларның чыгышын тамашачылар зур кызыксыну белән тыңладылар.

* * *

Шагыйрь Рәдиф Гатауллин һәм Татарстанның атказанган артисты Габдулла Рәхимкулов Балык Бистәсе районының Олы Елга, Олы Әнәк, Олы Солтан авылларында булып, әдәби кичәләр үткәреп кайттылар.

## СОНЕТ КИЧӘЛӘРЕ

Казанның Максим Горький исемендәге Үзәк ял паркында шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең сонетлар кичәсе уздырылды. Сонет формасы татар укучыларына аз таныш. Шуңа да карамастан, халык, бигрәк тә студент яшьләр, кичәгә бик күп килгән иде. Шагыйрь тамашачыларны үзенең «Җыр тюльпаным Сергей Есенин», «Алан буйлап ага ак томан», «Кызлар мине туйга дәштеләр», «Яратасыңмы дип сорама», «Син сөеп тә иркәң сөймәсә», «Канга сеңсә әгәр көнчелек», «Алтмыш яшьлек йөрәк кабынса» дигән сонетлары белән таныштырды. Аннары поэзиягә бәйле бик күп сорауларга җаваплар бирде. «Белем» җәмгыяте оештырган бу кичә бик җанлы узды.

Мәхмүт Хөсәеннең сонет кичәләре Биектау районының берничә авылы клубында һәм мәктәпләрендә дә үткәрелде.

## ЯШЬ ПРОЗАИКЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА СЕМИНАРЫ

Үткән елның 15—16 октябрендә Татарстан язучылар союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты инициативасы белән яшь прозаикларның республика семинары уздырылды. Семинарда катнашучылар башта филология фәннәре кандидаты, язучы Мөхәммәт Мәһдиевның яшь язучылар иҗаты турындагы докладын тыңладылар. Аннары яшь язучылардан Адлер Тимергалин, Хәниф Хәйруллин, Мәдинә Маликова, Фәрит Гыйльметдинов, Азат Ганиев, Вахит Монасыйпов, Абдулла Шәрәфетдинов, Кояш Тимбикова, Миргалим Харисов, Диләрә Зөбәерова, Габделхәй Сабитов һәм Рәзил Вәлиевның әсәрләре турында фикер алышу булды. Яшь әдипләрнең иҗатын тикшерүдә Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир, Аяз Гыйләҗев, Сафа Сабиров, Ибраһим Нуруллин, Ләбибә Ихсанова, Нурихан Фәттах, Рафаэль Мостафин, Хәсән Сарьян, Марс Шабаев, Барлас Камалов, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Гариф Гобәй, Шәүкәт Галиев, Гази Кашшаф, Фәрваз Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Яхъя Халитов, Роберт Батуллин, Ренат Харисов һәм Бәян Гыйззәт иптәшләр катнашты.

Башка елдагы семинарлардан аермалы буларак, бу семинарда бары тик китаплары басылып чыккан яшь прозаикларның иҗаты гына тикшерелде һәм аларның барысына да диярлек нигездә уңай бәя бирелде. Әсәрләре семинарда тикшерелгән иптәшләрнең байтагын инде язучылар Союзына член итеп алу турында да уйларга мөмкин, дигән фикер әйтелде.

Семинар барышында яшь язучылар өлкән әдибебез Гомәр Бәшировның үз иҗат тәҗрибәсен уртаклашуга багышланган бик файдалы һәм тирән мәгънәле чыгышын да тыңладылар.

## ӘДИПНЕҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАП

1970 елның 16 октябрендә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының киңәйтелгән гыйльми совет утырышы булды. Татарстан язучылар союзы идарәсе катнашы белән үткәрелгән һәм язучы Заһир Бигиевның тууына 100 ел тулуга багышланган ул утырышта әдипнең тормышы һәм иҗаты турындагы докладны филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин ясады.

* * *

Узган елның октябрендә Түбән Камада «Ленин нурлары» редакциясе һәм ВЛКСМ шәһәр комитеты каршында оештырылган «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең отчет-сайлау җыелышы булып узды. Берләшмәнең бер ел эчендәге эше турында докладны берләшмә председателе М. Зәйнетдинов ясады.

Бу утырыш беренче мәртәбә яшь рус язучылары катнашында уздырылды. Соңыннан «Кама таңнары»ның яңа бюро председателе итеп Р. Хисмәтуллин, секретаре итеп Ф. Абдуллин, ә рус секциясенең секретаре итеп Ю. Киселев сайландылар.

Җыелышта КПСС шәһәр комитеты секретаре Г. Ф. Гыйльметдинов, Татарстан язучылар союзы вәкилләре Г. Зәйнашева, Ю. Белостоцкий, «Ленин нурлары» газетасының редактор урынбасары Н. Кузнецов һәм башка иптәшләр катнаштылар.

*
* *

Икенче көнне Гөлшат Зәйнашева һәм Юрий Белостоцкий «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең членнары белән очраштылар. Алар Фәния Хуҗиәхмәтова, Альбина Мортазина, Фәтхулла Абдуллин, Мизхәт Хәбибуллин, Михаил Федосенко, Анатолий Архипов, Юрий Киселев иптәшләрнең әсәрләре белән танышып, яшьләргә файдалы киңәшләр бирделәр. Өлкә матбугатына тәкъдим итү өчен әсәрләр сайлап алдылар.

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

1970 елның октябрь аенда Архангельскида РСФСР язучылар союзының киңәйтелгән секретариат утырышы үткәрелеп, анда Новгород, Псков, Ленинград, Калининград, Вологда һәм Архангельск өлкәләрендә яшәүче һәм иҗат итүче язучыларның хезмәт темасына язылган әсәрләре тикшерелде. Ул утырышта РСФСР язучылар союзы секретаре, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Ибраһим Гази да катнашты. И. Гази Архангельск драма театры бинасында һәм офицерлар йортында китап сөючеләр белән очрашты һәм аларга татар әдәбияты турында сөйләде, үз әсәрләрен укыды.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Безнең журналга бернинди чикләүсез һәм илебездәге теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин. Аңа язылу шартлары «Союзпечать»ләрдәге газета-журналлар каталогында күрсәтелгән. «Казан утлары» ул каталогка 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210